# КАЗАН УТЛАРЫ

www.kazanutlary.ru

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*


## Бу санда


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Габдулла ТУКАЙ. Ваксынмыйм. *Шигырь*......3
Роза ТУФИТУЛЛОВА. Язмыш җиле. *Роман.* ......4
Луиза ЯНСУАР. Үз җаныңа гына хөкемдар бул... *Шигырьләр.* ......46
Марат ӘМИРХАНОВ. Саҗидә. *Повесть.* ......51
Таһир ШӘМСУАРОВ. Хәтерләрне яңарт тын гына... *Шигырьләр.* ......75
Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Сукыр Гаваз. *Повесть.* ......79
Әлфия СИТДЫЙКОВА. Чор бураны авыл эчендә... *Шигырьләр.* ......101
Альберт ГАДЕЛ. Итекче. *Бәян.* ......105

ЯҢА ИСЕМНӘР

Зөләйха ЗАКИРОВА. Бер-берсеннән матур уйларым бар... *Шигырьләр.* *(Э.Шәрифуллинаның кереш сүзе белән).* ......119
Альбина ГАЙНУЛЛИНА. Дустым, сердәшем... *Хикәя.* ......123

*Җәһәт тәнкыйть:* сәхифәне Дания ЗАҺИДУЛЛИНА алып бара. ......130

*Кардәш халыклар әдәбияты:* Улугбек ХАМДАМ. Гөлҗимеш. *Мини роман.* Күңелем дәрьясы. *Хикәя. (Ф.Сафинның кереш сүзе белән).* ......132

«ШИФАЛЫ КУЛЛАР» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Гөлфия ГАЛИУЛЛИНА. Локман карт хикмәтләре. *Хикәя.* ......148

*Шәхесләребез:* Әзһәр ШАКИРОВ. Артист язмалары. ......151

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ. Өч китапта – өч хикмәт *(Т.Галиуллин иҗатына бер караш).* ......157
Ләйлә МИНҺАҖЕВА. Могҗизалар ачар сүз остасы *(Г.Гыйльманов иҗаты турында).* ......162

*Хәтер:* Бикә РӘХИМОВА. Гамьле фикерләр. ......167

ТУКАЙ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Рауль МИР-ХӘЙДӘРОВ. Шагыйрьнең соңгы мәхәббәте. ......169
Рифә РАХМАН. «Үз иманы белән яши кеше...» ......174
*Гамьле әңгәмә:* «Ак калфакның табылган чагы...» *(«Ак калфак» иҗтимагый оешмасы җитәкчесе К.Идрисова белән А.Имамиева әңгәмәсе).* ......176

*Фән*: Илфан БИКМАЕВ. Галәм серләре. ......179

*Китап күзәтү:* Һүсәен БАРГАН. Шанлы сакчы. ......180

*Музейларыбыз:* Гүзәл ТӨХФӘТОВА. Габдулла Тукай әдәби музее. ......184

*Шаян сәхифә:* Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ алып бара.* ......185
*Ак җилкән:* Айзилә САБИРОВА. Өченче хатың кайда? *Хикәя.* ......187
Зөлфия ГАНИЕВА. Онытылмас батырлык. *Шигырь.* ......189

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ......190

КАЗАН УТЛАРЫ
*(«Огни Казани»)*
*№ 4 (1158) 2019*

*БАШ МӨХӘРРИР –*

**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*

**Ирада Әюпова**
**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Данил Салихов**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Рамил Ханнанов.**

*Җаваплы сәркатип:* **Вакыйф Нуриев.**

*Бүлек мөхәррирләре:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Фәнил Гыйләҗев, Фирүзә Җамалетдинова, Айсылу Имамиева, Камил Кәримов.**

*Мөхәррирләр:* **Лилия Вагыйзова, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева.**

*Сайт мөхәррире:* **Рәзилә Хәйретдинова.**

*Исәп-хисап бүлеге:* **Люция Сөләйманова** (өлкән бухгалтер).

*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1617).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
💻: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

ТМ Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 27.03.2019, график буенча 27.03.2019, басылып чыгу вакыты 12.04.2019.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-819. Тираж 5259.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен), П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), 16262 (Татарстаннан читтәге юридик затлар өчен), П2368 (Татарстандагы юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2019 ел

Габдулла
Тукай

## ВАКСЫНМЫЙМ

Син үзеңчә изге эш эшлим дигәндә халкыңа,
Әллә нинди былчырак баулар салалар гакълыңа:

– Бу заман шундый заман, – дип, –
бу вакыт мондый вакыт,
Син үзеңне дөньяда безнеңчә йөрт, безнеңчә тот.

Мин сыялмыйм андый шартлар,
фани дөнья вакътына,
Башны бөксәм – зур җинаятьтер олуг
җан хакъкына.

Ашкынамын мин әбәд* бетмәс урынга, мәңгегә,
Мәңгелеккә – мәңге рухлы, мәңге нурлы ямьлегә!

Анда мин мәңге көләч һәм мәңге яшь булмак телим;
Бу кояш сүнсен, җиренә мин кояш булмак телим.

Вакътыны йөртер кешеләр ул заман миннән күреп,
Файдалансын шунда миннән сәгатен һәркем борып.

---

*Әбәд – мәңге.



Роза
Туфитуллова

# ЯЗМЫШ ҖИЛЕ

РОМАН

*«Язмыш җиле». Бу әсәр заманының күренекле хатын-кызларыннан берсе, Петербургның атаклы саналган Бестужев югары курсларында белем алучы, 1912 елда Балкан сугышында шәфкать туташы буларак катнашып, зур каһарманлыклар күрсәткән, татар хатын-кызларының данын ераkларга таныткан Чистай кызы Гөлсем Камалованың тормыш юлын сурәтли.*

*Гөлсем ханым – милләтебезнең Г.Тукай, Г.Исхакый, М.Бигиев, Ф.Әмирхан, Ф.Кәрими, Й.Акчура, И.Нуруллин, А.Расих, М.Ногман кебек олуг шәхесләре белән аралашкан кеше. Аның Тукайга булган чиксез шагыйранә мәхәббәте – ул язмыш күгендә, еракта балкыган аҗаган төсле якты һәм серле. Гомумән, Гөлсем Камалова-Акчуринаның гомер юлы гаҗәеп катлаулы, гыйбрәтле һәм тарихи вакыйгаларга бай.*

*Бу әсәрне мин үзем генә яздым, дисәм, бигүк хаклы булмам. Чөнки аңа күпсанлы очрашулар-сөйләшүләр, күп авторларның тарихи мәгълүматлары нигез булды. Аларның һәммәсенә дә олы рәхмәтемне юллыйм.*

**Автордан**

## Кара төннең ак фәрештәсе

*Ауру җанның бишмәте-тәнне дәваның төрлесе*
*Берлә һәр көнне ямыйм, иртән тагын ертык күрәм.*

*Бар иде ялгыз калып, җырлап юанган чакларым,*
*Ярты җырда инде күкрәкне тотам да йөткерәм!*

«Хәстә хәле». Г.Тукай

Петербург бу юлы да мине үзенең кабатланмас матурлыгы – сихри ак төннәре белән каршылады. Табигатьнең әлеге могҗизасы бу калага аерым бер ямь, илаһилык өсти бугай. Шуңадырмы, аның урам-мәйданнарыннан узган чакта аяк очларына гына басып йөрисе, сөйләшкәндә исә пышылдап кына сөйләшәсе килә. Шулай итмәгәндә, бу мәгърур каланың серле аһәңен тоеп булмастыр кебек.

Петербургта җанга якын урыннар аз түгел. Бирегә килгән саен, мин шәһәрнең үзәк урамнарыннан саналган Казанский урамын урап кайтырга

Роза ТУФИТУЛЛОВА (1945) *– язучы-прозаик, публицист; «Олы Мәңгәр – гомер бишеге», «На пути к гражданскому обществу», «Бәйлисе бар йөрәкне» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

яратам. Исеме белән дә, җисеме белән дә игътибарны үзенә тартып торучы әлеге урам ничаклы сер, кадерле хатирәләр саклый. Заманында шушы урамның 39нчы йортында бөек поляк шагыйре Адам Мицкевич яшәп киткән. Аның янына русның бөек шагыйре Александр Пушкин һәм якын дусларыннан берсе – шагыйрь Антон Дельвиг килеп йөргәннәр. Соңрак бу йорт Петербургка сәфәрләрендә Николай Гогольнең сыену урынына әверелгән.

Казанский урамының сул як тыкрыгына урнашкан йортка (37нче йорт) Мәскәүдән – үзенең кардәше Ольга Фрейденбург янына яшь гашыйк шагыйрь Борис Пастернак килгәли торган булган.

Күпмедер вакытлар исә, урамның 3нче йортында русның атаклы шагыйрәсе Анна Ахматова яшәгән. Аның кабатланмас сурәтен таш диварлар әле дә хәтерлидер сыман... Кыскасы, Казанский урамын, һич икеләнмичә, шагыйрьләр урамы дияргә мөмкин.

Архитектура ягыннан әллә ни үзенчәлеге абайланмаса да, бу урамның мин эзләгән 5нче йорты да – күркәм, нурлы бина. «Казанский» мосафирханәсе урнашкан әлеге йортта элек-электән танылган шәхесләр туктала торган булган. Моннан йөз ел элек, төгәлрәк әйткәндә, 1912 елның апрель азагында, шушы йортта татарның мәшһүр яшь шагыйре Габдулла Тукай яшәп киткән.

...Тукай яшәп киткән...

...Петербургның ак төннәренә төренеп, сагышлы-сагынулы хисләремнән эчем-тышым туңган, елаган бер халәттә кунакханә катын сүзсез-өнсез күзәтәм. Бары тынгысыз уйларым гына гасырларның нәни Габдулланы саткан, елаткан, Тукай итеп моңландырган, җырлаткан, «милләтем» дип җан аттырган, ачы язмыш, тәкатьсез авырулар белән тилмерткән тарафка юнәлә... Әнә уйларымның күпмесе күз алдымда чәчелеп «җирдә» ята. Берәмтекләп җыям. Рухына багышлардай, юатырдай, кабатланмас нинди дога-сүзләр табарга?! Бәгырьләрне телгәләп, шагыйрь җаны сыктый:

Үпкәнеңнән бирле, әнкәй, иң ахыргы кәррә син,
Һәр ишектән сөрде угълыңны мәхәббәт сакчысы.

И мәхәббәт сакчысы! Син шулкадәрле таш бәгырьлемени соң?! Син әле дә булса биредә сакта торасың түгелме соң?! Бәлкем, синең өчен «үткән» дигән төшенчә дә юктыр. Димәк, әле син кулына ак ландышлар бәйләме тоткан, ак күңелле, Тукай өчен җан аткан, татарның затлы бер гүзәле Өммегөлсем-Джоконданы да хәтерлисеңдер?! Хәтерлисең, билгеле! Җавап тоту җилләргә йөкләнгән, диярсеңдер. Искәртмәстән, уйларымны кысрыкларга теләгәндәй, әнә шул җил, язмыш җиле искиткеч бер тизлек, куәт белән каракучкыл болытларны бирегә сөрә. Күз ачып йомганчы, салкын, күшектергеч яңгыр коеп үтә. Ахрысы, моннан бер гасыр элек булган вакыйгаларны искә төшерер өчендер...

...Ни кызганыч, Рәсәй башкаласын иңләп-буйлап йөрү, зиннәтле сарайларын, музей-театрларын күрү насыйп булмый шагыйребезгә. Петербургка килгәч, аның үзәк-бәгыренә төшкән үпкә чире тагын да көчәя төшә. Шәһәрнең җелекләргә үтә торган дымлы, салкын һавасы шагыйрьне көннәр буе мосафирханәдә утырырга мәҗбүр итә. Дөрес, биредә яшәүче дуслары аны ялгызын калдырмаска тырышалар. Шагыйрьне күреп, танышып калырга теләүчеләрнең дә саны көннән-көн арта бара.

Тик әлегә шагыйрь берәүнең дә ишек шакуын теләми. Аның, гадәтенчә,

кулларын баш астына куеп, күзләрен йомып, Муса Бигиевларда[1] үткәргән кара төннең ак фәрештәсен генә күңеленнән кичереп, янә бер юанасы килә. Ни хикмәт, шушы яшерен-тансык хыялый бер мизгел аның каһәрле ютәлен, авыруын, туңуларын оныттырып торадыр кебек.

...«Дөнья читлегеннән» очып чыгарга җыенган чарасыз шагыйрь йөрәгенә кинәт – сак кына, ак фәрештә килеп «орынасы» итте. Фәрештә күзгә күренеп йөри башласа, билгеле инде... Төн фәрештәсе «ак томан» эченнән «йөзеп чыгып», телгә килде. Нинди йомшак, моңлы иркә тавыш:

– Тукай әфәнде, зинһар, кичерә күрегез. Башкача түзеп торырлыгым калмады. Ютәлегез бигрәк көчле. Сезнең өчен җаным пәрә-пәрә килә... Шушы мәтрүшкәле кайнар сөтне эчеп карагыз әле. Шифасы тимичә калмас. Савыга күрегез! – диде дә элгәре ничек гаип булса, шулай ук «эреп» юкка да чыкты.

Дивар аша гына шагыйрьнең шул дәрәҗә газаплануын ничек тыныч күңел белән тыңлап ятсын Өммегөлсем. Аның тыю-чикләүләргә буйсынмаган, ни гомер сөю утында дөрләгән кайнар йөрәге бар бит әле. Яраткан Тукаен савыктырыр өчен аның бер уе, бер сүзе, бер сулышы җитәр төсле иде. Аһ, хыял белән чынбарлык арасы нинди тирән упкын икән.

Өммегөлсемнең кодачасы, дус кызы Мәрьямнең дә җаны үкси, тәне дерелди, ул шылт иткән тавыштан да сискәнеп, ишек катында кизү тора. Өммегөлсем өйдәгеләр күзенә чалынмасын да, Муса әфәнде генә уяна күрмәсен. Ходайның рәхмәте, ул бүген балалар янында йоклый. «Оят, гарьлек, син ничек җөрьәт иттең?» – дип, күзен дә ачырмаслар. Тукайны да кыен хәлгә куярлар. Аңлатып та, акланып та өлгерә алмассың...

– Ихлас, фәрештәдер! – дип уйлады Тукай, үзен яшәү белән үлем арасында тоткан бума ютәле басыла төшкәч. Ләкин шунда ук бу «кирәксез» тойгыга бар күзәнәкләре, вөҗүде белән карышты.

– Күр, бу курсистканың кыюлыгын, тәвәккәллеген! Җәлләгән... Сез түгел, туташ, мине язмыш үзе дә җәлләмәгән. Кирәкми дә. Минем максатым, юлым башка. Мине кызганганнарны сөймим мин, туташ. Сез нык ялгыштыгыз...

Монысы ниткән өн тагын, язгы чирәм төсле кантарлы юл читендә баш калкыта?

– Шагыйрем, син үзең бу минутларда яныңда яраткан бер җан иясенең булуын теләгән идең түгелме соң?! Менә «мәхәббәт сакчысы» аны синең хозурыңнан тыймады.

Бәхеткә, «хикмәтле төн» тагын кабатланасы итте. «Соңгы сулыш» алганда, тагын теге «ак фәрештә» иңде. Ниндидер тылсым өрде, иркә пышылдады. Һәм тагын шулай нур эчендә тиз генә эреп юкка чыкты. Янә каршылыклы уйлар бил алышты. «Хөкемдар мәхәббәт сакчысы» пәйда булды. Һәм әлеге шигырь битен «ачып куйды»:

Дәртемә минем дару бар: йә үлем, йә кавышу;
Боларның һәрберсе бу сораучыны шатландырыр.

Аңладыңмы, и гүзәл! Йә җаным бул, йә җанымны ал;
Мине яныңда үлү белән бәхеткә ирештер.

– Үлем фәрештәсе шулай ук якынмыни?

– Юк...

– Ә син ялгышасың, минем «җан фәрештәм» ул түгел ич.

[1] М.Бигиев – күренекле дин галиме, язучы, фәлсәфәче.

– Беләм.

– Минем соңгы шигырем дә Күкләр аһәңе белән башкача яңгыраячак.

– Хәбәрдар. «Васыятең» дә үзең кебек изге һәм бөек шәкелдә. Син дөньяга елап килсәң дә, киткәндә җырлап китәргә җыенасың. Дөрес әйтәмме?

– Ихтимал. Мәхәббәт фәрештәсе, син соңгы көннәрдә бик үзгәрдең әле. Әмма мин тизрәк бу йорттан качу, синең тарафтан сөрелү телим. Син үз асылыңа хыянәт итмәссең бит инде?!

...Менә, ниһаять, Тукай, үзе теләгәнчә, «иректә». Дуслары аны Бигиевлардан алып мосафирханәгә күчерде. Әмма ул биредә дә салкыннан, ютәлдән һәм фәрештәләрдән кача алмас, күрәсең.

– Шулай да, рәхмәт сиңа, кара төннең ак фәрештәсе...

Шагыйрь кинәт сискәнеп китте, менә тагын кемдер бүлмә ишеген шакыды.

– Ишек ачык. Керегез! – диде Тукай, ниндидер эчке бер моңсулык белән.

Ишектән елмаеп кереп килүче, европача киенгән озын зифа буйлы кызны күрүгә, шагыйрь бер мәлгә телсез калды. Ә кыз исә ул арада, шагыйрьне сәламләп, түргә узды. Кулындагы яңа ачылып кына килүче ландышлар бәйләмен өстәлгә куйды да, Тукайның чәчәкләргә гаҗәпсенеп карап торуын күргәч:

– Чәчәкләр каян, дисезме? Урам чатында финнар сатып тора иде. Бу чәчәкләр Сезгә дә ошый, дип беләм. Баксаң, Петербургка да яз килеп җитә икән, – дип елмайды.

Үзе белән бүлмәгә яз исен, чәчәкләр исен, ургып торган яшьлек дәртен алып кергән бу кыз, төнге «ак фәрештә» шагыйрьгә яхшы таныш. Ул дусты Фатих Әмирханның[2] сөйгән кызы Шәмсенисаның бертуган сеңлесе, Чистай кызы Өммегөлсем Камалова иде. Апалы-сеңелле бу кызлар еш кына «Әлислах» газетасы редакциясенә Фатих янына кереп йөриләр[3].

Кайчакларда аларга Шәмсенисаның уртанчы сеңлесе Хәтимә дә ияртә. Берсеннән-берсе чибәр, укымышлы бу кызлар редакциягә килеп керсә, Фатих үзен күкнең җиденче катындагыдай хис итә башлый. Бигрәк тә сөеклесе, асыл зат Шәмсенисаның иҗатка тартылуын, рус, француз телләреннән хикәяләр тәрҗемә итәргә алынуын бөтен йөрәге белән хуплый иде.

Кызлар арасында чаялыгы белән аерылып торган Өммегөлсемнең үзенә җан атып йөрүен белә иде Тукай. (Казанның укымышлы кызлары арасында азмыни аңа җан атучылар?) Әмма кызны күрмәмешкә салышып, һәрчак бүлмәдән тизрәк чыгып китү ягын карый торган иде. Тик менә бүген, мосафирханәдә аның белән икәүдән-икәү, күзгә-күз калгач, күрмәмешкә салышу мөмкин түгел. Ишетүенчә, Өммегөлсем Петербургның данлыклы Бестужев курсларында белем ала. Күр, әнә ничек үзгәргән!.. Русның аксөяк кызларына биргесез... Юк, юк, аңа иң килешкәне – ак фәрештә сурәтендә йөрү.

Өммегөлсем дә Тукайны күзәтә. Шагыйрь бераз хәл алганга охшый. Ютәле дә элеккегечә куркыныч түгел. Юкса теге төннәрдә Тукайны җәлләп күпме зар елады Гөлсем.

Бүлмәдә урнашкан уңайсыз тынлыкны Тукай боза:

– Сезне бирегә Муса әфәнде җибәрдеме? – диде шагыйрь аңа шактый кырыс кына.

– Юк, юк. Муса әфәнде минем сезнең янга килүемнән хәбәрдар түгел. Мин алар фатирында онытып калдырган әйберләрегезне китердем, – дип, кыз кечкенә ридикюленнән өстәлгә портсигар белән чәч тарагы чыгарып куйды.

[2] Ф.Әмирхан – язучы, публицист.
[3] Әмирхан Р. Әмирханнар. – Казан: «Мәгариф» нәшр., 2005.

– Юкка мәшәкатьләнгәнсез, берәр студент кереп алган булыр иде әле.

– Һичбер мәшәкать түгел, Тукай әфәнде, – диде кыз, үзгә бер итагатьлелек белән.

Тик әллә каян сизелеп тора: кызның шагыйрьгә тагы нидер әйтәсе бар. Ниһаять, ул бөтен ихтыяр көчен туплап, сүз башлый:

– Әгәр дә сөекле шагыйребезнең өч төн буе Муса әфәнделәрдә газаплануларын күреп калмасам, бирегә килеп, сезне борчып йөрмәгән дә булыр идем. Сезгә кичекмәстән Кырымга китәргә кирәк, Тукай әфәнде. Кырым һавасы белән диңгез суы сезне бик тиз аякка бастырачак. Кырымда минем белән бер курста укучы Мәймүнә атлы кызның әти-әнисе яши. Алар – гаҗәеп кешеләр, сезне бу көннәрдә үк кабул итәргә әзер, – дип, кыз шагыйрьгә телеграф кәгазен суза. – Әгәр риза булсагыз, без Мәймүнә белән сезне Кырымга чаклы озата да барыр идек...

Тукайның кинәт йөзе үзгәрүен күреп, кыз сүзеннән туктап кала.

– Нинди гадәт соң бу укымышлы бай кызларында! «Әфәндем» дия-дия эч пошырулары җитмәгән, бер-берсен уздыра-уздыра мине дәваламакчылар, – дип, шагыйрь ихтыярыз йодрыгын кысып куйды. Аннан тагын, кырысрак күренергә тырышып, сүзен дәвам итте:

– Юкка хафаланасыз, туташ. Миңа Кырым да, Швейцария белән Финляндиягез дә кирәк түгел. Кичә мине Петербургның иң абруйлы докторына күрсәттеләр. Ул авыруымның узгынчы булуын әйтте.

– Бу хәбәргә мин чиксез шат, тик менә минем бирегә килүем генә сезгә куаныч өстәмәде, – дип, Өммегөлсем урыныннан кузгалды.

Тукайның: «Кара төннең ак фәрештәсе, рәхмәт сиңа, артыгын сөйләмә, кирәкми, хуш!» – диясе килде. Кая инде ул аларны әйтү. Ул сүзләр тел очында калды.

Өммегөлсем янә ихлас дәлилләвен дәвам итәргә уйлады:

– Тукай әфәнде, сүз сезне җаныннан артык яраткан, шигырьләрегезне догага тиң күргән саф күңелле туташлар турында бара. Сез алардан йөз чөерәсез. Диңгездән баш тартуыгыз да гаҗәпләндерә. Ә бит диңгез үзе сезгә күпме шигъри илһам өстәр иде.

Тукайның күзендә зәһәр очкыннар күреп, Гөлсем тагын туктарга мәҗбүр булды.

– Туташ, Ходай сезгә Рәсәй башкаласында белем алу мөмкинлеген авыру шагыйрь янында утырыр өчен бирмәгәндер, дип уйлыйм. Сезнең кебек белем үрләрен яулаучы кызларыбызны мин башка уй-хисләр белән яналар дип уйласам, сезне күбрәк вак-төяк мәсьәләләр биләп алган булып чыкты. Милләтебезнең зур үзгәрешләр алдында торуын азмы-күпме чамалыйсыздыр, шәт? Халкыбызга хезмәткә күпме фидакарь мөгаллим-мөгаллимәләр кирәк хәзер.

– Кичерегез, – диде кыз, ишетелер-ишетелмәс. – Ни генә дисәгез дә, Сезгә ярдәм итәргә йөрүемне мин вак-төяк эш, дип саный алмыйм. Серноводскидан Сезгә дустыгыз Фатих әфәнде Әмирхан аркылы җибәргән мәктүбемдә мин үземнең мөгаллимә һәм нинди мөгаллимә булырга җыенуымны ачык итеп язган идем шикелле. Мөгаллимә булу – минем дә изге хыялым.

Кызның бу сүзләреннән соң үзен чамасыз бер киеренкелектә сизгән Тукай аңа текәлеп карамый булдыра алмады. Өммегөлсемнең бит урталарыннан тыелгысыз агучы күз яшьләре аны тирән гаҗизлеккә салды. Ул эчтән үзен әрләргә дә, акларга да өлгермәде, ишек шакыдылар.

– Керегез, – диде шагыйрь, үз тавышын үзе танымыйча аптырап. Һәм бүлмәгә шаулап-гөрләп, Петербургта укучы бер төркем татар студентлары кереп тулды.

– Мөмкиндер бит, Тукай әфәнде?
– Әссәламегаләйкем, сөекле шагыйребез!
– Хуш килдегез, Тукай әфәнде!
– Саумысыз? Күрми калабыз, дип, шундый борчылган идек...
– Без мәшһүр Тукаебыз янында, нинди бәхет!
– Менә бит, насыйп булгач...

Һәрберсе шулай үзенчә сөенеп, Тукайны олылап, кул биреп күреште, шигырь белән сәламләде:

Бер мөкаддәс хис белән һәрбер кеше хәйран бүген;
Уйный сазым да минем бәйрәм көен, бәйрәм бүген!
Тыңладым әкрен генә искәндә бәйрәм көн җилен;
Ансы да сөйли тагын: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

– Джоконда, син дә биредә?! Син һәрвакыттагыча өлгер инде... һәм чибәр, – диде егетләрнең чаярагы, игътибар үзәген бер мизгелгә Өммегөлсемгә күчереп. Тукай чак кына җиңел сулап куйды.

– Ә без сине шәһәр бетереп эзләп йөрибез. Муса әфәнделәргә дә кереп чыктык. Сенат мәйданында узачак «Ак чәчкә» акциясе иртәгегә күчерелде. Мәрьям туташ белән икегезгә җаваплы эш тапшырыла. Беләсеңдер, шәт, – диде җитди кыяфәтле, өлкәнрәк күренгән егетләрнең берсе.

Өммегөлсем, «беләм» дигәндәй, баш кагып куйды да ашыгып ишеккә юнәлде. Әллә инде хушлашмады да...

– Ә нигә сез аңа «Джоконда» дип эндәшәсез? – дип сорады Тукай, кыз чыгып киткәч.

«Өммегөлсем», дип, эчтән генә өзелгән, үзе дә хыялый елмайган егетләрнең берсе җавапны озакка сузмады.

– Нигә дип... Серле елмаюы өчендер. Гаяз ага Исхакый[4] Петербургта чагында аңа һәрчак «Джоконда», дип эндәшә иде. Ул: «Мәшһүр итальян рәссамының атаклы портретын хәтерләтә», – дигән иде.

– Әйе шул, Өммегөлсемне Леонардо да Винчи портретыннан төшкән серле сурәт диярсең, – диде күзлек аша зәңгәр күзләре көлеп торганы.

– Аның үз исеме тагын да килешлерәк, минемчә, – диде Тукай, егетләргә карамаска тырышып.

– Әйе шул, ант шулай!
– Чын татарча!
– Бигрәк ямьле исем! – дип, калганнары, гөр килеп, шагыйрьне куәтләде.

Тукайның да йөзе җанланып, алсуланып китте. Яшьләрнең телгә осталары шагыйрьнең кәефен күтәрмәк булып күбрәк сөйләде. Тыйнак-сабырлары бу саваплы очрашуга эчтән генә сөенде. Күңеле нечкәләренең йөрәгеннән кан саркыды. Тукай белән, шигырь белән төшләнгәннәре шигырь укыды:

– Айрылып китсәм дә синнән гомремнең таңында мин,
И Казан арты! Сиңа кайттым сөеп тагын да мин.

Ул таныш кырлар, болыннар тартты әүвәл хиссеми;
Тарта торгач куймады, кайтарды ахыр җисмеми.
.............................................................................
Зур бу урман: читләре күренмидер, диңгез кеби;
Биниһая, бихисаптыр, гаскәри Чыңгыз кеби.

[4] Г.Исхакый – күренекле сәясәтче, язучы, драматург, нәшир.

Кылт итеп искә төшәдер намнары, дәүләтләре
Карт бабайларның, моны күрсәң, бөтен сауләтләре.

Ачыла алдыңда тарихтан театр пәрдәсе:
Аһ! дисең, без ник болай соң? Без дә Хакның бәндәсе.

Тукай аңлады: болар чын татар балалары, чөнки татар җаны беркайчан да моңсыз, сагынуларсыз була алмый. Алар әнә Тукайның үзен дә җылы, сагынулы-яратулы хисләргә төреп куйдылар. Шагыйрь бу яшьләргә рәхмәтле иде. Очрашуга йомгак ясап, аларга бүләк – бер шигъри рух өстәргә теләве дә шуның өчен иде.

Сөям мин сезне, сез – чын яшь егетләр;
Өмет бар сездә, сез – интеллигентлар.

***

Бар уем кичен – көндезен сезнең хакта, милләтем:
Саулыгың – минем саулык, авыруың – минем авыруым.

Син каршымда бар нәрсәдән дә изге һәм хөрмәтле:
Дөнья бирсәләр дә сатмам милләт, миллиятемне.

Тукай беравык алкышларга һәм сокланулы авазларга күмелеп торды...
– Тукай әфәнде, иртәгә сезне «Ак чәчкә» бәйрәменә чакырабыз.
– Без сезне иртән үк кереп алырбыз.
– Туберкулёз белән авыручыларга ярдәм йөзеннән оештырыла ул.
– Петербургның бөтен татар яшьләре җыелачак анда.
Студентлар, Тукай белән очрашудан биһуш булып, иртәгәгә чаклы саубуллашып чыгып киттеләр. Шагыйрь бәйрәмгә барырга ризалык бирде.
Бүлмә тынып калды. Тик нигәдер һаман «Сагыныр вакытлар» тынгылык бирмәде:

Йоклыйсың рәхәт кенә; төнлә уянсаң берзаман,
Як-ягың тып-тын – әле юк яктылык, таң атмаган.

Шулвакыт яшьләр күзеңдә: җан ачып, җан сызланып
Егълыйсың, Җан-Зөһрә берлән, Җан-Таһирны кызганып.

...Шагыйрь елый иде.
Оят, валлаһи! Петербургтагы журналист дуслары Кәрим Сәгыйд белән Кәбир Бәкергә шушы «фәрештәдән» зарланды түгелме соң инде ул? Имеш, Муса Бигиевларның болай да кысынкы фатирларын курсисткалар чорнап алган. Дөреслектә исә, шагыйрьнең эчке һәм тышкы халәте аларның артык илтифатын, артык олылавын кабул итәр дәрәҗәдә түгел иде шул.
Менә тагын аның каршылыклы җаны, холкы, авыруы, ачы язмышы, санаулы көннәре, мәхәббәт, бәхет хакындагы уйлары, сүз берләшкәндәй, күкрәгенә килеп ябышты... Тукайның җанында аяусыз тугыз баллы дулкын күтәрелде. Ярсыган ак күбекле дулкын-хисләр чайкалды, чайпалды, чәрдәкләнде.
– Кырым, дисең син, «табигать иркәсе». Ә син бит яхшы беләсең: ул – суның кояшлы, сай җирендә йөзүчеләр өчен генә җылы икәнен. Минем кебек хакыйкать диңгезендә йөзгәннәр өчен ул башкача. Тирәнрәк төшкән саен,

аның суы салкынрак һәм басымы көчлерәк. Шагыйрь күңелендә купкан хисси давылларның куәтен дә, күпме уй-хыялларымны тормыш атлы иң кырыс диңгез йотканын да син әле соңрак аңларсың...

Бу мизгелдә күз яшьләренә күмелеп, баскычтан төшеп килүче Өммегөлсем-Джоконда бер генә нәрсә турында уйлый иде: тизрәк биредән китәргә! Тизрәк! Аяклары аны үзеннән-үзе Нева ярына тартты. Яз язлыгын итә. Невада боз кузгалган чак. Көзгедәй су өстендә берсеннән-берсе зиннәтлерәк сарайлар, йортлар чайкала. Бозлар эреп ята. Тик менә шагыйрь йөрәгендәге боз катламын гына кузгатырлык түгел икән.

Тәкъдирнең мәңгелек туңын-бозын эретергә Өммегөлсемнең кайнар хисләре генә җитмәс, күрәсең. Тукай зур бер айсберг төсле. Аңа синең ак җилкәнле корабыңа сугылып китү берни тормый кебек. Шулай түгелмени?!

– Юк, юк, һич алай түгел, – дип, кайнарланып, күз яшьләре белән үз-үзенә исбатларга тотынды Өммегөлсем. Чөнки ул әле моңа чаклы Казанда Дворяннар клубында узган әдәби-музыкаль кичәнең татлы «төше» белән яши иде[5]. «Почта уены» ничек якынайткан иде аларны ул кичне. Гашыйк «почтальон Өммегөлсем», форсаттан файдаланып, Тукайга бер-бер артлы хатлар яза да, серле елмаеп, шагыйрьнең учына илтеп сала. Ник башка бер генә кызның хатын тапшырсын! Тукай да моңарчы күрелмәгән бер җылылык белән: «Мине «сәлам хатлары» белән сөендерүче гүзәл туташ шулай берәү генә булдымыни? – дип шаярта. – Сезгә почтальон булу бик килешә. Ә хатларыгызны уку – бәйрәм», – дип пышылдый һәм Өммегөлсемнең кулын йомшак кына тоткан килеш беравык җибәрмичә тора. Кызның бит урталары алланып яна, карашы өтә, елмаюы иркәли. Ул горур кыяфәт, нәфис буй-сын, нәни энҗе калфак, ак энҗе тешләр, чиядәй ымсындырган иреннәр...

Шагыйрь йөрәген ниндидер бер билгесез рәхәтлек хисе биләп ала.

– Тукай әфәнде, ә сез хатларны кычкырып укыгыз, – дип, яшьләрнең шаугөр килүләре генә аны җиргә төшерә.

– Рөхсәт итсәгез, мин хат иясенә бер шигыремне генә укырмын.

Яшьләр, Тукай авызыннан әйтеләчәк могҗизаи сүзләрне көтеп, тын калды.

Җанын фида иткән фәкыйрьмен, гыйшкың күбәләгемен;
Кил, гүзәл, күрсәт матурлыгың: янаем, кил, янаем.

И Хода, бир акыл, тоткыннар йортына эләкмим;
Бу кызга гыйшкым сәбәпле диванамын, диванамын.

...Ә менә ул хәзер «шагыйрьне дәвалыйм», дип бәрелеп-сугылып йөрүе белән көлке бер хәлдә. «Кырымга барырга акча туплыйм», дип, үзенең бөтен бизәнү әйберләрен, затлы энҗеле калфакларын сатып җибәрде. Аннан күреп, тагын берничә кыз үзләренең яраткан алка, беләзекләреннән ваз кичтеләр. Шагыйрь бу хәлләрне белә калса, аны бүлмәсеннән куып ук чыгарган булыр иде. Өммегөлсемдә нинди гашыйк җан яшәвен күрергә теләми шул шагыйрь. Ә бер атна элек кенә аннан да бәхетлерәк кеше юк иде ләса. Көтмәгәндә-уйламаганда,

[5] Казанда беренче тапкыр үткәрелгән әдәби-музыкаль кичәдә Гөлсем Тукай белән очраша. Тукайның замандашы, язучы, дин белгече, публицист Галиәсгар Гафуров-Чыгътай үзенең көндәлегендә бу вакыйганы төгәл вакыты белән язып куя. 1908 елның 8 март киче була ул. Ул кичне Чыгътай шагыйрьнең Чистай ишаны кызлары тирәсендәрәк чуалуын яза. Икенче көнне иртән Тукай тарафыннан язылган «Кулың» шигыренең шул кызларның берсенә аталуын да искәртә (Гафуров-Чыгътай Г. Сайланма әсәрләр. Казан: «Ихлас» нәшр., 2013. – 331-333, 342-345 бб.). Г.Тукай белән Зәйтүнәнең беренче очрашуларына килсәк, ул 1908 елның май башына туры килә (Алиева Ә., Ибраһимова Ф. Габдулла Тукай: тормыш һәм иҗат елъязмасы. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2003).

Тукайның Петербургка килүен үз күзләре белән күргәч, ул сөенеченнән нишләргә дә белмәгән иде. Кемнәрдә тукталасы иткән диген әле? Өммегөлсемнең җизнәсе, Петербург мулласы, танылган дин галиме Муса Бигиевларда!

Тукайны Петербургка чакырып язучы Муса әфәнде булганга, шагыйрь вокзалдан туры аларга килә. 1912 елның башында Петербургның бер төркем зыялылары Петербургта «Сүз» йә «Хәбәр» исемле газета чыгарырга җыеналар. Яңа газетага мөхәррир итеп Тукайны чакырып хат язалар. Әмма газета оешып китә алмый. Тукай яз башында Петербургка килеп төшкәндә, бу мәсьәлә инде көн тәртибеннән алынган була. Тик менә алдан хәбәр итмәгәнгә, бераз уңайсызрак килеп чыга. Табигый ки, өйдә ыгы-зыгы куба. Кунакка Муса әфәнденең эш кабинетын бушаталар. Күн диванда урын җәелә. Юлда авырып киткәнме, аңа чаклы ук булгандырмы, Тукай туктаусыз ютәлли. Тамагына берни капмый. Өммегөлсем шагыйрьне иртәнге якта юыну бүлмәсенә кергәндә күреп хәйран кала. Кызның күзләрен ирексездән яшь пәрдәсе томалый. Гадәттән тыш ябык, яшүсмер кыяфәтле шагыйрь бу минутларда аңа чиктән тыш якын һәм кызганыч булып тоела. Сөйләшәсе, юатасы иде үзен, әмма Әсма апасы аны да, Өммегөлсемгә кодача тиешле Мәрьямне дә, Тукай янына якын да җибәрми. Әсма ханымның әмере катгый: «Әдәпсезләнмәгез, шагыйрьгә комачаулап йөрисе түгел!» Апасының тыюлары гына туктата алса икән Өммегөлсемне? Ул инде шагыйрьнең игътибарын җәлеп итәрлек планнар кора, аны дәвалау юлларын эзләргә керешә. Әйтик, шагыйрь хәлләнү белән, ул аңа хәзрәти Пушкин йөргән урыннарны күрсәтәчәк. Тиздән мәшһүр җырчы Шаляпинның концерты көтелә. Ул да таң белән билетка чиратка басар... Дәресләрдән соң шундый матур хыялларга чумып, Бигиевларга барып керсә, ачык ишектән буш диванны күреп Өммегөлсем өнсез кала.

– Кая ул?

– Кая? Баязитов[6] кешеләре килеп алып китте аны, – ди Әсма апасы. – Җизнәң кайтканны да көтәргә теләмәделәр. Күренеп тора: апасының кәефе нык кырылган. – Юкка гына борынгылар: «Ит яхшылык, көт яманлык», – димәгәннәрдер шул...

– Апа, ни сөйлисең? Нинди яманлык тагы? Тукай нык сырхау. Алар аны, мөгаен, докторга алып киткәннәрдер?

– Ә җизнәң ни белән шөгыльләнә? Өченче көн инде ниндидер яһүд профессоры артыннан йөгереп йөри. Менә ул хәзер профессор белән кайтып керсә, ни эшләрбез? Кунагыбыздан җилләр искән.

Җайсызрак килеп чыга икән шул. Җизнәсенең олуг кунагын аякка бастырыр өчен җанын бирердәй булып йөрүен Өммегөлсем күрмимени? Петербург татарлары арасында Муса әфәнде кебек укымышлы, итагатьле кешене табуы кыендыр. Шәһәрдәге татар студентлары өчен ул алыштыргысыз киңәшче, остаз. Аның мәхәлләсенә галимнең вәгазьләрен тыңлар өчен шәһәрнең иң ерак почмакларыннан җыелалар. Тукай, бәлки, аның ни дәрәҗәдәге гыйлем иясе булуын төшенеп җитмәгәндер? Юкса Муса әфәнде белән киңәшмичә бу эшне эшләмәс иде. Их, Гаяз абзыйның Петербургта чагы булса! Өч бөек затның очрашуы бөтенләй үзгә төрле булыр иде бит. Әле берничә ай элек кенә Исхакый барында Петербург кайнап-гөрләп торды. Шәһәр чын татар тормышы белән яшәп алды. Язучының яңа язылган әсәрләрен бергәләшеп уку дисеңме, музыкаль кичәләр оештырумы... Төрмәдән качып, Петербургта яшеренеп йөрүче Гаяз Исхакыйны күптән түгел янә кулга алдылар. Төрмәдән

[6] С.Баязитов – Петербург ахуны, «Нур» газетасының нәшире.

ул Өммегөлсемгә хатлар язгалый. Петербург хәбәрләрен сораша. Ай, бу татар язмышлары! Ай, бу ачы язмыш җилләре!..

Өммегөлсем, буш диванга утырып, үксеп-үксеп еларга тотынды. Нигә, нигә аның изге уй-ниятләре җимерелә дә тора? Нигә болай бу? Ул бит авыру шагыйрь өчен җанын фида кылырга да әзер. Аңа хәзер бер генә чара кала: «Нур» газетасы идарәсенә барып, Тукайның кайда тукталуын белешү. Аның ашыгып чыгып китәргә җыенуын күргәч, ахирәте Мәрьям аңа шагыйрь онытып калдырган портсигар белән чәч тарагын суза. Сизгер җан бу Мәрьям. Тукай янына бару өчен болар менә дигән сылтау ич.

Сылтау... Менә ул Тукай белән күрешеп, гарьлегеннән үләргә җитешеп, янә Бигиевларга кайтып бара. Мәрьям белән Әсма апасына ни әйтер икән инде ул хәзер? Тукай мине ишетергә теләмәде, диярме? Ярый әле өйдәгеләр, аның халәтен күреп, кирәкмәс сораулар белән аптыратмадылар.

– Тынычлан, иркә таем. Тәкъдиреңә язылмаган булса, әллә ни эшләсәң дә юк инде. Чистайда Тукай турында: «Безнең Хәйдәр абзый кызы Зәйтүнәне сөя икән», – дигән сүзләр йөрде. Бер дә колагыңа чалынмадымыни?

– Зәйтүнә? Зәйтүнә, дисеңме, апа? Кайчан, кай арада өлгергән соң әле ул кызый Тукайның күңелен яуларга?

– Бик чая кыз, синең кебек укырга да омтылышы зур, дип сөйлиләр. Әле Әгерҗе якларына Бубыйлар мәктәбенә белем алырга киткән, ди.

Өммегөлсем өчен тагы да үтергечрәк хәбәр иде бу. Туганнан туган сеңлесе Зәйтүнәне ул яшүсмер кызга гына санап йөри иде. Ә ул, әнә, үсеп тә җиткән, Тукай тиклем шагыйрьне үзенә гашыйк та иткән. Сөйкемле җан шул Хәйдәр абзыйның төпчек кызы. Аның укырга һәвәслеген күреп, Өммегөлсем аңа әледән-әле китап-журналлар биргәли. Чамадан тыш ярлы яшәүләрен белгәнгә, кием-салымнан да өлеш чыгаргалый иде. Соңгы кайтуында алар туйганчы Чулманда су коендылар. Күр әле, Тукайны ник бер тапкыр телгә алсын! Нәрсә-нәрсә, тик мондый борылышны көтмәгән иде Өммегөлсем.

Икенче көнне ул Сенат мәйданына барыргамы-бармаскамы дип, озак икеләнде. Мондый халәттә берәүгә дә күренәсе килми иде аның. Тик үзе башлаган эшне азагына җиткерергә өйрәнгән кыз ничек бармыйча калсын?

Туберкулёз белән интегүчеләргә ярдәм итәргә теләүчеләр күп була ул көнне. Тукайны да алып киләләр. Европача киенеп куйган шагыйрьне бүген танырлык та түгел. Үзен сырып алган студентларны ул тыныч кына тыңлый. Ара-тирә ютәлләп ала. Өммегөлсем ягына ялгыш кына да күз салмый. Аннан аны тагы каядыр алып китәләр. Тукай белән соңгы күрешү кыз өчен әнә шулай гадәттән тыш моңсу тәмамлана.

Берничә көннән Өммегөлсем Муса әфәнде Бигиевтан Тукайның Петербургтан китәргә җыенуы турында ишетә. Муса әфәнде Тукай янына барып, күрешеп йөри икән. Шагыйрьне озату мәҗлесендә дә катнаша. Әмма, ни сәбәпледер, аны озатырга вокзалга төшми кала. Дус кызлары ничаклы гына өндәп карасалар да, Өммегөлсем дә вокзалга бармаска була. Соңрак Невский урамында очратып, Тукайны Петербургтан Мәскәүгә чаклы озатып куйган журналист Кәбир Бәкер аңа:

– Тукай, үзен озатучылар арасында сине күрмәгәч, нәүмизләнеп калды. «Бик горур кыз булып чыкты сезнең «Джокондагыз», – ди.

– Башка берни дә әйтмәдеме?

– Аның көннәре санаулы. Догада тор... Моны доктор да раслады.

– Ничек? Догада?.. Әйт, зинһар? Ходай хакы өчен, әйт. Аны ничек табарга була?

– Син соңладың, Джоконда. Без барыбыз да соңладык...

Шушы сүзләре белән Кәбир Бәкер кызны урам уртасында, йөзләгән кеше арасында япа-ялгызын калдырып китеп тә бара. Мондый хәбәрдән соң ничек итеп институтка барып утырмак кирәк? Янәшәдә генә почта бинасын күреп, Өммегөлсем шунда керергә була. Тиз генә хәлне аңлатып, Фатих Әмирханга хат язып салыргадыр. Ул ни дә булса уйлап тапмый калмас. Тукта, нигә Фатих Әмирханга? Дөньяда саф чык тамчысыдай Зәйтүнә бар бит әле. Урасын үзенең кайнар мәхәббәте белән шагыйрь йөрәген. Бөтен барлыгын биләсен. Шагыйрь җанындагы барлык үпкә-рәнҗүләрне юып алсын! Тик Тукай гына исән була күрсен! Ак кәгазь битенә «Зәйтүнә, иркә таем» дигән сүзләрне язуга, Өммегөлсем күз яшьләрен тыя алмады. Юк, яза алмый икән ул бу хатны. Хатны ул иң якын сердәше – апасы Шәмсенисага юллый. Аңардан тиз арада Зәйтүнәне әзерләп, юлына һәм яшәренә акча биреп, Тукай янына Троицкига озатып җибәрүен үтенә. Шәмсенисаның җавабы озак көттерми. Ул Өммегөлсемгә Зәйтүнәне Чистайдан да, Казаннан да таба алмауларын хәбәр итә. Язмышның мәкерле уйнавымы соң бу? Сенат мәйданында Тукайны соңгы тапкыр күрүе идемени соң Өммегөлсемнең? Юк, юк, алай була алмый...

Гүя гыйшкың – бер чиркәү, ә мин – аның чаңымын;
Аһ-ваһ итеп, мин ул тавышны көчәйтергә тырышамын.

Безнең арабыз аерылышу пәрдәсе белән капланган;
И Аллаһ! Күтәр син бездән бу караңгы пәрдәне.

Шагыйрь шулай ачыргаланып язган. Өммегөлсем аларны шулай өзелеп-өзелеп кабатлый, Тукайча ялвара. Һәм «мәхәббәт сакчысы» бу юлы, язмышның йомшак җиле булып, Өммегөлсемнең матур коңгырт чәчләреннән иркәләп сыйпап кына үтәсе итә.

***

...Көннәрдән бер көнне бу караңгы пәрдә чынлап та күтәрелер. Мәңгелек сәфәргә җыенучы шагыйрь алдында ерак сәфәрләрдән, зарыгып, сагынып кайткан ак фәрештә пәйда булыр. Һәм...

Тик әлегә алда, соңгы бәянга илтүче сынаулы озын юл һәм кул сузымы гына еламсак ел көтәр.

## Шәфкать туташы

*И Тәгалә! Җир йөзеннән алчы бу алтынны, ал,*
*Яндыручы бу мөкаддәс җирне – бу ялкынны ал!*
«Алтынга каршы». Г.Тукай

Гөлсем, чыннан да, Тукай фаразлаганча, «кара төннең ак фәрештәсе»дер, күрәсең. Әнә ич ул «мәхәббәт сакчысы»ның да үз телендә сөйләшә. Саф, эчкерсез ярату, шәфкать иясе булу – фәрештәләр теле, фәрештәләр сыйфаты, фәрештәләр гамәле. Шагыйранә яну-яратулар шулай күп чак күктәге фәрештәләрне җиргә, җирдәгеләрен күккә аштыра. Хәер, бүгенге көзге, карлы-бозлы яңгыр аларның да юлын тоткарлый булыр. Җиле дә үтәли исә, үтәли кисә. Җанлы, җансызы, һәммәсе күшеккән. Андый чакларда Гөлсемнең уен, ирексездән, Тукай били. «Ул да өшидер. Тагын ютәле эченә – бәгъренә төшәдер. Ә шәфкать туташы берни эшли алмый. Шәфкать туташы тәкъдир каршында көчсез...»

Көчсез?! Уйлап баксаң, хәйраннар калырлык: «кара төннең ак фәрештәсе» яралы кара төннәрне, яралы тәннәрне, яралы йөрәкләрне дәваларга сугышка китеп бара.

Өммегөлсемнең көтмәгәндә-уйламаганда мондый карарга килүе язмышның ниндидер бер сынавы, маҗарасы булдымы? Әллә аны гел алгысыткан яңарыш, каһарманлык, үзен һәрдаим исбатлау, милли азатлык тойгысы йөртә идеме? Бәлкем, бәлкем... Югыйсә, Петербургта хатын-кызларның Югары педагогика курсларына эләгү өчен нинди генә кыенлыкларны җиңәргә туры килмәде аңа. Көн димәде, төн димәде, урыс, француз, немец телләрен өйрәнде. Классикларын йотлыгып укыды. Бер дигәнче ятлап, Тукай шигырьләрен күңеленең иң кадерле почмагына җыя барды. Илһамланды, хыял канатларында очты.

Өммегөлсем башта Чистайның рус кызлар гимназиясендә укыды, аннан Казандагы данлыклы Александра Котова гимназиясенә читтән торып имтиханнар тотты. Камаловларның ишле, атаклы гаиләсендә гимназия тәмамлаучы кызларның да беренчесе ул иде. Гаиләдә сеңелләре өчен үз мәктәбен булдырып, үз сабакларын биргән абыйсы Ибраһим да төпчек сеңлесенең шул дәрәҗәдә ушлы, сәләтле булуына хәйран кала һәм ихлас сөенә иде. Инде менә гадәттән тыш бер сусау белән физика-математика бүлегенең өченче курсында укып йөргән жиреннән Өммегөлсем күз күрмәгән, хәвеф чорнаган бер илгә китеп бара.

Сәфәрнең башы болай башланды. Берничә көн элек аны Петербург мөселманнарының шәһәр җир идарәсе бинасында узачак җыелышына чакырдылар. Ул бирегә килеп кергәндә, трибунада «Нур» газетасы журналисты Кәбир Бәкер, Балкан сугышында хурлыклы җиңелүгә дучар булган төрек мөселманнарына ярдәм итәр өчен, яшьләр төркеме туплау зарурлыгы хакында кайнарлана-кайнарлана сөйли иде.

Билгеле, Өммегөлсем Балкан вакыйгаларыннан хәбәрдар. Балкан сугышы башлануга: «Христианнарга ярдәмгә», дип, бирегә «халык ополчениеләре» туплый башладылар. Чынлыкта исә, бу Төркиягә рус гаскәрен кертүнең бер юлы иде. Балкан ярымутравы һәрчак шулай Госманлы Төркия белән Рус империясе арасында сугыш-низаг тудырып торды. Бу хакта бөтен газеталар үз каланчасыннан торып чаң сукты. Әнә «Ялт-Йолт»ның 13 октябрь санындагы рәсем-карикатура астына да «Балканда» дигән исем куелган һәм түбәндәге сүзләр язылган:

Курыкмыймын, селкенми хәтта фәс чугы;
Мә, кирәксә, дүртеңә дүрт йозрыгым!

Кыз, ул юлларны укып: «Тукай!» – дип куйган иде. Янә нигәдер уена Тукай керәсе итте, хәтта шелтәле сүзләренә тикле яңгырагандай булды.

Кәбир Бәкернең соңгы җөмләсе аны «җиргә төшерде»:

– Шәфкать туташларын да әлеге изге эшкә тарта алсак, төрек кардәшләребезне тагы да сөендерер идек, – дип, тәэсирләнеп, залга күз ташлады һәм карашы нәкъ Өммегөлсемдә тукталып калды.

...Аннары бер-бер артлы III Дәүләт Думасының мөселман фракциясе депутатлары чыгыш ясады. Алар да бу изге эш-гамәлләрне ихлас күңелдән хуплауларын белдерделәр. Чыгышлар тәмамлангач, мөселман кардәшләргә ярдәм йөзеннән хәйрия җыю оештырылды.

Кәбир Бәкернең: «Кызыл Хач» җәмгыяте яралы сугышчыларга ярдәмгә

килергә тиеш», – дигән сүзләрен һәрдаим тәкрарлавында үзенә бер хосусият бар иде. Истанбул атлы хыял-шәһәрне күрү, андагы зыялылар белән күрешү-танышу – аның күптәнге изге теләге, һәм аны тормышка ашыру өчен форсат та чыкты. Татарның каһарман яшьләрен, бигрәк тә асыл, игелекле, ауропача укымышлы, зыялы шәфкать туташларын төрекләргә таныту уе тәмам өлгергән иде. Ул янә трибунага күтәрелде һәм бу юлы үзе белән тагын өч егетнең Балкан сугышына китәргә әзер булуын хәбәр итте.

Тукайны Муса Бигиевлардан рөхсәтсез алып киткәне өчен Өммегөлсем бу егетне өнәп бетермәсә дә, әлеге минутларда ул үзен аның янәшәсендә итеп тойды. Әйтерсең, ниндидер бер билгесез көч аны урыныннан йолкып алды да трибунага этәрде. Бу чибәр, горур йөз-кыяфәтне, гүзәл буй-сынны күреп, зал бер мәлгә тын калды.

– Мин – Гөлсем Камалова. Моннан ике ай элек «Царское село» хастаханәсендә ике айлык шәфкать туташлары курсын тәмамладым. Төрек телендә дә беркадәр аңлаша алам. Язгыгыз мине дә китүчеләр төркеменә, – диде ул, яңгыравыклы, ышанычлы тавыш белән.

Зал кызны алкышларга күмде. Бәгъзеләр соклануда «аһ» итте, бәгъзеләре йөрәге «өзелеп төшәр» дәрәҗәгә җитеп җәлләде. Урынына борылып кайтканда, Өммегөлсем икенче рәттә утырган җизнәсе Муса Бигиевны күреп, эсселе-суыклы булып китте. Ни әйтер икән аңа Муса әфәнде? Капма-каршы партия вәкиле Кәбир Бәкергә ияреп сугышка китәргә фатихасын бирерме? Муса әфәнде һәрвакыттагыча үз югарылыгында калды. Гыйлемлелек, тәрбиялелек һәм зыялылык җиңде.

– Хәерле сәгатьтә, Гөлсем[7], – дип, ул кызның кулларын кысты.

Әмма, Әсма апасының Петербургта чагы булса, Гөлсем-Өммегөлсемнең тормышында мондый борылыш була алыр идеме икән? Юк, җибәрмәс иде апасы аны мондый куркыныч, хәвефле юлга!

Әсма ханым балалары белән әлегә Чистайда, әнисе Бибифатыйма янында. Муса әфәнде гаиләне тотарлык берәр җүнле эш табу белән, ул бирегә очып килеп җитәчәк. Җизнәсенә университетның көнчыгыш телләр факультетында урын вәгъдә итәләр итүен. Ләкин кайчан булыр ул, Муса әфәнденең хезмәтләрен танырга теләмәүчеләр анда да барып җитмәсме? Сак белән Сок кебек сагынышып, аерым яшәргә мәҗбүр булган апасы белән җизнәсен Гөлсем бик кызгана иде. Муса әфәнденең чалара башлаган чәчләренә күзе төшкәч, йөрәге тагын да кысылып куйды. Аңа бары 34 яшь кенә бит әле. Бер-берсен ничек яраталар алар! Аерылышып яшәүләрен ничек авыр кичерәләр.

Балаларын алып, Чистайга кайтып китәр алдыннан, Әсма апасы белән Гөлсем арасында авыр сөйләшү булды. Сәбәпчесе – Тукай. Шагыйрь Петербургтан Казанга кайту белән, «Ялт-Йолт» журналында (1912 ел, июль саны) «Мәкаләи махсуса» дип исемләнгән сәяхәтнамәсен бастырып чыгара. Петербург тормышын сурәтләгәндә, Бигиевлар гаиләсен дә читләтеп үтми. Әлбәттә инде, Тукайга хас булганча, чәнечкеле итеп яза. Бу хәлгә нык рәнҗегән Әсма апасы Гөлсемне битәрләп ташлый:

– Яхшылыкка яманлык белән җавап бирүче шушы адәм өчен тагын күпме янарсың икән? Син әллә үзеңнең Мөхәммәдзакир ишан кызы булуыңны да онытып барасың инде? – ди ул, ярсуын тыя алмыйча.

Әтисен бөтенләй хәтерләмәсә дә (Гөлсем әтисеннән дүрт яшьлек сабый булып кала), Гөлсем үзенең кем баласы икәнен бөтен күзәнәкләре белән тоя. Ничек кенә тоя әле! Ташып торган энергия, күпләрне хәйран итәрлек тәвәккәллек, кыюлык әтисеннән килмичә, каян килсен ди сиңа? Мөхәммәдзакир

[7] Барлык туганнары да Өммегөлсемнең исемен кыскартып, «Гөлсем», дип йөртәләр.

кызы булмаса, ул бүген биредә утырыр идеме? Сугыш уен эш түгел. Яшь булса да, Гөлсем аерылу газабын белә. Гөлсемнең сугышка китүен ишетсә, Тукай ни уйлар икән? Аның ут эченә китүен дә «вак-төяк эш» дип санармы икән ул?

Залда янә алкышлар яңгырады. Гөлсем уйларына чумып утырган арада трибунага тагын өч туташ чыккан. Билгеле, Гөлсем бу кызларның өчесен дә яхшы белә. Рокыя Юнысова – Петербург мулласы Мөхәммәтзариф Юнысов кызы, булачак табибә. Ташкент кызы Мәрьям Якупова да аның кебек Югары медицина курсларында укый. Ростов шәһәреннән килгән Мәрьям Паташова да – булачак табибә. Ул психоневрология институтында белем ала. Гөлсем ирексездән: «Алар белән миңа җиңел булмастыр», – дип уйлап куйды.

Юлга иртән кузгалырга сүз куештылар. Бу – 1912 елның 7 ноябре иде.

Шәһәр мөселманнары иртән гает намазларын укыганның соңында вокзалга җыелдылар. Чалмалы кешеләрнең күплегеннән пассажирлар бер-берсенә сәерсенеп карасалар да, шик-шөбһә белдерүче табылмады. Озата килүчеләр арасында Муса Бигиев та бар иде[8]. Озатучылар исеменнән ул да бу игелекле һәм дә шактый авыр сәфәргә чыгарга җөрьәт иткән мосафирларга рәхмәтләрен белдереп, һәрбарчасының аларга хәер-догада, изге теләктә калуларын җиткерде. Гөлсем җизнәсеннән әлегә туганнарына үзенең сугышка китүен әйтмичә торуын үтенде. Муса әфәнде дә «шулай дөресрәк булыр» дигәндәй, башын кагып кына ризалыгын белдерде.

...Уйлар инде күптән юлда. Алар әле очалар, әле йөгерәләр, әле туктап калалар, әле үткәннәргә кайтмакчы булып талпыналар. Акыл дигәннәре генә үзләрен күздән яздырмыйча саклый иде бугай.

8 ноябрь көнне алар Одесса шәһәрендә иделәр инде. Биредә Төркиягә ярдәмгә килүче яшьләрне Ырынбурның «Вакыт» газетасы нәшире, мөхәррире, язучы, галим Фатих Кәрими каршы алды. Кырык яшьләр тирәсендәге бу кешенең йөз-кыяфәте тәэсирләндерә торган. Тавышы, сөйләү рәвеше йөрәккә ятышлы. Ул кызларны французча сәламләде һәм бер-бер артлы сораулар яудыра башлады. Исәбе – аларның бу телне ни дәрәҗәдә камил белүләрен ачыклау иде бугай. Язучының Гөлсем белән әңгәмәсе озаккарак сузылды. Кызның французчасына тел-теш тидерерлек түгел иде.

Авазларның үзенчәлекле яңгырашы, көйле сөйләме өчен аерата яратып өйрәнде бу телне Гөлсем. Француз теленнән аларны бөтен Петербургка исеме танылган Лягонд мөгаллим укытты. Германиядән килеп алман телен укыткан профессор Клейненберт та күренеклеләрдән иде.

– Сез Казан кызымы, мадемуазель? – дип сорады Фатих әфәнде. Ул, канәгать елмаеп, инде татарчага күчкән иде.

– Чистайдан мин, мишәр кызы.

– Туктагыз әле, Чистайның атаклы ишаны Мөхәммәдзакир Камалов хәзрәтләренең кызы түгелсездер бит?

– Нәкъ үзе!

– Кайсысы?

– Төпчеге, Гөлсем булам.

– Машалла! Менә очрашу! Минем Чистайда булмаганыма күпме еллар инде...

– «Комедия Чистайда» әсәрен язучы сез бит инде. Сезне Чистайда яхшы хәтерлиләр.

Язучы рәхәтләнеп бер көлеп алды да: «Искә төшерерлек вакыйгалар шактый булды анда, бер сөйләшербез әле, язган булса», – дип, Өммегөлсемнең

[8] Тагирзянова А. Книга о Мусе эфенди, его времени и современниках. – Казань, 2009.

күзләренә тутырып, төбәп карады. «Ниндидер серле-моңлы, нурлы елмаю», – дип, үзенә бер соклану белән күңел дәфтәренә теркәп куйды.

Кызлар үзләренчә урнашкан арада, Фатих Кәрими Чистайны, Гөлсемнәр гаиләсен берәмтекләп хәтереннән кичерде. Мөхәммәдзакир Габделваһаб улы – Россия күләмендә мәшһүр ишан, күренекле мәгърифәтче, II гильдия сәүдәгәр. 1882 елда Чистайда үз акчасына мәдрәсә салдыра. Ике мәчет төзетә һәм гомер буе имам булып тора. Ризаэддин Фәхреддин, Гаяз Исхакый... һәм Фатих үзе дә шунда белем эстәде. Гаиләдәге сигез кыз һәм ата-ананың бердәнбере, горурлыгы булган Ибраһим – бүгенгедәй хәтерендә.

Гаҗәеп тәрбия һәм гыйлем алып үсүләренә искитәрлек. Гарәп, фарсы, төрек, татар һәм көнбатыш классиклары әсәрләреннән тупланган бай китапханәләре үзе генә дә ни тора! Халык хак әйтә шул: «Оясында ни күрсә, очканында шул булыр». Ибраһим да башлангыч белемне әтисе мәдрәсәсендә ала. Аннан соң Каһирәдә Шәрык дөньясының иң күренекле «Әл-Әзһәр» университетында укый. Муса Бигиев белән дуслыклары да шул еллардан килә. Инде менә сөекле сеңлесе Әсма белән татарның Муса Бигиев кебек зур зыялысының никахлашуларын бәхет дими, ни диярсең?!

Ибраһим өчен сеңелләре күз карасыдай кадерле. Алар – яраткан абыйлары канаты астында. Шәмсениса, Хәтимә, Гөлсем һәм тагын мәгариф өлкәсенең күренекле шәхесләре булачак Чистайның берничә кызын Ибраһим үзе укыта.

«Тау белән тау гына очрашмас, кеше белән кеше очрашыр», – диләр шул. Бу очрашу язучы күңелен бер дә уйламаганда канатландырып, Чистайларны уратып, яшьлектә сәяхәт иттереп кайтарды. Күр әле син, диңгез төсле әллә кайларга җәйрәгән Чулман-Кама да, аның ярларын әледән-әле чупылдатып сөеп торган дулкыннары да, акчарлакларның туктаусыз очып уйнаулары да җанланды диярсең. Борынгы Җүкәтау өстендә күзнең явын алырлык йолдызлы күк тә, нәкъ менә йолдыз атылганда кабул булачак дип юраган теләк-хыялларның да җете төс-сурәтләре уңмаган икән ләбаса.

Бер карасаң, әле генә кебек, исәпләсәң, егерме елдан артык вакыт узып киткән. «Камалия»[9] мәдрәсәсеннән чыгарылса да, Фатихның ул елларга, ул гаиләгә рәхмәте зур. Менә бит дөньялар ничек, Ибраһимның җанын аямаган кече, иркә сеңлесе, гүзәл мадемуазель сугыш кырына керергә бара, диген... Иншалла, кулыннан килгән бар ярдәмне дә эшләр Фатих кызлар өчен.

Фатих Кәрими – чит илләрдә йөреп, күпне гыйбрәт иткән абруйлы асыл зат. Татарның атаклы бае Шакир әфәнде Рәмиев[10] белән бергә юлдаш, тәрҗемәче һәм журналист сыйфатында биш айга сузылган «Аурупа сәяхәте» генә дә ни тора! Мәскәү, Петербург, Берлин, Брюссель, Париж, Ницца, Монте-Карло, Милан, Вена, Будапешт, Истанбул. Һәрберсе хакында гаять киң масштаблы, сурәт-тасвирлы, этрафлы юлъязмалар белән татар дөньясын шаулаткан шәхес.

Истанбулга китүче пароход кузгалганчы, сөйләшергә-аралашырга вакыт җитәрлек булды. Язучы кызларга Төркиянең нинди ил икәнен, гореф-гадәтләрен, иң мөһим хасиятләрен кыска, әмма хәтердә калырлык итеп сөйләргә тырышты. Сүз кайсы гына әдәбият, төрек яки француз язучысы хакында чыкса да, Гөлсемнең алар иҗаты белән таныш булуы язучыны торып-торып гаҗәпләндерде. «Безнең татар кызларымы соң болар?!» дигәндәй, Кәрими әледән-әле кызга сокланып-сөеп карады.

---

[9] Мөхәммәдзакир ишан шәкертне яшерен рәвештә рус телен өйрәнүе һәм «Тәрҗеман» газетасын даими укып баруы өчен мәдрәсәдән чыгара.

[10] Закир, Шакир Рәмиевләр – Уралдагы алтын приискасы хуҗалары. «Вакыт» газетасы һәм «Шура» журналлары нәширләре.

Туташларның ауропача киенүләре дә, үз-үзләрен тотышлары да аның күңеленә горурлык хисе өстәде. Ә бит, баксаң, Төркиягә китүчеләрнең һәммәсе дә мулла балалары. Иманын-динен саклаган хәлдә яңалыкка омтылу. Бу чиксез катлаулы дөньяны аңларга тырышу. Болар берәүгә дә җиңел генә бирелми. Әйе, байтак еллар элек ул да беренче кат диңгез кичеп, Истанбулга килеп төшкән иде. Диңгез портыннан турыдан-туры атаклы төрек язучысы Әхмәт Мидхәтне эзләп киткән иде. Егет Чистайның «Камалия» мәдрәсәсендә укыганда, аңа хатлар язып торды. Ни гаҗәп, язучы аларның һәрберсенә җавап биреп барды. Истанбулга килгәч исә шәкертне өендә туганыдай кабул итте. Әхмәт бәй укуга омтылышы ташып торган Фатихны Истанбулның иң күренекле кеше балалары гына укый торган «Мөлкия» мәктәбенә урнаштырды. Затлы әдәплелек, чит телләргә һәм Төркиягә ихтирам, мәхәббәт менә каян килә. Биредә ул иҗат эшен дә дәвам иттерә. Монда хәзер аның дуслары, фикердәшләре яши. Бу юлы ул Төркиягә «Вакыт» газетасы өчен язмалар әзерләү нияте белән килә. Дөресрәге, ул кайчандыр үзен сыендырган илнең җиңелү сәбәпләрен ачыкларга, авыр хәлен уртаклашырга дип килә. Хәер, бу вакыт Төркия язмышында гына түгел, ә бәлки Россиядә яшәгән төрки халыклар, шул исәптән татарларның да тормышында хәлиткеч тарихи дәвер була.

Публицист, фәлсәфәче, сәясәтче, язучы Фатих Кәримине[11] хатын-кыз азатлыгы, булачак мәгърифәтле аналарның язмышы икътисади, хәрби, сәяси мәсьәләләргә караганда да ныграк кызыксындыра. Шуңа күрә дә ул ауропалашып килүче бу кыю татар кызларын күз уңында тотарга җыена.

...Әлегә... Әлегә юл. Кара диңгез кичәсе. Күңелеңнән догалар укып, теләкләр телисе: «Аллам-Раббым, исән-имин барып, исән-сау кайтырга язсын!» Юк, юк та караңгыда шомлы уйлар шуышып үтә. Тукай әйтмешли:

> Күктә ни булмас, дисең, – очсыз-кырыйсыз күк бит ул!

И-и газиз Тукаем, син генә исән тора күр. «Сәбәп» чыкты: Гөлсемнең битеннән юл-юл кайнар яшь акты. «Их, йөрәк шагыйрен Кырымнарга алып барып, дәвалыйсы иде дә бит... Гөлсем тагын соңгы очрашуны күз алдына китерде. Берүк «соңгы» гына була күрмәсен! Шагыйрьгә аның әнә очы хәтле генә дә ачуы, үпкәсе юк. Тукай хәтле Тукай кызлар кулына тотынып Кырымга китте ди сиңа! Гөлсемнең битен тагын юл-юл кайнар яшь юды. Шөкер, син бар, Тукай, йөрәк янганда, ярату хисенә сусаганда, сагынганда «сөйләр-сөйләшер» өчен син һәм бәгырьдә сакланган шигырьләрең бар.

Гөлсем әкрен генә каюта ишеген ачып, палубага чыкты. Шунда ук йөзенә салкын су җиле, язмыш җиле килеп бәрелде. Диңгез дә шактый ук чайкала, чайкый. Озакламый Кара диңгезнең миллион еллардан бирле килә торган хикмәтле кануны тагын көченә керер. Диңгез аяусыз бер көч белән актарылыр, айкалыр, давыл дулар, дулкыннар бер-берсен ак күбеккә батып куышыр, юлында торганнарны юк итә барыр...

> Чыкты җилләр,
> Купты тулкын –
> Ил корабын җил сөрә!..
> Кайсы юллар,
> Нинди упкын
> Тарта безне, җан сорап?!

[11] Кәрими Ф. Биографиясе һәм хезмәтләреннән үрнәкләр (Төзүчесе – Мәсгуд Гайнетдин). – Казан: «Иман» нәшр., 1432/2011.

Гаҗәп, Гөлсемнең җаны бүген шигъри дулкында. Әнә «кайгылы, моңлы» Дәрдемәнднең «Кораб»ы каршыга килә һәм күңелне тирән фәлсәфи уйларга, моңнарга төреп үтә. Ул да – Гөлсемнең яраткан шагыйре. Дәрдемәнд – Закир Рәмиев тә Истанбулда белем эстәгән. Тукайның да: «Истанбулны бер барып күрсәң ярар иде ул», – дигән уе булган. Күп зыялыларның күңелен тарткан, сыендырган якын, кардәш ил. Авыр вакытта ярдәмгә килү – ул олуглык, күркәмлек сыйфаты. Ярый әле юлга вакытында кузгалдылар. Инде тынычланып, бераз ял итәргә кирәк.

Гөлсемнең сак кына каюта ишеген ачуы булды, Мәрьямнең сулкылдап елавы тышка бәреп чыкты:

– Гөлсем, шунда үлеп калсак?..

– Кем әйтте сиңа без анда үләргә барабыз дип? Дускаем, без үзебез «үлгәннәрне» терелтергә тиеш, шулай түгелмени?! Шуңа анда безне дүрт күзләп көтәләр. Бу ямьсез уйларыңны матур башыңнан тизрәк чыгарып ташла, яме, – дип, йомшак кына чәчләреннән сыйпап, аналарча бер җылылык белән кочаклап, Мәрьямне тынычландырырга тырышты.

– И-и Гөлсем, Ходай сиңа шултикле ихтыяр көче биргән. Син – гел сокландыргыч, изге бер җан.

– Мин дә шулай, сезгә карап сокланам.

– Болай син генә әйтә аласың инде, Гөлсем җаным. Рәхмәт яусын.

– Мәрьям, Тукай шигырьләрен укыйммы үзеңә?

Мәрьямнең күңеле тагын бер ташып-түгелеп алды. Кыз баш кагып кына җавап бирде дә, күзлеген салып, күзләрен сөртеп, Гөлсем белән бергә шигърият диңгезенә «чумды».

**Мәхәббәт**

Җир яшәрмәс, гөл ачылмас – төшми яңгыр тамчысы;
Кайдан алсын шигъре шагыйрь, булмаса илһамчысы.

Бер гүзәлдән кайсы шагыйрь, әйтеңез, рухланмаган?
Байроның, Лермонтовыңмы, Пушкиныңмы – кайсысы?

Файдасыз бер ит кисәгеннән гыйбарәттер йөрәк,
Парә-парә кисмәсә гыйшык-мәхәббәт кайчысы.

Тешләренең гәүһәреннән кабызып алдым менә
Мин бу шигъре, – әйтсәңез лә, энҗедән ким кай төше?

– Тукай шул дәрәҗәдә гашыйк шагыйрьме, Гөлсем?

– Тыңла, сораулар соңыннан:

**Булмаса**

Кем белер кадреңне, җаным, дәртле күңел булмаса?
Наз итәр кемнәргә гөл – каршында былбыл булмаса?

Сурәтеңнең иң чыны, бел: шагыйрең күңлендәдер;
Көзгеләрдән чын төсеңне күрмисең – ул булмаса.

Бирмәде Ләйлә кеби мәхбүбәгә дөнья бәһа;
Ул болай бер кыз гына – каршында Мәҗнүн булмаса.

Һич килештермим синең төсле гүзәллек шаһына,
Ичмасам, бер хисле шагыйрь дә килеп кол булмаса.

– Гөлсем, бу шигырь сиңа багышланганмы?

– Юк, Мәрьям. Әмма ул йөрәгендә мәхәббәт хисе булган һәркемгә аталган. Чын, бөек шигърият, минемчә, нәкъ шундый була.

– Петербурга килгәч, Тукай безнең белән очрашырга да теләмәде ич.

– И-и Мәрьям, Тукай нык авыру иде ул көннәрдә. Мин ул көннәрне исемә төшерсәм, әле дә йөрәгемнән кан саркый.

– Син Тукайны чын-чыннан яратасың бугай, Гөлсем.

– Тукайны да яратмасак, аннан без кем, нинди милләт булабыз?!. Тик менә берничек тә ярдәм итә алмыйм. Исән генә тора күрсен инде... Ул минем йөрәгемнең ярасы...

– Син – чын әүлия, Гөлсем-җаным, – диде Мәрьям. Чөнки хәзер аның күңелендә дә мәхәббәткә тартым илаһи бер нур балкый иде.

Күрше каютадагы Мәрьям белән Рокыяның да уй-тойгылары, сүз куешкандай, бер тирәдәрәк йөрде. Алар да озак кына сөйләшеп, аннан бераз егълашып, йөрәк серләренә күчтеләр. Инде хәзер шул сихри дулкын кочагында кинәнеп йөзүләрендә иделәр.

Фатих әфәнде генә егетләргә дә, туташларга да хәерле-имин төннәр теләп чыгып, намазларын, догаларын укып ятса да, күзенә һич йокы кермәде. Кара диңгез дә дулкын-дулкын хатирәләрне күңел ярына чыгара торды. Моннан унөч еллар элгәре «Аурупа сәяхәте»нең унөч көне Истанбулга багышланган иде. Йөргән-күргәннәрдән, очрашу-танышулардан бик мәмнүн булып, май аеның кояшлы бер иртәсендә Кара диңгез буйлап кайтыр юл, туган җир уңаена йөзделәр...

Ә менә бүгенгесе – барыр юл уңае. Бу тарафта әлегә уйлар да, гамьнәр дә, вазгыять тә башкача. Балканны сугыш уты өтә. Илнең иминлеге кыл өстендә. Нигә? Нилектән? Әлеге бихисап сорауларга җавап эзлисе, табасы һәм халык күңеленә җиткерәсе. Чын аристократ, асыл затлар катламыннан, шул ук вакытта көрәшче табигатьле Фатих Кәрими үзенә әнә шундый олы вазифалар йөкләп, утлы сызык уңаена китеп бара.

Ә инде Истанбул белән бу юлы очрашу тәэссоратын Фатих Кәрими үзенең мәшһүр «Истанбул мәктүпләре»ндә[12] болай дип бәян итә:

«9 ноябрьдә җомга көн кич безнең пароход Истанбул бугазына килеп кергәндә, сирәк-сирәк кенә туп тавышлары ишетелә иде. Одессада: «Истанбулны болгарлар тупка тоталар икән», – дигән хәбәрләрне ишетеп килгән кешеләргә җитә калды. Юлчылар:

– Харап булдык, туп астына килеп керәбез бит, – диешә башладылар. Әмма Истанбул әхвәлен белгән рум вә әрмәннәр:

– Курыкмагыз, әфәнделәр, мөселманнарның Корбан бәйрәмедер, алар бәйрәмнең дүртенче көнендә һәр намаз вакытында туп аталар, – дип, куркак кешеләрне тынычландырдылар.

Һәйбәт җылы кояш астында, ике ягы да ямь-яшел бакчалар вә агачлардан гыйбарәт бугаз эченә килеп кергәч, зан итәмен ки, бер кешенең дә күңелендә сугыш куркулары калмагандыр. Бугазның ике сахилендәге (диңгез кырыендагы) әмсалсыз (мисалсыз) дәрәҗәдә матур манзаралар һәркемнең күңелен дә, күзләрен дә үзләренә җәлеп иттеләр. Йөз мәртәбә күреп үткән кешеләр дә йөз беренче мәртәбә улмак үзрә (булган булса да), тагын шул ук әүвәлгесе шикелле һәвәс белән сәер вә тамаша итәләр иде».

Истанбулга тәүге кат аяк басучы яшьләребез өчен бу бигрәк тә шулай.

[12] Кәрими Ф. Истанбул мәктүпләре (Төзүчесе – Э.Нигъмәтуллин). – «Мирас китапханәсе» // «Гасырлар авазы» журналы.

Алларында моңарчы күрелмәгән нинди гүзәл манзара. Су өстендә бихисап төрле төстәге утлар җемелди, әллә ничә айлы манаралар «йөзә». Шәһәр өстендә илаһи азан моңы тибрәлә. Шушы сихри тылсым эчендә туганда ук калебкә кереп урнашкан хәтер хәяте җанлана, йөрәкләр ашкынып куя.

Истанбулда һәрдаим шулай аларны сокландырган күренешләр дә, гаҗәпсендергән сәер хәлләр дә чиратлаша торды. Пароходтан төшеп, «Мәсәррат» отеленә барганда, ике урамның ике ягына тезелеп киткән бихисап каһвәханәләр һәм аларның эчен-тышын, тирә-ягын тутырган, кибарле киенгән тап-таза төрек ирләренең сугыш барган көннәрдә шулай ваемсыз утырулары барсын да таң калдырды.

Хәер, бирегә мәҗрух-яралыларны карарга дип Русиядән килгән, ауропача киенгән мәдәниятле шәфкать туташлары да төрек дөньясын үзләренчә таң калдырырга җыена иде: фидакарьлек, кыюлык, каһарманлык белән.

Фатих Кәрими исә, Рокыя әйтмешли, «Кызларның юлына чыккан Хозыр Ильяс» иде. Иң элек ул аларны Русия илчелегенә алып барып килүләрен рәсмиләштерде. Аннан «Һилал Әхмәр» («Кызыл Ай») җәмгыятенең мәркәзи идарәсендә очрашып күрешкәннән соң, әлегә төрек телен камил үк белмәгән кызларны княгиня Елизавета Николаевна Оболенская эшләгән хастаханәгә билгеләделәр. Хастаханә Мәрмәрә диңгезе буенда Кадергә мәйданында гаять зур берничә бинадан гыйбарәт иде. Элек биредә бала тудыру йорты, акушерлык мәктәбе булган. Сугыш чыккач, аны яралылар өчен хастаханә иткәннәр. Докторларның берничәсе – ирләр, хезмәт күрсәтүчеләрнең калганнары хатын-кызлар булып, шәфкать туташларыбызны да җылы, матур кабул иттеләр.

Хастаханәнең яралылар яткан бүлмәләрендә пакьлек, яктылык. Ике йөз урынга яхшы караватлар, һәйбәт юрганнар. Яралыларның өс-башлары да сөт шикелле ап-актан.

Княгиня Оболенская да:

– Мин – инсаният тарафдарымын, төрекләрне сөямен. Төрекләрдән дусларым күп, шуңа монда килдем, – дигән сүзләре белән сокландырды.

Русия илчесенең хатыны мадам Гирс та килеп, хастаханәне ошатып киткән булган.

Ни гаҗәп, шәфкать туташларын барып кергән мәлгә үк эшкә тәгаенләделәр. Җәүдәт табиб хирургия бүлегенә Гөлсемне сайлап алды. Гөлсем аңа калган өч кызның булачак табибәләр икәнлеген дә, әзерлекләре, тәҗрибәләре буенча өстенрәк булуларын французча бик шәрехләп аңлатырга тырышса да, үзе дә француз телен искиткеч камил белүче доктор, елмаеп: «Чок гүзәл, чок гүзәл», – дия-дия, кызны хирургия бүлегенә алып кереп китте. Гадел атлы төрек егетенең бер аягын кисәчәкләр. Моны ишетүгә үк Гөлсемнең күз аллары караңгыланды, чак-чак укшудан тыелып, «теше-тырнагы» белән егетнең кисәсе аягына ябышты. Табибның сизгерлеге көчле, тәҗрибәсе зур иде, кызга тиз генә нашатырь китереп тоттырды. Кан эчендә яткан яшь егетнең тавышсыз-өнсез генә елавын күргәч, Гөлсем үзен бер дигәнче кулга алды. Маңгаендагы бөрчек-бөрчек тирләрне сак кына сөртеп, берөзлексез дога укыды, Ходайга ялварды. Тик үзенең күз яшен ничек тыярга, ничек күрсәтмәскә, ихтыяр көчен ничек тупларга?! Беренче операциядән алган сүзсез тетрәнү «ак фәрештә» җанына онытылмаслык тирән эз сызып узды.

Яралы хәрбиләр саны көннән-көн арта торды. Ноябрь азагында болгар хәрбиләре Истанбулны утлы боҗра эченә алдылар. Сугыш госпитальнең капка төбенә үк килеп җиткәндәй булды. Тупларның туктаусыз гөрселдәвеннән тәрәз пыялалары коелып бетә язды. Бу минутларда әлеге мәхшәр, гарасат эчендә

калган кызларның хәленә керсә, Кәбир Бәкер генә кергәндер. Аның әледән-әле: «Чүгәләгез! Ятыгыз! Марш подвалга!» – дигән әмерләре яңгырап торды. Кызлар аның әйткәннәрен үтәргә тырышсалар да, үз-үзләрен аямыйча, авыр яралыларны карауларын дәвам иттерделәр. Фатих Кәрими ул көннәр турында «Истанбул мәктүпләре»ндә болай дип язды: «Хастаханә һәйәтләре вә табиблар безнең Русия мөселманнарыннан гаять разый вә мәмнүннәр. Аларның армый-талмый яхшы эшләүләренә исләре китә. Безнекеләр үз мәсьрафлары (чыгымнары) илә килеп шулкадәр тырышып хезмәт итәләр». Алай гынамы, кызлар европалылар һәм мөселман дөньясы алдында халыкның йөзен билгеләүче – татар халкын танытучы буларак мәйдан тоталар. Кәрими исә төрек кардәшләренә һәм мөселман дөньясына яңа заман ир-атларының хатын-кызлар белән нинди мөгамәләдә булу үрнәген күрсәтә. Публицист үзенең атаклы сәяхәтнамәсендә хатын-кыз иреге мәсьәләсен хәл итүне Ислам дөньясы алдында беренче урында торган бурыч итеп тәгаенли. Ислам дөньясының яңарышы, килер көне – шул мәсьәләне хәл итә алуыбызга кайтып кала, ди ул. Һәм шәфкать туташларыбызны үз канаты астына алып, кызларыбызның холык-фигыле, тәрбиясе, эшчәнлеге мисалында әлеге яңалыкның нәрсәдән гыйбарәт икәнен Ислам галәменә таныта. Кызлар да шул идеалларны гәүдәләндерә алырлык югарылыкка ирешкән булалар.

Алар Төркиянең җәмәгать тормышында да актив катнашырга вакыт табалар. Хәтта хатын-кызлар хәрәкәтен оештыруда башлап йөрүчеләр булып китәләр. Фронтка ярдәм максатында «Мөдәфәгаи миллия» («Милләтне саклау») дигән җәмәгать оешмасы барлыкка килгәч, кызлар бу оешмага язма «Мөрәҗәгать» тапшыралар. Анда: хатыннар арасында да иганә җыюны оештырырга, хатыннар арасында да фикер (мәгълүмат, аңлатулар) таратырга, хатыннардан фиркаләр (бүлекләр) төзеп, сугышка озатырга, хатыннардан вәкилләр җибәреп, солтанның үзенең дә сугышка чыгуын үтенергә. Шәфкать туташлары үзләрен дә сугыш мәйданына якын кыр лазаретларына җибәрүләрен сораганнар.

Кызларның һәр чыгышын, һәр адымын төрекләр яклый, хуплый, аларга соклана, үзләре өчен иң авыр вакытта хәлләренә керергә, теләктәшлек белдерергә, ихлас ярдәм итәргә килгән ерактагы якын туганнары итеп, олы хөрмәт белән карый. Бу күренекле кызларны төрле иҗтимагый оешмаларга чыгып, үзләре алдында чыгыш ясауларын үтенәләр.

Фатих Кәрими «Истанбул мәктүпләре»ндә исә болай тасвир итә:

«Соң вакытта Истанбулда һәр көн яңгыр явып тора, һавалар артык суык түгел, кырларда үлән вә агачларның яшеллеге бетмәгән әле. Истанбул тирәләрендәге бакчаларда ашый торган үлән, яфракларны, яшелләкләрне җыялар.

23 ноябрьдә мондагы татар таләбәсе (шәкертләре) җәмгыяте үзләренең клубына мовәггәтән (вакытлыча) Истанбулда булып «Һиляле Әхмәр» хастаханәләрендә хезмәт итүче Өммегөлсем, Рокыя, Мәрьям ханымнарны Петербургтан килгән Кәбир Бәкер, Шәриф Әхмәтҗан, Фатих Рәхимов әфәнделәрне вә мине чәйгә чакырдылар. Шәһриләр (якташлар) илә танышып мосахәбәт иттек (кара-каршы сөйләшеп утырдык). Русиядәге мөселманнарның мәгыйшәтләренә, уку вә мәгарифләренә, тәрәккый вә тәмәдденнәренә (культуралашуларына) гаид бәгъзе нәрсәләр сораштылар. Белгән кадәр мәгълүмат бирелде. Өммегөлсем ханым Русиядәге мөселманнарның мәгыйшәтләренә, уку вә мәгариф юлындагы хәрәкәтләренә даир мәгълүмат бирде. «Төрек йурды» мөдире Йосыф әфәнде Акчурин да мәҗлестә хазир иде».

Җөмләдән тагын берсе, ифрат тәэсирләндергәне – шул ук елның ноябрендә Истанбул университетында алты мең төрек хатын-кызы катнашында

уздырылган зур җыен[13]. Гөлсем Камалованың анда сөйләгән сүзләре әле дә кыйммәтен югалтмаган. «Тыңлап» багыйк:

«Мин бу мөнбәргә сезгә вәгазь әйтү, акыл өйрәтү өчен менмәдем. Бәлки сезгә Русиядәге миллионнарча туташ вә сеңелләребезнең сәламен ирештерү, мондагы хәсрәтләр өчен аларның да күзләре яшьле, калебләре канлы буларак, сезнең кайгыларыгызны уртаклашуларын белдерер өчен чыктым.

...Ханымнар! Бүген гайрәт вә тырышлык күрсәтә торган көнебездер. Тарихларда күренәдер ки – Ватан вә милләтнең хәле мөшкеллеккә төшкәч, аларны күп мәртәбәләр хамиятле ханымнар вә галиҗәнап аналар коткарганнар. Без дә алардан үрнәк алыйк, гыйбрәтләник! Кулдан килгәнне эшлик вә киләчәк нәселләрнең ләгънәтләреннән котылыйк!»

Каян килгән бу Чистай кызына мондый кыюлык? Мондый рух күтәренкелеге? Җаннарны кузгатырлык җанлы сүз? Фатих Кәрими әлеге ялкынлы чыгыш белән газета укучыларын да таныштыра. Шулай ук Балкан сугышы вакытында «День» газетасында 45 егет һәм кызның рус матбугатында мөселманнарны хурлау-кимсетүгә каршы «Протесты» бирелә. Анда Чистай кызы Гөлсем Камалованың да имзасы тора. Текстның тәрҗемәсен Фатих Кәрими «Вакыт» газетасында бастырып чыгара.

Мәгълүм ки, Тукай да «Истанбул мәктүпләре»н зур кызыксыну белән укып бара. Фатих әфәнде Кәриминең Төркиядән «Кара диңгез аша йөздереп җибәргән» хәбәрләрен ул «халык өстәленә куелган җан азыгы» дип бәяли. Димәк, шагыйрь шәфкать туташларының кыю эш-гамәлләреннән дә, төрек дөньясында йөз аклыгы булуларыннан да хәбәрдар. Әмма Тукай бу хакта нигәдер бер генә сүз дә язмый. Дөньяны шаулаткан бу вакыйгадан читтә кала.

Уйлап баксаң, Русиядән килгән төрки хатын-кызларының каһарманлыгы хакында Төркиянең матбугат басмалары гына түгел, француз, алман газеталары да язып чыга. Һәм рәхмәт йөзеннән хәйрия акчалары юллаучы принцессалар да табыла.

...Инде менә яңа ел ишек кага. 1913 ел. Хәере, иминлеге белән генә килә күрсен! Кызлар өчен ул көтелмәгәнчә, бер хозурлык белән башланып китте. Русия илчесе Гирс хатыны шәрәфенә «Кагул» сугыш пароходында бал оештырып, туташларыбызны шул мәҗлескә махсус алдырды. Анда илчелек вәкилләре, мосафир кунаклар да күп булып, кызларга аерым бер ихтирам, соклану белән карадылар. Мадам Гирс бу фидакарь, һәрьяклап үрнәк, изге җанлы шәфкать туташлары хөрмәтенә тост тәкъдим итте, музыка яңгырады. Кызлар хәтта берникадәр уңайсызланып та куйдылар. Әмма алар өчен бу мәҗлес сусаганда берничә йотым су кебек кадерле, рәхәт, тансык иде.

Мадам Гирс хастаханәгә һәр килүендә кызларга гаять игътибарлы, һәдия итеп конфетлар, шоколадлар өләшеп, кулларын үбеп чыгып китә иде. Әмма ләкин бу аяусыз сугыш китергән һәлакәт, хәсрәт эзләре җаннан тиз генә җуелырлык түгел шул. Аяксыз, кулсыз, күзсез калып, сызланудан, чарасызлыктан, өйләренә кайта алмаудан зар-интизар яшь солдатлар белән тулган палаталарны бер әйләнеп чыгу да йөрәкләргә кан саудыра. Ни өчен адәм баласы һаман берсен-берсе сугышка тартып кертә, гарипләндерә, үтерә?! Каян килә бу кадәр үч, нәфрәт, нәфес, җан кыю?! Күкләрнең, җирләрнең сакчы фәрештәләре кайда?! Әллә инде кеше дигәнең аларның да канатларын көйдердеме?!

...Гөлсем бүген төн озынына ут кебек янды, саташты, куркыныч төш күрде.

[13] Биктимирова Т. Хәтерләрне яңартыйк. – Казан: ТР Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты, 2012.

Ул аңа елан чаккандай тәэсир итте. Кыз сикереп торып утырды да, чыннан да, төш кенә идеме соң бу, дип, һушына килә алмый йөдәде.

Әйе, төш өнне алырдай, куркыныч иде. Әнә аның каршысына ярдәм сорап, канга, балчыкка баткан өч төрек офицеры йөгерә. Ныклабрак караса, ни күрсен, имеш, аның берсе Ибраһим абыйсы, икенчесе Фатих Кәрими, ә өченчесе таныш түгел, әмма истә калырлык гаять күркәм йөз. Йә Аллам, килеп җитәләр генә дигәндә, әллә каян дөньяны ату тавышлары томалый. Тау-таш җимерелә, алар өчесе дә гөрселдәп җиргә ава.

Дистә еллар узгач, рас киләчәк бу төшнең авыр шаукымы кичкә кадәр дәвам итте диярлек. Әле Гөлсемнең «биш кенә минутка», дип сорап, ишегалдына чыгуы. Моңарчы Мәрмәрә диңгезе аңа гел Чулман-Каманы хәтерләтеп, сагынулы җанына шифа, куәт биреп торды. Әмма ләкин бүген диңгез дә салкын җил теле белән үз аһ-зарын гына сөйләп калырга ашыга төсле. Хикмәт! Аны бүген хәтта Тукай да юата алмый, туташ әлегә шагыйрьгә дә дәгъвалы:

Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен,
Тибрәтмәкче булсаң иң нечкә кылларын,
Уйнау тиеш, әлбәт, ачы хәсрәт көен,
Кирәк түгел мәгънәсе юк көлке, уен.

– Тукай бәгърем, әйт әле, бу дөньяда ачы хәсрәт көен күпме уйнарга була соң?

...Бүген йөрәгенә ял таба алмас, ахрысы, керергә кирәк.

Гөлсем кинәт артында гына: «Сәламүгаләйкүм, чок гүзәл табибә? – дигән сүзләрне ишетеп, сискәнеп китте. Борылып караса, каршында зур гына кул арбасы тоткан, кечкенә генә буйлы ундүрт-унбиш яшьләр тирәсендәге бер чибәр кыз бала басып тора. Гөлсем сәламне кабул итәргә дә өлгермәде, кыз тиз-тиз тезде дә тезде:

– Мин – Айсели. Мин сезне беләм, чок гүзәл табибә. Сез минем Гаделемне үлемнән алып калдыгыз. Сез яралылар өчен хәйрия җыясыз. Сез аларга җан җылыгызны өләшәсез. Сез... Сез...

Кызның чем-кара зур күзләреннән, озын керфекләреннән тыелгысыз эре-эре яшь ага.

– Айсели, Айсылу, Ай кызы...

Гөлсем юка гына олы җилән эчендә калтыранган һәм тагын да курачрак гәүдәле, үрсәләнгән җанлы бу баланы кысып кочаклады да, үзе дә кайнар яшьләренә батып чак кына тын торганнан соң, телгә килде:

– Чок гүзәл йөрәкле, чок гүзәл бала, мин шәфкать туташы гына. Бар да минем иркемдә булса, яралылар өчен әлләниләр эшләр идем. Айсели, син Гаделнең кеме? Син аны алып китәргә дип килдеңме? Өегездә тагын кемнәрегез бар? Ничек курыкмыйча мондый озын, хәвефле юлга ялгызыңны чыгарып җибәрделәр? – дип, кызны ак мамык шәленә төрә-төрә, ашыга-ашыга сорау арты сорау яудырды.

Кыз нәни чыпчык баласы төсле чирык-чирык сайрады да сайрады:

– Чок гүзәл табибә, мин дә уйдамын, сезнең дә яраткан кемсәгез бардыр. Ничек ул сезне курыкмыйча ут эченә җибәрде? Әйтимме нигә? Ходай сезне Гаделем хакына, сөю хакына җибәргән һәм сезгә мәхәббәт фәрештәсен сакка куйган.

Гөлсем авыз ачып сүз әйткәнче, кыз тагын көяләнә-көяләнә дәвам итте:

– Безнең якта арнаут күңелле сугышчылар, дошман илә сугышудан битәр,

төрек әфисәрләрен үтереп, төрек авылларын яндырып, талап, малларыбызны куып алып киттеләр. Мин ул чакта авылда түгел идем, бабам (атам) аларга каршы тормак булгач, аны атып үтергәннәр. Анам мин тугач ук вафаттыр... Авылдан күмер генә калган. Безнең өйгә нык зыян тимәгән. Төштә күрдем: фәрештәләр канатлары белән ябып сакладылар. Үзләре чак-чак янмый калды. Валлаһи.

– Ышанам, Айсели күз нурым. Ә Гаделләрнең өе?

– Без күршеләр ич. Мәрьям ана гына куркудан егылган, хәзер урын өстендә. Мин багам. Ул да миңа «күз нурым», ди. Мин аларны бик яратам. Алар да... Сез Гаделне минем белән җибәрерсез бит?

Гөлсем елмая төшеп, баш кагып кына өлгерде. Нәни чыпчык тагын чирык-чирык үзенекен сайрады:

– Мин әүвәл юлларны өйрәндем. Инде бүген арбамны да алдым. Чок гүзәл табибәм, мин юл буе Ходайдан сезнең белән күрештерүне сорадым. Сез курыкмагыз, мин бик көчле, чыдам. Килгәндә җимешле суымны да аз гына эчтем. Берничә телем ипием дә шул килеш. Гадел өчен. Мин аны бик-бик яратам, мин аны бик-бик сагындым... бик-бик!

– И-и җаным, җирдәге гүзәл кыз бала сурәтендәге Ай кызы! Әйдә, тизрәк керик, син инде бик-бик арыгансың. Хәзер ашарсың, эчәрсең, ял итәрсең. Ә иртәгә сезне машина белән озатырбыз.

– Машина белән! Ә арбам? Ул – бабам төсе. Миңа аны калдырырга ярамый.

– Арбаңны да салырбыз, сөеклем.

Шәфкать туташлары бүлмәсендә Гөлсем янә исе китеп, яратып, кызны күзәтте. Аның арыган күзләре «менә йомылам, менә йомылам», дип елмая. Ул кайнар чәен дә, боткасын да калак очы белән генә каба да, уймак тикле генә нәни авызында тотып тора. Аннан гына ләззәтле бер елмаю белән йотып җибәрә.

Ләкин аны биредә көнозын сагалаган арыганлык куып җитә. Күзләре үзеннән-үзе йомыла, талчыккан кулыннан кашыгы шуып төшә, тәне изри. Гөлсем аны сак кына кушеткага яткыра да, хасиятләп, җылы җәймәләр белән төреп куя.

...Бу «Ай кызы» миңа, мөгаен, күктән гыйбрәт өчен иңгәндер.

Нинди садә, нинди илаһи көч син, мәхәббәт! Никадәр татлы хыял, якты өмет, яшәү көче синдә!

Гөлсемнең шагыйранә мәхәббәте дә – хыял, сагыну, әрнү. Кәбир Бәкер аны Петербургта: «Тукайның көннәре санаулы. Догада тор!» – дип, үзәк өзгеч уйларга салды. Димәк, мәхәббәтнең дә көннәре санаулы гына калып бара. Ә ул Тукайдан шундый еракта. Кайчан гына кайтып күрер әле...

Аның сагышлы уйларын аксый-туксый, сөенеченнән балкып килеп кергән Гадел бүлдерде:

– Мәрхәбә, мәрхәбә, – диде шәфкать туташы, Гаделгә Айсели янындагы урындыкны тәкъдим итеп.

Гөлсем тагын аның операция өстәлендәге төсле тавышсыз-өнсез генә илереп елаганын абайлады, һәм үзенең дә күңеле янәдән бер мөлдерәп түгелде.

«Ай кызы»ның килү хәбәре сәгате-минуты белән таралып өлгергән иде. Берара бүлмә ишеге ябылып торырга да өлгермәде. Барысы да шаулашып керделәр дә аяк очларына гына басып чыгып киттеләр. Гадел генә сәгатьләр буе, кыздан күзен алмый, утырды да утырды.

...Хастаханә бүген әкияти бер төн кичерде. Гөлсемнән башлап, барлык шәфкать туташлары, табиблар төргәк-төргәк бүләк, күчтәнәч әзерләделәр.

Иртәгесен аягында йөргән һәркем тәрәзәдә иде. Бәхет-сәгадәттән балкыган Гадел белән Айселине яралыларны алырга баручы машинага утыртып кадерләп

озаттылар. Гөлсем аларны, тәмам күздән югалганчы, карап торды. Инде менә офык артына кереп югалырлар... Әмма шәфкать туташының йөрәгендә әлеге мәхәббәт хатирәсе гомере буена сакланыр.

...Бүген Гөлсемнең көне кояшлы, төне йолдызлы иде. Чөнки, Истанбулга килеп яшәүләренә өч ай дигәндә, аңа Чистайдан беренче тапкыр хат килеп төште. Хат Хәтимәдән иде. «Һәркайсыбыз кайтуыңны сабырсызланып көтәбез. Әй, «иркә таебыз», кайларга чыгып чаптың бит. Синең өчен борчылуларыбызның чиге булмады. Ә сөенечебез шул: Шәмсенисаның улы туды», – дип язган. Узган җәй абыйсы Ибраһим Шәмсенисаны, ай-ваена карамый, Сембернең данлыклы фабрикантлары нәселеннән булган Рөстәм атлы егеткә кияүгә бирде. Әмма ул үзенең нинди җәүһәргә тап булуын аңлап җиткермәде бугай. Ундүрт яшьтән бирле сөеп йөргән кызының һич белмәгән кешегә кияүгә чыгуын Фатих Әмирхан да авыр кичерде. Камаловлар гаиләсендәге кызлар белән аралашмас булды. Һәр җәйне дәү җизнәләре Нәҗип муллага кунакка килеп йөрүче, дөньяга күзлек аша караучы бу сөйкемле егет күпме хыял, көтелмәгән күпме сөенечләр бүләк итте аларга...

Искә төшерсәң, хатирәләр җитәрлек. 1907 елның җәендә әниләре Бибифатыйма кызларын Самара шәһәреннән ерак булмаган Серноводскига – күкерт суы белән дәвалый торган шифаханәгә алып килә. Берничә көннән кияве Нәҗип хәзрәт бәхетсезлеккә тарыган энекәшен – Фатих Әмирханны да бирегә китереп китә. Егетне паралич сугып, аяклары йөрмәс булган. Әмма ул бирешергә җыенмый, үзенең йөреп китәсенә аз гына да шикләнми.

Ах, ул Серноводскиның йолдызлы аяз кичләре! Әниләре Бибифатыйманың ястү намазын укып, йокларга ятуы була, кызлар аяк очларына гына басып, шифаханәнең борынгы паркына йөгерәләр. Аларның чыгуын коляскасында түземсезләнеп көтеп утыручы Фатих кызларны сихри йолдызлар дөньясына алып китә. Күкләрнең тылсымын барысына караганда да ныграк тоя, ахрысы, ул. Әнә йолдызлар серенә кушып, ул бүген Шәмсенисага йөрәк серен дә кыйсса итә.

– Хәтерлисеңме, Шәмсениса, бер кичтә без күктән «йолдыз чүпләгән» идек. Беренче тапкыр...

Ничек хәтерләмәсен ди! Кыяр-кыймас кына кызның бит очыннан үбеп алган иде Фатих. Шул көннән башлап Шәмсениса йолдызларга яратып, хыялланып карый торган булды.

– Менә хәзер аякларыма баса алсам, үрелеп кенә ә-әнә теге үзең төсле иң якты йолдызны бүләк итәр идем, күңел кояшым.

Мондый «бүләк»тән соң хыялланмый гына яшәп кара! Шәмсениса белән Фатих күптән инде күкнең җиденче катында. Сеңелләре аларга карап сокланып туя алмый. Чын ярату менә шундыйдыр ул! Әйе! Шәмсениса әдипнең мәңгелек зур мәхәббәте булып кала. Язучының «Кадерле минутлар» хикәясендәге өченче мәхәббәт тарихы Шәмсенисага багышлап язылган.

Фатих рәхимсез авыруга дучар ителеп, гариплләр арбасына калгач та, Шәмсениса сөйгәненнән ваз кичмәде. Ул көннәрдә аңа Казан белән Чистай арасын күп таптарга туры килде. Әмма язмыш башкача язылды. Абыйсы Ибраһим һаман үзенекен тәкрарлады: «Ике чирле бергә ничек гомер кичерсен? – дип, әледән-әле сеңлесенең йөрәк өянәген исенә төшереп торды. Һәм озакка сузмыйча, Шәмсенисаны кияүгә дә биреп куйды. Их, Шәмсүк, яныңда булсам, юатыр идем, дип, шәфкать туташлары бүлмәсендә күз яшьләренә күмелеп утырганда, кемдер ишек шакыгандай булды. Караса, бүлмәгә Фатих Кәрими кереп килә икән. Ул керә-керешкә:

– Мин сиңа бик сагынычлы сәлам тапшырырга дип кердем, – диде. – Беләсеңме кемнән? Гаяз Исхакыйдан! Аны тиздән төрмәдән азат итәргә җыеналар. Бирегә килеп чыгуы да бик ихтимал.

– Чынлап тамы? Дөрес хәбәрме бу? – диде Гөлсем, ихластан сөенеп.

Димәк, Гаяз абзый аның кайда йөрүен,ниләр эшләвен белә һәм хуплый.

– Ул үзенең «Зөләйха» драмасының кулъязмасы хакында борчылып яза.

– Борчыла күрмәсен. Аның «Зөләйха»сы ышанычлы урында, – диде Гөлсем.

Әйе, моннан нәкъ бер ел элек, Петербургта чакта, әдип аңа, зур ышаныч күрсәтеп, данлыклы «Зөләйха» драмасының кулъязмасын сакларга биреп калдырды. Һәм шул ук кичне кулга алынып, янә элек утырган төрмәгә – Архангел губернасына җибәрелде. Петербургта качып-посып яшәсә дә, ул әледән-әле студент яшьләр белән очрашкалап торды. Ни гаҗәп, әдип беренче очрашуда ук Гөлсемне танып алды һәм үзенең игътибар үзәгеннән җибәрмәде. Джоконда исеме дә Гөлсемгә аның аркасында ябышып калды. Әмма бу исемне аңа бүләк итүче башка берәү иде. Әлеге вакыйганың тарихы болай: 1911 елның ноябрь башында Гөлсем укыган институтка курсисткалар белән очрашуга бер төркем шагыйрьләр чакырыла. Алар арасында бердәнбер хатын-кыз шагыйрә Анна Ахматова да була. Институт белән танышып йөргәндә, кунаклар баскыч янында серле елмаюга төренеп берьялгызы басып торган зифа буйлы кызга игътибар итми калмыйлар.

– Бу кызыгыз Джоконданы хәтерләтә. Итальян кызы түгелдер бит? – дип сорый Анна Ахматова.

– Юк, юк, – ди кунакларны озатып йөрүче олы яшьтәге мөлаем ханым. – Ул – мөселман кызы. Эмма, якынрак кил әле. Кунаклар синең белән танышырга тели, – дип, кызны үзләре янына чакырып ала.

– Мин – Чистайдан. Кама елгасы ярындагы иң гүзәл шәһәрләрнең берсеннән. Татар кызымын.

– Сез бик тә Джокондага охшагансыз. Аның хакында ишеткәнегез бармы? – ди Ахматова, әңгәмәне дәвам итеп.

– Ул бөек Леонардо да Винчиның иң данлыклы портретларыннан берсе дип беләм. Әлеге портрет Парижда, Луврда саклана, – дип җавап бирә Гөлсем, аз гына да икеләнмичә. – ...Сез үзегез дә безнең татарның затлы кенәз кызларын хәтерләтәсез. Без әле сезнең белән, бәлки, ерак кардәшләрдәдер?

– Бәлки, – дип көлемсерәп баш кага шагыйрә.

Аның янәшәсендә басып торучы чибәр йөз-кыяфәтле ир кеше түзми, сүзгә кушылып:

– Сез, чынлап та, бер-берегезгә нык охшагансыз, – ди. (Бу кешенең бөек рус шагыйре Александр Блок икәнлеген Гөлсем очрашуга кергәч кенә белә.) Ахматова исә, нәни генә ридикюленнән кәгазь алып, нидер яза да кызга суза:

– Бу минем күптән түгел генә язган шигырем. Сиңа истәлеккә бүләк итәм.

Мондый бүләкне Гөлсем ничек Гаяз Исхакыйга күрсәтмичә калсын ди инде? Шагыйрәнең «Белой ночью» дип исемләнгән шигыре астына язылган сүзләре ни тора! Ахматова аңа: «Моей тысячаюродной сестре – Джоконде с любовью», – дип язып куйган.

– Шагыйрә генә түгел синең бу танышың. Ул күрәзәчегә охшаган. Хәтта аңарда пәйгамбәрлек тә бар кебек, – ди Гаяз Исхакый, шигырьне укыгач. (Хак сүзләр болар. Заманының бөек шагыйрәсе булып танылачак Анна Ахматова үзенең үтә катлаулы язмышында күрәчәк кайгы-хәсрәтләрне шигырьләрендә алдан әйтә торган булган.)

Их, нинди күңелле чаклар булган икән Петербургта Гаяз Исхакый белән

очрашкан мәлләр! Әдип Гөлсемнең аерым бер ләззәтләнү белән Тукай шигырьләрен укуын ярата. Кызның үзенә дә шигырьләр язып карарга киңәш итә. Чыннан да, шигырь, шигъри сүз дигәндә, Гөлсемнең җаны фида. Тыштан ут кебек Чистай кызының күңел шәрәфе үзе бер шигъри садәлектән, нәфис моңнан һәм шигъри ташкын куәтеннән тора кебек. Шуңадырмы, Гаяз Исхакыйга адреслап төрмәгә юллаган хатларын Гөлсем һәрчак шигъри юллар белән язарга тырыша[14].

Әдипнең үзенә бер иркә игътибарын өнәп бетермәүче дус кызларына ул һәрдаим: «Гаяз абзый – абыемның якын дусты. Ә аның сеңелләре – Фәридәбану, Хәлимәбанулар – минем дусларым», – дип аңлатырга тырышып караса да, кызлар беравыздан: «Күрмисеңмени, гашыйк бит ул сиңа», – дип, Гөлсемнең авызын тиз томалыйлар иде. Андый чакларда ул гаҗизлектән ни дияргә дә белми. Аларны моның өчен гаеппләп тә булмый. Алар бит Гөлсем шикелле абыйсы Ибраһим, Фатих Әмирхан, Гаяз Исхакый кебек татарның асыл затлары белән аралашып үсмәгәннәр. Гаяз абзый аның өчен барыннан да бигрәк рухи остаз. Ә Гөлсем – әдип күрергә теләгән яңа заман татар кызы. Шулай гынамы? Әлеге сорауны Гөлсем үз-үзенә гомеренең азагынача бирер. Исхакыйга карата булган соклану, горурлану хисләрен кая куясың? Күңелнең кайсыдыр яшерен почмагында яши ләбаса алар.

Әле кайчан гына Петербургның чатнама суык төнендә ахирәте Мәрьям белән, извозчикларны алыштыра-алыштыра, әдипнең «Зөләйха» трагедиясенең кульъязмасын яшерергә йөргәннәр иде. Ул кичне шәһәрнең әдәбият сөючеләре, студент яшьләре генерал шәйх Галиның хатыны Мәктүм ханымның өенә язучының «Зөләйха» трагедиясен тыңларга җыелдылар. Әдипне күз яшьләрсез генә тыңлау мөмкин түгел иде. Тетрәндергеч әсәр. Менә нинди бөек талант иясе икән аларның Гаяз абыйлары.

– Йөрәгемнең кайсыдыр җепселе өзелгәндәй булды, – диде Мәрьям, кайтырга кузгалгач. – Мин хәзер бернәрсәгә дә гамьсез карый алмамдыр... Кызның битләреннән юл-юл булып аккан күз яшьләрен сөртеп, Гөлсем дустын юатырга тотынды. Ул арада аларны Гаяз абыйлары куып җитте.

– Менә нәрсә, Джоконда, мин сезгә «Зөләйха»ның кульъязмасын сакларга калдырам. Бу – аның бердәнбер нөсхәсе. Ишетәсезме? Бердәнбер... Соңгы көннәрдә арттан йөрүче шымчылар күбәйде, – диде дә, кулындагы төргәген Гөлсемгә сузып, ашыгып китеп тә барды. Шунысы көн кебек ачык: бу «йөк» белән хәзер фатирга кайтырга ярамый. Бәлки, Әсма апаларына? Алла сакласын! Кая барырга? Сиңа кирәк чакта извозчиклары да күренми бит әле аның. Шулай да төнге сәгать бер тулганда каяндыр бер извозчик килеп чыкты. Ә төнге өчтә алар Бестужев курсларында югары алгебра укытучы Екатерина Лебедева-Миллер ишеген шакыдылар. Суыктан туңып кызарган укучыларын күргәч, галимә ни дияргә дә белми торды. Берәр бәлагә тарыганнармы, Ходаем. Баксаң, кызлар «татар Шекспиры»ның кульъязмасын коткарырга йөриләр икән. Авторына төрмә яный. Екатерина Викторовна кызларны йокларга үзендә калдыра. Ә иртән: «Борчылмагыз, кульъязма миндә сакланыр», – ди.

Исхакый дөрес сизенгән икән. Аны шул көнне үк фатирына кайтып барганда кулга алалар. Янә элек утырган төрмәгә, Архангел губернасына озаталар. Төрмәдә әдип «Бер токарның саташуы» дигән яңа әсәрен яза. Истәлекләрендә ул аны үзенең «бөек әсәре» дип атый. Әсәрдә «Зөләйха» пьесасының кульъязмасын саклап калучы курсисткалар – Гөлсем Камалова

[14] Казан жандарм идарәсендәге тәрҗемәче аларны рус теленә тәрҗемә иткәндә, «мәхәббәт хатлары», дип кенә бәяли (Рәхимов С. Архив документлары // Шәхесләребез. Гаяз Исхакый. – «Җыен» нәшр., 2011. – 579 б.).

белән Мәрьям Бигиеваларның батырлыкка тиң изге гамәлләрен аерым бер рәхмәт хисләре белән сурәтли.

...Әле дә шөкер, Исхакыйлар, Бигилар, Акчуралар, Кәримиләр кебек асыл затлар бар. Әнә шәфкать туташларыбыз Истанбулга килгән көннән бу дөньяга Фатих абыйлары күзе белән карыйлар. Юкса, бу кадәр хөрмәт күреп, менә хәзергедәй, борынгы каланың меңәр еллык тарихи урыннарын, данлыклы мәчетләрен, күптөрле диннәр, мәдәният тормышын эченә алган мең төрле төсләрдән, мең төрле авазлардан торган хәятен манзара кылып йөри алырлар идемени?!

Тарихта гел гыйбрәт. Византия кебек шөһрәтле ил-дәүләтләр дә, халыклар да юкка чыккан. Чакрымнарга сузылган таш хәрабәләр уйлата.

Тукай да әнә, «Шүрәле»се булып, «Балкан көйләре»ндә шуларны искәртеп «кытыклап» китә:

Артык шаулыйсыз,
Бик күп даулыйсыз.
Нигә тарихтан
Гыйбрәт алмыйсыз?

...Вакыт инде сизелеп язга авышып бара. Истанбулга килүләренә дүрт ай дигәндә, кызларның юлында тагын «Хозыр Ильяс» күренде. Бу сөенечле хәбәрне ишетүгә, кызлар дәррәү Фатих абыйларына сарылып, чак аягыннан екмадылар. Кайтырга вакыт җиткән! Ниһаять, өйгә! Лондонда Балкан сугышында катнашучы илләр арасында килешү Солыхы әзерләнеп ята. Сугыш тукталырга тора. Төркия өчен ул зур югалтулар белән тәмамланачак. Төркия бу сугышта үзенең Европадагы биләмәләреннән колак кагачак. Төрекләргә хәзер Истанбулны саклап кала алулары зур могҗиза булып тоелачак.

Ә иртәгә, җомга көн Фатих абыйлары аларны «Сәламлык»ка алып барырга рөхсәт алган.

Шәфкать туташларыбызга анда да иң олы хөрмәт күрсәтелә. Аларны Солтан мәчеткә кереп китә торган ишек янына ук урнаштыралар. Фаэтоннан төшеп, болдырга басуга, Солтан иң элек кызларны сәламли. Янәдән, махсус хезмәтчесе чыгып, аларга телдән, Солтанның сәламен, рәхмәтләрен тапшыра. Садр әгъзам (баш вәзир, премьер-министр) Мәхмүд Шәүкәт паша һәммәсе белән кул биреп күрешә: «Мөселман хатын-кызларының зур калебле, галиҗәнап икәнлекләрен сез гамәлдә күрсәттегез», – дип, олы рәхмәтләрен белдерә.

Әнвәр паша белән очрашу мизгелләре, җыйнаулашып фотосурәткә төшүләр дә, аның әйткән тәэсирле сүзләре дә һәм тагын әллә никадәр шундый очрашулар күңел сандыгына салына.

Шәфкать туташлары өчен хушлашуның иң авыры – яралылар белән саубуллашу. – Китү хәбәрен ишеткәч, алар балаларча еладылар да, игелекле хезмәт итеп, исән-имин туган җиргә кайту форсаты өчен ихлас сөенделәр дә. Ә кызларның җаннары-тәннәре чымырдады. Алар бу көнне мәңгегә дә онытмаслар. Әнә, ап-ак киемнәренә йөрәкләреннән кан саркыган, канатлары көйгән йөзләрчә «сакчы фәрештә» тәрәзәгә «кунган».

Фатих абыйларына да Истанбул белән хушлашу җиңел түгел. Бу килүендә ул атасы кебек газиз, иң игелекле, иң олы остазы Әхмәт Мидхәтне җирләп калдыра.

Әйтүе генә ансат, күп зыялылар өчен икенче Ватан булган Төркиянең җиңү-җиңелүләрен дә, хәсрәт-борчуларын да, үткәнен һәм киләчәген дә «Истанбул мәктүпләре» итеп, ничә айлар дәвамында йөрәгенә язып алып китә.

...Китүче мосафирларны Мәрмәрә дулкыннары озата чыга, ә Кара диңгез тагын колачын җәеп каршы ала. Яралы йөрәкләрне яз сулышы, дәррәү ачылып килүче бөреләрнең бииһая татлы хуш исе иркәли. Еракта, яр буенда әллә ничә айлы манара сәлам биреп кала. Шәһәр өстендә илаһи азан моңы, ә җаннарда аерылышу сагышы, кайту куанычы тибрәлә. Күңел тула...

## Аерылабыз, ахрысы...

*Ни була тугъмак сыйратын кичмәсәм,*
*Бу ачы гомрем шәрабен эчмәсәм?!*
«Читен әле». Г.Тукай

Балкан сугышында Төркиягә теләктәшлек белдереп, Истанбулга бер айга яралыларны карарга килгән шәфкать туташлары, дүрт ай дигәндә, ниһаять, Русия башкаласына әйләнеп кайттылар. Петербургта да яз. Әмма кояш әлегә биредә йөзен чытып кына елмая. Нева ярыннан, гадәттәгечә, ачы җил исә. Шәһәрне бик еш кар болытлары томалап куя.

Туташлар үзләренә бер горурлык, дәрт, уй-хыяллар белән кайтсалар да, аларны, ата-аналарыннан, туганнарыннан кала берәү дә өзелеп көтеп тормый икән. Кызлар көн-төн укып, имтиханнарны экстерн рәвештә бирү теләге белән янсалар да, уку йортларында аларны ишетергә дә теләмәделәр. Киләсе елга, уку елы башыннан...

Кызлар, алай да, март ахырларына кадәр үҗәтләнеп, үзлекләреннән баш күтәрми укыдылар. Тик, имтиханга әзерлекләрен белдереп, институтларына тагын бер мәртәбә барып карасалар да, нәтиҗәсе булмады. Өч туташ, эчтән сөенеп, туган якларына кайтып китәргә җыенды. Арылган, сагынылган. Биредә күңелләргә җан җылысы җитми. Фатих абыйларының юклыгы да нык сиздерә. Нинди зур терәк, киңәшче иде ул алар өчен Истанбулда. Юлларына «Хозыр Ильяс» булып чыккан Фатих Кәримине шәфкать туташлары әле озак юксыныр һәм гомер буе рәхмәт, соклану хисләре белән искә алыр.

Ә хәзер – юлга!

Тизрәк Тукайлы Казанга, тизрәк туып-үскән Чистаена!

Бу сәбәптән аңладым мин, и туган җирем, синең
Җанга ягымлы икәндер ялкының да дулкының!
Җөмләтән изге икән ич: инешең, чишмәң, кырың,
Юлларың, авыл, әвен, кибәннәрең дә ындырың...

И кадерле Тукаем, сагыну-җирсүләрне тагын кем синең кебек шулай итеп әйтә алыр?! Минем җанымдагы иң гүзәл почмак шушы бит инде.

...Тизрәк әнкәсенә, туган йортның җылысына сыенырга. Туган җирнең күкрәк тутырып язгы һавасын суларга, кушучлап «Изгеләр чишмәсе»ннән су эчәргә. Аулакта бер туйганчы еларга, бер рәхәтләнеп, кинәнеп көләргә, иркенләп Ходай Тәгаләгә барысы-барысы өчен рәхмәт укырга, дога кылырга.

Ниһаять, Казан! Ул да нәкъ Тукайча:

Әйтә иртәнге намазга бик матур, моңлы азан;
И Казан! Дәртле Казан, моңлы Казан, нурлы Казан!

Гөлсемне шагыйрь белән күрешү алгысыта. Шәһәргә якынлашкан саен, иркә тайның йөрәге поезд алдыннан чабар дәрәҗәгә җитеп ярсый, ашкына. Хәерлегә генә булсын...

Ә монда, вокзалда, Хәтимә нишләргә белми өзгәләнә. Ул алдан төшкәнгә карап кына поезд алдан килми шул.

...Ниһаять! Йә Алла! Күзенә генә күренәме, каршысына Гөлсем йөгерәме?!

– Хәтимә!

– Гөлсем, иркә таем! Аллага шөкер, исән-сау!

Елашып, кочаклашып күрештеләр. Хәтимә әле дә исе-һушы китеп, извозчик чакырырга да онытып, мөлдерәмә күзләре белән Гөлсемгә багуында.

– Карашың бигрәк тә моңсу, ул-бу булмагандыр бит. Барысы да исән-саулардыр? Тукай ничек?! Нигә бер сүз дә әйтмисең?

Хәтимәнең авыр көрсенүе тышына ук бәреп чыкты.

– Хәле шәптән түгел шул. Инде айга якын Клячкин хастаханәсендә ята.

– Син фатирыңа кайта тор, ә мин шунда йөгердем.

– Акыллым, иртәнге биштә сине кем кертсен анда. Чәйләр эчкәч, икәүләп килербез.

Кая инде ул хәзер Хәтимәне тыңлап тору. Әмма ул хаклы булган. Хастаханә ишеген ачтыру җиңел эш түгел иде. Сукранып ишек ачучы олы гәүдәле, яртылаш йокымсыраган марҗа шактый акча төрткәч кенә, йомшап, аны кизү торучы шәфкать туташы янына алып килде.

Анысы ишетергә дә теләмәде.

– Күреп торасыз, мин үзем дә шәфкать туташы, Ольга...

– Ольга Николаевна. Ә сез элегрәк кайда идегез соң?

– Төркиядә. Сугыш кырында. Яралы солдатларны карадык.

– Чынлапмы?

– Әйе, чынлап. Ольга, хөрмәтлем, зинһар, рөхсәт итегез, мин әле поездан гына төштем, ул – минем өчен бик-бик кадерле кеше.

– Кызык сез татарлар. Кергән берегез, шагыйрьне иң якын, иң кадерле кешебез, туганыбыз, ди. Шаккатам, шулай кадерле булгач, нигә аны «Печән базары»на алып килеп сатканнар соң?! Нигә алданрак дәвалау юлларын эзләмәгәннәр. Нинди яшь килеш китеп бара...

Гөлсем, тагын да илтифатлырак булырга тырышып: «Ольга Николаевна, хөрмәтлем, үтенәм сездән», – дип, йомшак кына кулын тоткан атлы булып, мәрҗән кашлы алтын йөзеген кидереп тә өлгерде.

Бу минутларда ишек янында торучы «мәхәббәт сакчысы» да Гөлсемгә хәерхаһ иде. Ни дисәң дә, Гөлсем, Тукай фаразлаганча, «ак фәрештә». Ә фәрештәләрнең «үз теле». Ул хәтта кызның тапкырлыгыннан, үҗәтлегеннән елмаеп та куйды кебек. Кизү торучы шәфкать туташы да авыз чите белән генә көлемсерәгәндәй итте дә Гөлсемне кирәкле палатага алып китте[15]. Һәм пышылдап кына, Тукай янында утыручы яшь бер ир-атның чыгып торуын үтенде. Тегесе сүзсез генә ишеккә юнәлде. Ак халат белән ак башлык кигән Гөлсемгә әллә ни игътибар да итмәде бугай. Тукай биек ак мендәр өстендә күзләрен йомган килеш ята. Йоклаганга охшамый. Гөлсем аяк очларына гына басып, ятакка якынрак килде.

Карават башында элеп куелган кәгазьгә күзе төшеп, йөрәге жу-у итте.

«И мөкаддәс моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнәмен, аерылабыз, ахрысы!..»

[15] 1993 ел. Гөлсем Камалованың якын дусты Мәрьям Бигиевага Тукайның соңгы сәгатьләре тасвирланган хатын Петербург татарлары турында зур хезмәтләр авторы, күренекле галим Дауд Әминовка тапшыралар. Д.Әминовның вафатыннан соң, аның хатыны Мәдинә ханым Әминова ул хатны, гарәп телендә язылган, дип, үз куллары белән Көнчыгыш телләре галиме Әнәс Бакый улы Халидевкә (1929-2001) илтеп бирә.

Тукайның үз кулы белән язылган һәр юлыннан, һәр хәрефеннән моң, сагыш сарка. Утлар-сулар кичеп, үлем белән күзгә-күз очрашкан каһарман туташ бер мәлгә, гүя, бу дөньядан юк булып торды.

– Нигә Тукай, нигә башка берәү түгел?.. Тукай...

Кыз, аеруча бер саклык белән, кулын шагыйрьнең маңгаена куймыйча булдыра алмады. Әйтерсең, Гөлсемнең үзен ут алды. Шагыйрь бик югары температура белән ята, дөресрәге, яна иде. Менә Тукай шактый авырлык белән күзләрен ачты. Каршысындагы «ак фәрештә»не таныгач, сискәнеп киткәндәй булды.

– Син?!

– Мин, Тукай...

Кыз ридикюленнән нәфис кулъяулыгын алып, юешләтеп, шагыйрьнең маңгаена куйды. Аннары иелә төшеп, балаларныкы кебек кеп-кечкенә калган кулларын әле бер як битенә, әле икенчесенә куеп торды. Кызның ихтыярсыз тамган күз яшьләре шагыйрьне тагын телгә китерде.

– Петербургтан киткәндә, син мине озатырга килмәгән идең. Ә бу юлы ерак диңгезләр кичә-кичә кайтып җиткәнсең... Күргәнеңчә, минем поезд инде кузгалырга тора. Урыным азаккы вагонда... Хуш...

– Хуш, Тукай... Син минем күңел күгендәге якты кояшым, нурлы аем булдың. Ишетәсеңме мине?!

Ул ишетә һәм артыгы белән аңлый иде. Әмма кайтарып бер сүз дә әйтмәде. Тик җаныннан гына: «Әйе, син бу дөньяда миңа соңгы сөю фәрештәсе булып, хушлашырга килдең», – дигән якты бер уй сызылып узды...

...И-их, ул үзе эчтән генә гөман иткәнчә, сау-сәламәт булып, гомере дә озынрак булса, билгеле, бер гүзәлнең кайнар кочагында биһуш яши дә алыр иде... Ләкин аны язмыш тулысы белән милләтнеке итте. Шагыйрь өчен милләтенең гасырлар дәвамында сөюе, сөекле итүе күпкә кадерлерәк иде.

Гөлсемгә бирелгән вакыт чыкты. Ике шәфкать туташы да бу юлы «ым» белән генә сөйләшүгә күчте.

Ольга Николаевна, Гөлсемнең халәтен, тыелгысыз аккан күз яшьләрен күреп: «Чыннан да, бик кадерле, яраткан кешесе икән», – дигән фикергә килде. Хәтта йөзеген дә кире кайтармакчы иде. Гөлсем, кулын йөрәгенә куеп, башын ия төшеп, рәхмәт белән ихластан бирелгәнен аңлатты. Һәм шагыйрьнең соңгы сурәтен гомерлеккә күңеленә яшереп, ишеккә юнәлде.

– Һай, соңладым, соңладым шул, – диде Гөлсем үз алдына, үзен битәрләп.

– Шөкер, өлгердем, диген, – дип пышылдады кемнеңдер йомшак тавышы.

Гөлсем эсселе-суыклы булып китте. Янында беркем дә юк түгелме соң?..

Гөлсем көч-хәл белән Хәтимә янына кайтып «егылды». Аның да бөтен эче-тышы яна иде.

...Сызланып кына таң атты. Тукай бераз йоклап та алды кебек. Күзләрен ачканда, аның янында Шиһап Әхмәров белән Әхмәт Урманчиев утыра иде. Аларның эче еласа да, тышка чыгармаска тырыштылар. Тукайның бу кадәр сабырлыгына аларның исләре китә иде. Хикмәт, әле дә карашында илаһи бер нур, горур олпатлык.

– Тукайҗан, шөкер, бүген кәефең бөтенләй яхшырганга охшап тора.

– Әгәр дә чәй эчкәч, сине фотога төшерсәк, каршы килмәссеңме?

– Ә нигә, соңгы стансада, соңгы ядкәр итеп төшерергә дә мөмкин.

– Син Газраилнең: «Тукай кадәр Тукай янына килергә җөрьәт итмим», – дип китеп барганын ишетмәдеңмени әле?

– «Кирәк черсен, кирәк түзсен – ни ул тән? Чыдамсыз бер кием ул җанны өркеткән!»

– Беләбез, сиңа «курку белән өркү харам».

– Минем һәр минутым дөнья бәһасе торганын да беләсез...

– Беләбез!

– Менә мендәреңне биегрәк күтәрик әле, үзең ятканча, кулларыңны баш артына куйсаң ничек булыр?

– Чын булыр.

– Берсен утырган килеш төшерәбезме әллә?

Өчиледән Рабига апасы биреп җибәргән каз мамыклы йомшак мендәрне бу юлы аркасына терәп куйдылар. Тукай ике куллап тезләрен кочаклады. Тыны кысылып китте, ахрысы, чак кына авызын ача төште. Каядыр төбәлгән зур моңсу күзләрендә сизелер-сизелмәс кенә уйчан елмаю хасил булды...

Тукта, Мизгел, син Мәңгелек!

Әмма әлегә бу гаҗәеп кадерле Мизгел белән илаһи Мәңгелек арасында, соң көченә егерме җиде еллык гомерне иңләп, ахыргы егерме җиде сәгать ярсып чаба...

Соңгы минутында аңа тагын «кара төннең ак фәрештәсе» иңәр. Тукай аның үҗәтлегенә, самимилегенә тагын бер кат гаҗәпләнеп, сокланып елмаер.

– Син?

– Мин, Тукай...

Һәм йөзендәге шушы соңгы елмаю белән шагыйрь олуг Газраил фәрештәне каршылар. Вәгъдә иткәнчә, җавап тотып, әкрен генә моңлы итеп көйләр:

Җырлый-җырлый үләрмен мин үлгәндә дә,
Дәшми калмам Газраилне күргәндә дә;
«Без китәрбез, сез каласыз!» – дип җырлармын,
Җәсәдемне туфрак берлә күмгәндә дә.

Газраил фәрештә үзе дә ихластан моңаеп, шагыйрьне тыңлап бетерер. Аннан соң гына, аеруча бер илтифат вә йомшаклык берлән, хәзрәти Тукайның «күңел кошын» Күкләргә, бөек Илаһысы тарафына очырыр...

Һәм апрель иртәсе белән үзәк өзгеч хәбәр таралыр: Тукай вафат...

Бу хәбәрдән җирләр, күкләр иңрәп куяр. Дөньяның бар сазлары ачы хәсрәт көен уйнар. Кырлай урманнары, шүрәлеләр үксер... Гөлсемнең Тукайга биниһая гашыйк җаны гынамы, Галәм йөрәге елар...

...Гөлсемне бүген Хәтимә дә, беркем дә, берни дә юата алмый. Иртәгә ничекләр итеп җирләргә барыр ул Тукаен. Ай, әҗәл авыруы кагылмаган булса, ул аны төрек кызы Айсели кебек, Чистайга алып китмәс идеме?! И-и нәрсәләр уйлый, нәрсәләр сөйли Гөлсем?! Кичәдән бирле үзе дә, йөрәге дә дер-дер калтырый. Әйтерсең, Тукайның януы да, туңуы да Гөлсемгә күчкән. Хәтимәнең аны мондый хәлдә гомергә дә күргәне юк иде. Ул, ашыга-ашыга, Чистайдан җыеп алып килгән җиде төрле үлән белән чәй пешерде, кипкән җир җиләкләре салды, юкә балы болгатты.

– И канәт, шифасы гына тия күрсен берүк. Иртәгә дә болай булсаң, мин сине беркая да чыгармыйм.

– Син ни сөйлисең? Иртәгә Тукайны соңгы юлга озатачаклар, аңлыйсыңмы син шуны?

– Аңламаган кая, бу кадәр үз-үзеңне бетерсәң, Алла сакласын... Син Истанбулда ул кадәр яралылар янында ничекләр эшләдең соң?

– Бу – Тукай. Һәммәбез өчен бердәнбер булган Тукай! Нинди чагыштыру булырга мөмкин! Без аны саклап кала алмадык.

– Тәкъдир ул, иркә таем, синең белән миннән сорап йөрми. Зинһар, тынычлан.

Гөлсемнең моңа чаклы берәүнең үлеме өчен дә бу кадәр ут йотканы, көйгәне, ачыргаланганы булмагандыр, юктыр.

– Белмим, гомере буе җылыга туймаган Тукайны иртәгә ничекләр итеп бөтенләйгә салкын җир куенына салып калдырырбыз, апам?!

– Үзең җир куены, дисең ич. Кабер суыгы ул җәен генә була. Син бераз ятып хәл җый. Мин чәчәк кибетеннән урап килим әле.

...Әйтерсең, Казан бу төндә бөтенләй керфек какмаган. Иртәдән үк урамда халык ташкыны. Ул ташкын артканнан-арта, көчәйгәннән-көчәя бара[16]. Тукай шушы халкына бит иң кыйммәтле, иң олы бәһасен үзе исән чагында ук биреп калдырган иде: «Дөресен әйткәндә, халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул!» Менә хәзер шушы зур халык, моңлы халык Аны йөрәк түренә салып, иңнәренә күтәреп, соңгы юлга озата.

...Яңа Бистәдәге татар зираты. Тукай кабере. Өстә, ак болыт сурәтенә кереп, фәрештәләр сакта тора. Җирләр – Күкләргә, Күкләр Җирләргә сәлам биреп, җавап тота:

– Җиде мулла нәселеннән булган, «садренә Иман берлә, Коръән нуры тулган» Мөхәммәтгариф улы Габдулла Тукаев хәзрәтләре Хозурыбызга кайтты. Рәхмәт берлән каршыладык.

...Халыкның югалтуы зур. Кайгысы зур. Һәркем аны үзенчә тоя, үзенчә кичерә. Гөлсемнең исә җаны үкси. Ул кабер өстенә тезгән ак чәчкәләре белән бергә инде ничәнче кат бер үк шигъри доганы кабатлый:

...Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы!

– Шунда тамсын, газиз Тукаем...

(Яңа Бистә зиратына Тукай хакына, дип, ул көнне беренче тапкыр хатын-кызларны да кертәләр.)

***

И күк! Ал җанымны, тик, зинһар, алма шөһрәтемне;  
Минемчә, онытылу, тибәрелү үлемнән яманрак.

Милләт тирән кайгы кичерә. Халык шагыйре Габдулла Тукайның вафаты турындагы үзәк өзгеч хәбәр татарлар яшәгән бар төбәкләрне, ил-кыйтгаларны урый.

Кайгы уртаклашкан тәгъзия телеграммаларның исәбе-хисабы юк. Кайлардан, кемнәр генә язмаган да, шагыйрьгә карата нинди генә асыл, һиммәтле сүзләр әйтелмәгән. Аларда халыкның чиксез яратуы, күз яшьләре белән хушлашуы, әйтеп бетергесез хәсрәте... Гөлсем атна буена бер генә газетаны да калдырмыйча укып барды. Аның ише: «Тукай!» – дип җан атучылар дөнья буйлап сибелгән икән ич!

– Соңгы көннәрдә Гөлсем өчен тәмам хафага төшкән Хәтимә сеңлесен килеп кочаклады да:

– Иркә таем, зинһар, тынычлан инде. Үлгән артыннан үлеп тә, үлгәнне терелтеп тә булмый. Дога белән генә сагыныйк. Үткән үткәндә калсын. Исәннәргә киләчәк белән яшәргә кирәк. Син бит инде акыл утырткан кыз.

– Рәхмәт сиңа! Барысы-барысы өчен дә рәхмәт! Бу көннәрдә синнән башка

[16] Нуруллин И. Тукай. – М: Изд.-во «Молодая гвардия», 1977.

нишләр идем, кая барыр идем?! Алла теләсә, таң белән юлга тәвәккәлләрмен, дим. Инде сагынуларым да хәттин ашты.

– И бала, и иркә таем...

Тагын бер кочаклашып елаштылар.

***

...Апрель. Юл өзеге. Тәкъдирләр өзеге. Чистайга кайту юллары да әлегә язмыш төсле өзек-өзек, урау-урау. Гөлсемнең Казаннан чыкканына да унике сәгать. Бу вакыт эчендә аның уена кемнәр генә килмәде дә, ниләр генә кичмәде. Хикмәт, алар бүген гел шигъри бер кимәлдә агылалар да агылалар. Бәлкем, адәм баласын башына төшкән кайгылары, күңеленә тулган сагышлары шулай шагыйрь итәдер. Әнә бит әнкәсе Бибифатыйманың да «Җыру, мөнәҗәтләр, бәетләр» дәфтәре бар. Яшереп кенә тота. «Үзәгем өзелгәндә язып куям шунда», – дияр иде. Бу юлы ничек тә сорап укыр әле ул аны.

...Ниһаять, Чистай! Әнә пароход та, бөтен ярларны яңгыратып: «Каршылагыз, килеп җитәбез» дигәндәй, сузып-сузып аваз сала.

Гөлсем бу борынгы, кадерле туган тарафның һәр күренешен күздән кичереп калырга ашыга. Әнә әткәсе Мөхәммәдзакир ишанның Хаҗдан алып кайткан алтынсу-кызыл бакыр табагы тиклем кояшның бихисап нурлары Чулмансуда чумып уйный. Кояш берара тирә-юньне шулай шәфәкъ балкышы белән камап кинәнер дә озакламый үзе дә нурлары артыннан елгага чумар.

Гөлсем хәтта бала чагындагыча кояш белән сөйләшеп алырга да өлгерде:

– Кояшым, син суда батмыйсың ич, син йөзә беләсең ич, иртәгә каршыдан тагын елмаеп чыгарсың ич?!

...Бүген Гөлсемне балачакның, яшьлекнең онытылмас хатирәләре каршылый шулай. Яр башында аны песиле таллар, тарантаслы атлар көтә. Кама буйлап тезелгән хәтер көймәләре сәламләп чайкала.

Каршында – җил, яңгыр, кар, еллар төсе сеңгән, эченә-тышына дулкын шавы тулган, китүләрнең моңсулыгын, кайтуларның шатлыгын саклаган, һәр пароход тавышына адарынып, «биеп» торган агач пристань. Түбә белән тәрәзә җекләре буйлап тезелеп киткән карлыгач оялары. Барысы да элеккечә, барысы да хәтерендәгечә.

Ниһаять, аны кайчаннан бирле тыны белән тартып алырдай булып көткән газиз әнкәсе аермачык күренә. Хәер, ак ефәк шәлен япкан мәһабәт кыяфәтле әнкәсен Гөлсем әллә кайлардан, әллә кайчан абайлап алды. Акчарлак булып, яннарыннан әллә ничә урап «очып» та килде.

...Пристань алды гөрләп тора. Әнкәсенең бер ягында җизнәсе Нәҗип хәзрәт белән апасы Камиләтенниса, аларның балалары, дус кызлары тезелгән. Зәйтүнә дә монда!

Йә Алла, ниһаять, юл өзекләрен, айларны-елларны ялгап, туган ярга басма сузыла. Тизрәк, тизрәк! Әллә – Гөлсем, әллә әнкәсе Гөлсем каршына «оча».

– Әнкәем, бәгърем...

– И татлы төпчегем, балам-җаным! Аллага шөкер, исән-сау! И-и, ул сагынуларымны, ут йотуларымны белсәң, балам. – Бибифатыйманың сабырлыгы төкәнеп, күзләреннән, йөрәгеннән кайнар яшь тама. Ләкин бу – барыбер күрешү шатлыгы.

Юл шактый арыткан. Гөлсемнең инде тизрәк әткәсенең төсе булып сакланган Юкәтау талчыбыкларыннан үрелгән кадерле тарантасына, әнкәсенең иркә кочагына кереп чумасы килә. Чөнки бу минутта аның өчен дөньяда иң зур бәхет шушы!

Тик менә уе тагын гомере буена ана назына тилмергән Тукайга тоташты.

Әйтерсең, сабый Габдулла хәзер алар янәшәсендә кар өстеннән әнкәсенең җеназасы артыннан яланаяк йөгерә һәм: «Әнкәйне кайтарыгыз, әнкәйне бирегез!» – дип илереп ялвара. Гөлсем аның саен әнкәсенә ныграк сыена төшә, аның саен Тукай өчен үзәге ныграк өзелә, җаны елый.

Бибифатыйма сизми каламы соң баласының бу үзгәлэнүләрен?!

– Әй йөрәк парәм, ниләр дип кенә юатыйм. Нишләмәк кирәк, Ходай шулай яраткан: берәүләр килә, берәүләр китә.

– Зәйтүнә бик нык үзгәргән.

– Ул бала Иж-Бубыйдан бик каты салкын тидереп, авырып кайткан, бик нык ютәлли. Мин дә баллар, үләннәр илткән идем әле. Бүген сине хаклап кына төшкәндер.

Ни аяныч, Зәйтүнә Тукай белән хушлаша алмый калды. Гөлсем Чистайга алданрак кайтып өлгергән булсамы?! Ул Зәйтүнәне, ташып аккан бозлар өстеннән җитәкләп, җәяүләп булса да, Казанга алып килеп җиткерер иде. Юкса шагыйрь Зәйтүнәсе юлына нинди мәхәббәт шигырьләрен җәеп куйган иде... Сизеп тора Гөлсем: Зәйтүнә белән кочаклашып елашасылары алда...

Ул арада алмачуар атлар бер ашкыну белән соңгы үрне менде. Инде алда атаклы Мөхәммәдзакир ишанның какшамас илаһи рухы, ул дәвернең гүзәл чагылышы, төсе булган мәчет-мәдрәсәләре, туган йортлары балкып күренде. Чистайның фирүзә күгеннән айлы манараларга елышып кына яңа туган көмеш ай, йөзьяшәр тупыллар арасыннан качып кына йолдызлар карады. Һәм аларга бүген «ак фәрештә»нең дә ак нурлары, серләре өстәлде.

...Иртәгесен Чулмансудан янә кояш күтәрелер, таңга чаклы чалкан ятып ай йөзәр. Апрель – майга, май – җәйләргә, айлар елларга тоташыр. Һәм алар шәфкать туташына аерата шәфкать белән килер.

## Чистай кызлары

*Иел, и халкы дөнья! Уртадан юл бир хатыннарга!*
*Яшә, и галәме өнса! Вакыт хакларны аңларга!*

*...Укы, яз, бел, тырыш син, и мөкаддәс яртыбыз безнең!*
*Кеше булмак өчен иң беренче шартыбыз безнең!*

Г.Тукай

Гөлсемнең бу юлы Чистайга кайтуы үзе зур бер вакыйгага әйләнде. Атна-ун көн йортларыннан туган-тумача, дус-иш, күрше-күлән, таныш-белеш өзелеп тормады. Көн дә төрле мич ашлары пеште. Мөхәммәдзакир ишанның Мәкәрҗәдән алып кайткан, җырлый-җырлый чәй эчергән зур самовары өстәлдән төшмәде. Килгән-киткән ихласлык белән бер үк сүзләрне кабатлады: «Җиде яшәр юлдан кайтса, җитмеш яшәр күрешә килер». Барысының да Төркия дигән кардәш илдәге сугыш хәлләрен шәфкать туташының үз авызыннан ишетәсе килде.

Бу атнакичтә кунакларның аеруча якыннары, могтәбәрләре көтелде. Гадәтенчә, иң элек Гыйльмениса абыстай килеп җитте. Аягында каюлы читек, күкрәкчәләп тегелгән киң итәкле юка йон күлмәк. Укалы камзулы, башындагы озын чуклы ак ефәк шәле, куш беләзекләре аны гаять күркәм күрсәтә. Өстәвенә, кулы да, тыны да шифалы булып, Бибифатыйма кебек бик якыннарына догалыклар язып, фал китабын да төреп килә. Үзе дә нур чәчеп торган остабикә каршында Бибифатыйма да кояш төсле балкый. Аллага шөкер, әнә ич Гөлсемгә юраганнары ничек рас килде. Баласы исән-имин йөреп, игелекле гамәлләр кылып, ил-көн алдында абруй казанып, каһарманнар рәтендә кайтты.

Менә һәммәсе, керә-керешкә үк, бер кат шушы шатлыкларны уртаклашып, күгәрчен күк гөрләп алды. Һәркем бу вакыйгалар нисбәтеннән сөаль-сорауларын бирергә ашыкты. Сүз арасында, Бибифатыйма шушы көнгә дип сакланган тозлы каз итеннән пешергән, авыз суларын китереп торган кайнар бәлешен бүлде. Апасы Камиләтенниса үзенең затлы, каклы катламасын өлешләде. Самовар өстендә аламалы зур чәйнектә Гыйльмениса абыстай хасиятләп киптергән гөлҗимеш, каен, җир җиләкләре, сары мәтрүшкәләрдән торган хуш исле «Чистай чәе» төнәп утырды. Гөлсем, шуларны мактый-мактый, кыстый-кыстый, чәй ясады, алай гынамы соң, үзенә күрә бер имтихан тотты.

Үз гомерендә күпне күргән олы буын әнкә-әбекәйләре сугыш гарасатын үз йөрәкләре аша үткәреп, тамактан калып тыңладылар.

– И-и Өммегөлсем бәбкәм, өрекмиенчә, ничекләр бундыен юлга тәвәккәлләдең? Ут эченә барганың ич!

– Инде үзеңне Алла саклаган, диң.

– Изге ният белән йөргәнгә саклаган ул, йаннарым.

– Шулайдыр, чибәр җиңгә, шулайдыр.

– Карале, Фатихны «безләр өчен юлыбызда Хозыр Ильяс булды», дисең, булгандыр да.

– И карт җиңги, яңлыш сүләмисеңме соң?

– Ниткән яңлыш булсын, Сәгыйдә? Ул бала бунда унбер еллап укыды ич. Шул заман кемлеге билгеле ие. Ризаэддин нәселе. Бәгъзан, безгә дә чыбык очы туган. Бак, мин бәйләп биргән бариганы[17] һәнүз онытмаган, ди.

– Олан, Төркиядә татарлар күп, диярең. Анлар мөһаҗирләрдер инде, бәгырьләрем?

– Син әйт: аңларның һәркаюсы олылап озатырга килгән, диң!

– И-и Нурбикәттәй, ишеттеңме, анлар бик егълашып калдылар, ди.

– Әй йаннарым...

– Гөлсем, бәбкәм, бәнем януларым үзеңә мәгълүм. Гаяз абзаңның хәбәр-хәтерен ишетмәдеңме, Төркиядә очратмадыңмы, дим, йөрәк маем. Яуширмә тиңентен йирләрдән былчырак ерып килүләрем әлеге дә баягы шул Мөхәммәтгаяз абзаң өчен инде.

Гөлсем Гаяз абзыйсы белән бәйле күп серләрне сөйли алмаса да, олы тутасының күңеленә ял булырлыкларын табып, үтә дә бер җылылык белән тасвирлады. Тагын бик күп асыл исемнәр телгә алынып, дөньяларга иминлек, бу йортка сәгадәтле тормыш теләп догалар кылынды, рәхмәтләр укылды.

Менә шулай сәгатьләр буе бәйнә-бәйнә сөйли, сөйләшә торгач, күпне күргән, күпне ишеткән җиз самовар да берзаман тынып калды. Хәл-әхвәл белергә килүчеләр дә, Гөлсемгә ияреп дөньялар гизеп, үзләренең олуг эшләреннән мәмнүн булып, хушлашып китәргә җыендылар.

Гөлсем, аларның иңнәреннән сөя-сөя рәхмәтләр әйтеп, озата чыкты. Алар шушы борынгы җирләрдә туып, шушында яшәп, оя корганнар, балалар үстергәннәр, төрлечә гыйлем эстәгәннәр. Кайчандыр, әнкәсе кебек, өязнең яшь, чибәр, сылу кызлары булганнар. Инде менә гомерләренең көзләренә, кышларына кереп барган Чистайның шушы чиста, садә җанлы, беркатлы тута-җиңгәләренә, апа-әбиләренә карап, күңеле тулып, ямансулап калды. Шулай әлегәчә шау чәчәктә утырган куш шомырт агачына сөялеп, аклыгына хәйран булып торганда, янында Гыйльмениса абыстайны күреп, әллә нигә уңайсызланып калды.

[17] Барига *(диал.)* – бияләй.

– Олан, сагышланма, күңел күзем сине шушылай ак чәчәктә күрә. Ай башы белән үзеңне ак юл көтә. Язмышыңның алтын капкалары ачылырга тора, – дип, Гөлсемне әллә күктән җиргә төшереп, әллә җирдән күккә күтәреп, бер дигәнче китеп тә барды.

Гөлсем, кичен йокларга яткач та, озак кына шул серле сүзләр, талгын уйлар таганында атынды. Төшендә ул балачакка кайтты, иң рәхәт балачакка.

...Әле иртә. Өйдәгеләр иртәнге чәйгә әзерләнәләр. Гөлсем тиз-тиз киенеп, урамга ашыга. Тышта тын гына көзге яфраклар коела. Гөлсем шуларны күзли-күзли, эчке бер сөенеч белән дустын көтеп тора. Ибраһим абыйсы, сеңелләре белән бергә, Чистай мәдрәсәләренең попечителе, сәүдәгәр Мортаза Ваһаповның да кызын укырга чакырган. Дусларның инде берничә ай күрешкәннәре юк. Әнә, ниһаять, каршысына ашыгып-ашыгып Фатыймаи-Фәридә атлый. Йөзендә искиткеч якты, ягымлы елмаю. Гөлсем үзе дә елмая һәм шундый хозур бер халәттә уянып китә.

Әле иртә. Төн чак кына таңга авышып килә. Гөлсемнең башында, төшнең дәвамы булып, сокланулы уйлар тантана итә. Аны тора-тора сокландырганы, гаҗәпләндергәне – Чистай кызлары. Аларның аерым бер үҗәтлек белән гыйлем үрләре яулавы. Бервакыт Гөлсем Гаяз абыйсының: «Һәрбер кыз ничек кенә булса да укып, мөгаллимлек дәрәҗәсенә ирешүне идеал итә», – дигән сүзләрен ишетеп калган иде. Әүлия сүзләре!

Чыннан да, Чистайда ул елларда кайсы кыз бала мөгаллимә булырга хыялланмады икән! Ирекkә, гыйлемгә сусау иде бугай ул. Әле нинди сусау! Бу хакыйкатьне аңлату өчен исеме бөтен татар дөньясына танылган Чистай кызы Фатыймаи-Фәридә исемен атау да җитәдер, мөгаен.

Киң карашлы Мортаза әфәнде үзенең бердәнбер «энҗе бөртегенә», яраткан иркә кызына гыйлем бирү нисбәтеннән барын да эшләргә тырышкан. Ә менә җаны белән һәрчак яңалыкка омтылган кызның күңеленә иң хуш килгәне – Гөлсемнең Ибраһим абыйсы укыткан мәктәп! Ибраһим Камалов әүвәле этисе Мөхәммәдзакир мәдрәсәсендә, аның вафатыннан соң, Истанбул һәм Каһирәдә белем алып кайткач, үзенең биш сеңлесен үзе танышкан алымнар белән укыта башлаган. Программалар төзеп, махсус дәресханә җиһазлаган.

«...Иртә белән әзерләндереп, сабакка озаттылар. Шул вакыт миндәге шатлык сөйләп бетерерлек түгел иде. Һәм куркып, һәм шатланып бардым. Ибраһим әфәнде кайтып сөйләгән булырга кирәк, дустым Өммегөлсем көтеп тора иде. ...шатланып күрештек»[18].

Хәзер алар җидәү. Фатыймаи-Фәридә Гөлсем белән бер партада утыралар. (Бирелә Мәрвәрит һәм Илһамия Туктаровалар да белем алган.) «Еллык имтихан булды. Яхшы имтихан биреп, чәчәкле шаһәдәтнамәләр алдык», – дип, тагын көндәлегенә язып куяр морадына ирешкән кыз.

Әмма Ибраһим абзыйлары Мәккәи-Мәдинәгә китеп торганда, этисе аны тагын укырга Казанга илтер. Кызын сагынып, тагын кире барып алыр. Фатыймаи-Фәридә дә дуслары белән дәмеллага сабакка йөрер һәм көндәлегенә болай дип теркәр: «1903 елда мин дәмелладан укый башладым. Тагын бәхетле идем. Әлләниләр булган төсле шатланып йөри идем. Укыган дәресләребез: әнмүзәҗ (гарәп теле синтаксисы), тарих, җәгърафия, шифаһия (телдән сөйләү, әдәбият).

Бу кышны бик рәхәт укыдым. Ибраһим абзый Мәдинәдән «Ибн һәм Һибн» исемле китап җибәргән иде. Соңга таба шуны укый башладык. Бу вакытлар бик хозур үтте. Кашки һәм лә гомер (әгәр бөтен гомер) шулай бәхетле узса иде!»

[18] Мәхмүтова А. Милләт аналары. – Казан: «Җыен» нәшр., 2012.

1904 елның март башында Мәдинәдән Ибраһим әфәнде кайткан һәм, XX гасыр башы татар зыялыларының максат-омтылышларына туры китереп, сеңелләрен яңадан үзе укытырга булган.

«Беркөнне дустым язу җибәреп, икенче көн дәрес башлаячакларын белгертте. Язуны әтигә күрсәттем, укырга рөхсәт бирде. Аһ! Бу вакытлар никадәр кыйммәтле, әтием миңа бөтен дөньяны биргән шикелле шатландым... Әллә күктән, әллә җирдән барам... Дәрес башладык. Ибраһим абзый бик иҗтиһат белән укытачак. Русча да укыттырачак».

Ибраһим Камалов кызларга дөньяви фәннәрдән – география, арифметика, тарих, табигать белеменнән дәресләр биргән. Төрек, гарәп, фарсы, татар телләре белән дә кызлар бик җитди шөгыльләнгәннәр. Романнар укыганнар.

Кызлар бу көндәлекләргә язылган хиссиятләр, язылмый калган эч серләре белән дә бүлешкәннәр. Алар шулай бергә дә, ялгыз калып та хыял дәрьясында йөзгәннәр. Ул хыяллар – хатын-кыз иреге хакында. Кызлар мәктәпләре ачу, үзләренең мәгърифәт үрләре яулавы, мөгаллимлек итү хакындагы хыяллар.

Инде 1903-1904 елларда ук Фатыймаи-Фәридә үз өендә башлангыч җәдит мәктәбе тибындагы мәктәп оештырып, якыннарыннан булган җиде кызны укыта башлаган. Остазы йогынтысында бик күп укыган. Татар, төрек, гарәп, фарсы, рус әдәбиятыннан торган зур китапханә булдырган. Якташы Гаяз Исхакый бу елларда татар иҗтимагый фикер үсешендә искиткеч зур роль уйнаган. «Ике йөз елдан соң инкыйраз» исемле атаклы фантастик-публицистик повесте, мөгаен, аның карашыннан читтә калмагандыр. Гаяз абзыйларының абруйлы исеме аңа балачактан таныш. Чистайга төрле төбәкләрдән килгән яшь зыялыларның яшерен җыелышы Гаяз Исхакый җитәкчелегендә нәкъ менә алар йортында төнлә уза. Фатыймаи-Фәридә үзе дә революцион рухлы Чистай яшьләре белән аралашкан. Сәяси тоткыннарга ярдәм оештырудан да читтә калмаган.

Аннан эзәрлекләүләр башланса кирәк, 1907 елның җәендә гаилә Бөгелмә өязенең Кәрәкәшле авылына күченеп килә. Әмма дуслар арасында хәбәрләшү дәвам итә.

«21 сентябрь. Аһ! Бу көн – нинди гаҗәп көн!

...Иртә берлә дустымнан хат алдым. Хатында дустым: «Укыйм. Гимназиягә әзерләнәм», – дигән. Аңа ифрат шатландым. Ул бәхетле. Әмма үземнең укый алмау гына түгел, бер авылда бер хәбәрсез, аягы-кулы богаулы төсле ятуыма ифрат кайгырдым. Һәрвакыт «алда укырмын» хыялы белән яшим, ләкин көннән-көн алтыннан кадерле, гәүһәрдән кыйммәтле вакытларым бушка үтеп бара. Ләкин ни хәл итим?! Йа Рабби, дустыма башлаган эшен шатлык белән тәмам итәргә насыйп ит!» – дип кичерешләрен көндәлегенә дә язып куйган.

Ләкин озак та үтмәс, Фатыймаи-Фәридә башлангыч җәдит кызлар мәктәбе оештырып җибәрер. Беренче көнне биш-алты кыз килсә, ел ахырына алар җитмешкә якынлашыр. Бер ел эчендә ул дистәдән артык күрше авыл остабикәләрен һәм кызларын җәдит ысулы белән таныштырыр. Ә алар үз авылларында башлангыч мәктәпләр оештырып җибәрер.

Кәрәкәшледә Фатыймаи-Фәридә бер ел гына яши, 1908 елның җәендә зыялы, укымышлы яшьләрдән саналган Мөхәммәтвагыйз Нәүрүзов исемле кешегә кияүгә чыгып, Себергә, Томск шәһәренә китә. Милләткә хезмәт итү теләге белән янган Фатыймаи-Фәридә биредә дә кызлар мәктәбендә укыта. Шәһәрнең иҗтимагый тормышында, хәйрия чараларын оештыруда актив катнаша, күптөрле җәмгыятьләрнең әгъзасы була. Үзе кызлар гимназиясендә

имтихан тота. Төрле курсларга очрашуларга йөри. 1912 елның февраленнән Мөхәммәтвагыйз Нәүрүзов бу якларда «Сибирия» исемле беренче татар газетасы чыгара башлый. Фатыймаи-Фәридә дә мөгаллимлеген редакциядә эшләү белән бергә алып бара. Беренче саннан ук «Хатын-кыз дөньясы» дип аталган бүлек ача. Ул һәр санда чыгып бара. 145 санның 123ен чыгарганда, мөхәррирлек вазифаларын да башкарган. «Фатыймаи-Фәридә татар җәмгыятендә күренә башлаган яңа тип хатын-кызның чын үрнәге булган. Журналист, публицист хатын-кыз һәм газета өчен җаваплы булу – ул чорда моны күзаллау да кыен. Сәләтен, яшьлеген, фикер кыюлыгын, чиктән тыш эшчәнлеген, гүзәллеген, ягымлылыгын да искә алсак, аның Томск зыялылары тарафыннан танылуы да, аңа Тукайның хәйран калулары да гаять табигый.

...Гөлсем дә бүген иртәдән үк «Сибирия» газетасының май саннарын укып, дустының уңышларына, шул дәрәҗәдә тырышлыгына, талантына, кыюлыгына сокланып, сөенеп, үзе дә хыял диңгезендә йөзә.

Әмма хәзергә дустының гомере өзелергә санаулы гына айлар калып барганын башына да китерә алмый иде. 1914 елның салкын кышында газеталар җан өшеткеч хәбәр китерерләр.

«Татар хатыннарының якты йолдызы сүнде», – дип язар 19 февраль санында «Тормыш» газетасы.

Тукайны югалтудан соң, татар җәмәгатьчелеге Фатыймаи-Фәриданең үлемен зур милли фаҗига, зур югалту итеп кабул иткән. Русиянең төрле почмакларыннан кайгылы телеграммалар, хатлар яуган. Берничә санында йөзгә якын кайгынамә урнаштырган «Тормыш» газетасы укучылардан гафу үтенеп, ике йөздән артык телеграмма һәм хатны баса алмавы хакында хәбәр итәргә мәҗбүр булган. Кәрәкәшле авылында узган Фатыймаи-Фәридәне җирләү мәрасимендә тирә-күрше авыллардан мең ярымнан артык кеше катнашкан. Мәктәп-мәдрәсәләрдә дәресләр булмаган. Ялкынлы кайгы нотыклары сөйләнгән. «Фатыймаи-Фәридә ханым вафат булды. Ләкин ул үзенең батыр татар хатыны булуын ачык күрсәтеп, онытылмаслык исем калдырып китте», – диярләр. Һәм нибары чирек гасыр яшәлгән гомернең гаять кыйммәтен исбатлагандай, энҗе-энҗе кар явып торыр.

...Гөлсем исә башта бу кайгылы хәбәрне укып, үз күзләренә үзе ышанмый торыр. Аннары газетадагы портретын күкрәгенә кысып, үксеп-үксеп елар. Көндәлекләрен кат-кат укып, дуслыкларын кабат-кабат күңеленнән кичерер.

«...Килгәннән бирле бу тал миңа әллә ниләр уйлата. Чынлап та бу тал ниләр күрмәгәндер; бу йортны кемнәр салгандыр да безгә торырга туры килгән. Тагын бездән соң ниләр булыр? Шуның шикелле адәм дә үз гомерендә ниләр күрми, ниләргә очрамый. Һәммәсе дә бер төш шикелле».

Гөлсем нәкъ менә хәзер дустының җанындагы бер тоемлауны абайлар: аның өчен вакыт, гомер һәрдаим алтыннан кадерле, гәүһәрдән кыйммәт булып бәяләнер иде.

«...Алтын-энҗедән кыйммәтле вакытның бер файдасыз үтүе – минем вөҗданымны газаплый торган нәрсәләрнең беренчеседер».

«...Кечкенә вә артык бәхетле чагымда Ибраһим абзыйда укыганда, гарәп әдәбиятыннан өйрәнеп язып алган нәрсә бар кулымда. Шуны кабатлап йөри идем. Хыялга чумганнан-чумам, бер бәхетле кеше булам. Менә китапларым кайта, кызлар укытам... Бернәрсә белмәгән кызларны укырга-язарга өйрәтәм, фикерләрен ачам, аларга газеталар укыйм, үзләреннән укытам. Шулай итеп,

алар бик яхшы милләт анасы, балаларын яхшы тәрбия итә торган бер дәрәҗә мәгълүматлы кызлар булсалар, милләткә аз булса да хезмәтем тия; вөҗданым рәхәтләнә; үзләреннән мөгаллимәләр җитештерәм».

Менә ул Фатыймаи-Фәридә белән Гөлсемнең иң якты хыяллары!

Югары курсларны гына тәмамласын, ул да үз мәктәбен ачачак. Әмма кайда булыр ул, әлегә әйтүе читен. Ә менә Зәйтүнә – әзер мөгаллимәләрнең берсе. Әнә Чистайның рус гимназиясендә укучылар саны да арткан. Аларның да яңага омтылышы, фикер хөрлеге куандыра. Анда да Гөлсемнең дуслары, танышлары шактый.

Олы апасы Кәмиләтенниса белән Нәҗип җизнәсенең кызлары Зәйнәп тә рус гимназиясендә укый башлаган. Чистайда аны туганнан туган абыйсы Фатих Әмирханның йөрәк сердәшчесе, дип сөйлиләр. Бу Гөлсемне иң сөендергән хәбәр иде.

Тик кызларның марҗаларга охшатып киенүе, алар телендә русча сөйләшеп йөрүләре, рус гимназиясендә укырга омтылулары әниләре Бибифатыйманың бәгърен көйдерә. Бу хәлләрне аталары Мөхәммәдзакир ишан күрсә, нишләр иде икән? Ул мәрхүмкәй үз мәдрәсәсендә рус телен укыттырмас өчен ничек кенә көрәшмәде. Бу хакта сүз кузгалган саен, Ибраһим гына әнисен кочаклап ала да:

– Дөнья үзгәрде. Нык үзгәрде. Каршы төшмә, әни, – дип, сүзне төгәлләп куя.

Әле бүген дә бер төркем шундый кызлар киләчәк.

Озак та үтмәде, өй эче яшьлек дәртенә күмелде. Гөлсемгә сорау арты сорау яуды. Төрек кызы Айселинең мәхәббәт кыйссасын «аһ» итеп тыңладылар. Гөлсемнең хәтта драма итеп язуын үтенделәр. Ә үзләре ике пәрдәле пьеса куярга җыенып йөриләр икән. Пьесаның эчтәлеге дә бик заманча. Гимназиядә укытмас өчен, унбиш яшьлек кызларын кияүгә бирергә ашкынып йөргән ата-ананың көлкегә калуы сурәтләнә. Авторы – ундүрт яшен яңа тутырган Сания исемле кыз бала.

Сания! (Соңыннан ул Сания Гыйффәт исемле талантлы шагыйрә һәм драматург булып танылачак.) Гөлсемнең җан дусты Фатыймаи-Фәридәнең якын туганы. Сания дә Чистайда сәүдәгәр гаиләсендә туа[19]. Әмма әнисеннән бик яшьли ятим кала. Кечкенә Санияне үз чоры өчен гаять укымышлы әбисе тәрбияли. Ул сөйләгән экиятләрне, риваять-кыйссаларны, халык җырларын җанына сеңдерә барган кызның күңелендә үз шигырьләре, үз иҗаты да бик иртә бөреләнә. Күр, нинди шигырьләр, драмалар яза яшь туташ!

Әле кайчан гына соң бәләкәй Сания, Фатыймаи-Фәридәгә ияреп, Гөлсемнәргә килә иде. Янып торган кара күзләр, бөдрәләнеп торган чәчләр! Гөлсем апасы яратып, аңа тагын шомырт чәчкәләре кадап куя йә такыялар үреп кидертә. Кечкенә калай савыт тулы төрле төстәге, берсеннән-берсе тәмле конфетлар белән сыйлый. Аннары апалары аны алмаш-тилмәш таганда атындыралар. Сания хыял канатларында оча...

Алга китеп, шуларны да бәян итик: инде Фатыймаи-Фәридә кияүгә чыгып, Томскида яши башлагач, аны үз гаиләсенә алдыра. Туган апасы аның юлында иң якты маяк. Мөгаллимә булу – Саниянең дә иң мөкаддәс уе, теләге. Озакламас, Фатыймаи-Фәридә аны Бубый кызлар мәктәбенә укырга илтер. Берничә елдан ул дипломлы укытучы булыр. Аның милләт язмышын, милләт борчуларын үзәккә куйган шигырьләре «Сибирия», «Тормыш» газеталарында, «Яңа милли юл» журналында басылыр. Мәхәббәт тә озак көттермәс. Сания

[19] Гаффарова Ф. Сания Гыйффәт // «Безнең мирас» журналы. – 2016. – №11.

бик яшьли илаһият галиме, җәмәгать эшлеклесе һәм сәясәтче Закир Кадыйрига кияүгә чыгар. Аның татар милли тәрәккыятенә багышланган эшчәнлегендә ярдәмче дә, киңәшче дә булыр.

1917 елда килеп туган вазгыять аларны илдән китәргә мәҗбүр итәр. Язмыш дөнья буйлап йөртер: Кытай, Финляндия, Төркия... Сания һәрчак татар мәктәпләрендә укыту, татар вакытлы матбугатында эшләү җаен табар.

1957 елда Сания Гыйффәтнең вафаты уңае белән, Төркиянең «Төрек юрду» журналы болай дип язар: «Кечкенә генә гәүдәдә зур рух яшәткән бу шагыйрь хатынның Ерак Көнчыгыштан Финляндиягә кадәр сузылган төрки дөньяда даны, тавышы, ә карлы җиһанда яки комлы сахраларда эзе бар! Аның Казан сөйләмендә язган шигъри юлларының кайберләре әле бүген дә дога булып кабатланалар. Тумыштан нечкә күңелгә ия булган һәм бик иртә – унике яшьтән үк шигырьләр яза башлаган Сания Гыйффәт иҗатының үзенчәлеге һәм өстенлеге аның милли шагыйрь булуындадыр».

Финляндия татарлары нәкъ менә шушы милли эшчәнлегенә, милли иҗатына рәхмәт йөзеннән, Чистай кызының каберенә таш куяр.

...Туган туфрак та мөһаҗирлектә йөргән балаларын көткәндер. Җир үзе дә җирсегәндер... Сания Гыйффәт шигырьләрендәге, мөһаҗирләр йөрәгендәге милли азатлык идеясе – ул безнең дә «Антыбыз».

Күтәрелгән байрак төшмәс кулдан.
......................................................
Үз ирекле көнгә җиткәнче.

Һәм әле XXI гасырда да безнең иң изге максатыбыз!

***

Пьесаны сәхнәгә куярга йөрүче кызлар яучы ролендә Гөлсемнең дә катнашуын бик телиләр. Ни кызганыч, аларның үтенечләрен кире кагарга туры килә. Ул берсекөнгә иртән юлга җыена, Сембергә, Шәмсениса янына. Аның инде көтә-көтә түземлеге беткәндер.

– Туктагыз әле, ә сез нигә Зәйтүнәне чакырмыйсыз? – диде ул кызларга, үз тәкъдименә үзе сөенеп.

– Зәйтүнә чирли.

– Бик каты ютәлли.

Гөлсемнең тәне чымырдап куйды. Менә ни сәбәпле килми тора икән Зәйтүнә. Пристаньда күрешкәннән бирле Гөлсемнең аны күргәне юк.

Кичке якта, эңгер-меңгер төшеп килгәндә, Гөлсем Зәйтүнәне эзләп китте. Ул әнисе белән Чистайның руслар яши торган ягында фатирда тора булып чыкты. Гөлсем килеп кергәч, икесе дә аптырашта калды. Әнисе чәй көйләргә тотынды. Зәйтүнә чынлап та туктаусыз ютәлли, йөз-кыяфәте бөтенләй сулыгып калган. «Йа Хода, аңарда да Тукай чире булмагае», дигән уй Гөлсемнең миен яндырып узды. Кичекмәстән аны үзем белән Казанга алып китәргә кирәк! Алар кочаклашкан килеш озак кына басып тордылар. Зәйтүнәнең кайнар күз яшьләре Гөлсемнең җанын-тәнен куырды.

– Берсекөнгә мин сине үзем белән Казанга алып китәм. Хәтимә профессорга күрсәтер. Тизрәк дәвалау чарасын күрергә кирәк.

– Үз мәрхәмәтең меңе белән үзенә кайтсын! – дия-дия, сүзгә Зәйтүнәнең әнисе дә кушылды. Ул да елый. Язмышларның болай булуы өчен дә,

фәкыйрьлекләре өчен дә, гөлдәй кызының бу чирдән арына алмавы өчен дә көенеп елый.

– Троицкига китәргә булдык инде, таем. Зәйтүнәне дә остазы Мөхлисә абыстай чакыра. Улым Шакирның кайтуын гына көтәбез. Зәйтүнә генә терелсен, Зәйтүнә генә!

– Тереләчәк, тереләчәк...

***

Кызларны Казанга алып китүче ак пароход Чистайдан кичке алтыда кузгалып китә. Җылы июнь киченә иркәләнәсе килепме, Кама-Чулман өстендә тын гына акчарлаклар чайкала. Елга үзе дә ниндидер бер илаһи тынлыкта. Гөлсемнең шушы манзараны туйганчы күзәтәсе килсә дә, юлдашының бизгәк тоткандай калтыранып басып торуын күргәч, аны каютага алып кереп китте. Каютага керүгә, Зәйтүнә бөтенләй хәлсезләнеп ятакка ауды. Ютәле дә көчәя төште. Гөлсем тагын эченнән: «И Раббым, берүкләр Тукайныкы кебек куркыныч чир генә була күрмәсен», – дип өзгәләнде. Ашыгып, кайнар чәй сорап алды.

Сөтле чәйдән соң Зәйтүнәгә хәл кергәндәй булды. Әллә каян сизелеп тора, икәүдән-икәү генә чагында аның Тукай хакында сөйләттерәсе, сораштырасы килә. Гөлсемнең җанында да еллар буе тынгылык бирмәгән бер сорау сулкылдый.

– Зәйтүнә, узган язда Шәмсениса сине эзләп тапкан булса, Тукай янына барган булыр идеңме?

Бу катгый сорауга иң элек көчле ютәл килеп бәрелде. Зәйтүнә, уңайсызланып, күзләрен түбән төшерде. Чак кына сүзсез торганнан соң, ишетелер-ишетелмәс кенә итеп:

– Юк, Гөлсем апа, бармаган булыр идем, – диде.

– Ничек алай?

– Ничек икәнен үзем дә белмим. Эчке бер каршылык, димме, ышанып җитмәүме, Тукайның бөеклеге алдында бертөсле сагаюмы... Хәер, аңа тиң түгеллегемне мин күптән аңладым инде.

– Кемнең кемгә тиңлеген бер Ходай үзе генә беләдер.

– Ул минем яратуымнан качты ич.

– И җүләркәем, соң аның иң кайнар, иң көчле мәхәббәт шигырьләре сиңа багышланган. Аңлыйсыңмы, Зәйтүнә, син нинди бәхетле?!

Кыз, чак кына елмаеп, башын каккандай итте. Аннан соң, моң-сагыш сарган күзләрен Гөлсемгә төбәп, әйтеп куйды:

– Чистайда аны сиңа атап та шигырьләр чыгарган, diләр.

Гөлсем: «Кеше ни сөйләмәс», – сүзе белән чикләнде. Мондый үзәк өзгеч халәттә үз серләрен, кичерешләрен сөйләп, туганының болай да җәрәхәтле йөрәген нигә яраласын ди Гөлсем. Хәзер ул аның елыйсын гына китерә...

Зәйтүнәнең үзенең дә әлегә берәүгә дә сөйлисе, белгертәсе килмәгән яшерен дөньясы, үкенечләре, серләре, хыяллары бар. Аның да шагыйрьне югалту хәсрәте зур. Аның да җаны сагыну-юксыну, үкенүләргә дучар. Ничек кенә дучар әле. Бәлкем, дөнья шагыйрьне кан костырып яшәтмәгән булса... Гомере шулай иртә өзелмәгән булса... Бәлкем... Бу уйларга янә мәрхәмәтсез ютәл үчегә. Әйтерсең, ул Зәйтүнәнең йөрәк-бәгырендә бик тирәнгә яшерелгән хисләрен шулай бөтенләйгә бәреп чыгарырга җыена иде. Гөлсем тагын куркуга төште. Тагын аның балаларча ябык, кечкенә гәүдәсеннән кочып алды.

Бу елда Зәйтүнә күпне кичергән, бик күпне. Хәтта хәзер кемнең сынаулары ачырак, авыррак икәнен әйтүе дә читен. Гөлсем хәзер үзенең математик аңы белән шушы «тәкъдир» дип аталган иң катлаулы теореманың иң дөрес чишелеш юлын табарга теләп уйлана. Һәм шундый нәтиҗәгә килә. Зәйтүнә нәкъ менә Тукай күрергә хыялланган чын татар кызы икән.

Зәйтүнәнең йөрәге, әнә шул хакыйкатьне аңлатырга теләгәндәй, күкрәк читлегеннән чыгардай булып, сулкылдап кага. Хәзер аның җанына да, тәненә дә дәва кирәк. Дәва... Зәйтүнә хәтта үзенең Тукай янәшәсендә мәңгелеккә атлавын да анык аңлар, абайлар дәрәҗәдә түгел. Әлегә ул нык сырхау.

...Ә чынлыкта исә ул гаҗәеп бер гүзәл сурәте белән – тарих битләрендә. Шунысы бәхәссез: татар яшәгән дәвердә Зәйтүнә белән Тукайның исемнәре мәңге янәшә йөрер. Туачак гасырларда да татар йөрәге аларны бергә күрергә, бәхетле итәргә теләп талпыныр. Зәйтүнәгә Тукайның җан сөйгәне итеп карар, сокланыр, яманатлардан йолып, күз карасы кебек саклар.

Ә Гөлсем нишләрме?! Гомере буена Тукайны яд итеп яшәр.

Ә иртәгә иртән Казанга килеп җитүгә, Зәйтүнә Тукай каберенә юнәлер. Бирдә аның да, нәкъ Гөлсемнеке кебек, яралы һәм яраткан җаны үксер. Ул да шагыйрьнең шигырьләрен дога итәр. Бәхиллеген сорар. Тәкрарлый-тәкрарлый егълар:

...Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы!

Бу мәлдә дә янә кабер өстендә, ак болыт сурәтенә кереп, фәрештәләр сакта торыр. «Мәхәббәт сакчысы» яңадан җиргә иңәр. Ә бөек Тукайның бөек Рухы, шатланып, тагын күкләргә күтәрелер.


***

Аннан, Зәйтүнә Тукай эзләреннән үтеп, Хәтимәләргә кайтыр, һәм чак кына хәл алуга, табибка күренергә китәрләр. Ә Гөлсем өйләдән соң янә пароходта Сембер ягына юл тотар. Анда аны кайчаннардан бирле сабырсызланып Шәмсениса, алай гынамы – ак язмышы көтә. Сембердә ул аны икенче Габдулла белән очраштырыр, төгәлрәге, мәшһүр татар фабрикантларының дәвамчысы Абдулла Акчурин беренче көннән Гөлсемгә гашыйк булыр. Һәм бер ай дигәндә, Гөлсем белән Абдулланың Камада йөзүче ак пароходта туйлары узар.

Казанда дәваланганнан соң, Зәйтүнә дә әнисе белән Троицк каласына китеп барыр. Остазы Мөхлисә Бубый аны мөгаллимә итеп кызлар гимназиясенә эшкә чакыра. Ә бер елдан ул да Троицк каласының данлыклы Зәйнулла ишан гаиләсенә килен булып төшәр.

Гөлсем белән Зәйтүнә исә шушы моңсу сәяхәттән соң кырык өч ел узгач кына очрашу-күрешүгә ирешерләр.

*(Ахыры киләсе санда)*



Луиза
Янсуар

# ҮЗ ҖАНЫҢА ГЫНА ХӨКЕМДАР БУЛ...

## Мәмләкәт

*Бог сохраняет всё; особенно – слова*
*прощенья и любви, как собственный свой голос.*
Иосиф Бродский

Без түгел, шәһәрләр сөйләшә
Борынгы-борынгы бер телдә.
Ул телгә кадәрле яшәгән
Дөньядан... калмады беркем дә.

Әнә шул югалган дәвернең
Ярчыклап җыйганда хәтерен,
Кубардык солтаннар каберен,
Сыкраттык әрвахлар бәгырен.

Без түгел, йөрәкләр сөйләшә
Үзләре белгән бер сөйләмдә.
Ә безгә ни кала? Яңадан
Өйрәнеп, иҗекләп көйләргә...

Кайчандыр даладан кубарып
Кайтканмы? Мәрмәргә ятканмы? –
Ул телдә, эзләсәң дә, инде
Тапмассың чәрдәкле ватанны.

Сүзләрдән, җәядән чыккандай,
Яшәгән мәмләкәт эчендә
Саташкан тукрандай – син һәм мин –
Тукылдый һаман бар көченә...

Әйтерсең, кайрысын каерып
Төзәтә меңьяшәр ярасын...
Төзәтеп булмаса...
Нишләрбез?!
«Бездән соң бер сүз дә калмасын...»

---

Луиза ЯНСУАР (1981) – *шагыйрә; «Мин күкләргә кайтам», «Болан кызы», «Без җан өргән учак» исемле китаплар авторы. Россия-Италиянең Халыкара «Белла» һәм Республиканың М.Җәлил, язучыларның С.Сөләйманова исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Казанда яши.*

## Шагыйрь

*Пуля у виска. Пуля наверняка.*
*Улыбайся только своим.*
Диана Арбенина

Ялгыз килгән җиргә, ялгыз китә.
Ә калганы аның – язмыш эше.
Ул урманнан тотып алып кайткан
Киек сыман.
Юкса – шул ук кеше.

Бар тапканын, барлык югалтканын
Чәркәләргә салып кат-кат чайкый.
Җанындагы упкыннардан качып,
Мәгарәгә керә, җирне айкый.

Юк, белми ул шул җанында кайчан
Галәм шартлап, йолдыз атыласын.
Янартаулар уянасын...
Әле
Җир күрмәгән энҗе табыласын.

Күзләренә карамый да, кайчак
Тоя үзе бимазасын ятның.
Яна, яна, яна...
Тынга каба!
Ә акылы... аек кала, салкын.

Ул һичкемгә яр да түгел, пар да –
Кияүгә бир аны, хет өйләндер.
Авызлыгын чәйнәп, чабыш көтә
Фатирларда –
Яшәп кем беләндер.

Көтә мәхәббәтнең һичберәүгә
Очрамаган иң бөеген...
Хагын...
Һәм ваз кичә аннан ул сөюдән:
«Тапмадым, – дип, – ул булмадың тагын...»

Ул капшанып бара, бара, бара
Чытырманнан –
Эз салмаган бәндә.
«Минеке бу туфрак!
Һәм җир шары!..» –
Шапырына...
Тик үзе дә хәтта –

Үзенеке түгел.
Ил, чорныкы...
Чәркәдәге ялкын түзми, чатный.

Авызлыктан ычкынырга теләп
Бәргәләнә...
Юк!
Ычкына алмый!

...ычкынса да... ычкыначак бары –
Мәңгелеккә.
Монда –
Бу «урман»да –
Ялгыш кулга төшкән бер киек ул –
Уңыш елмаймаган бер сунарда.

Улый, улый, улый...
Җиңәлмичә
Үзеннән мең тапкыр олы көчне.
Дөнья чигәсеннән тишеп уза...
Ә калганы инде –
Ходай эше.

***

Синең өчен генә, минем өчен
Яңа карлар, бала карлар ява.
...Бу ярату мәңге үтмәс төсле...
Сайлаганга безне... рәхмәт аңа!
Бер тәүлектә гүя бер дәверне
Яшибездер сыман... яшидер дә...
Бу сөйләшү мәңге бетмәс төсле...
Сөйләшәбез юкса дәшми генә!
Яңа карлар, бала карлар ява...
Ак корабтай, ак диңгездә йөзгән,
Ак дәрвиштәй, җир мазасын өзгән,
Бу – Мәңгелек узып бара бездән.

## Бәллү

Әйдә, әйдә, әйдә, хыяллардан
Ак сарайлар төзик. Җимерик.
Беркем табалмаган кабиләне
Яулап алыйк. Аннан җиңелик.
Таҗ кидереп, яңа солтан сайлыйк.
Фетнә ясап, бәреп төшерик.
Мәмләкәтнең бөтен оланнарын
Сүз сөйләшмәс телгә күчерик.
Әйдә, яңа канун игълан итик.
Алыштырыйк аннан искегә.
Сурәтләрен танымыйча торсын
Күргән берсе чалыш көзгедә.
Әйдә, яңа җәза уйлап табыйк.
Ә аннары килик иманга.
Кемнәр – безнең белән, кемнәр – түгел.
Кем – уйнап, кем чынлап инана.
Әйдә, әйдә, ягыйк хыялларны...
Калсын торып кара риваять.
– Уянырга иде, уянырга...
Уянырга инде!
Ниһаять!

...«Син кечкенә әле...
Бу төш кенә...
Ниләр кермәс сабый төшенә...» –
Күзләреннән үбеп юата да
Җиргә ап-ак карлар төшерә.
Юылсын, дип, хәтереннән корым,
Яңгырларын учтан эчерә.
Кичерә...

– Әйдә, әйдә, әйдә...

## Мәрмәр

*Иосифка һәм сиңа*

Кичке мәйданнарга күләгәләр яткач,
Йә күперләр кабат үз урынына кайткач,
Йә әйләнгәч дулкын, Дионистай, сынга,
Ышан янә бер кат монда кайтасыңа.
Ышан бер карусыз. Булмаганга чараң.
Ярты гасыр буе төзәлмәгән яраң
Төзәлерме әллә яңа яртысында?!
Бу бердәнбер пунктир йөрәк картасында:
Без очрашыр йортлар һәм тыкрыклар булган –
Вәгъдәләрсез, антсыз... Бары каударлыктан...
Горурлыгың тыяр һәм үзеңне җиңәр,
Пәлтәң якасыннан йолкыганда җилләр.
Һәм ышаныйм моңа тәүге кабат мин дә.
Бу – гашыйклар, диеп уйласыннар җирдә.
Үзебез... ул серне чишми китик,
Яме!
Калсын мәрмәрләнеп иреннәрдә тәме.

...кемдер, килеп, кабат чишкәнчегә хәтле...

***

Үз дөньяңның гына җүләре бул,
Үз дөньяңның гына – зирәге.
«Яшәгез, – дип, – бергә...» –
Сипте дә УЛ...
Тормыш безне сайлап иләде.
Иләкләрнең эресеннән уздык,
Иләкләрнең уздык вагыннан.
Ә аннары – намус иләгеннән...
Һәм елмайдык:
«Бүтән... табылмам...»
Карлар сырган юрганына төренеп
Йоклый изрәп... тәмләп...
Карачы!
Үз жаныңа гына хөкемдар бул.
Үз жаныңның гына – палачы.

## Вакыт буенча күчешләр турында сюрреалистик баллада

Кичәгедән бүгенгегә кайтумы бу? Киресеме?
Җирдә һаман – урта гасыр.
Сызгырышып исә җилләр.
Тик бер ташны урыныннан кузгатырга хыялланып,
Гасыр саен фонарь тотып без йөрибез – ике җүләр.
– Исәнлекме? –
Кулны биреп күрешәбез,
Зәхмәттән дә
Өрекмичә.
– Нихәлләр бар – бүген... кичә?
Кылычына ишарәли... Кашын ярган җөй эзенә...
Һәм сырасын төбенәчә тотып эчә.
Дөнья кисеп җилләр исә.
– Кемне, олан, җуйдыгыз, – дип,
Иңебезгә кулын сала дөнья карты.
Торабыз без, башны кашып:
– Дәүләте дә... малы да юк...
Гасырлардан урап бары аты кайтты...
– И бичара малкай! – диеп көрсенә карт.
Аннан өсти:
– Без, кешедә, ат кадәрле акыл булса-а-а!..
Җирдә һаман – урта гасыр.
Сары фонарь – сигнал уты.
Әнә ишек. Әнә тотка. Әнә тупса.
Күчешләрдән күчешләргә каңгырап, йә, нәрсә таптык:
Чылбырында – Урда эзе... Хәзәр көзе...
Дәүләте дә... мөлкәте дә... олау-олау кодрәте дә
Кая күчә?
Ник тураклый бу ил безне?!
Ни дыңгычлый бункерларга?
ДОТлардан[1], күзен ертып,
Акылыннан тәмам шашкан үлем бага.
– Хәерле юл, оланнар! – дип, иңгә кага дөнья карты. –
Кайтыйм инде... төшеп тора, әнә, кар да...

...Күмә ул кар урамнарны...
Бульварларны...
Рыцарьлар да
Утыралар өрәксыман – баштанаяк!
Без эзләгән табышмакның
Юктыр, ахры, чишелеше...
Пышылдыйсың:
– Без үзебез бугай... җавап.

[1] Карелия Ныгытылган районында (КаУР) 230лап ДОТ (Долговременная огневая точка) бар. 1993 елда хәрбиләр аларны ничек бар, шулай килеш томаламый-нитми ташлап китә. Фин култыгыннан алып Ладога буена кадәр сузылган «иске чик»тәге, Карелия муентыгындагы әлеге хәрби нокталар – көчле радиация чыганагы. Аларда 226нчы радий барлыгы ачыкланды. ДОТларның кайберләрендә ул «җемелдәп» ята. Кайчандыр немецлар «Сталин линиясе» дип йөрткән ныгытмаларга юл хәзер теләсә кем өчен ачык. Бирегә металл эзләүчеләр дә, сталкерлар да, туристлар да, узгыннар да, тирә-юньдәге бакчачылык участогыннан килгән балалар да кереп йөри, уйный. (*Сталкерлар сөйләгәннән.)*



# Марат Әмирханов

## САҖИДӘ

ПОВЕСТЬ

*Йомшак күңелле ак фәрештә.*
Габдулла Тукай

Аһ, бу күзләр!

Кипкән чыра шикелле юкарып, учка сыярдай гына кечерәеп калган гөнаһсыз чырайны биләп торучы мөлдерәмә күзләр. Әнә ничек, киндер ашъяулык өстендә, валчыгын да төшермичә, телем-телем ипекәй кискәләүче бабасының һәр хәрәкәтен, һәр сулышын ау мәчеседәй йотылып күзәтеп тора.

Зиннәтулла үзе дә ипи исе ләззәтеннән авызына килгән суны йотып-йотып куя. Бу вакытта аның торна муенындагы шалкандай зур адәм төере сирәк сакалы арасыннан уйнаклап-уйнаклап алгалый. Шул көйгә кычкырып, телем ияләренең исемен атый.

– Монысы, кызым Саҗидә, сиңа.

Саҗидә кул арасына кереп килүче җиткән кыз инде, йорт эшләрендә анасының терәге, ундүрт яшен тутырып килә, яучылар җимеше. Шуңа күрә телемнең дә иң зурысы өлкән апайга.

– Бусы Гөлчәһрә кызыма.

Гөлчәһрә дә апасыннан әлләни калышмый, тугызга чыкты. Аның вазифалары башка, аш-су тирәсендә кайнашырга яратмый ул. Кизләүдән су ташу, бәбкәләр саклау кебек гамәли мәшәкатьләр белән мәшгуль. Җитез, өлгер бала, усаллыгы да шуңа тиң. Хәтта малайлар да аның белән сүзгә керми, чөнки бөтереп салырга да күп сорамый.

– Инде чират улым Кәшфелкәбиргә җитте, аңа апасы мәрхүмә Гандәлип өлешен дә өстим. Ник дисәң, Аллаһы рәхмәте белән, мәхәлләгә хуҗа буласы, башына хәзрәт чалмасынураячак мәртәбәле инсан.

Төпчегем Кәшфинур аерым исәптә, аңарга кибән башы, тешләре ныгысын...

Габдуллаҗан түземсезлек белән үз исеме чыгуны көтә, хәлбуки, икмәк инде туралып бетте диярлек, бабасы кулындагы ул кыерчыктан үзенә дә, абыстайга да өлеш чыгарасы бар.

---

Марат ӘМИРХАНОВ (1933) – *прозаик; «Таш һәйкәл», «И кылган догам минем», «Дөя муены» һ.б. китаплар авторы. Журнал укучыларына ул тарихи темага язылган «Үрбәт ханәкә гыйшкы», «Гәүһәршад», «Әлвидаг» романнары белән таныш. Казанда яши.*

Ишле гаиләләргә көн аралаш бушлай бирелә торган бу икмәктә, башкалар белән беррәттән, Габдуллаҗанның да тулы хокукы бар, әлбәттә. Чөнки күләме гаиләдәге барлык кешеләр исәбеннән чыгып тәгаенләнә. Әле ярый, хөкүмәт ярдәм кулын суза, югыйсә, туксанынчы еллардагы бу ачлык күпләрнең башына җитә иде.

Зиннәтулла әлеге кыерчыкны озак кына учында әйләндергәләп торды да икегә бүлде...

Габдуллаҗанның күз бәбәкләренә яшь тыгылды, аны бабасы онытты лабаса, онытты!

– Авырлы әниегезгә йомшаграк җиреннән кисик әле, балалар, Ходай кушып, янә бер нарасый алып кайтасы бар бит әле аның...

– Ә миңа?

Бу сорау тышка бәреп чыкмады, сыкрау булып, Габдуллаҗанның авыз куышлыгында йотылып калды, чөнки ятим балага еладың ни, кычкырдың ни – барыбер файдасы юк. Киресенчә, тезгенне генә кыскарталар. Бу хакыйкатьне ул күптәннән күңел түренә салып куйган иде инде. Бабасына үпкәсе юк-югын, какмый-сукмый дигәндәй, тик балалар көнозын абыстай карамагында. Ә абыстай каты куллы, чеметкәләп кенә тора. Хәер, усаллыгы җитмәүчелектән, тормыш авырлыгыннан килгән усаллык иде булса кирәк, кайчак кочагына алып, мышык-мышык елаштырып та алгалый үзе.

Зиннәтулла оныгын онытмаган икән, юк, онытмаган, бисмилласын әйтеп, тамагын кыргалап алды да сакалын сыпыргалап әйтте:

– Калганы Габдуллаҗан белән миңа инде, балалар, гаеп итмәгез, – диде.

Калган дигәне кәгазь калынлыгындагы үтә күренмәле телем иде.

Ул арада йомышчы хатын җамаякларга аш салды. Кичә Саҗидә белән Гөлчәһрә Шәберде урманыннан җыеп кайткан алабута башларыннан, бераз чөгендер яфракларын да өстәп пешерелгән кысыр үлән ашы. Халык шулай җан асрый.

Саҗидә Габдуллаҗанны янәшәсенә утыртты да, үз телеменнән зур гына ипи кисәген сындырып, аның итәгенә шудырды.

Моны борыч тел Гөлчәһрә күреп калган икән.

– И, әрәм тамак, кеше өлешенә кереп утыра, килмешәк, – дип ысылдап, Габдуллаҗанны тинтерәтеп алды.

Саҗидә дә, үз чиратында, сеңлесенең ботын күгәртте.

Бу астыртын ыгы-зыгыны Зиннәтулланың тавышы басты.

– Җә, балалар, дога: әгүзе билләһи минәш-шайтанир-иражим...

Саҗидә, йокларга яткач та, Габдуллаҗанны үз янына алды, кочагына кертте.

– Апаем, оҗмах син, – дип пышылдады малай ләззәт хозурлыгында, – үскәч, мин сиңа тегермән ташыннан да зуррак ипи сатып алып бирермен, валлаһи менә, алдашсам, җир йотсын.

– Акча каян алырсың соң?

– Апай, мин үскәч, тегермәнче булам. Тегермәнчеләр иң бай кешеләр бит алар. Әнә, безнең авылга килгән Арча тегермәнчесе Микулай ничек көрәеп йөри. Аягында шыгырдап торган күн итек, фуражкасының күдериге дә кешенекенә охшамаган, ат тоягыннан эшләнгән, ди. Казанда да берничә генә кешедә, ди андый фуражка...

– Җә, житәр, хыялый, иртүк торасым бар, – дип, Саҗидә энесен кочагыннан чыгарды, – әйдә, йоклыйк.

Өй эче тынып калды. Шуны гына көтеп торган икән, мич аралыгыннан чикерткә аваз салды. Төнге сихри караңгылык пәрдәсенә төренгән бу сузынкы сайрау аһәңе арып-талып мендәр-ястыкка баш салган бәндәләрне, әлли-бәлли

бишек җыры кебек, үзенә бер самими вә илаһи рәхәтлек дулкынында тирбәтә иде. Әнә, ничек, балалар, мәрткә киткәндәй, тигез тын белән тавыш-тынсыз гына татлы йокыга талганнар.

Габдуллаҗан гына әле һаман үзе корган хыял дәрьясында йөзә иде.

– Апай, апай...

Саҗидә бу пышылдауны ишетмәде, аның күзләре йомык иде инде.

– Апай, апай, синең май ягып, өстенә бармак калынлыгы бал сыланган зур телем ак күмәч ашаганың бармы?

– Чер-р-р, чер-р-р...

Чикерткә сайравыннан гайре тавыш ишетелмәде. Хәер, малайның – чикерткәдә, чикерткәнең малайда хасияте юк иде.

– Ә минем ашаганым бар, – диде Габдуллаҗан, иреннәрен чапылдатып, – Саснага әнием янына алып килгәч, Мөхәммәдшакир хәзрәт, рәхмәт төшкере, май ягып, өстенә бармак калынлыгы бал сыланган ак күмәч белән сыйлаган иде. И, аның тәмлелекләре, апай, гомеремә онытасым юк, тәме әле дә авызымда тора. Тегермәндә эшли башлагач, мин сине гел шундый тәмле ризыклар белән генә сыйлармын...

Апай, җәме, апай...

Габдуллаҗанның керсез, саф кайнар яшьләре, яңгыр тамчыларыдай, бит очларыннан урын өстенә тәгәрәде. Һәм, күп тә үтми, чикерткә моңына кушылып, ул, үз яшьләре чылаткан мендәргә битен куеп, йоклап китте.

Тормыш елгасының үз кануны. Ачлыкмы-туклыкмы, шатлыкмы-кайгымы, җилме-яңгырмы – аңа бернәрсә дә киртә була алмый. Ходай фатихасы белән, үзе салган юлдан ага да ага, ага да ага. Кешеләр дә шулай. Аларны да язмыш шаукымнары юлдан яздыра алмый, тормыш теләсә-нинди шартларда да дәвам итә, ачлык чорында да корсак кайгысы яшәү учагын сүндерә алмый. Халык ата-бабадан килгән көндәлек мәшгульлектә: дөнья көтә, мәчеткә йөри, кунак җыя, туй ясый. Бала-чага да нәкъ элеккечә чыр-чу килә, уйныйлар, шаярышалар, көлешәләр.

Габдуллаҗан да, тыны-өне бетеп, урамнан кайтып керде дә, килә-килешкә, мунча алдында кер уып йөргән Саҗидәгә шатлыгын җиткерде.

– Апай, тыңла әле, мин шигырь чыгардым, – диде.

Габдуллаҗанның тезмә сүзгә һәвәслеген бөтен авыл белә, аны шаяртып, бәетче, дип йөртәләр.

– Җә, бу юлы нәрсә уйлап таптың? – диде Саҗидә, эшен дәвам иткән хәлдә.

– Менә, тыңла:

Гөлчәһрәнең теле телме,
Теле очына ут каба;
Ары чаба, бире чаба,
Әйтерсең лә корт чага.

– Ишкәнсең икән арыш шишарасын, – дип, кулын селтәде Саҗидә, – берүк үзе ишетә күрмәсен, арагыз тәмам бозылыр.

– Апай, мин синең турында да шигырь чыгарам әле, – диде Габдуллаҗан, – матур шигырь...

– И, хәчтерүш, – дип, Саҗидә энесенең аркасыннан сыйпап куйды, – алдан кычкырган күкенең башы авырта аның, белдеңме, подаука баш.

Габдуллаҗан борын астыннан гына елмайгандай итте дә:

– Авыртмый башым, авыртмый, мин ул шигырьне иртән иртүк чыгарган идем инде.

Хур кызларыннан да чибәр,
Игелек иясе Мәрьям анадай;
Кем ул, дип сорасаң, әйтеп бирәм:
Бу минем Сажидә апай.

– Чибәр сиңа, – дип, Сажидә кулындагы керен чиләккә ыргытты, – чибәр кыз, беләсең килсә, энем, түп-түгәрәк ап-ак йөзле, чем-кара кашлы, кап-кара күзле, озын кара чәчле, түгәрәк тулы гәүдәле, кыска-кыска гына итчән бармаклы була ул. Ә мин, марҗаларныкы кебек озынча тутык йөз, чәчләрем коңгырт, күзләрем дә кара түгел, гәүдәм армут җимешедәй, билем өзелергә тора, бармакларны әйтәсе дә юк, күр, шүрәленеке кебек бит, кул чугыма гүя орчыклар элеп куйганнар...

– Дөрес түгел, апай, синнән дә чибәр кыз юк, – диде Габдуллаҗан, зурларча җитди төс белән, – бөтен авыл шулай сөйли.

Сажидәнең балалык белән балигълык арасындагы үсмер чагы. Җилекләре әле май белән тулышырга өлгермәгән, шуңа күрә гәүдәсе бөреләнеп кенә килүче күл камышын хәтерләтә иде. Әмма күңелендә инде ашкынулы яз. Кызлардагы бу илаһи хис җиһанга йә җыр-моң булып ишелеп чыга, йә елмаю булып балкый, йә күз яшьләренә әйләнә. Рәвеше санап бетергесез.

Бу мизгелдә Габдуллаҗанның сүзеннән яшь кыз тулган айдай нурга күмелде.

– Син, энем, күңелем сизә, үскәч, мөгаен, белем эстәп, әһле каләм юлына кереп китәрсең, – диде, – тегермәнче – мулла нәселе шөгыле түгел ул, аны күңелеңнән чыгарып ташла.

– Апай, «Сак-Сок»ны көйлә әле, – дип, малай игътибарны янә апасы бакчасына юнәлтте, – син аны бик моңлы итеп көйлисең, күздән яшьләр килә.

Сажидә күз очы белән генә энесенә шелтәле караш ташлады.

– Булмаганны, көпә-көндез, эш вакытында, кеше көлдереп, нинди бәет көйләү ди ул?

– Җә инде, апай, ялындырма, ишегалдында без икәү генә бит, бабай мәчеттә, әбинең өйдә үз шөгыле, Гөлчәһрәләр инеш буена төшеп китте... апай, дим, апай...

Синнән котылып буламы соң, дигәндәй, Сажидә йөзен чыткандай итте дә, кулыннан керен төшермичә генә, сузынкы бәет җөмләләрен мөнәҗәти моңга төрә башлады.

Мәдрәсә – мәсҗед, пыяла ишек,
Сак белән Сокның бәетен ишет...

Сажидәнең самими вә моң тулы аһәңле мамыктай йомшак тавышы, гүя чишмә җыры, челтер-челтер, челтер-челтер, күңел түренең иң эрактагы күзәнәкләренә кадәр барып җитә:

Әткәй калдыргач, өйдә калдык без,
Әнкәй каргагач, Сак-Сок булдык без...

– Кызганыч, Сак белән Сок гомерлеккә шулай кош сурәтендә кала бит инде, – дип, Габдуллаҗан кул аркасы белән күзләрен сыпыргалап алды, – кавыша да алмыйлар...

Апасы аңа бәет сүзләре белән җавап бирде.

Ата-ана каргышы төшми дип уйламагыз,
Нәфескә ирек биреп, уен да уйнамагыз.

– Апай, бүгеннән Сәмига әби кәҗәсенең койрыгын кысып, үзем дә кычкыртмыйм, Кәшфелкәбиргә дә ирек бирмим, – диде Габдуллаҗан, – вәгъдә!

– Миңа хәзер эти кыз-хатыннар язмышына мөнәсәбәтле дастан-бәетләр бирә башлады, – диде Сажидә, – син абыстай буласы, балаларга мәгърифәт

нуры иңдерүче зат, гыйлемеңне арттыр, кеше арасында, кем кызы, дигәндә, Зиннәтулла хәзрәт кызы, дип әйтерлек бул, ди.

Ул бәет-дастаннар бик гыйбрәтле. «Ханәкә солтан» бәетеннән бер юл тыңлап кара әле.

Госман бер хафиз кызы идем, Ханәкә солтан атлы идем,
Сәхтиян кимәс наз идем, чабата тапмый барамын.

– Бу моң түгел, апай, бу зар, – диде Габдуллаҗан, – сүзләре дә аңлашылмый, сәхтиян, имеш.

– Сәхтиян ул, энем, өч йә алты аена хәтле ана сөте имгән кәҗә тиресеннән (сарыкныкы да ярый) махсус үсемлек сыгынтылары белән эшкәртелгән күн, ягъни дә сәхтиян, – диде Саҗидә, – хәлле кызларның әһле хыялы.

Их, сәхтиян читекләр киеп, урам узасы иде, Таһир-Зөһрә мәхәббәтенә бәрабәр гыйшык утларында янасы, үз тиңең белән никахларга керәсе иде.

Таһирҗаның килгәндер,
Уян, Зөһрә солтаным...

– Апай, үзең уян, әнә, чиләгең ауган, итәкләрең манма су, сизмисеңмени? – дип, Габдуллаҗан бот чабып көлде, – хе-хе-хе, мәхәббәт, Таһирҗан, хе-хе-хе...

– Башың яшь, подаука баш, – диде Саҗидә, – бу һәркемгә дә килә торган хәлләр.

– Хәлләр, хәлләр, их, менә ничек була ул хәлләр.

Габдуллаҗан көчле черелдек тавыш белән җырлап җибәрде.

Аклы ситса күлмәгемнең
Якаларын кем уйган?
Җан күк күргән дустым Закир иде,
Газиз башым шул җуйган.

– Җырлама шул зимагур җырын, дип ничә тапкыр әйттем инде мин сиңа малай актыгы, – дип, Саҗидә энесенең изүеннән эләктермәк иткән иде дә, туктап калды.

– Абау, күзләрең?!

Габдуллаҗанның күзләре эчке хәл-халәтенә тәңгәл рәвештә, җофар киекнеке шикелле, мизгел эчендә әле бер, әле икенче кыяфәткә керә иде.

Монысы инде ипи бүлгәндәге нәүмиз караш түгел, күзләреннән кыланчык котырыклык бөркелеп тора.

Их, апакай, күз тияр, дип,
Йөзләреңә туйганчы карамадым...

– Җыламаган бала көлә дә белмәс, диюләре дөреслеккә туры килми икән, – диде Саҗидә, – кешедән көләргә сиңа куш, ясап куйган кебек.

Хак, Габдуллаҗанны өйдә каты бәгырьле, дип битәрлиләр иде. Шулай да Саҗидәгә бер тапкыр энесенең яшьләрен күрергә туры килде. Һәм бу вакыйга аның күңелендә юшкын шикелле мәңгелеккә утырып калды.

Бу хәл, бердәнбер улы вафатыннан соң, Кырлай авылы кешесе Сәгъдетдин агайның Габдуллаҗанны асрамага сорарга килгәч булды. Булышырга Нәфисә атлы хатынны да иярткән иде.

Нәфисә – Өчиле кызы, Габдуллаҗанның анасы Бибимәмдүдәнең бергә уйнап үскән ахирәт дусты.

– Сәгъди абзый – авылыбызның аягында нык басып торучы хәлле кешесе, – дип, сүзне дә ул башлады, – Габдуллаҗанның тамагы тук, өсте бөтен булыр, Аллаһы боерса, абыстайга сабакка да йөрер, шулай бит, Сәгъди абзый?

– Әйе, әйе, килен, шулай булмыйча теге, мулла баласының гыйлемле булуы мәгъкуль, – дип җөпләде агай булышчысының сүзен.

Габдуллаҗанны чакырып, хәлне аңлаттылар. Ул, кашын җыерып, бераз уйланып торды да:

– Апай, син дә минем белән барасыңмы? – дип, Саҗидәгә текәлде.

Габдуллаҗанның мөлдерәмә яшьле күзләре мескенлек вә чарасызлык белән тулышкан иде.

Саҗидә бу караштан сыгылып төште. Үзен-үзе белештермичә, энесен җитәкләп алды да өйалдына атылды...

Зиннәтулла да яшьләренә тыгылды.

– Гафу, җәмәгать, кире уйламасагыз, берәр атна-ун көннән тагын сугылырсыз, бүгенгә хушыгыз, – дип, кырлайлыларны озатып җибәрде.

***

Саҗидә көне буе хатны кулыннан төшермәде. Әле дә өйлә намазын төгәлләүгә, укалы челтәр сурәтләр булып ак кәгазьгә юлга-юл тезелешкән җөмләләрне, сабый баланы иркәләгәндәй, бәү-бәү сыпыргалап алды да күңелен эреткәннәрен янә күз уңыннан үткәрергә кереште.

«30 июнь 1903 сәнаи миладия.

Биисми Габдулла бине Мөхәммәдгариф Тукаев.

Фөтүвәтле вә сәгадәтле җизнәмез илән миһербанә вә мөшфика Саҗидә апайга биниһая догаи-сәламләремне васил вә мөтәвасил әйләдем...»

Габдуллаҗан сәлам һәм изге теләкләрен гаиләдәге һәр затка, шул исәптән балаларга да, Бибимәсрүрә белән Габделваһабка да, ихластан ирештерүне үтенгән иде.

Саҗидә үзенә мөнәсәбәтле җөмләләрне кат-кат укып чыкты.

«Мөшфика апаем! Синең сабый вакытта һәм хәзер дә кылган изгелекләреңне кабердә ятсам да онытмам. Анам дарелбәкайә рихләт иткәч, бабайлар өендә бәңа мәрхәмәт күзе илә караучы юк иде, мәгәр син бар идең».

Ялгышасың, энем, әтием Зиннәтулла хәзрәт сине һәрдаим күз уңында тотып, кагу-кыерсытуларга юл куймый иде, ә балачакта төрткәләшү-чеметешүләр гадәти хәл инде ул, бу җәһәттән үпкә саклау урынсыз, дип уйлап куйды Саҗидә.

Ишек уемында Әхмәтсафаның җыйнак гәүдәсе күренде. Аның өйлә намазыннан кайтып килеше. Ул шулай Хөзер галәйһиссәлам кебек искәрмәстән генә пәйда була.

– Мыштым хәзрәт, бел: бу кыланышларыңнан бер йөрәгем ярыла әле минем, – диде Саҗидә, назлы шелтәләү белән, – тамак кыргалап алсаң, үзеңә савап кына булыр иде ич, Алла колы.

– Җә-җә, чәпчемә абыстай, – дип, Әхмәтсафа хәләле алдына бүрек кадәрле бер төргәк китереп куйды, – үзеңә, әнә, күчтәнәч алып кайттым.

– Тәм-томга акчаңны әрәм итмәсәң дә ярар иде анысы, – диде Саҗидә, – хатыннарны алай узындырырга ярамый.

– Хатыннар түгел, абыстай, ә хатын, Ходай насыйп иткән җан җәмәгатем.

Хәзрәт хәләленә елышмак иткән иде дә, тегесе ирне суыту җаен бик тиз тапты.

– Каенишең Габдуллаҗан бик күп сәлам юллаган үзеңә, – дип, хатны сузды.

– Таныш ич инде мин бу хат белән, – диде Әхмәтсафа, йөзен чытыбрак, – җизнәсенең исем-атын да белмәгән каенишнең каенишлеге, ташка үлчим, сыерчык белән чыпчыкның туганлыгы гына инде ул. Туй вакытында, әгәр хәтереңдә сакласаң, мөхтәрәм абыстай, мәһдүмне хәлвәт бүлмәсенә чакырып кертеп, тәм-том белән сыйлап, ике җәпле кияү пәкесе дә бүләк иткән идем...

Саҗидәнең авызы капланды, иренең үпкәсен кайтарырдай бер дәлиле дә юк иде. Чөнки хатта ап-ачык теркәлгән: «Сез, җизнәңнән күп сәлам, дип язасыз, – диелә анда, – ләкин җизнәм нә исемдә вә кайда тәхсиле голүм иткән – шулары бәңа бик мәҗһүлдер. Мөмкин булса, хат язганда мәгълүм итеңез».

Хак, Саҗидәгә энесенең хаты тоташ шатлык-куанычлардан гына гыйбарәт кебек иде. Ул аңа узган кыш юлаучы артыннан бер савыт манпаси һәм җиләк кагы җибәргән иде. Онытмаган, рәхмәт төшкере, кагыгыздан һәр апаларыма өлеш чыгардым, дигән, бик рәхмәт укыдылар, дигән. «Сезнең йибәргән чиккән аяк чолгавыңызны, апай төсе, дип, кадерләп кенә тотамын», дип тә өстәгән. Моңарга ничек куанмыйсың да ничек шатланмыйсың ди.

Әүвәл асрамага алган якыннары да үзен хәтердә тота икән: «Бу үткән кышта Кырлайдагы анам да кура җиләге кагы җибәргән иде», – дип яза Габдуллаҗан.

– Җә, ярар инде, атасы, бик тәшвишләнмә, – диде Саҗидә, – Габдуллаҗан түгел, мин гаепле, аңлатып язмаганмын, мине орыш...

– Каенишнең гыйлемгә һәвәслеге бу үпкәләрнең барысын да юып төшерә, – дип, Әхмәтсафа янә хатынына үрелде.

Бу юлы Саҗидә карышмады.

Чираттагы хатында хатасын төзәткән иде инде Габдуллаҗан. Тәүге җөмләсен үк җизнәсенә мәдхия җырлаудан башлаган: «Сезки, кешеләрнең иң кадерлесе, югары дәрәҗәләрнең иң ихтирамлы булган хөрмәтле җизнәбезгә, гадәттәгечә, сәламнәребезне җибәреп ирештергәннән соң, хәер-догаларыгызны өмет итеп калам...»

Апасына исә ярты кадак чәй, яулык, исле сабын җибәргән иде.

Әхмәтсафаның күңеленә каенишенең алар никахына багышлап язылган «Ишек бавы» шигыре дә бик хуш килде, рәхәтләнеп көлде.

Саранланыр чак түгел,
Бир, җизни, комсызланма;
Акча бирми кертмибез,
Тукта, сабырсызланма.

Никах, туй җәй башында, җыен вакытында булды. Алар моңарчы берберсен белми иде, күрешкәннәре дә, очрашканнары да юк иде. Гореф-гадәт кысаларында барысын да ата-аналары хәл кылды.

Әхмәтсафаны атасы Зариф хәлфә үсмер чагында ук дөнья күрсен, зур җирдә, ишле кешеләр арасында акыл җыйсын, дип, танышлары аша Казан бае Әхмәт Хөсәеновка самавырчы итеп урнаштырды.

Бай бу сүз тыңлаучан булдыклы малайны ошатты. Ошатты гынамы, аңа буй җиткереп килүче зәгыйфь кызын тәгаенләргә ният итте. Шуңа күрә әҗерен дә мулдан куйды, иреген дә артык кысмады.

Самавырчы малай моннан бик оста файдаланды. Акчасын тиененә кадәр җыеп барды да, мая туплап, ел ярымнан «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга керде. Укуын тәмамлагач, Бишбалта балаларына аң-белем бирде.

Көтернәскә бер кайтуында атасы каршысына утыртты да әйтте:

– Улым, Ходайның рәхмәте, йөзебезгә кызыллык китермичә, үз көчең белән аякка бастың, мин синнән риза-бәхилмен, башлы-күзле дә итсәм, Аллаһы каршындагы изге бурычым да үтәлгән булыр иде, – диде, – әзерлән, яучы, кәләш хәлләрен үзем хәл итәрмен.

– Тәшәккүрдән гаҗизмен, атаем, – дип, Әхмәтсафа әтисенең чапан итәген үпте. Әмма кемгә яучы җибәрәсен төпченмәде. Чөнки ата-ана гамәле – изге

гамәл, ул шәрехләүгә мохтаҗ түгел. Баланың бурычы – барысын да ничек бар, шулай кабул итү.

Югыйсә, бу бала егерме сигезен тутырып килә иде инде.

Саҗидәнең дә тормышында үзгәрешләр башланды, көннәрдән бер көнне бирнә сандыгы ишек катындагы почмактан түргә менеп кунаклады. Анасы Латыйфа абыстай, сандыкка һич тынгы бирми, нәрсәләрнедер барлый, саный,ниләрдер өсти, авыз эченнән сөйләнә-сөйләнә, көне буе шул тирәдә мәш килә.

Болары гына бер хәл, «ярамый»лар күбәйде. Йомышсыз урамга чыгып йөрергә ярамый, дусларың белән элеккечә аралашырга ярамый, кычкырып сөйләшергә, көләргә ярамый, хәтта көтү каршыларга да ярамый...

Ни гаҗәп, әүвәл ярамаган кайбер гамәлләргә үзеннән-үзе юл ачылды. Әйтик, кучкарда кершән, иннек, сөрмә савытлары пәйда булды. Әнисе дә:

– Битеңне кояш ашамасын, кызым, кершәннәр сөрткәлә, – дип, моңарчы яшеренеп кенә башкарылган төзәнү-бизәнүләрне рәсмиләштереп тә куйды.

Кызлар яулык болгый да көзге уйната, ди, Саҗидәнең дә кул көзгесе кесәсендә генә йөри иде. Көзге аның якын дусты да, килешмәс дошманы да. Ике арада туктаусыз тарткалаш бара. Матурмы ул, ямьсезме? Ошбу хәлиткеч сорауга тәгаен генә җавапның әлегә табылганы юк.

Бер карый, Сусылу ханәкә кебек чибәрнең-чибәре, икенче карый, Мокыт гыйбатның утырып калган кызыдай, битенә катык сөртсәң, көчек яламас бер күңел кайтаргыч нәмәстә...

Әле дә тиз-тиз генә табынны җыештырып, кашык-аякларны урнаштырды да бакча эчендәге келәткә элдертте.

Көзге бүген башка көннәрдәгедән мәрхәмәтлерәк иде, кил, кара, сурәтеңне бозмый-нитми күрсәтәм, дип үзенә чакырып тора.

Көзгедән аңа тутый коштай таранган, аккоштай ясанган алма битле чибәркәй карап тора иде. Түгәрәк ак йөз, матур борын, нурлы күзләр... Мәмрәп пешкән чиядәй тулы иреннәр өслүбендә гадәтидән кыскарак шакмак ияге дә хәтта килешсез булып тоелмый иде. Һәрхәлдә, карашы бу тирәдә тоткарланмыйча гына узып китте.

Узып китте дә бит очларына сибелгән сипкелләрдә тукталып калды.

Сипкелләр кызның иң авырткан җире иде. Хәлбуки, беленер-беленмәс кенә сибелгән тәкәрлек тимгелләр аңа, киресенчә, сөйкемлелек, ягымлылык кына өсти иде үзе.

Бәхәс бүген дә аның файдасына төгәлләнмәде. Чөнки мул итеп ягылган иннек астыннан да бу каһәрле сипкелләр, менә без, дип, ак җәймәгә сибелгән тары бөртекләредәй, хыянәтчел рәвештә чәтрәннәп күренеп торалар иде.

– Уф, үләм!

Кыз ачуыннан көзгене иске-москы өстенә бәрде дә, мөлдерәмә тулы күз яшьләрен алъяпкыч читенә сөртеп, сулыга-сулыга үксергә тотынды.

Шулвакыт, искәрмәстән, идән ярыгыннан учта гына йөртерлек бик сылу тычкан баласы кәтүк кебек кенә тәгәрәп килеп чыкмасынмы. Чыкты да, нәни нәфис аяклары белән битен сыйпаштыра-сыйпаштыра, түгәрәк шомырт кара күзләрен туташ тарафына юнәлтте.

– И, Чибәрапай, елама болай, елаган кеше ямьсез күренә, күзләре дә нурсызлана...

Саҗидә көлеп җибәрде...

Ул шулай юктан гына елый, юктан гына көлә. Аңа хәзер урынны да аерым җәяләр, энеләре-сеңелләре арасында кысылып ятмый. Хәер, йокысы да үзгәрде. Еш кына төн уртасында нindидер ашкынулы ят хисләр кочагында кемгәдер сыенып, уянып китә башлады.

Бу «кемнеңдер»нең тәгаен шәхсән заты юк, әлбәттә, әмма ия-үрнәге бар. Ул – Миркасык би углы Түләк солтан.

Зиннәтулла хәзрәт шәкерт чорыннан бирле борынгы кулъязмаларга мөкиббән. Ул аларны эзли, җыя, укырлык хәлгә китерә, күчереп яза. Инде кызын да шушы изге шөгыльгә ниятләде.

Чираттагы табышы – «Түләк – Сусылу» дастаны аның кулына искиткеч таушалган хәлдә килеп керде. Шулай булмыйча, ничә еллар кышын-җәен чормада яткан бит. Кәгазь битләрен тузан ашап бетерә язган.

– Кызым, бу кулъязманы синең ярдәмнән башка рәткә китереп булмас, ахры, бергәләп тотыныйк, – диде.

Саҗидә атасының битенә ябыштырып кына куйгандай тырпаеп торган нәзек мыегын, очлы сирәк сакалын, арык гәүдәсен күзеннән кичерде дә:

– Мин риза, әтием, – диде, – хикәяткә тотынганчы, чәй ясап алып килим әле, буы чыгып торганын, син иреннәрне пешерерлек кайнарын яратасың бит.

– Бик муафыйк булыр иде, кызым, әллә нигә авыз эчем кибешеп тора, – диде Зиннәтулла.

Ата белән кыз шушы эш белән мәшгуль, яртысына җитеп киләләр инде. Дастанда сурәтләнгән ашкынулы гыйшкый вакыйгалар бик мавыктыргыч иде, күңелгә сеңеп, бөтереп алалар.

...Берзаман көнчел кулдашларының хыянәте аркасында Түләк солтан алты көнлек юл ераклыгындагы чит-ят җиргә килеп эләгә.

«Ул сәгать Түләк аты туктаган йирдә бер кыз күрде: гайәт сахибе җәмалдыр, кем күрсә, гыйшкындин җан бирердәй булыр иде. Ул су пәрисе Чачдар хан дигән падишаһның кызы иде... Түләк килеп кызга сәлам бирде. Кыз, сачын йөзендин китәреп, әйләнеп карады, Түләкне күрде, аһ итде, гашыйк булды.

Түләк кызга кушаг әйтде:
Инеп килдем атымдан
Имде күрәсең үзеңә,
Сәлам бирдем бән сәңа,
Ай тик күрекле йөзеңә.
Гашыйк булдым бән сәңа –
Нәзек зифа буйыңа,
Сүзең әйтче, Сусылу!

Кыз йәнә Түләккә әйтде:
Мән усалының үзенә
Гашыйк булма, бай углы;
Алтын сыргам бирәйен –
Бүләк булсын, бай углы.
Безнең йирләр – каты йир,
Тузалмассың, бай углы;
Хәстә булып үләрсең,
Кайтып киткел, бай углы!

Шушы урында дастанның берничә бите бөтенләй челтәргә әйләнгән иде, алай да өзек-өзек ике җырны азмы-күпме укырлык иттеләр.

Андан кыз әйтде:
Бүләк биреп алмайсән,
Нидер сәнең теләгең,
Сүзең әйтче, Түләгем?
Андан Түләк әйтде:
Йөзек-бүләк кирәкмәс, –
Зифа буйың теләгем!
Сүзем шулдыр, Сусылу!

– Әтием, син үзеңнең шигыреңдә Бибимәмдүдә апайны да нәзек зифа буйсынлы, дип сурәтлисең, ул да Сусылу кебек матур булган икән, – дип, Саҗидә дастан вакыйгаларын үз ягына борып җибәрмәк итте.

Нуры газизем, кызымның төрбәседер бу мәзар
Әйләмеш нәзек вөҗүден хак дәвре рузыкар...

Зиннәтулланың кара тут озынча йөзенә моңсу күләгә ятты.

– Мин аны күзем туйганчы күрә дә алмый калдым, – диде, – хур кызларыдай чибәр иде апаең...

Тынып калдылар. Бакча өе ачык тәрәзә аша чыр-чыр килүче песнәк авазлары белән тулды. Аларга әниләре тирәли яфрак чүпләп йөрүче тавык чебиләренең күңелле чикелдәшүе килеп кушылды.

– Бәбкә үлән, чеп-чеп-чеп, бәбкә үлән, чеп-чеп-чеп...

– Ә мин апаема охшамаганмын, – дип офтанды Саҗидә.

Зиннәтулла кызының аркасыннан сыйпаштырып алды да:

– Сөбханалла, кызым, син чын татар милли сылуы, – диде.

– Әтием, син әйтәсең дә ул, керпе дә баласын: «Йомшагым, йомшагым», – дип сөя ди бит.

– Әстәгъфирулла, дигең, кызым, Ходайның биргәненә рәхмәтле бул, йөзең тулган ай кебек, аяк-кулларың, шөкер, исән-сау, буй-сыныңа тел-теш тидерерлек түгел, – дип, Зиннәтулла озаклап дога кылды.

Җитү кызның әлеге тәшвишләнүләренә анасы Латыйфа абыстай нокта куйды.

– Чибәр чибәр күренми, сөйгән чибәр күренә, – диде.

Аллаһым Түләк солтан кебек асыл зат насыйп ит!

Ходай Саҗидәнең теләкләрен ишетте, менә дигән егеттән яучылар килде.

Егет кеше шул булыр:
Кысып бәйләр билбавын.
Егет тавышын кыз ишетсә,
Шалтыратыр кул бавын.

Ике як та никахка хәер-фатыйхасын бирде. Алмакның салмагы бар, дигәндәй, бүләк-мәһәр җәһәтеннән дә бик тиз уртак тел таптылар.

Егет хәлле иде, мәһәргә йон шәл, читек-кәвеш, калфак, өч күлмәк, комган, егерме биш тәңкә акча һәм башка кирәк-яраклар тәгаенләде.

Күз карашлары аша гына булса да, яшьләр дә бер-берсен белеште.

Әхмәтсафа кәләшенә бер караудa гашыйк булды, күр, матурның матуры икән ләбаса. Саҗидәнең төн йокыларын качырган сипкелләр дә, киресенчә, аңарда ашкынулы хисләр уятты, аларны сыйпаштырасы, назлыйсы килеп китте.

Саҗидә дә егеткә керфек каккан арада гына күз төшереп алса да, хатын-кызларга хас зирәк тоемлау белән барысын да абайлап өлгерде. Әхмәтсафа атасы шикелле озын буйлы, төз гәүдәле, гүәрдиндәй азамат егет икән. Зәңгәрсу күзле, коңгырт чәчле, ачык йөзле. Ул моңа бик сөенде, чөнки аның кәтәнә егетләрне җене сөйми иде.

Шәһәрчә купшы киемнән. Хәтфә кәләпүше, җилән шикелле озын кәзәкие үзенә бик килешеп тора. Балагы төшерелгән чалбар, аягында штиблет.

Икенче мизгелдә Саҗидәнең күңеленә шик ташы килеп утырды: санлап яшәрме ул аны, мондый фырт егетләр мут була, алтын Ибанда, хатын ишанда, ди, ә аның хәләлен бөрәү белән дә бүлешәсе килми.

Ходай әйтерсең лә кызның бу шик-шөбһәләрен ишетеп торган, аңа булачак киявен сынау мөмкинлекләрен дә бирде. Туй көне билгеләнгәч кенә, Көтернәс мулласы хәер-фатыйхасын кире алды, чөнки Саҗидәгә әле уналты яшь кенә булуы ачыкланды. Хөкүмәт указлары нигезендә исә бу яшьтә укылган никах кануни саналмый икән.

– Мин законны боза алмыйм, – дип кырт кисте мулла.

Никах бер елга кичектерелде. Шушы вакыт эчендә Әхмәтсафа үз мәхәббәтенең, әһле хисләренең ихласлыгын, саф вә пакьлеген хатлары аша исбат итте.

Саҗидә ул хатларга җавап язмады, әмма мәгъшугының ярым яшерен бу хатларын түземсезлек белән көтеп ала иде. Әхмәтсафа аңа «Насыйбым» «Кошчыгым», дип мөрәҗәгать итә иде. Дөрес, «кошчыгым», дип нәни балаларга гына әйтәләр анысы, тик шулай да андый сүз ишетүе барыбер рәхәт иде.

«Кошчыгым», бу җиһанда иң бәхетле җисем – ул кояш, – дип язды бер хатында, – чөнки ул сине һәрвакыт күрә. Кавышканнан соң, ул безгә нуры, яктылыгы белән түләргә бурычлы булып калачак».

И, җүләрем минем, олы дөрес хыялыем!

Шөкер, сөбханалла, башлы-күзле булганнарына инде дистә елга якын вакыт узып китте. Туйдан соң ук Әхмәтсафаны Каенсар авылына мулла итеп тәгаенләделәр.

Каенсар – Мәңгәр суы кушылдыгы Үрәтмә елгасы буенда нигезләнгән бер мәхәлләле җыйнак кына авыл. Табигате матур, халкы әйбәт, мәнле, игътибарлы, олыны олы, кечене кече итә беләләр. Абыстай вазифасында Саҗидәнең урыны түрдән, балаларга сабак та бирә. Шушы вакыт эчендә бер ул, ике кыз бала алып кайтырга да өлгерде. Гаиләләре – бөтен тирә-якка үрнәк гаилә. Ир белән хатын, әле һаман яңа гына кавышкандай, бер-беренә гашыйк. Әхмәтсафа «насыйбым», «кошчыгым», дигән тылсымлы сүзләрен дә онытмады.

– Имам-хатыйбка мәгъшук шәкертләр кебек гыйшык-мыйшык уеннары уйнау килешә торган хәл түгел, кеше арасында хисләреңне йөгәнли бел, – дип, Саҗидә аңа үзе киртә куйды.

– Бик хуш, абыстай, – диде Әхмәтсафа, сакалын сыпыргалап, – шәт, ошбу чикләүләр кызларым Мәсрүрә белән Өммеһаниягә кагылмыйдыр бит?

– Ул бәгърем җимешләрем – сөю-сәгадәт тасвирлары – Ходайдан килгән лазем гамәл, – диде Саҗидә, – алай да бу хәләл җефетеңне бөтенләй исәптән чыгарып ташлауны аңлатмый, хәзрәт, үзеңә дә мәгълүм, хатын-кыз колагы белән ярата бит ул...

– Килештек, абыстай, әлеге ләззәтле сүзләрне мин, икәүдән-икәү калгач, колагыңа гына пышылдармын.

***

Сәлам хатлары, бүләк-күчтәнәчләре артыннан, ниһаять, Габдуллаҗан үзе дә туган-үскән якларына әйләнеп кайтты. 1907 елның көзе иде, суга бер кашык суык кергән мәл иде. Булса унбер синтәбер – җәйдән инде бит сыпыр. Бу әйтем һава торышына бөтенләе белән туры килә иде. Көз нишләптер ашыгыбрак килде, иртәрәк суытты, хәтта кар тәңкәләре дә үзләрен күрсәтеп алырга өлгерде инде.

Габдуллаҗан Каенсарга килеп төшкән көнне дә ара-тирә кар бөртекләре күренгәли иде әле.

Бусагада озынчарак йөзле, җитү чәчле, авыл мохитенә туры килми торган ыспай киемле егет күренгәч, Саҗидә аптырап калды.

– Әссәләмегаләйкүм, абыстай, сау-сәламәт кенә яшисезме, Ходай фөтүвәтле вә сәгадәтле Әхмәтсафа хәзрәтләренә озын гомер, гамәлләрендә бетмәс-төкәнмәс уңышлар насыйп итсен...

Әхмәтсафага йомышы бар ахрысы, дип уйлап куйды Саҗидә.

– Имам-хатыйб мәчеттә иде шул әле, хәзер... теге...

Ул тотлыгып калды. Йөзендә самими елмаю балкыган бу әфәнденең күз карашы бик таныш кебек тоелды, күңел түрендәге хатирәләрне уятып җибәрде.

– Габдуллаҗан, әллә син инде, Габдуллаҗан...

– Апаем минем, ак фәрештәм...

Алар, бер-берсенә сыенышып, озак кына идән уртасында басып тордылар.

– Көтә-көтә көтек булып беттек, – дип, иң әүвәл Саҗидә телгә килде.

– Башта Кушлавычка сугылдым, аннан Масрада, Өчиледә булдым, хәзер менә Каенсарга килеп җиттем, – диде Габдуллаҗан, апасын кочагыннан чыгармыйча, – сездә озаграк юанырмындыр, мөгаен. Солдатка каралырга кайттым бит...

Әңгәмә өзелде, өйгә, ашыгып-кабаланып, Әхмәтсафа кайтып керде.

– Сөбханалла, сөбханалла-машалла, әссәламегаләйкүм, мин сине нәкъ шулай күз алдыма китерә идем, – дип, каенише белән ике куллап күреште, – бөтен авыл шаулый анда, шагыйрь Тукай килгән, шагыйрь Тукай килгән...

– Вәгаләйкемәссәлам, хөрмәтле вә затлы җизнәм, – диде Габдуллаҗан, – туган җиремне бик сагынган идем, иҗатыма да дәрт өстәлде, юлда бер шигырь аһәңе дә бөреләнеп өлгерде.

Айрылып китсәм дә синнән гомеремнең таңында мин,
И Казан арты! Сиңа кайттым сөеп тагын да мин...

– Каләм бар – очыннан алтын тамар, каләм бар – очыннан дөнья янар, – диде Әхмәтсафа, – афәрин, каениш, күңелеңдә Колшәриф, Мөхәммәдьярларның утын йөртәсең икән, ялкынын дөрләтергә язсын.

– Рәхмәт, хәзрәт, – диде Габдуллаҗан, – син исемнәрен атаган бу асыл шәхесләр – Казан ханлыгының мөстәкыйльлеге энә очында калган авыр вакытта орыш кырында башларын салган әһле каләм ияләре. Безгә якты үрнәк. Тик әлеге җиңелүдән соң, татар йомылып калган, аны хәзер уятырга вакыт җитте. Бу минем дә иң изге мәсләгем.

Татар бәхете өчен мин җан атармын:
Татар бит мин, үзем дә чын татармын.

– Габдуллаҗан, җизнәң менә шундый инде ул, гәп корырдай белекле кеше белән очрашса, дөньясын оныта, – дип, Саҗидә ирен җиңелчә генә битәрләп алды, – әйдә, табынга рәхим итегез, аш-су әзер.

Ишек уемында якты йөзле, пешкән бөрлегәндәй тулы иренле, өч-дүрт яшьләрдәге кыз бала пәйда булды.

Кыю вә тәвәккәл икән, леп-леп кенә атлап, Габдуллаҗан каршысына килеп басты да:

– Әссәлә, тәти абый? Ничек хәлләгең?! – дип сорады.

– Бу безнең төпчегебез Өммеһания була, – диде Саҗидә, – зур үсеп килә инде, бер шигыреңне яттан да сөйли белә.

– Әйе, беләм, – диде кызчык, – менә тыңла.

Кәҗә әйтә: «Мә-мә-мә»,
Сагык әйтә: «Бә-бә-бә»,
Биг, димиләг, мә-бә, диләг,
Ниндәй юмагт бәтиләг.

– Афәрин, – дип, Габдуллаҗан кызчыкка кәнфит сузды.

– Хәтерләмисеңдер инде, – дип аңлатма бирде Саҗидә, – син бу шигырьне бәләкәй чакта Саснада чыгаргансың, аны әниең Бибимәмдүдә апай әтиебез Зиннәтулла хәзрәткә сөйләгән, инде менә Өммеһания отып алды.

Габдуллаҗан сеңлесен күтәреп алып, бит очларыннан чуп-чуп үбә-үбә:

– Телисеңме, бер бәти турында хикәят сөйлим, – диде.

– Сөйлә.

– Бер кәҗә бәтие, бүре тиресен киеп, бакчага килә.

Яшел чирәмнәрне татымак булып, авызын түбән таба суза гына икән, аны ерактан күргән этләр, чын бүре дип белеп, уптым-илаһи моның өстенә ташланалар.

Бу хәлне көтүчеләр күреп, этләрне көч-хәл белән генә аерып алганнар...

Кызчык хикәятне ошатмады булса кирәк, тәти абыйсын:

– Ә синең нишләп сакалың юк, әтиемнеке баг бит, – дип бүлде.

– Кызым, безне йөдәткәнең дә бик җиткән, тәти абыеңны да аптыртма, бар, абыең белән апаң янына теге өйгә кер, аштан соң үзебез чакырырбыз, – дип, анасы кызын ишектән чыгарып җибәрде.

– Габделваһап белән Бибимәсрүрә җитеп киләләрдер инде, – диде Габдуллаҗан.

– Габделваһап – мәдрәсә шәкерте, Бибимәсрүрә әлегә үземдә сабак ала.

***

Солдатка каралу мәшәкатьләре бер атнага сузылды. Хәрби медицина комиссиясен, волость үзәге булса да, Олы Мәңгәрдә түгел, Олы Әтнәдә үтәргә туры килде.

Кече буйлы, чандыр гәүдәле, бер күзенә ак төшкән Габдуллаҗанны сәламәтлеге буенча солдатка яраксыз дип таптылар.

– Их, булмады, җизни, озын кунычлы капрал итекләрен киеп, марҗа кызларының күзләрен кыздырырга исәбем бик көчле иде дә, барып чыкмады, – дип, Әхмәтсафаны көлдереп тә алды.

– Борчылма, каениш, монда да менә дигән кәләш табарбыз, – диде җизни кеше, – апаң бу хакта күптәннән баш вата инде.

Чыннан да, икенче кайтуында Саҗидә сүзне шуннан башлады.

– Башлы-күзле булу – ир-атның Аллаһ алдында рәсүлебез Мөхәммәд галәйһиссәламнән килә торган изгедән-изге илаһи бурычы, – диде, – яшең җитте, шул хактагы уй-ниятләреңне беләсем килә.

Габдуллаҗан бу хакта авыз чайкарга яратмый, сүз башлаучыны да дорфа рәвештә ярты юлда туктата иде. Тик үзенә әнкә җылылыгы биргән кадерле апасына карата ул андый була алмый. Шуңа күрә әңгәмәне уен-көлкегә борып җибәрәсе итте.

> Хатын алмак читен бит һәм мәшәкать,
> Бер алгач, булмый бит шәйтанны ташлап...

– Габдуллаҗан, зинһар өчен, апаңны юләргә санама, мин чынлап сорыйм, – дип, Саҗидә аны бик тиз урынына утыртты.

Габдуллаҗан яртылаш буш чәй йомырысын ике учына йомып, әйләндергәләп торды да һаман шул юмор кысасыннан чыкмыйча әйтте:

– Апай, хөрмәтлем, мин, җүләр балык, үземә күрә генә түгел бит, бик четерекле кеше, әгәр ошатканым кире какса, егыл да үл инде. Күреп торасыз, кыяфәтем ташка үлчим...

– Тәүбә, тәүбә, каениш, үз өстеңә әйтмә, сөбханалла, бар җирең дә килгән, – дип, Әхмәтсафа да хәләленә ярдәмгә килде, – һәр мөхтәрәм татар кешесе синең белән туганлашуны зур дәрәҗәгә санар иде.

– Рөхсәт итсәң, димче хәстәрен үзем күрермен, – диде Саҗидә, – Ходайның рәхмәте белән, үзеңә лаек кәләш табылмый калмас, иншаллаһ.

Габдулла, урыныннан торып, тәрәзә каршына килеп басты. Урам кар яктысыннан гөлт итеп тора иде. Бер-берсен куыша-куыша, бала-чага чыр-чу килә. Бәгъзеләре чана тарткан, бәгъзеләре чаңгы шуа.

Их, шул гөнаһсыз, мәшәкатьсез балачакка кире кайтасы иде. Апасы да шушындый көйсез сораулар биреп тинтерәтмәс иде. Ә ул, әнә, түземсезлек белән җавап көтә.

– Димчеләр бар ул, апай, борчылма, – диде, ниһаять, Габдуллаҗан, – дустым

Фатихның әти-әнисе, Мөхәммәдзариф белән аның җәмәгате Рәбига абыстай, бер укымышлы хәлле туташны димлиләр, әйтүләренә караганда, инде яшәү урынын да тәгаенләгәннәр, бер бай йортының икенче катын килешеп куйганнар, имеш.

– И-и, рәхмәт төшкере, нигә аны әйтми торасың, бик хуш, бик хуш, энем, Ходай бәхетле тигез тормыш бирсен, – дип, Саҗидә энесен кочаклап алды.

Габдулла тирән сулап куйды, чөнки шул ук дусты Фатих аны моннан алдан Зәйтүнә исемле кодачасы белән таныштырган иде. Туташ аның бичара күңелен ашкындырып, күк кабагы ачылгандай бер ялтырап алды да, күздән югалды, Чистаена кайтып китте. Шигырь белән юаныргa калды.

И матур! Иренмәче, еш-еш кына көзгегә бак! –
Күр йөзеңне: нинди нурлы, нинди алсу, нинди ак!

– Апай, әйдә, бу турыдагы сүзләрне туктатып торыйк, – диде Габдуллаҗан, хатирәләреннән арынып, – барысы да Ходай кулында, Ходайдан узмыш юк. Иртәгә юлга чыгасы, көннәр генә буранламасын инде.

Көн буранламады, әмма шактый суыткан иде. Аяз зәңгәр күктә симез йолдызлар әле иртән дә күзләрен уйнатып, сүнә алмыйча җемелдәштеләр.

Габдуллаҗанга көн ошады, һәрвакыттагыча, теленә шигъри тезмә ятты.

Җидегәндә җиде кыз,
Ай янында Зөһрә кыз,
Таң янында Чулпан кыз,
Унике йолдыз – унике кыз,
Тимерказык берьялгыз.

– Тимерказык мин буламдыр инде, шулаймы? – дип шаяртты ул җигүле ат янында мәш килгән җизнәсен.

– Ыспай туңмас, калтырар, ди, әйдә, менә бу толыпны да киеп җибәр әле, май эчендә генә кайтырсың, – дип, Әхмәтсафа аңа толып кидерде.

– Апай биргән киез итекләр дә тап-таман, бияләйләре дә чак, – диде Габдуллаҗан, – толып та кигәч, мин чын ир-егеткә әйләндем инде, кара, ничек юанайдым.

– Телеңә салынма, җайлап утыр, кузгалдык, юл кешесенең юлда булуы мәслихәт, – дип, Әхмәтсафа кулына дилбегәсен тотты.

Аларны күтәрмә өстеннән кулын болгый-болгый, Саҗидә озатып калды.

– Хәерле сәфәргә!

Атна-ун көннән Габдуллаҗаннан хат килеп төште. Сәлам-рәхмәтләреннән тыш, анда түбәндәге үкенечле хәбәр дә урын алган иде.

«Апай! Киез итек һәм бияләйләр белән бик җылынып кайтсам да, киптерергә куйган җирендә киез итекнең берсен яндырдым».

Саҗидә тиз генә энесенә тагын бер пар киез итек бастырып җибәрде.

***

Еллар үтә, гомер сүтә, заманасына күрә манарасы корыла. Тузар илнең җәнҗалы – үктәбер инкыйлабы әнә ничек дөньяның астын-өскә әйләндереп ташлады. Иң яманы, кешеләр сыйнфый яктан икегә бүленде, дошманлашты. Дошманнар рәтенә, ни кызганыч, моңарчы халыкка аң-белем биреп, гыйлем нуры сибүче, рухи вә әхлак пакьлеге өчен җан атып тырышучы дин әһелләре дә кертелде.

Җиде бала атасы, илле сигез яшьлек Әхмәтсафа хәзрәт артыннан 1922 елның февраль аенда килделәр.

Кырлачның зәмһәрир салкын көне иде. Суыкка чыдый алмыйча, өй

бүрәнәләре шартлый, тәрәзә пыялаларында бер илле боз. Ярый әле тимер мич бар, бала-чага канат җылысында чебердәшкән чебиләр кебек шуңа елыша.

– Ут алганчы мал-туарларны карап керим әле, ашарларына да салыйм, – дип, Әхмәтсафа башына бүрек киеп, иңенә кыска тунын салган гына иде, ишек уемында сәүит кизүенең сыкыга сарылган малахае күренде.

– Әссәламегаләйкүм, исән-сау торасызмы?

– Аллага шөкер, Нурмөхәммәт абзый, сезнең хәер-фатыйхада.

Әхмәтсафа бияләйләрен кучкарга куйды да:

– Җүнне хуҗа этен дә урамга чыгармастай көндә нинди кичектергесез йомышка тардың? – дип сорады.

– Хөкүмәт эше бик уажный вазифа ул, әнәтрәк, менә сине райуннан килгән урындагы кешеләр сәүиткә терибе, – диде кизү, борынын чөебрәк, – бер аягың монда, икенчесе анда булсын, диеп, колагымны киртләделәр, әнәтрәк.

– Ярый соң, әйдә, киттек...

Алар артыннан ишек ябылуга, Саҗидә дә улы Габделвәһапларга чыгып йөгерде.

– Атагызны сәүиткә алып киттеләр, бу бер дә яхшыга түгел, – диде, күзләренә тыгылган яшьләрен сөрткәли-сөрткәли, – әнә, узган ел күрше авыллардан берничә мулланы Себергә сөрделәр бит, бик куркам, балам, бар, сөйләш, арала.

Габделвәһап нәкъ вакытында барып җитте, Әхмәтсафаны ниндидер кәгазьгә кул куйдырып маташалар иде инде. Ул, йөгереп барып, атасының кулындагы каләмен тартып алды да идәнгә бәрде.

Бу шулкадәр тиз һәм көтелмәгәнчә булды ки, бүлмәдәге киң якалы ак фабричный тунлы хәрби адәмнәр бермәлгә югалып калдылар.

– Бу бит һөҗүм! – дип кычкырды аңына килгән карсак гәүдәлесе, – властька һөҗүм!

Саргылт мыеклысы, маташа торгач, ниһаять, кабурасыннан наганын тартып чыгарды.

– Кто вы такой?

– Участник первой мировой войны, драгун конной армии, член солдатского реввоенкомитета, боец Красной Армии, участник разгрома белого генерала Колчака под Иркутском, ныне завдеревенской начальной школы Хабибуллин Габделваһап Ахметсафович, этот человек – мой отец.

– Мулла малае, димәк ки...

Карсак гәүдә җөмләсен төгәлли алмады, саргылт мыек Габделвәһапны кочаклап алды.

– Вагап, это ты чтоли, мы же однополчане, помнишь, ты служил в первом взводе, я – во втором, помнишь...

– Василий...

Полкташлар кочаклашып, бер-берсенә суккалап торган арада карсак гәүдә янә агуын сипте.

– Дошман ул, беләсең килсә, теләсә-нинди калыпка керә, хамелеон ул дошман...

– Ялгышасың, иптәш ВЧК вәкиле, безнең гаилә – авылыбызда совет властенең төп терәге, – диде Габделвәһап, – мин, хатыным Зәйнәп, сеңлем Өммеһания, балалар укыту белән бергә, агитация-масса эшләре алып барабыз, зурларны укырга-язарга өйрәтәбез. Әтием хәзер Совет властена теләктәш бер керәстиән, күптән инде муллалыктан читләштерелде.

Бу вакыйга менә шулай очраклы рәвештә хәвеф-хәтәрсез генә төгәлләнде. Шулай да Әхмәтсафаның муллалыгы яңа режимның тамагына кадалган сөяк булып кала биргән икән. 1937 елның кара көзендә аны янә исләренә төшерделәр.

– Хәбибуллин Әхмәтсафа шушы өйдә торамы? – дип, бер көн тужуркалы адәм ишекне каерып ачып килеп керде, – җыенсын, мин аны үзем белән алып китәм.

Өйдә Саҗидә үзе генә иде.

– И, иптәш-тауариш, Ходайга мең рәхмәт, ул сездән алданрак җитеште шул, – диде.

Җитмеш өч яшьлек Әхмәтсафаны әле бер атна элек кенә җирләгәннәр иде.

Саҗидә укытучы улы Солтанәхмәт тәрбиясендә калды. Ул сугышка алынгач, Норлат районындагы Бәчек авылы мәктәбендә директор булып эшләүче кызы Өммеһания әнисен, сеңлесе Әкълимәне үз янына алдырды.

Авыл халкы Саҗидәне үз итте. Хәер, шулай булмыйча, бөек Тукайның яраткан апасы лабаса! Өстәвенә, абыстай, имам җәмәгате. Ә борынгы мәчетле Бәчек динне уптым-илаһи читкә типмәгән, аны, ничектер, бер-берсенә каршы куймыйча, җайлап кына совет чынбарлыгына яраклаштыра алган.

Бу күркәм яңалык Саҗидәнең йөрәгенә сары май булып ятты. Сүз дә юк, абыстай исемен йөртү, шагыйрь апасы булу – танылу китерүче зур мәртәбә. Тик кеше кешене барыннан да элек кылган гамәлләренә карап бәяли. Шәхсән синең үз абруең булу зарур. Читтән килеп төпләнгән кеше өчен кемлегеңне таныту аеруча мөһим.

Саҗидәләр яшәгән мәктәп йортыннан ике генә өй аркылы Фәхрибану исемле ятимә карчык бар иде. Көннәрдән бер көнне буранлы төн караңгылыгында аның бердәнбер куанычы, бердәнбер туйдыручысы булган кәҗәсен бүреләр буып чыккан.

Бөтен авыл буенча өйдән-өйгә кереп, кан яшьләрен түгә-түгә, кайгысын сөйләп чыкты карчык. Хәленә керде авылдашлары, әмма ярдәм кулын сузучы табылмады, сугыш чоры бит, һәркемнең үз хәле хәл.

Директор өенә керергә кыенсынгандыр, күрәсең, аларга сугылмады, Саҗидә аны үзе эзләп тапты.

Карчык каушап төште, нишләргә белми, әле торып баса, әле утыра, ниһаять, аңына килеп, самавырына барып ябышты.

– Гаеп итмәссең инде, абыстай, табыным такы-токы, чәем дә сөтсез...

– Бер дә борчылма, Фәхрибану әби, Аллаһы боерса, иртәгә, әлхәмдүлиллаһ, сөтле чәй эчәрсең, сәдакаларымнан җыелган бераз акчам бар иде, кызым Әкълимә Норлат базарыннан кәҗә сатып алып кайтып бирер, – диде Саҗидә, – әйдә, хәзер бер дога.

Авыл аһ итте.

– Син инде бигрәк, әни, – диде Өммеһания дә, – юмарт йомран.

– Алай димә, кызым, – диде Саҗидә, – без бит тәкъваи заттан, Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәссәлам әйткән, кешенең йөзен дүрт нәрсә нурландырыр дигән: Аллаһыдан курку; сәдака бирү; мохтаҗларга ярдәм итү; рәхмәтле булу. Мин инде рәсүлебез яшен узып киттем, бакыйга нурлы йөз белән иңәсем килә.

– Кичер, әнием, шаяртып кына әйтүем, мин синең белән горурланам, гамәлләремдә дә сиңа охшарга тырышам, – диде кызы, – халык гаме үземә дә бик якын. Һәм ул моны исбатлады да.

Урып-җыю эшләренең иң кызган чагы иде. Карты-яше, олысы-кечесе, чирлесе-сырхавы, баласы-чагасы – барысы да басуда. Һәркем, хәленнән килгәнчә, тын белән өреп үстергәндәй үстергән ашлыкны бөртеген дә әрәм-шәрәм итмичә җыеп алуда үз өлешен кертергә тырыша. Укытучыларда берничә көймә койрыгы: көндез – агитаторлык, аңлату эшләре, кич – ындыр табагында ашлык иләү. Мәктәпне ремонтларга да вакыт табарга кирәк.

Өммеһанияне район вәкиле ындыр табагында эзләп тапты.

Чандыр гәүдәле, җитез хәрәкәтле, партия әһелләренә хас булганча, чыбыкны тоткан җиреннән сындырырга күнеккән үзсүзле бу әби авыз[1] ханымны ул өнәп бетерми иде. Әле дә, тагын нинди мөгез чыгарырга йөри инде бу, дип уйлап куйды.

– Иптәш Хәбибуллина, – диде вәкил рәсми кимәлдә, – фронтта хәлләр киеренке, фашист Кавказ, Түбән Идел буйларына омтыла, ләкин иптәш Сталин һәм Совет командованиесе моңа ирек бирмәс. Җиңү безнең якта булыр. Бу шартларда авыл эшчәннәренең төп бурычы – фронтка мөмкин кадәр күбрәк азык-төлек бирү. Кызганыч, колхоз икмәк тапшыру планын үтәп җиткерми...

– Болар миңа да мәгълүм, – дип бүлде аны Өммеһания, – вакытым тар, әйтегез әле, миңа нинди сүзегез бар?

– Миңа урлашулар турында сигналлар килә башлады, – диде вәкил, иреннәрен бөрештереп, – кыз-хатыннар ыштан төпләренә, ыштан балакларына кесә тегеп, бөртек урлап алып кайталар икән. Бу җинаятькә немедленно чик куярга кирәк, иртәгәдән басу капкалары янында эштән кайтучыларга поголовный тентү үткәрү максатка ярашлы булыр дип саныйм. Югары оч капкасына үзем басам, түбән очныкына сез басарсыз.

– Тентүне прокуратура карары белән милиция органнары гына үткәрә бит, миңа андый вәкаләт бирелмәгән, – диде Өммеһания, бераз уйланып торганнан соң.

Вәкил ханымның аскы ирене, бөрешеп, дуга рәвешенә керде, бүлтәеп чыкты.

– Иптәш Хәбибуллина, фронтка юриспруденция хикмәтләре түгел, ашлык кирәк, аңлыйсызмы, ашлык!

– Мин законга каршы бара алмыйм, – дип өзде Өммеһания, – хокукым юк.

– Мин сезне эштән кудырам! – дип төкерек чәчте вәкил.

Өммеһания аның эшеннән кудыруын көтеп тормады, үзе районга төшеп, райком секретарена керде, хәлне аңлатып бирде. Секретарь аның хәленә керде, уртак тел таптылар. Колхозга да яңа вәкил килде.

***

Бәчек Тукай рухы белән яши башлады. Саҗидәне әле клубка, әле мәктәпкә чакыралар, истәлекләрен сөйләтәләр. Ялындырмый, хатирәләре белән теләп уртаклаша. Бүген, әнә, шагыйрьнең туган көненә багышланган кичәгә алып килделәр.

– Нинди матур, күркәм яз килә, – дип башлады ул чыгышын, – Габдуллаҗан тәүге мәртәбә җиһанга аваз салганда да көн менә шулай якты, кояшлы, җылы булган. Җир инде уянган, басу эшләре гөрли. Сабан эзеннән чыр-чу килеп, кошлар җим чүрли, зәңгәр күк өстендә тургай моңы. Күңелләрдә – өмет, йөзләрдә – шатлык, кулда – эш. Шулай, язган булыр яз башында, ди. Ындырда ыңгырашмыйм, дисәң, сабанда сайрашу зарур.

Бераз күрсәтер чын төсен җир,
Чәч орлык, сөр сабан инде, бу – чын җир, –

дип тәкрарлар әлеге Кушлавыч малае, зур үскәч.

– Тукайның бала чагы авыр һәм михнәттә үткән, – дип торып басты сугышта уң кулын калдырып кайткан Мәхмүт исемле фронтовик, – бу – реаль тормышта балаларга карата мөнәсәбәтенә тискәре йогынты ясамаганмы?

Саҗидә яшел камзулына җыерылыбрак төшкән француз яулыгын рәтләгәндәй итте дә:

– Киресенчә, ул балалар күрсә, дөньясын оныта иде, үзе балага әверелә иде, Өммеһания шаһит, әнә, – диде.

[1] Әби авыз *(фраз.)* – өске ирене нечкә-юка булып та, аскысы зур һәм салынкы булып торган авыз.

– Мин – Габдуллаҗан абыемның сыртына атланып, күп юллар үткән данлы шәмсуар, – дип, кешеләрне көлдереп алды Өммеһания, – ул – толпар, мин – җайдак.

– Беркөнне энем Кәшфелкәбирнең кызы Нурания дә көлдерде әле, – дип дәвамлады Саҗидә, – Габдуллаҗан, Өчилегә кунакка кайткач: «Нурания, песиең бик каралган, бар мунчада юып кайт», – дип әйтә икән. Кызчык песи баласын култык астына кыстырып киткән, ә мунча ягылмаган.

Әйе, шаянлыгы, җорлыгы хәттин ашкан иде. Менә, этисе ягыннан туганы Газизә Зәбирова сөйләгәннәрдән бер рисалә.

Габдуллаҗанның Галиәсгар җизнәләренә килгән көне була бу.

Газизә әле генә бик кадерләп төреп куйган намазлыгын таба алмый интегә. Бөтен җирне актара, ә намазлык юк, ут була да су була. Бәлкем, аш бүлмәсендәдер?

Кереп бакса, энесе әлеге мазалы намазлыкны бау белән биленә бәйләп куйган да, җиң сызганып, савыт-саба юып йөри икән.

– Габдулла, ни эшең бу, намазлыкны билгә бәйлиләрмени? – дип орыша апасы.

– Һи, апай, – ди Габдуллаҗан, – исең китмәсен иске чикмәнгә, без мәдрәсәдә аш-су пешерсәк тә, кашыгаяк юсак та, корымлы чуенны мичкә куярга кирәк булса да, намазлык тотабыз, – дип, ирен чите белән генә елмая.

– Алъяпкыч алып кит, бездә күп алар, – ди Газизә.

– Әй, апай, алъяпкыч итәргә иң җайлы нәрсә шул намазлык инде ул, – ди шук шәкерт.

Рисаләне Мәхмүт җөпләп куйды.

Күп яттык без мәдрәсәдә,
Аңламадык бернәрсә дә...

– Мәхмүт, Тукай иҗатына хәерхаһ икәнсең, – дип, Өммеһания егетне мактап алды, – сиңа сугыш бүлгән укуыңны дәвам итү бик мәслихәт булыр иде.

– Рәхмәт яхшы сүзегезгә, мин, тизләтелгән тәртиптә уку өчен, Норлат урта мәктәбенә гариза язып бирдем инде, – диде Мәхмүт, – гуманитар юнәлешне үз итәм, шул юнәлештәге югары уку йортына керергә планлаштырам. Тукай иҗаты аеруча якын. Тукай бит ул – киләчәктән җибәрелгән бөек зат, һәр чор өчен дәва. Шәрәф Мөдәррис бик дөрес яза:

Әй Тукай, ил һәм гасырда ялкының янган Тукай,
Ай-кояштан, хөрияттән яктылык алган Тукай.
Караңгы төн караңгысын яшендәй ярган Тукай!

Инде тәкъдимем: безнең колхозга Тукай исемен бирү бик мәгъкуль булыр иде.

Залдагылар, фронтовикның тәкъдимен хуплап, гөрләтеп кул чаптылар.

***

Мәхмүтнең тәкъдиме район җитәкчелегендә дә зур каршылыкка очрамады, гомуми җыелышка куеп тикшерегез, без, шуннан чыгып, тиешле чарасын күрербез, диделәр.

Җыелыш әүвәл дала елгасында аккан судай ипле генә, тавышсыз-тынсыз гына барды, каршы килүче табылмады.

– Тавышка куегыз, мәсьәлә ачык, кул күтәрәбез дә, бетте-китте вәссәлам, – дип кычкырды урыннан берәү.

– Дөрес, дөрес, – дип шаулашты башкалар, – әйдәң, кул күтәрик...

– Иптәшләр...

Рәис бүленде, чөнки моңарчы авызына су капкандай дәшми-тынмый гына утырган тарих укытучысы Рәсимә Саматова торып басты.

– Минем фикеремне дә протоколга теркәгез әле, – диде кырыс карашы аша, – безнең җыелыш баштанаяк милләтчелек сөреме белән сугарылган. Бу оппортунистик идеологияне фаш итүне мин үземнең большевистик бурычым дип саныйм.

Колаклар үрә торды, утыз җиденче ел җилләре искәндәй, зал шым булып тынып калды.

– Рә-рә-хим итегез, Рә-ә-симә Фәлаховна, – диде рәис, тотлыга-тотлыга, – бездә сүз иреге...

Рәсимә озын буе өстеннән генә кешеләргә сөзеп карап алды да дәвамлады:

– Мин, иптәшләр, колхозның исемен үзгәртергә каршы түгел. Чыннан да, «Ызандаш», «Сабанчы», «Уракчы» кебек нейтраль исемнәр сәяси кыйммәтен югалтып баралар. Самат батрак, күмәк хуҗалык активисты кызы буларак, мин колхозга изүче сыйныф, буржуазия вәкиле, мулла улы, ата милләтче Тукаев исемен бирүгә категорически каршы.

– Тәкъдимегез!

– Без – интернационалистлар, – диде Рәсимә, төкереген йотып, – фәнни коммунизмга нигез салучы Карл Маркс, Фридрих Энгельс, мисал өчен...

– Районда алар исемендәге хуҗалыклар бар ич инде, – диде рәис.

– Беләм, ә менә Клара Цеткин? Бу бөек революционер исеме колхозыбызның абруен ныгытыр, аны халыкара масштабка күтәрер иде.

– Чурту-матер, ничу юкка тел чарларга, калсын элекке исем, – дип оран салды көмеш сакал иясе агай.

– Синең тәкъдимең дә теркәлә, Мөхетдин абзый, – диде рәис, – ә хәзер Өммеһания Әхмәтсафовнага сүз бирәм, күптәннән чиратын көтеп утыра.

Өммеһания заманча зәвыклы кара жакеттан иде. Габдулла Тукайның 60 еллык юбилее уңаеннан бүләк ителгән бу жакетны ул бүгенге кебек аеруча тантаналы вакыйгалар уңаеннан гына кия. Ак ефәк яулыгы да бик килешле, кура җиләге кебек тулышкан нәфис алсу йөзенә нур өстәп, ялык-йолык ялтырый. Урта бармак шикелле чибәр мөслимә, бөтен килеш-килбәтеннән затлылык, садәлек бөркелеп тора.

– Мин, хөрмәтле иптәшләр, колхозга нинди исем бирү мәсьәләсенә тукталып тормыйм, бу күмәк хуҗалык әгъзаларының, ягъни сезнең теләккә бәйле, нинди исем телисез, шуны кушасыз, – дип башлады сүзен калтыраулырак тонык тавыш белән, – мин Рәсимә Фәлаховнаның чыгышы уңаеннан гына сезгә аңлатма бирүне кирәк саныйм. Чөнки халкыбызның бөек шагыйре, күренекле җәмәгать эшлеклесе Габдулла Тукайга нахак бәла тагу – ул бөтен татар милләтенә пычрак ату белән бер.

Аңлатмамны изүче сыйныф кәсафәтеннән башлыйсым килә. Ятимлектән интеккән, кеше өстендә гомер кичергән, ач-ялангачлыкта аздан гына исән калган Габдулланы изүче сыйныфка тәгаенләү бернинди кысаларга да сыймый, әлбәттә. Аны мулла малае булган өчен битәрләү дә – тар карашлылык билгесе. Чөнки Октябрьга кадәрге барлык татар зыялылары да – дин әһелләре гаиләсендә тәрбия алган кешеләр. Аларны чүплеккә чыгарып ташласак, кемебез калыр соң?

Революция бу тигезсезлекне төзәтте, кыска гына вакыт эчендә эшче-крестьян интеллигенциясе үсеп чыкты. Рәсимә Фәлаховна да – шуларның бер мөхтәрәм вәкиле.

Тукайның дөньяга карашы, җәмгыяти позициясе ул уралган мохиттән чыгып тәгаенләнә. Аның теләктәш фикердәшләренең берничәсен генә атап узам. Болар – социаль-демократик «Урал» газетасын чыгаручы РСДРП әгъзасы Хөсәен Ямашев.

Көч белән бергә гүзәллекне җыйган диңгез кеби,
Ул иде өстен вә кул җитмәс кеше, йолдыз кеби.

Янә дә татар пролетар әдәбиятына олы юл ачкан Гафур Коләхмәтов. Алар күп, беренче татар милли театрын оештыручы Габдулла Кариев, драматург Галиәсгар Камал...

– Өммеһания Әхмәтсафовна, Тукай үзенең «Сорыкортларга» дигән шигырендә кемлеген ачыктан-ачык белдерә ләбаса.

Чебен җанымны чын юлда бирәм бең кәррә[2], кызганмыйм,
Минем чөн мәсләгем-юлым бөтенләй социаллардай.

– Рәхмәт ярдәмеңә, Мәхмүт, – диде Өммеһания, сәгатенә күз төшереп, – гафу итегез, озынрак сузылды, дин мәсьәләсенә генә тукталам да тәгәллим...

– Кирәкми, «Ишан» шигыре барыбызга да мәгълүм, – дип аваз салды зал.

Рәис маңгаена бәреп чыккан тир бөртекләрен кул аркасы белән генә сыпыргалап ташлады да:

– Иптәшләр, тәкъдимнәрне керү тәртибеннән тавышка куям, – диде.

Аны янә бүлделәр. Мәхмүт, нык-нык атлап, халык каршына чыгып басты да, солдатларга хас көчле калын тавыш белән, җыр башлады, аңа башкалар кушылды:

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

Тарих укытучысы да Тукай исемен хуплап тавыш бирде.

Җыелыштан кайткач, Сәҗидә:

– Син Габдуллаҗанны дәһри затка, динсезгә чыгардың, – дип, кызына үпкәсен белдерде, – йөрәгем бик әрнеде, шикәрем дә күтәрелде...

– Үзең күреп-ишетеп тордың ич, әни, шулай кирәк иде, – дип акланды Өммеһания.

***

Шушы мәшәкатьле вакыйгалар йогынтысы идеме, күптәнге сырхаулары борын күтәрдеме, иртә таңда Сәҗидә йөрәк өянәгеннән уянып китте.

– Кызым, Коръәнне күкрәгемә куй, – диде кысылган тыны аша, – бәх-хил булыгыз...

Әкълимә йөгертеп кенә фельдшерны алып керде, шөкер, күршедә генә иде.

Өммеһания авылда бердәнбер телефон аппараты куелган Авыл советына йөгерде. Баксаң, элемтә өч көн элек үк өзелгән булган икән инде. Бәхетенә, колхозның бер көн эшләп, өч көн ремонтта тора торган хәрабә машинасы бүген аякта иде. Сәҗидәне шуңа утыртып, район хастаханәсенә алып килделәр.

– Инфаркт, – диде табиб, – хәле җитди.

– Өмет-ышаныч бармы? – дип белеште Өммеһания.

– Канында шикәр микъдары бик югары, – диде табиб, – диабет хәлне бик катлауландыра, без кулдан килгәннең барысын да эшләрбез, әлбәттә, ләкин өздереп кенә бернәрсә дә әйтә алмыйм, хәстәрен күрә башласагыз зыян итмәс.

Өммеһания туганнарына телеграмма сукты. Иртәнгә Каенсардан хатыны Зәйнәп белән Габделваһап, Казаннан Фатыйма белән Нурдидә хастаханә капкасы янына килеп басканнар иде инде. Мәсрүрә генә күренми, Орнашбашка телеграмма барып җитмәгән, күрәсең.

Чиратлашып әниләрен сакладылар.

Ходайның рәхмәте, биш көннән Сәҗидәнең иреннәренә алсу төс керде,

[2] Бең кәррә – мең тапкыр.

тамагына сөтле чәй йотып куйды. Кичке якта теле кайтты. Бу Габделваһап кизү торганда булды.

– Улым, оныкларым ни хәлдә, исән-саулармы?

Тәүге соравы шул булды.

– Аллага шөкер, исән-саулар, әни, сигезе дә тыпырдап тора, төпчегебез Нуриягә дә биш яшь тулды бит инде, Камил үзе эти кеше хәзер...

– И, шул туган-үскән җирләрне кайтып күрергә иде, – диде Саҗидә, – этиеңнең каберен зиярәт кылып, догаларымны ирештерәсем килә...

– Тизрәк терел генә, әни, машина белән килеп алырмын, теләсәң, үзебездә яшәргә калырсың, – диде Габделваһап, шатлык тулы яшьләренә игътибар итмичә, – тизрәк терел генә, әни...

Акрынлап аягына да басты Саҗидә, ләкин аңа ерак юлга чыгу насыйп түгел иде инде.

Әкълимәнең апалары янында Казанга урнашып, бер-бер һөнәр үзләштерү, эшкә керү, үз көнен үзе күрү турындагы хыялларына да шул рәвешле нокта куелды. Әнисе тулысы белән аның карамагында калды.

Салмак агышлы, иртәнге сәхрәгә охшаш тыныч вә тәкъваи ихтиятан тормыш башланды. Хәер, бу тормыш ара-тирә арыш басуы өстендә уйнаучы төнге аҗагандай ялкынланып-ялкынланып та алгалый иде.

Беркөнне Саҗидә бакчада мәчедән котылып калган чыпчык баласына тап булды. Чырыш бала булса кирәк, бирешмәгән. Әмма шактый тәпәләгән үзен теге явыз, бер канаты каерылган, дер-дер калтырана.

Мәшәкать чыкты абыстайларга, атна-ун көн шушы бичара кошчык белән мәш килделәр. Тегесе дә ятсынмады, чәбәләнмәде дә.

– Өйдә генә тотарбыз инде моны, – диде Әкълимә, – әнә ничек тиз ияләште, чырык та чырык, куанычы эченә сыймый.

Ә чыпчыккай, хәлләнүгә, тәрбиячеләрен хафага салып, үз дөньясына очты. Шулай да ерак китмәде, өй кыегындагы буш сыерчык оясын үз итте.

Көннәрдән бер көнне исә дөпһәтән сайрарга да тотынды бу.

– Әстәгъфирулла, теге кыбырсык сыерчык тавышы чыгарып сайрый бит, әни, – диде Әкълимә, – вәйт әртис.

– Сөбханалла, әррахмәниррахим, мәлики йәүмид дин...

Чыпчык шулай, һәр иртәдә әле сыерчык шикелле сайрап, әле песнәк кебек чүтелдәп, тәрбиячеләренең күңелен күтәрә торган булып китте.

– Яхшылыкка – яхшылык, бу Ходай рәхмәте инде, кызым, – диде Саҗидә, – догада булыйк.

Төн ярканат теләге белән йөрми. Кеше тормышы да инсанның дөньяви мәнфәгатьләренә буйсынмый, аның чоңгыллары, сикәлтәләре, бормалары бихисап. Һәм алар, башлыча, искәрмәстән, көтмәгәндә генә калкып чыгалар. Әле дә тагын да саллырак, тагын да мөһимрәк бер вакыйга гомергә телдән төшмәс төсле тоелган әртис чыпчык маҗарасын читкә тибеп ташлады.

Мәхмүт Өммеһанияне сорарга килде. Гимнастёркасын юган, сырлар чыгарып үтүкләгән, җиз пүгемисләре ялык-йолык җемелди. Якасына ап-ап эчлек теккән, итекләре майланган. Кыскасы, менә дигән кияү егете.

Исән кулы белән тамаша остасы җитезлегендә өстәлгә (каян юнәткәндер) бер төргәк кәнфит-прәннек сипте дә үгезне мөгезеннән алып әйтте:

– Саҗидә абыстай, гафу үтенәм, мин кыз сорауның нечкәлекләрен белмим, сүзем солдатларча кыска һәм туп-турыдан булыр, нәкъ Тукайча: күз аттым мин бүген бер шәп кәләшкә. Бу кәләш – Өммеһания. Бирегез аны миңа.

Тынлык урнашты. Өйгә ачык тәрәзәдән чыпчык чыркылдавы кереп тулды. Ул бүген сайрамый, күгәрчендәй гөрли иде. Тик аңа игътибар итүче булмады.

– Заманалар үзгәрде бит, Мәхмүт энем, – диде Саҗидә, озак кына уйланып торганнан соң, – хәзер өйләнешү-кавышу хәлләрен егет белән кыз үзләре хәл итә, дип беләм. Әгәр Өммеһания...

– Әйе, – диде бу манзараны әле генә кайтып кереп, ишек катында тыңлап торучы Өммеһания, – без Совет чорында яшибез һәм бу мәсьәләне икәүдән-икәү генә, үзебез генә хәл итәргә тиеш. Әйдә, Мәхмүт, бераз йөреп керик, шунда барысын да ачыкларбыз.

Ишек ябылуга, Әкълимә энисенең кочагына килеп керде дә:

– Их, безгә мондый бәхетләр тәтемәс инде, – диде офтанып, – каһәр суккан сугыш кияү егетләрен йотып бетерде бит, минем Хафизым да чит җирләрдә ятып калды, ә нинди мәхәббәт хатлары яза иде... Нурдидә апаемның сөйгәне дә...

– Алай димә, кызым, – дип юатты Саҗидә төпчеген, – таифән нисаэ – хатын-кызның кырык бер чырасы бар, берсе янмаса, берсе янар, ди, Ходайның рәхмәте киң, насыйбыгыз чыкмый калмас.

Өммеһания соң кайтты. Тавыш-тынсыз гына чишенде дә, тавыш-тынсыз гына юрган астына кереп чумды.

Иртән иртүк аның үкси-үкси елавыннан уянып киттеләр. Әмма берсе дә сүз кушарга кыймады, яшь аралаш үзе хисен түкте.

– Яраткан кеше йөрәк парәсенең артыннан йөри ул, озатып куя, каршы ала, назлый, коча, үбә... Мәхмүтнең кулымнан да тотып караганы юк бит ичмасам, һаман сүз дә сүз... минем алай хиссез, яратусыз, кияүгә чыгу кирәк булган өчен генә кавышасым килми... аннан, безнең яшь аермасы да шактый.

Барысы да аңлашылды, Өммеһания тәкъдимне кире каккан.

Мәхмүт шуннан соң күзгә-башка күренмәде, Норлаттагы туган апасы янына күченеп киткән, дип сөйләделәр.

***

Табигатьнең салкыннарны өнәмичә, соңгы яфракларына кадәр тартышып өзгәләнгән мәле иде. Ишегалдында көз, таң атып өлгерми, кич була, ара-тирә катканаклы җир йөзенә кырпак кар бөртекләре дә төшкәли.

Шушы юл-сәфәргә бимаһир көннәрнең берсендә Бәчеккә Татарстан радиосыннан журналист килеп төште. Ачык йөзле, төче сүзле, хөр күңелле, сәләтле, үз һөнәренә баштанаяк бирелгән чибәр генә кыз икән. Гомер буе дуслашып, аралашып яшәгән әһле якын кешедәй, ишектән килеп керүгә: «И, Саҗидә апай-җаным, бигрәкләр дә күркәм зат инде син, матурлыгың да, акыл-зирәклегең дә ташып тора», – дип сөйләнә-сөйләнә, итәгенә ярты кадак бөртек чәй, бизәкле яулык, бер исле сабын китереп салды.

Саҗидәнең йөрәге лепердәп китте. Энесе Габдуллаҗан Җаектан аңа нәкъ менә шушындый күчтәнәчләр җибәрә иде ич.

– Исегезгә төштеме, апай-җаным? – диде журналист кыз, – Тукайның замандашы, дусты Миргазиз Укмасига биргән интервьюыгызда сез шушы бүләкләрне искә аласыз, мин шуны кабатларга җөрьәт иттем, ачуланмыйсыздыр бит?

– Рәхмәт, сеңлем, мин инде күптәннән шул хатирәләр дөньясында яшим, – диде Саҗидә, – гомер ахырында алар гыйбадәт кылу белән тиңләшә икән.

Журналист әңгәмәгә әнә шулай җайлы гына сукмак салып куйды.

Сораулары да четерекле, тапталмаган, моңарчы шагыйрь тормышының читтәрәк калып килгән бәхәсле якларына багышланган иде.

– Саҗидә апай-җаным, Габдулла Тукайның Җаектан сезгә 1903 елның июнь аенда язган хатыннан бер өзек укыйм, бик авыр булмаса, шуны шәрехләгез әле, – дип, әлеге текстны укып чыкты.

– [. . .] дия золым-җәберләрнең җәрәхәте җәннәте гаденгә керсәм дә, йөрәгемдән китмәс. [. . .]ләр дә шуның тәвабигыннан иде [. . .]... дөрестен әйтеңез. [. . .] хәзер ничек тора, һәм дә ул да Саҗидә апай илән бер атадан, бер анадан туганмы?

Сүз, белүемчә, сеңлегез Гөлчәһрә турында бара. Бу катгыйлыкның сәбәбе нидә?

Саҗидә, яулыгын рәтли-рәтли, җиңелчә генә көлемсерәгәндәй итте дә:

– Бала чак бит, Габдуллаҗанга – биш-алты, Гөлчәһрәгә тугыз-ун яшь, икесе дә башбирмәс затлар. Кирелектә, үзсүзлелектә Габдуллаҗан да апасыннан калышмый иде. Мин сезгә, сеңлем, икенче хатны да укып карарга киңәш итәр идем.

– Мин аны яттан беләм, – диде журналист. – «Кадерле һәм хөрмәтле тутабыз Гөлчәһрә белән хөрмәтле һәм кайгыртучан җизнәбезгә, барлык гаиләсенә чиксез күп һәм бетмәс-төкәнмәс сәламнәребезне җибәреп ирештердем».

– Менә бит, соравыңа үзең үк җавабын да бирдең, – диде Саҗидә, – халыкка да шуны җиткерү зарур, энәдән дөя ясарга ярамый.

– Мин монда, сезнең янга, шуның өчен килдем дә инде, апай-җаным, – диде журналист, микрофонын җайлый-җайлый, – инде чираттагысы, берүк рәнҗи күрмәгез, сез әниегез Латыйфа абыстайны ярата идегезме?

Саҗидә җавап бирергә ашыкмады.

– Латыйфа абыстайның усал, дорфа, кешелексез дигән яманаты чыккан, – дип, кыз соравын конкретлаштыра төште.

– Бу – кайбер галим-голамәнең, журналистларның нахак уйдырмасы, – дип, сүзләрен пичәтләде, ниһаять, Саҗидә, – ни кызганыч, монда Габдуллаҗанның үз өлеше дә бар.

– Ничек?

– Аның «Исемдә калганнар» рисаләсендә безнең Өчиледәге тормышыбыз яктыртылган. Әйтик, Габдуллаҗан үзе язганча, алты күгәрчен арасында һич тә чәүкә түгел иде ул. Әтием Зиннәтулла хәзрәт аны бик ярата иде, барча кылган гамәлләре оныгының гомерен саклап калуга юнәлдерелгән иде. Без, барыбыз да, бергә әүмәкләшеп үстек. Бу – бер. Икенчедән, ире үлеп, тол калган әнием Латыйфа абыстайга, әти белән кушылганда, нибары унҗиде-унсигез яшь була. Ул ничек алты бала ияртеп килсен?

– Бу хакта энегезгә әйткәнегез булдымы?

– Әйтмичә, әйттем, әлбәттә. Ә ул рисаләсенең беренче бүлеген тәмам иткән җөмләсен укып күрсәтте. Анда: «Бу урында игътибарән тәрҗемәи хәлемне үземдән хикәя итүне күңелем хаклы тапканга, «булган»ны – «булды»га, «йөргәнмен»не, «йөрдем»гә алмаштырам».

– Димәк, ул беренче өлешне кеше сөйләве буенча, ишеткәннәреннән чыгып кына язган, ә кешеләр гайбәттән хали түгел, шулаймы?

– Хак, сеңлем, без әле һаман Тукай турында язылган китапларда ияреп килгән килмешәк балалар булып саналабыз[3]. Мескен ул Шәрифә карчыкны ничек кенә мәсхәрә итмиләр? Ятим баланы караган өчен, үзенә Аллаһыдан савап кына килә, югыйсә, урыны оҗмахта булсын.

Латыйфа абыстайга килгәндә, сеңлем, җиһанга алты нарасый китергән мөслимәгә «усал» дигән ярлык тагу, тәүбә-тәүбә, дәһри гамәл, гөнаһлы гамәл. Ана – изге зат. Мөхәммәд галәйһиссәлам дә мөселманнарны аналарны рәнҗетмәскә өнди, Җәннәт аналар аяк астында, дип кисәтә.

[3] Ниһаять, әлеге төгәлсезлекләргә рәсми рәвештә нокта куелды. 2016 елда нәшер ителгән «Габдулла Тукай энциклопедиясе»ндә күп кенә бәхәсле мәсьәләләргә ачыклык кертелә *(авт.)*.

Без әниебезне бик яраттык, әле дә көн саен аның рухына дога юллыйбыз.

Журналист кыз, песи баласын иркәләгәндәй, Сәҗидәнең кул аркасыннан сыйпаштыра-сыйпаштыра сөеп торды да:

– Апай-җаным, тагын бер генә үтенечем калды, мөмкинме? – диде.

– Мондый ягымлы, тәмле телле чибәркәйгә ничек каршы киләсең инде, – диде Сәҗидә, – мөмкин-мөмкин, әйдә, сора.

– Тукайның атасы ягыннан туганы Газизә Зәбирова Казанда яши, Бәчектән кайткач, мин аның белән дә әңгәмә корачакмын. Сезнең мөнәсәбәтләр ничек, элемтәгез бармы?

– Казанда Тукайга багышлап үткәрелгән кичәләрдә бергә утырабыз, – диде Сәҗидә, – без бер елгы бит, шөкер, миңа караганда, Газизәнең сәламәтлеге күпкә әйбәтрәк, Ходай озын гомер бирсен.

– Тукайның вафатыннан соң, Газизә апа «Кояш» газетасында мәрхүмнең «биш йөз рублядән артык акчасы калмыш» турындагы хәбәрне укыгач, редакциягә үзенең хакыйкый варис булуын белдереп хат юллый. Энегез Габдуллаҗанның мирас язмышы сезгә мәгълүмме?

Сәҗидә бушаган чәшкесенә чәй агызып, самавырдан кайнар су өстәде дә бер-ике йотым эчеп куйды. Аннан соң учы белән итчән йомры ияген сыпыргалап алды, озак кына тәрәзәгә төбәлеп карап торды. Шуннан соң әйтте:

– Сеңлем, бу хакта Газизәнең үзеннән сора инде, яме, – диде, – Тукайның асыл мирасы – аның әсәрләре. Ул әсәрләр бөтен татар халкыныкы.

Әтиебез Зиннәтулла хәзрәт безне, бу дөньяда үлми һәм бетми торган бер генә нәрсә бар – ул тапсыз исем, дип өйрәтеп үстерде. Аллаһының рәхмәте белән, шөкер, байлык артыннан кумадык, нәселебез исеменә тап төшермәдек. Шуңа куанып яшибез.

– Сезнең нәсел, Сәҗидә апай, рухани җанлы, зыялы нәсел бит ул, – дип, журналист янә үтенечен тәгаенләде, – Зиннәтулла хәзрәт тә, Бибимәмдүдә абыстай да шигырь язган. Сез үзегез дә каләм тибрәтәсез. Радио тыңлаучыларны иҗат җимешләрегез белән дә таныштырып үтәсе килә. Зинһар өчен, апай-җаным, берәр шигырегезне сөйләгез әле.

Сәҗидә карышмады да, ялындырмады да.

– Ярар соң, Ватан сугышында хәбәрсез югалган улым Солтанәхмәткә багышлап чыгарган шигыремне сөйләп карыйм алайса, – диде. – Озынрак шул ул, ошатырсың микән, – дип тә өстәде.

– Зыян юк, апай-җаным, рәхим ит.

Бүлмә эче Сәҗидәнең күкрәгеннән агып чыккан таң чишмәседәй сагыш катыш яңгыравыклы саф тавышы белән тулды.

Кайда киттең, балам, син югалдың,
Беләсеңме әнкәң калганын?!
Сине сагыну минем күкрәгемдә
Мәңгелеккә урын алганын?!
Сайрамачы, былбыл, ник сайрыйсың?
Өзелә үзәк синең тавышка...

– Афәрин, Сәҗидә апай, мең-мең рәхмәт, инде, чыннан да, иң соңгысы, әйтегез әле, зинһар өчен, Тукай халкыбыз өчен барыннан да элек кем ул? – дип, журналист кыз әңгәмә иясенә текәлеп бакты.

Сәҗидә битенә дога иңдерде дә, башын кыңгыр салып, сүзләрен мөһерләде:

– Тукай – татар милләтенең намус сагында торучы пәйгамбәр ул.



Таһир
Шәмсуаров

# ХӘТЕРЛӘРНЕ ЯҢАРТ ТЫН ГЫНА...

## Тел елый...

Тел кирәкми?.. Күзге яңгыр
Йөзләремә яшь сылый.
Гарьлегеннән түзәлмичә,
Ил өстендә тел елый.

Бишек җыры көйли-көйли,
Җанга иман салган тел.
Ватан китсә, сөте булып,
Үксез итми калган тел!

Эчкән суым, сулар һавам,
Бүгенгем, киләчәгем.
Дөньядагы бар нәрсәне
Тик синнән беләчәгем.

Кол Гали, Тукай сүзләрен
Кабат искә алырбыз.
Без тарихта телле булдык,
Телле булып калырбыз!

Тота да бу көзге яңгыр
Йөзләремә яшь сылый.
Каргамыйча, гарьлегеннән
Ил өстендә тел елый!..

Таһир ШӘМСУАРОВ (1954) – *шагыйрь; «Җанлы шәм», «Яратудан тора җир шары», «Ярату белән» һ.б. китаплар авторы. Лениногорскида яши.*

## Авыл

Авыл киче, теләмичә, алсуланып кояш бата,
Кич утыру гадәте бар – сала халкы бик соң ята.
Олысының-кечесенең җаны керсез, якты уе,
Татарлыгын ачып сала ямьле җәйдә Сабан туе.

Милләт язмышы биредә, бишегендә – татар теле,
Авылымның нигез ташы – бер, бердәнбер ислам дине!
Монда минем тамырларым, монда ята анам-атам,
Бәхет кошы оялаган авылымны бик яратам!

Иген игә ул бүген дә, язын чәчә, көзен ура,
Җиң сызганып, зарланмыйча, ил амбарларын тутыра.
Төп байлыгы – кешеләре гомер бакый төпле, зирәк,
Илең имин торсын, дисәң, менә шушы авыл кирәк.

Җырлыйм да мин, елыймын да, вакытлыча ерак китсәм,
Кайту белән очып йөрим, җәйрәп ята, авыл – исән!
Бар талы да сандугачлы, ияләшкән бетмәс бер моң,
Чормасыннан төшеп килә түзалмыйча тальян гармун.

Кайберәүләр, ятма монда, калага кит, шагыйрь, диләр,
Кендек каны тамган җирне ташлау мөмкинмени, җүләр!
Нәни ил дип юкка гына атамаган ата-баба,
Кич җитсә дә, йокламый ул, йөзен борган көнгә таба...

## Табыну

Урта диңгез дулкыннары сыман
Бәргәләнгән чагы җанымның.
Алания буйлап йөрегәндә,
Гади кычытканны сагындым!

Күз күрмәгән илгә юнәлсә дә,
Туган җире истә кешенең.
Балачакта колач җәеп йөзгән
Шушма, сине искә төшердем...

Серле мәгарәгә менгән мәлдә
Бер сулкылдап типте йөрәгем.
Шандорга тиң биек текә тауны –
Бөек тауны монда күрмәдем.

Кипарислар, фикус, пальмалары –
Бар да гүзәл, исләр китмәле.
Тизрәк кайт, дип калган сандугачлы
Бөдрә таллар миңа җитмәде!

Төрек җырын тыңлап утырганда,
Моңга сусау телде бәгырьне.

Анталия уртасына басып,
Мин җырладым безнең «Шөгерне».

Юк, мин башка ташлап китә алмам
Кендек каны тамган җиремне.
Бүген төштә Казан урамыннан
Кол Шәрифкә таба йөгердем!

Урта диңгездәге көймә сыман
Бәргәләнгән чагы җанымның.
Солтан иле буйлап йөргәндә,
Гади кычытканны сагындым!

## Саҗидәсен халык сагына

*Шагыйрә Саҗидә Сөләймалованың*
*якты истәлегенә багышлана.*

Тезелешеп кошлар китеп баргач
Вакытлыча торыр ягына,
Каен яфраклары телгә килә:
«Саҗидәсен Әлмәт сагына!»

Ул болай да бәгырьләрдә иде,
Көткән бер моң иде һәр өйдә.
Басмасыннан офыкларга багып,
Керләр чайкый иде Саҗидә!

Холкы шундый, халкы шундый инде,
Карый җиргә күзе моңаеп.
Онытмаган газиз халкым, диеп,
Күр, Саҗидә карый елмаеп.

Шагыйрьләргә шулай язылгандыр:
Ак каләмен хискә мана да
Гасырларның күрке саналырлык
Җыр калдыра чиксез җиһанда.

Игезәге иде ул өметнең,
Язны күрде кышның карында.
Тел – мәңгелек, яши, яшәячәк,
Нәни иле – авыл барында!

Кайберәүләр Тукай исеменнән,
Кабаланып, бүләк алганда,
Шагыйрәсе белән күрешергә
Татар килә шушы мәйданга.

Тезелешеп кошлар китеп баргач
Вакытлыча торыр ягына,
Күзгә яңгыр туры җанга тама,
Саҗидәсен халык сагына!

## Рәнҗетмәгез

Рәнҗетмәгез туган нигезләрне,
Күрә торып читкә какмагыз.
Әти-әни төсе җуелмасын,
Күз карасы төсле саклагыз!

Сатылган йорт түзми, елый, диләр,
Җаны барның килми китәсе.
Күз күрмәгән җирдә каршы ала
Сандугачлы җәйнең иртәсен.

Буш нигезгә бәхет ояламый,
Йөгермиләр нәни балалар.
Капка төпләрендә туктамыйлар
Малай чакта шуган чаналар.

Төшләреңә керә туган йортың,
Беләм, аны бар да сагына.
Әти ясап биргән таганнарда
Көзге җилләр бүген атына.

Чормасында яткан ятим бишек
Тансык җырны көйли тын гына.
Урам буендагы тәрәзәләр
Борылып карый авыл ягына.

Рәнҗетмәгез туган нигезләрне,
Белә торып читкә какмагыз.
Үкенүләр читтә йөрсен, дисәң,
Балкып торсын, берүк, сатмагыз!..

## Изге җир

Яктылык сыенган урын,
Мин табынган җир ул, бел.
Исеме дә җырлап тора,
Изге урын – нәни ил!

Таң әтәчләре торганчы
Йокысыннан уяна.
Җаны барга өмет сирпеп,
Тәрәзәдә ут яна!

Авыл дип атыйлар аны,
Сала, диләр бабайлар.
Киткәннәр озак торалмый –
Сагынганга кайталар.

Чорлар бикле заманда да,
Юк, бикләнмәде ишек.
Үткәнгә күз сал, түрендә
Җырлый сиртмәле бишек.

Күңеле ак. Тупсасыннан
Бисмилла әйтеп керә.
Шул талбишек баласына
Тиңсез мирас – тел бирә.

Нәни ил телдән бизмәсен,
Җуелмасын моңнары.
Гармунчылары кулында
Сайрасын гармуннары.

Авылның уңган кешесе
Далаларны гөл иткән.
Хезмәт сөю каннан килә –
Олы илне ил иткән!

Җәе матурлык иңдерә,
Аклык өләшә кышы.
Исеме дә җырлап тора,
Мин табынган җир шушы.

## Табибка

Сиңа булган хөрмәт кимемәгән,
Ак күңелең китми уемнан.
Гиппократның анты йөрәгеңә
Җуелмаслык итеп уелган!

Авырганда үлән төнәтмәсе,
Өшкерүче эзләп чабабыз.
Тик барыбер сырхау дәваларын,
Сырхауханә, синдә табабыз.

Күргәнем бар, өйдә тереләм, дип,
Савыгуны өзелеп көткәнне.
Палатаның ишеген бик соң ачып,
Бакыйлыкка күчеп киткәнне...

Дару-мазар, укол кирәккәндә,
Аптекадан, әйе, ташыйбыз.
Барына да риза, табиб туган,
Исән генә чыксын башыбыз!

Без аларны тиргибез дә кайчак,
Карамыйлар, диеп, әрлибез.
«Ашыгыч ярдәм» килсә сөенәбез,
Бар өметне сиңа бәйлибез.

Имән сыман таза, исәннәр дә
Уйга таралардыр берара.
Үлем кочагыннан тартып ала,
Шул табиблар безне коткара!

Ак халатлы яшәү фәрештәсе,
Ак күңелең китми уемнан.
Гиппократның анты йөрәгеңә
Җуелмаслык итеп уелган!..



Тәлгат
Галиуллин

# СУКЫР ГАВАЗ

ПОВЕСТЬ

1

Гаваз ял итәргә тиеш иде. Мәгәр аның кулдашы хохол егете Тарасенко яраланып, хастаханәгә эләгү сәбәпле, менә инде ничәнче көн тоташ, немецлар куеп калдырган миналарны эзләргә, сүндерергә аңа чыгарга туры килә. Чигенеп баручы фашистларның үкчәләренә басып, ажгырып килә торган танк армадасына юлны әзерләү, үлем күсәкләрен табып шартлату яисә алып ташлау бурычы минёрлар җилкәсенә төшә.

Пилотка астыннан әрсезләнеп, як-якка сибелеп торган чәчләре, өлгергән шомырттай кара күзле, табак битле, ачык чырайлы, тыгыз гәүдәле татар егете Гаваз Әсәдуллин чираттан тыш «ышанычны» шатланып кабул итте, дип әйтү дөреслеккә туры килмәс иде. Әмма сугыш вакытында приказны тикшереп яисә карышып тору була алмый. Кемнәрдер, чит-ят илләрне күрүне, үзгә лөгатьле халыклар белән аралашуны мәртәбә санап, туган авылларына кайтып масаер өчен, истәлеккә тәти «уенчыклар» җыярга тырышса, Чирмешән буйларында урнашкан, Әсәй авылында туып-үскән егет, Балтыйк диңгезе кырында, Көнчыгыш Аурупада гомер сөргән кавемнәрнең ни табигатенә, ни гореф-гадәтләренә, ни яшәү рәвешләренә таң калып, аһ-ваһ килеп сикереп төшмәде. Һәр милләт Ходай Тәгалә тарафыннан ничек яратылган булса, һәммәсе үзенчә көн күрә, үзенчә яши, башкача бии, җырлый... нәсел калдыра. Эстон, поляк, маҗарлар, безгә дустанә күренергә тырышып, елмаеп исәнләшсәләр дә, совет солдатлары аларның ихласлыкларына ышанып бетмиләр. Командирлары да «җирле халык белән аралашырга туры килсә, сак булыгыз, тәмле сүзләренә балавыз кебек эреп китмәгез», дип кисәтеп кенә торалар. «Безнең яклы» дигәннәренең дә кесәләрендә нәрсә йөрткәнен, күңелләрендә ни ятканын белеп булмый. Телләре дә, ничектер, күңелгә ятышлы түгел, дигән әрсез уй Гавазны сискәндереп җибәргәндәй булды. Әнә бит, минем нинди төзек, нәзакәтле, моңлы, җырлап торган телемне дә урыслар яратмый, үлем астында дус булып

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН (1938) – *язучы, тәнкыйтьче; филология фәннәре докторы, Татарстанның һәм Россиянең атказанган фән эшлеклесе. «Сәет Сакманов» роман-трилогиясе, «Замана балалары», «Дәгъва», «Мәһдиев йолдызлыгы» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

йөргәннәре дә, татарлар белән очрашып, үз телебездә аралаша башласак, «кеше аңларлык лөгатьтә сөйләшегез әле», дип, төрлечә мыскыллаудан да тартынып тормый. Исемемне Гриша-Григорийга, һич югы Егоркага әйләндерүгә омтылулар бихисап булды. Бу сүз гарәпчәдән алынган, дигәч кенә, бераз тынычланып, бозып, җимереп булса да, метрикәгә язылганча әйтергә тырыштылар. «Уйлап җиткермичәрәк, ялгыш кына, исемем «су астыннан энҗе эзләүче водолаз» мәгънәсен аңлата, дигән идем, шул минем кушаматым булып китте: «Татарин-водолаз», вәссәлам!

Чит җырләрне өнәп бетермәү, анда яшәүче милләтләрнең телләренә кырын карау Сәвиткә берләшүдән киләдер әле дип тә уйлап куйгалады Гаваз. Кем арбасына утырсаң – шуның җырын җырларга мәҗбүрсең...

Сугышның соңгы елында армия алдына куелган төп максат: җайлана гына барган яшәешебезне пыран-заран китергән илбасарны үз өнендә тар-мар итү, ә Гавазга, исән-имин калып, тизрәк туган авылына кайту, әтиләрен югалтканнан соң, хәсрәт дәрьясына чумган әнисен юату. Сувенир эзләп йөрүчеләрдән көлсә дә, шултиклем үлем белән бил алышып йөреп, берәр истәлек алып кайтмасаң, дөрес булмастыр. Якташлары – фронтовиклар аңламаслар, тәки авыл мокыты булып калгансың, диярләр. Тик кайберәүләр кебек, немецның авыз сыбызгысы дәрәҗәсенә төшмәскә иде. Аккордеон, сәгать, келәм кебек җитдирәк әйберләр кыстырып кайтып, гимнастёрка түшенә медальләрен, ялтыравык билгеләрне тагып, Мөнирәсе алдында, күктән төшкән фәрештәдәй пәйда булып, кәҗүн итекләрне (бәлки әле, немец ботинкаларын), бер-берсенә шакы-шокы бәреп, кызның «ушын» алсаң, иллә кызык тамаша булыр иде. Мине күргәч, матуркаем, үзен ничек тотар иде икән? Әүвәл, һичшиксез, танымыйча аптырап, югалып калыр, аннан тулышкан күкрәген сулыш белән тутырганнан соң: «Гавазым, синме бу, төшемме, өнемме, кайттыңмы, ник алдан хәбәр итмәдең?» – дип, өлгергән чиядәй кызыл иреннәрен турсайтып торыр, шуннан соң, йөгереп килеп кочаклап алгач, елап җибәрергә дә күп сорамас. Нишләтәсең, хатын-кызның холкы, менәзе шундыйрак. Табигать аларны шулай яраткан. Сугыштан кайтып, берничә көн йокысын туйдырганнан соң, Мөнирәгә тәкъдим ясап, миңа – хатын, әнигә килен кирәк, дип кистереп әйтер.

Иң татлы хыялларын бүлдереп, сөйгәненең соңгы хатына һаман да җавап бирә алмаганы исенә төште. Бүген үк гафу үтенеп, җавап мәктүбе язар. Күңел түрендә кат-кат кабатлап йөрткән, әлегәчә беркем әйтә алмаган сүзләрне тезгәннән соң, гади генә итеп: «Сугыш тиздән бетәчәк, җиңү белән тәмамланачак, туй сөлгеләреңне чигә башласаң да, чак булыр», – дип тә шаяртып куяр!

Бүленгән татлы уйларына ирек биреп, Гаваз кечкенә куаклык уртасыннан агып яткан, суы сасырак тоелган шарлавыкны атлап үтте. Алда кечерәк кенә, тау дисәң, хәтере калырлык калкулык тора. Аны заданиегә озатканда, капитаннарның: «Будь очень внимательным, осторожным, немцы очень озлоблены, ибо им уже нечего терять», – диюе калкулык янында гына исенә төште.

Кемгәдер артык гадәти күренгән, аның өчен ифрат кадерле хыялларын, йөрәгеннән уздырып, Гаваз озын тимер сапка утыртылган мина эзләгечен әле алга, әле як-якка юнәлтеп, тар сукмактан атлавын дәвам итте. Командирлары, һәр адымда безне үлем афәте сагалап тора, бик сизгер булыгыз, дип, бераз арттыра иде бугай. Әби-бабасы, ата-анасы кадерләп үстергән ирләрне күпләп кыру орышы башланганның икенче елыннан ук, Гаваз Әсәдуллин, берничә

ай махсус курсларда шул шөгыльнең нәзари нигезләре белән танышканнан соң, менә инде өченче ел, кешенең башына да килмәслек мәкерле алымнар белән күмеп, яшереп калдырган үлем күсәкләрен – миналарны эзләп табып, юк итү белән мәшгуль. Табышмак чишкән шикелле, башны эшләтүне, җитезлекне сорый торган, ахыр чиктә гаять куркыныч шөгыль. Һәр минут сират күперен кичкәндәй буласың! Беришенең «йомшак җирен» табып, шөребен борып сүндерәсең, чыбыгын өзәсең, күп очракта читкә сикереп (өлгерсәң) шартлатасың! Җитезлегең җитмәсә, ялкын шары эчендә калып эрисең!

Гаваз дошман миналарын табып шартлатуның «асы» саналса да, бу һөнәрен яратып, мөкиббән китеп башкара дип санау ялгыш булыр иде. Чөнки аның фикеренчә, тумыштан акылы зәгыйфь кеше генә үлемнән курыкмый. Кем әйтмешли, берәү дә ике тапкыр тумый, ике кат үлми, шуңа күрә һәр инсан якты дөньяның һәр тумыш көнен, һәр сәгатен куанып, сөенеп, ата-ана тансык баланы көтеп алгандай елмаеп каршыларга тиеш. Әнә Гаваз белгән, мина белән бил алышкан минёр егетләрнең күпмесе генә исән-имин калды, нихәтлесе батырларча һәлак булды. Сугышның соңгы көннәрендә, бигрәк тә сөйгән ярың өзелеп көтеп торганда, җан тәслим кылсаң, ифрат үкенечле булыр иде. Хәер, кеше үзенең тууын да, үлемен дә күреп белми. Ахыр чиктә, иртәме, соңмы, барыбер Ходай хозурына күчәсе, ошбу халәт адәм баласының ихтыярыннан тормый. Шул хакыйкать сугышчыларны үлемнән курыкмаска өйрәтә булса кирәк.

Бүген көне дә ташка үлчим, әллә нинди шунда, күңелдә шом, сагыш уята торган. Төрледән-төрле җан ияләренә охшаган, берсе ертык, икенчесе канатлы болытлары да, кояшны ара-тирә, вакытлыча «чапаннарына» яшереп, җирдә шәүләләрен биетеп, күңелне бимазалап торалар.

Берничә ай элек кенә фашистлар кубызына биергә мәҗбүр халыклар, хәзер ду килеп, ирек, мөстәкыйльлек дәгъвалап шаулашалар. Ә немецларның үз хәсрәтләре: сәвит гаскәрләренең һөҗүмен туктата алмасалар да, ниятләре – булдыра алганча аяк чалу, төрлечә зарар ясау, ягъни гомерләрен озынайту. Шул максат белән, элеккеге ахириләренең кырларына, юл буйларына миналар урнаштырып калдыралар. Дөрес, сугышның беренче көннәрендәге мисле үлем күсәкләрен күпләп куя алмыйлар. Безнекеләрнең тын тартырга да ирек бирмәүләре бер хәл, хәчтерүшләрнең шартлаткычлары да бетеп бара торгандыр инде. Миналарын ашык-пошык, аз-азлап куюга карап кына үтергеч көче кимеми, кеше җанын алырга бик аз кирәк шул. Ә аны аякка бастырырга күпме көч түгәргә туры килә.

Аллаһның һәр бирмеш көнен: «Бәйрәм бүген, бүген бәйрәм!» – дип каршы ала Гаваз.

Һәр көн сугышның атнасына-аена торырлык булып, солдат боткасы, консерва, чиле-пешле ипиләре туйдырса да, бер дә яшисе килү дәрте сүнми. Күпчелек солдатлар, атака алдыннан бирелә торган, «Ворошилов йөз граммын» көтеп ала торганнар иде. Беренче мәлне Гавазны әче эчемлек әсир итә алмады, үз өлешенә тигән «көмешен» иптәшләренә биргәләсә, акрынлап хәмер үзенә дә ошый башлады, хәтта ошбу иблис коткысын көтеп ала торган булды. Хәмерне ничек кенә хурласалар да, ул солдат язмышының авырлыкларын оныттырып кына калмый, вакытлыча булса да, дошманга нәфрәтне арттыра, үлемгә битарафлык хисе уята. Ут чәчрәп торган дзотларны күкрәге белән каплаган, граната белән танк астына кереп яткан гаярь егетләрнең батырлыгында хәмернең өлешен инкарь итеп булмас. Мина эзләүчеләргә, пехотадан аермалы

буларак, «у вас ювелирная работа», дигән булып, эчемлекне заданиене үтәп кайтканнан соң гына бирәләр иде.

Совет мәктәбендә әхлакый тәрбия алган Гаваз үзе тапкан минаның берсен, халкым, илем өчен, дип шартлатса, икенчесен, фин сугышында батырларча һәлак булган газиз әтием хакына, дип, күккә очыра торган булды. Ошбу югалтудан ачык чырайлы, тыныч, мөлаем әнисенең кинәт картаеп, кечерәеп калуын күз алдына китерүгә, Гавазның йөрәге тартышып куя. Авыл советы сәркатибе, туганнары, Фатыймага әйтеп яздырган хатларын укыганда, Гаваз һәрдаим әнисен күз алдына китерә, үтә күренмәле, энҗедәй күз яшьләренең җыерчыклы бите буйлап тәгәрәп төшкәнен күргәндәй була.

Һәр хатында: «Улым, күз нурым, атаңнан соң бу фани дөньяда бердәнбер өметем син калдың! Үзеңне, зинһар, саклый күр...» кебек сүзләрен гел кабатласа да, анасының теләкләре кыйммәтен югалтмый. Гаваз һәр юлы аларны беренче кат укыгандай кабул итә. Соңгы хатында, ни өчендер, «Донбасстан Германиягә озатылган кызлар» турындагы бәетне дә күчертеп яздырган.

Әнисенең соңгы мәктүбе, Мөнирәсенә язасы сүзләре турында уйланып, аз-маз хисләнеп, тыныч кына атлаганда, кулындагы мина эзләгеченең калтыранып алуы аны кинәт чынбарлыкка кайтарды. Болай үзе калкулыкта көзен коелып калган яфраклардан, күптәнге чүп-чардан башка әйбер күренми. Тик нидер сизенгәндәй, аркасы гына тартышып куйды. Игътибар итмәскә, коткыга бирешмәскә, йокы алдыннан әнисе өйрәткән догаларны исенә төшерергә тырышып, алга титаклады. Калкулыкның кыл уртасына күтәрелгәч, яз кайда да – Аурупа дигәннәрендә дә, бездә дә – шул ук икән дип уйлап куйды. Әнә, тормыш җепселләренә тулышкан яфраклар, бәяләрен белеп, үзара сөйләшәләр, серләшәләр. Табигать шундый матур, камил, дошманнар да нәкъ безнең шикелле ике күзле, ике колаклы, бер борынлы адәмнәр ләбаса. Һәркайсыбызның гомере бер генә, ә нигәдер кешеләрне теге дөньяга озатудан тәм табабыз.

Җирнең калтыранып алгандай тоелган өлешеннән читкәрәк үтеп, бер-ике адым ясаган иде, аз-маз гына хәрәкәтләнгәндәй тоелган кечтеки түмгәккә җан кергәндәй булды, ул чүпрә салынган камырдай күперенеп, вулкан төсле, өскә күтәрелә башлады. Гөнаһ шомлыгы – Гавазның шул якка борылуы булды, читкә сикерергә өлгергәнче, кызыл шар дулкыны егетнең тәненә, битенә сыланып, эссе ташкын аны йомычкадай читкә ыргытты. Гаваз, әле берни аңышмыйча, аңын җуйганчы, яшьлек куәте белән урыныннан күтәрелергә, һич югы күзләрен ачарга тырышса да, булдыра алмады, керфекләренә авыр гер элеп куйганнар, диярсең, кул-аяклары ихтыярына буйсынмас булдылар. Көчле шартлаудан соң, тирә-юнь тып-тын калды, әйтерсең лә җиһан дөм караңгылыкка чумды. Гаваз үзен тирән упкынга төшеп киткәндәй тойды. Күршедә мина эзләүче иптәшләре, көчле шартлауны ишетеп, йөгереп килеп, нәрсә булганны бик тиз аңлап, егетнең сәлперәеп төшкән гәүдәсен күтәреп алып кайтып, санчастька тапшырдылар, авыр яралыны аннан Мәскәүгә озаттылар.

**2**

Гаваз үзенең кайда, күпме ятканын хәтерләми. Инде табиблар аның терелүенә ышанычны югалта ук башлагач, беркөнне, гафләт йокысыннан уянып киткәндәй, бер-берсенә җилем белән ябыштыргандай береккән иреннәре арасыннан кысып, егет үз туган телендә сорау чыгаруга иреште.

– Мин кайда ятам? Минем белән нәстә булды?

Тавышы чыгар-чыкмас булса да, аны ишетәләр.

Гавазның колагына ир-ат тавышы белән әйтелгән сүзләр килеп керә.

«Ой-ой, он, кажись, пришёл в себя, что-то попытался сказать».

Хатын-кыз тавышы:

«А что он сказал?»

«По документам он – татарин. Наверное, на своём что-то пробормотал. Неважно, что он произнёс, главное, наконец, он пришёл в себя. Ведь сколько времени лежит без сознания. Бедняга, он ещё не знает, что потерял оба глаза. А сколько из его тела мелких осколков вытащили! Не сосчитать...»

Болар кем турында сөйләшә соң, кем икән ул, кая югалтты икән ул мескенкәем күзләрен, дип, кемнедер ихластан кызганып, керфекләрен аерып, күз шәрифләрен ачарга тырышып караса да, булдыра алмады. Шунда аның башына коточкыч уй килде: әллә соң алар минем турыда сүз куерталармы! Фани дөньяны күрүдән мәхрүм калган «бедняга» ул түгелме икән?

Шул авыр уйлар Гавазның булыр-булмас хәлен алып, башының сызлавына, укшытуга түзә алмыйча, ул янәдән хушын югалтты. Күпме шулай ятканын да хәтерләми. Аңына килгәндәй тоелгач, үзен капшап карагач, күтәрелергә тырышса да, башын ятактан аера алмады. Шәфкать туташлары ярдәм итешеп, күтәреп, мендәргә яртылаш утыртып, кашыктан тамагын туйдыргач, үзенең аяныч хәле, киләчәк тормышы хакында уйлана башлады. Хәзер бер хакыйкать ачыкланды: димәк, ул газиз күзләрен еракта, чит-ят җирләргә «бүләк» итеп калдырган... Ничек көчле яңгырый... Сукыр Гаваз... Күзсез Гаваз Әсәдуллин... Мина шартлаган урында һәлак булса, хәзер батырлар сафында йөрер, каберенә (тапсалар) чәчәкләр китерерләр иде. Ә болай – ни бөтен, ни пултара... Так себе, гадәти мескен, мәхлук.

Кайсы тарафтан бәяләсәң дә, ни генә әйтсәң дә, безнең илдә сугыш кырында үлеп калу батырлык, югары үлчәү бирәмлеге санала. Үзләренең кирәксезлеген, артык кашык булуын аңлаган авыр яралылар «ник шунда тәгәрәп үлеп калмадым, болай газапланганчы», дип иза чигәләр. Тома сукыр килеш яшәүне Гаваз берничек тә кабул итә алмый. Җитмәсә, борчулы әнисенең «ай бәбкәм, нишләттеләр сине, каһәр суккырлары», дип йөрүләре төшләренә кереп йөдәтә.

Урман кисеп, утын ярып, печән чабып, мал карап үскән таза егет акрынлап торып утыра, тимер караватына таянып хәрәкәт итә, палатадагы чирдәшләре белән аралаша, фикер алыша башлый. Шәфкать туташлары, табиблар ягыннан җылы, аңлаучан, рәхимле мөнәсәбәт дарулардан да файдалырак тәэсир итә.

Мина чәрдәкләгән аягын киссәләр дә, ике кулы, күзләре исән, үзен Аркадий дип таныштырган ирдән әнисенә хат яздырганда, гариплеге турында ләм-мим сүз әйттермәде. Хатның русча язылуын болай аңлатты: «Уң кулым яраланган иде, хатны күршемә әйтеп яздырдым, минем хәрби хезмәтем әле дәвам итә, кайтуым соңрак булыр, вакытын тәгаен әйтә алмыйм», – дип, әнисен кызганудан алдашу юлына баса Гаваз.

Сырхауханәдән чыгар алдыннан поездга билетлар алып, тиешле кәгазьләрен кулына тоттырдылар. Гаваз туганнан туганы Замир абыйсына фәлән көнне, якынча шул сәгатьтә станциядан атың белән каршы ал, дип, телеграмма суктырды. Купеда барганда да, вагоннан төшкәндә дә, аның хәлен аңлаган күршеләре төрлечә ярдәм итәргә тырыштылар.

Замир абыйсының хәзер аты бармы-юкмы, ул кадәресеннән батыр егет хәбәрдар түгел. Элек калхуз эшенә адәм баласы шикелле гаҗәеп акыллы җирән кашка белән йөргәнен генә хәтерли. Атын да тапкан, вакытында килеп тә

җиткән иде абыйсы. Соңрак аңлатуынча, җирән кашкасын туган илне азат итү өченгә алып киткәннәр, һәм ул чит-ят җирләрдә «батырларча» һәлак булганмы, әллә сугышчыларның тамагын туйдыруга киткәнме, хәбәре килмәгән, кире авылга кайтмаган.

**3**

Перронда аркасына чантасын[1] элгән, кулына ниндидер төенчек тоткан кешене, ерактан күз сирпеп алуга, «Гаваз булырга тиеш», дип фаразлады һәм ялгышмады Замир абыйсы. Тораташ булып басып торган зур кара күзлекле адәм аның ягына борылып та карамады. Ул күзлеклегә якынлашты:

– Гаваз энем, синме бу?

Җансыз басып торган кеше, аның ягына яртылаш борылып:

– Әйе, бу мин, Гаваз булам, Замир абый, – дип, кулын бөтенләй икенче якка сузды.

Замир энекәшенең хәлен шундук аңлады, кочаклап алып, елап җибәрде дә, ни-нәрсә булганны төпченеп тормыйча, арбага җайлап утырырга булышты.

– Да, брат, фашист сиңа гумерлеккә истәлек калдырган. Ничава, кул-аякларың исән, акрынлап яңа хәлеңә күнегерсең. Әнә, тумыштан тома сукырлар да үзләренчә типтереп яшиләр, җырлыйлар, бииләр, өйләнешеп, менә дигән ачык күзле балалар үстерәләр.

Ә Гаваз юл буенча әнисе, Мөнирәсе турында уйланып кайтты, алар сукырны ничек кабул итәрләр? Бигрәк тә әнисе югалып калыр.

Чыннан да, борчылуы юкка булмаган икән.

Замир абыйсы әнисенә: «Улыңны – батырны каршы алырга стансыга барам», дип кисәткән икән, ат капка янына килеп туктауга, Хәмдениса абыстай, рәешкә генә саклап тоткан күлмәген, ак яулыгын җилкәсенә төшереп бәйләп, тәрәзәдән ат күренүгә, яше мөмкинлек биргәнчә, урамга йөгереп чыгып, «исән-имин кайтып җиттеңме, улым», дип, арба ягына ыргыла. Гаваз, урыныннан төшеп, тавыш килгән якка баргандай тоелса да, читкәрәк китә һәм чак кына егылмыйча кала. Чит кешеләрдән яздырган хатлары буенча да афәтне сизенгән ана улының, бөтен битен диярлек каплаган зур кара күзлек киеп, әле генә беренче адымнарын ясый башлаган сабый кебек атлавын күргәч, «аһ, балам, нишләттеләр сине», дип, Гавазны тотарга алга талпына, абына һәм, һушын югалтып, улының аяклары янына сыгылып төшә. Шул арада йөгерешеп килеп җиткән авылдашлары өйгә әнисен күтәреп, Гавазны җитәкләп алып керәләр. Шәфкать туташы, нәрсәдер иснәтеп, ананы айныта.

Күзләрен яу кырында калдыруы, гомумән, гариплеге белән кайнар канлы Гавазның һич кенә дә килешәсе килми. Туып-үскән йортларына кайтып төшүенең икенче көнендә үк каударланып, гимнастёркасын, чалбарын киеп, ызбадан чыга. Баскычтан төшкәндә, нәрсәнедер дөпелдәтеп аудара, аның янына үзе дә сузылып ята. Улын уятмаска тырышып, иртәнге чәйне әзерләү белән мәшгуль әнисе, уфылдап килеп чыгып, улын көч-хәл белән аягына бастыра. Кыскасы, Гаваз беренче тормыш дәресен ала. Адәм баласы барысына да: яхшысына да, яманына да бик тиз күнегә. Баскычта сузылып яту «бушка китми». Хәзер Гаваз «әтәчләнми», өй эчендә генә капшанып, тимер караватка, өстәлгә, әтисе ясап калдырган урындыкларга тотынып йөри, акрынлап, кече капкадан чыгып, коймаларына терәтеп куелган, әлеге дә баягы әтисе белән әмәлләгән эскәмияне «бәхетле» итәргә өйрәнә. Стансыдан алып кайткан Замир

[1] Чанта – биштәр.

абыйсы аңа шома кул таягы ясап биргәч, яшәеше бераз җайланып киткәндәй була. Мина эзләгечне йөрткән шикелле, тирә-юньне тикшереп алганнан соң гына аягын атлый. Бәдрәфкә үзе барып кайту, кечкенә капканы шыгырдатып ачып, эскәмияне табып утыру, аякларын берсе өстенә икенчесен атландырып куюю аның өчен зур шатлык, рейхстагка байрак элгәндәй зур җиңү иде. Менә, карагыз Гаваз әзиегезне, ул ничек матур итеп, читән башындагы кызыл кикрикле әтәч кебек кукраеп утыра, бәлки, әле кычкырырга да өйрәнер, дия кебек иде аның йөзе. Узып барганда, каяндыр кайтканда, яше-карты Гавазның хәлен белешмичә үтеп китми.

Аның янында иң еш булучыларның берсе – авылның түбән очындарак яшәүче, шулай ук сугышта чирканчык алып, бәхетенә исән-сау кайткан яшьлек дусты Гәзим иде. Бер килүендә Гәзим утыргычның сөрсегәнрәк такталарын яңага алыштырып куя да «эшлекле» тәкъдим кертә.

– Карале, ахири, бик матур, ипле, карап туйгысыз өр-яңа килеп чыкты.

– Ярый, рәхмәт, дустым! Мин сиңа ышанам.

Гәзимнең сүзе тәмамланмаган икән әле.

– Дусы бар, дошманы бар, дигәндәй, әллә, мәйтәм, чылатып җибәрәбезме?

Гаваз аркадашының сүз сөрешен аңламадымы, әллә юри башкага борып җибәрдеме.

– Әнигә әйт, су чыгарсын!

Гәзим, пырдымсызланып:

– Башыңны юләргә салма инде. Юып җибәрәбезме әллә, диюем?

– Соң, барыбер йә су, йә башка берәр сыек нәрсә кирәк була торгандыр инде.

– Риза булсаң, мин мигом кибет әйләнеп киләм.

Эчемлек турында искә төшерүгә, шул мизгелдә үк Гавазның фронтта Ворошилов «күчтәнәченә» өйрәнгән тамагына ниндидер зәхмәтле, төртеп төшергәнче сорап торган төер утыргандай булды. Әүвәл, бер шешәдән арттырмыйбыз дип башласалар да, анысын бушаткач, дусларга «тулы бәхет» өчен тагын күпмедер җитмәгәндәй тоелды. Шуның өстенә, Гаваз үзен бурычлы санады. Бу юлы, табигый буларак, тәкъдимне хуҗа кертте.

– Минем уң як галифе кесәсендә акча булырга тиеш, шуны ал да тагын берне алып кайт инде, булмаса. Әйбәт китте бит әле.

Шул уенны, тамак төбендәге «төерне төртеп» төшерүне дуслар һәр көнне диярлек кабатлый башлыйлар.

Сырхауханәдән чыкканда, командование исеменнән Гавазга шактый акча салынган конверт тоттырганнар иде, пенсиясе дә килеп тора. Башка авылдашлары да, бигрәк тә сугыш авырлыгын кичергәннәре, аеруча беренче мәлне, батыр егетнең хәлен белеп узуны намус эше, изге бурычлары санап, аракыга «битараф» түгеллеген белеп, «чуваш малаен» кыстырып киләләр. Солдат галәфие кебек киң күңелле Гаваз берәүне дә рәнҗетергә теләми. Эчкәч, гариплек хәсрәте онытылып торгандай була яисә бөтен барлыгын ваемсыз бушлык биләп ала. Шул рәвешле, уеннан уймак чыга, дигәндәй, хәмер белән шаярулар зурга китә, Гаваз хәтта, күңеле тулып, «иттә-иттә-иттәтә, ике дөнья – бер кәнди, фанида бер тапкыр яшибез», кебек такмакларны да сиптерүдән тартынып тормый.

Ул, әлбәттә, үзенең упкын кырыена якынлашып килүен аңламаслык мәхлук түгел иде. Дөньялыкта соңгы өмете, ышанычы, таянычы – улының болай азынып йөрүе әнисенә өстәмә хәсрәт тудырганын сизә, әмма тамак төбенә утырган төернең кытыклавы тартышта өскә чыга. Ана кеше, улының

аяныч халәтен аңлап, ярдәм итә алмаудан гаҗиз булып, язмыш тарафыннан рәнҗетелгән бердәнберенә каты бәрелми. Ана мәхәббәте чикләрне белми, дип юкка гына әйтмиләрдер. Шулай да, уфылдап, уфырып, уфтанып йөрүләрнең файдасы тимәгәч, Хәмдениса апа, бар «җаваплылыкны» үз өстенә генә алмыйча, өченче затка күчеп, ризасызлыгын улына ирештерү әмәлен таба. «Йа Аллам, сабырлык бир», дип, көндәлек кереш сүзен кабатлый да, эчке сөйләм рәвешендә, үз-үзенә генә әйткән булып, мәгәр Гаваз ишетерлек итеп, нәсыйхәтен тезә: «Улым, бу кыланмышларың турында уйлап карыйсыңмы, кайларга барып җитәрсең икән? Киләчәгеңне ничекләр күз алдыңа китерәсең? Әле бит гаилә корасың, балалар үстерәсең, нәсел җебен дәвам иттерәсең бар, аңлаган кеше күзеңне югалтуыңны кичерсә дә, начар гадәтләреңне белгәне сиңа кызын тоттырып җибәрмәс! Әдәп-гадәт саклап, үзеңне тыныч кына тотсаң, «иттә-иттә»ләрне җырлап утырмасаң, чиләгенә күрә капкачы, берәр җитешсезлеге (тел очында «аксак-туксагы» торса да, сүзгә күчерми) булганы табылыр иде. Үзебезнең авылда гына да тол хатыннар, ярын көтеп утырган кызлар аз түгел. Алкаш дигән даның таралса, синең белән сөйләшеп тә тормаячаклар».

Хәмдениса абыстай күңелендәгене вәгазьләп әйтсә дә, үз хыялын калкытып куя: «Миңа пешергән ризыкларымны яратып ашарлык, бәя бирерлек, ярдәм итәрлек килен, күлмәк читемә тагылып, дәү әни, әби, дип, аяк астында буталып йөрерлек оныклар кирәк. Тулы гаиләбез турындагы хыялымны үзем белән алып китәрменме инде, Йә Ходаем?»

Гавазның бәгырен телгәләгән сүзләрне тиле-миле карчыктай кабатлап йөрүен белә. Әнисенең йөрәгеннән ташып чыккан мондый сүзләргә егетнең бу шөгыльдән котылырга кирәк, дигән уе туса да, шунда ук берәр авылдашы көмешкәсен йә ачы балын кыстырып килсә, Гаваз, артык кыстатып тормыйча, тагын риза була. Шул тамаша көн саен диярлек кабатлана. Бер йотым икенчесенә, өченчесенә килеп тоташа. Иң соңыннан дусты Гәзим, әнисенең күзенә чалынмаскарак тырышып, минёрны өенә кертеп калдыра.

Тормыш үз агымы белән дәвам иткәндә, көтелмәгән бер очрашу Гавазның яшәү рәвешен үзгәртеп, бөтенләй башка юлга борып җибәрә.

Ул көнне Гәзим ахирәте Гавазны эскәмиядә утыртып калдыра.

– Син, дустым, өеңә кермичә, мине шунда көтеп утыр. Берәрсеннән акча юнәтә алсам, яныңа килеп җитәрмен. Юмарт кешесен таба алмасам, барыбер хәбәр бирермен, – ди.

## 4

Йомышчы һаман күренми. Көткәндә, вакыт агышы туктагандай тоела. Йолдызның калкуына өметен өзгән Гаваз, өенә керергә җыенып, урыныннан күтәрелгәндә, кемнеңдер үлән кыштырдатып, аягын сөйрәбрәк аңа якынлашканын сизә. Сукырның колагы ифрат сизгер була, диләр. Хактыр. Баш мие берәр югалтуның функциясен башка әгъзаларга күчереп, соңгысының вазифасын көчәйтә кебегрәк фикердә тора бер ише галимнәр. Галошын авыр күтәреп атлавына караганда, Гәзимгә охшамаган иде көтелмәгән миһман. Егетнең янына килеп җитүгә берничә адым калгач, «эһем-эһем», дип, тамагын кырып алуы буенча, үз теләге белән авыл мулласы вазифаларын үтәп йөрүче, аңа кем өчендер «Алла колы», ә кемгәдер «суган суфые» кушаматы белән билгеле Сәләхетдин карт булырга тиеш, дип фаразлый егет. Һәм ялгышмый. Картның: «Сау-сәламәтме, Гаваз энем?» – диюенә катырак бәрелмәкче иде дә,

вакытында тыелып кала алды. Шулай да, көткән кешесе урынына башкасы килүдән туган гарьлек хисен йөгәнли алмыйча:

– Саулыгым баштин ашкан, теләсә кем белән бүлешә алам, – дип, янына ук килеп бөялгән кешене юри танымаган булды. – Кем йөри әле анда, мин берәүне дә чакырмаган идем.

– Мин – әтиеңнең җан дусты Сәләхетдин бабаң. Танымаган булып кыланма? Сөйләшеп аласы гамем бар.

Сырты кабарган Гаваз:

– Сукырның кемгә кирәге булсын да, дөнья матурлыгын күрмәгән кеше белән нәрсә турында сөйләшеп булыр икән? – дип дорфаланды.

Тормышның ачысын-төчесен татыган, бүлешсә, күпләргә җитәрлек кагуны, рәнҗетүне кичергән, утызынчы елларда мәчет манарасын кистермәү өчен җан атып йөргән өчен түрәләр, имансызлар аны гавамны котыртуда гаепләп, биш елга якын хибес шулпасын «чөмереп» чыккан батыр йөрәкле Сәләхетдин, Гавазның кәефе начар булуга карамастан, төртмәле сүзләрен җитдигә алмады.

– Балам, син минем белән бөердән сөйләшмә әле. Гариплегеңә сыланып, рәнҗеп тә, үпкәләп тә утырма. Тегендәрәк күч әле, аякларым сызлый, яныңа чүмәшим. Мин күптәннән җыенып йөреп, сөйләшергә махсус килүем.

Гаваз, урыныннан кузгалмыйча гына, уң кулы белән эскәмияне капшады.

– Утырыгыз, урын җитә.

Ап-ак сакалы шикелле үк пакь йөзле, тыныч карашлы карт, кул таягын янына куеп, алдан уйлап килгән сүзләрен тезеп китте.

– Гаваз энем, сезнең гаиләне язмыш бик нык талкыды, шуңа күрә озаклап вәгазь укырга җыенмыйм. Турырак әйтсәм дә, үпкәләштән булмасын! Кичә кибеттән кайтканда, әниеңне күргән идем, картайганлыгы, синең өчен әрнегәнлеге күзгә бәрелеп тора. Мескенкәем, җылыга тарган боз шикелле эреп, югалып бара! Шайтан вәсвәсәсенә бирелеп, юкка чыгып барасың. Акча алганыңны көтеп, яныңда арзанлы мактаулары белән сәрхушләр генә йөри башлады, рәтле-башлы адәмнәр өегезне әйләнеп узалар.

Шунда карт, сүз агышын туктатып, тавышын күтәреп, кемнедер ачуланып алды.

– Кит моннан, мәлгунь, бу тирәдә буталып йөрисе булма!

Тегесе дә җавапсыз калмады.

– Каян килеп чыктың әле, «суган суфые», намазлык өстендә оеп утырасы кеше, монда эч пошырып йөрисең!

Гаваз шыпырт кына, әмма Гәзим ишетерлек итеп, «соңрак килерсең, мин монда булам әле», дип әйтергә өлгерде.

Чынында, бу мизгелдә картның әнисе турында әйткән сүзләре егетне уйга салды. Шул мизгелдә ул әнисенең борчулы, җыерчыклы йөзен, намазлыгында, Ходайдан ярлыкау сорап утыруын күзләре белән күрмәве өчен сөенеп куйгандай булды. Ул үзенең нәүмизләнеп, сабыйланып киткәнен сизде. Янәшәсендә, аңа нисбәтән изге теләкләр белән килгән олы зат утыра лабаса. Шул ук вакытта ниндидер үҗәтлек аны тиз генә килешмәскә, баш бирмәскә котыртып тора.

– Нишлим соң инде, Сәләхетдин абый, танырга да оят. Эчкәч, беразга булса да гариплегемне, берәүгә дә кирәксезлегемне онытып торам.

– Нихәл итмәк, бәгырь, һәркемнең үз язмышы. Адәм баласы җир астына Аллаһ хозурына кереп ятканчы, күпме сынау уза: беришесе нәфесен йөгәнли алмый, икенчесе нахакка рәнҗетелә, син исә туган җиреңне, халкыңны коллык газабыннан коткару юлында газиз күзләреңне шәһит иттең, башкалар рәхәттә

яшәсен өчен михнәт күрәсең. Батыр егет җен коткысына бирелергә тиеш түгел. Әле бит, гафу ит, маңгай күзеңнән бүтән күңел күзе бар. Шуны саклый белергә кирәк.

– Сукыр кешегә күңел күзе дә тәтеми торгандыр, – дип, егет үзен янәдән җиңел генә сыртка салдырмаска булды.

Егетнең тиз генә аратага керергә җыенмаганын, юриме, чынлапмы йонын кабартканын сизенгән карт төлке, сүзне үтемлерәк фикергә күчерергә булды.

– Сине, энем, Аллаһы Тәгаләбез ярдәменә таяну гына коткарыр! Аның бөеклегенә, мәрхәмәтенә ышансаң гына, син үзеңнең рухи яктан ялгыз булмавыңа инанырсың, иман нуры сине яктылыкка чыгарыр! Соңгы чорда басылган мәҗмугаларына кертелми килгән, сабыйларга киңәш-ярдәм рәвешендә балаларга мөрәҗәгать итеп язылган иң нәфис шигырьләренең берсен бөек Тукаебыз «Таян Аллага!» дип атаган. Хәтерем ялгышмаса. Дөрес, бу юлларны мин һәр көнне диярлек кабатлап йөрим.

Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!
Рәхмәте бик киң Аның, һәрдәм таян син Аллага!

Бу шигырьне бирелеп, хисләнеп, дөньясын онытып тыңласа да, аның ихтыярына буйсынмаган кирелек Гавазны «Аллага таянсам, ярдәмен сорасам, күзләремне кайтарырмы» кебек көфер сорауны бирергә котыртса да, әхлаклы гаиләдә үсү нәтиҗәсе – инсафлылык аны туктатып калды. Сәбәбен соңрак аңышты: изге картның үз җае белән аккан саф сулы инешне хәтерләткән, Аллаһка бирелгән тыныч, салмак, шул ук вакытта ышанычлы тавышы аның җанына, кан тамырларына җылы дулкын, сихәтле рәхәтлек иңдерүен сизде. Әле ул чорда яшүсмер генә булса да, Сәләхетдин абыйсының мәчет манарасын кистермәү өчен үзен аямыйча көрәшеп йөрүләрен, үзәктән килгән милициянең кулларына богау салып алып китүләрен хәтерли. Юк, сиңа бары тик изгелек теләп, олы башын кече итеп йөргән затны юк-бар сораулар белән рәнҗетергә ярамый.

Шулай да бер ачыкламыш сөален бирергә җөрьәт итте.

– Сәләхетдин бабай, нигә минем өчен шулай борчылып, ярдәм итеп йөрисең әле?

Җавап төгәл һәм кыска булды.

– Мәрхүм әтиең белән, илаһым урыны җәннәттә булсын, ахирәтләр, фикердәшләр, дигән идем бит. Тагын нәрсә өстим?

– Минем хәтерләвемчә, аның дуслары, аралашкан кешеләре күп иде. Тик алары Зәкиулланың сукыр улы турында синең кебек кайгырту күрсәтмиләр.

– Балакаем, Аллаһның кодрәтенә ышанган кеше юл чатында адашыпмы, буталыпмы калган кешегә булышмасын, ди. Икенче яктан, һәр татар татарга кулын сузарга, хәленнән килгәнчә ярдәм итәргә тиеш. Үзеннән башка безнең халыкның җиһанда бер яклаучысы да юк. Без – зурлыгыбызның кадерен белеп, шуны саклый алмыйча мескенлеккә төшкән милләт. Бар таянычыбыз – Аллаһ һәм ул тәкъдир иткән Ислам дине. Синең, гафу ит, эчүчелеккә бирелеп, үз-үзеңне югалта баруыңнан әниең дә борчыла-елый торгач, кара җир астына кереп ятса, кемгә кирәк булырсың?

Әнисе белән бер үк җырны җырлаган әңгәмәдәшеннән котылырга теләгәндәй, аның белән килешергә булды Гаваз.

Бер яктан, Сәләхетдин карт вакытсызрак килеп чыгып, үгет-нәсихәте белән

туйдырганрак тоелса да, икенче тарафтан, эчке тоемы белән күңел түренә якты нур иңдерә башлаган гәпнең дәвам итүен тели иде. Нәкъ менә шуңа күрә учакка коры «чыбык-чабык» өстәргә булды.

– Язмыштан узмыш юк, тәкъдиреңә ни язылган, шуны күрерсең, – дип тә әйтеп калдырган бабаларыбыз.

– Мондый сынамышларның башка эчтәлектә әйтелгәннәре дә күп. Тормыш тәсбихенең бер төймәсе генә бу төшенке әйтемнәр. Аллага таянып яшәгән көрәшчеләр син әйткән сүзләргә таянмас!

– Дөресен генә әйткәндә, чарасызлыктан, башка чын-чынлап берәүгә дә кирәгем булмаудан эчәм мин, Сәләхетдин абзый. Киләчәгем ничек буласын да чамалавы кыен. Менә шул эскәмиям төбенә ятып үләрмен кебек.

– Бу – шайтан вәсвәсәсе, җен коткысы, җиңел юл эзләүчеләр фәлсәфәсе. Бирешсәң, фаҗига һәммәбезне сагалап кына тора. Бердәмлек җитмәү, көнчелек, хөсетлек аркасында без – меңәр еллык дәүләтебезне югалткан халык, дигән идем.

Гаваз Сәләхетдин хәзрәтнең акыл сатып, әхлак сүтеп сөйләшеп утыру өчен генә килмәгәнлеген, үгет-нәсихәте артында, яшереп куйган мина шикелле, тирән сер булырга тиешлеген дә сизенде. Бу хакта сорауны кабыргасы белән куярга булды.

– Миңа нишләргә соң инде? Балта, пычкы белән ир-ат эшен башкара, кадак кага, агач юна алмыйм. Бир бер киңәшеңне?

Җавап кискен, җәядән чыккан ук мисле, көтелмәгәнчәрәк булды.

– Сиңа өйләнергә кирәк! Тиз арада!

Гаваз, тыңлаучан солдат шикелле, утыргычыннан кубып, аягына басты.

– Нәрсә, нәрсә дисез? Күзем күрмәсә дә, колагым яхшы ишетә. Миннән көләсезме?

– Һич юк! Көлү түгел, елмаймыйм да, халык мәнфәгатьләре белән яшәгән дин әһелләренең авыз ачып ыржайганнарын күргәнең бармы? Яныңа килүемнең төп сәбәбе дә нәкъ шул, гаилә кору турында сөйләшү иде. Нәсел агачыгызны корытмас өченгә, әниеңә килен төшерергә, оныклары белән сөендерергә тиешсең!

Гавазның чын-чынлап тузынуын күреп, карт аның култыгыннан алып, урынына утыртты.

– Углан! Кызма, башыңны эшләт! Сугышка алынганчы берәр кыз белән йөрдеңме, һич югы якыннан танышлыгың булдымы?

Сәләхетдин карт үзе уйлап, бәяләп җиткердеме-юкмы, әллә кәкрегә атып турыга тидердеме, чынында ул егетнең төн йокыларын качыра торган авырткан сөяленә басты, күңелен бимазалап торган иң нечкә хисләренә кагылды. Гаваз өйләнү, берәр балалы хатын белән булса да кушылу, гаилә кору турында күптәннән хыяллана. Гәзим кебек гомерлек буйдак булып каласы килми. Анысын да шомарта бугай, янәсе, ул фронтта ярасын бәйләгән белорус кызына үлепләр гашыйк булган да, чибәркәе әүвәл аның белән очрашып йөреп, бер әфисәргә ияреп, аны ташлап киткән. Шуннан Гәзим хатын-кыз заты белән аралашмаска ант иткән... Тукран тәүбәседер әле, Гавазны тынычландыру өчен генә алдаша, әйтә торгандыр.

Кешеләрнең зиһенен алыштырырлык, табигатен үзгәртерлек хатын-кыз ләззәтен, балалар үстерү шатлыгын татымыйча, фани дөньяны ташлап китәрменме икән, дип бер генә борчылмады Гаваз. Сәләхетдин карт, шул мәүзугъка сүз куерта башлауга, күз алдына келт итеп Мораса мәктәбендә

бергә укыган, Яңа Әмзә кызы Мөнирәне юксынып искә алулары, һәр төнне диярлек аның төшенә керүләре – барысы да хәтердә, газаплы, сагышлы уйлар үзәнендә. Күрше авыл кызы, чая, үткен сүзле, чибәр Мөнирә белән аралашулары үзе бер тарих. Мәктәптә үк аның толымыннан тартып чинатулар, аулакта саклап торып, кулларыннан тотарга тырышулар, биленә кагылган өчен мүкләшкә алулар, ә инде мәктәпне тәмамлаган чыгарылыш кичәсендә бит алмасыннан «пәп» итеп алганда, кызның инде карышмавы, армиягә алыну повесткасы килгәч, авылларына махсус барып та Мөнирәне (комсомол эшләре белән район үзәгенә киткән булып чыкты) күрә алмыйча, «мин сине яратам, көт мине», кебек берничә сүздән торган хатны күрше кызында калдыруы... Сугышка китәсе көнне Мөнирәсе военкоматка махсус килеп, берәүдән дә тартынып, оялып тормыйча, аны кочаклап, иреннәреннән суырып үбүе... Болары мәңгегә күңелгә уелган татлы сәхифәләр, тик барысы да үткән-беткән, булмаган да шикелле. Мөнирә инде күптәннән иренең иңенә башын салып йоклап, тәмле төшләр күреп, үзе кебек матур балалар үстереп, көнен күреп ята торгандыр.

Гаиләле булмаган очракта да, минем тома сукырлыгым турында ишетеп, кулын селтәгәндер, ни өчен әле ул үзенә өстәмә бәла, авыртмаган башына тимер таяк алып интексен, ди. Хохолың әйтмешли, дураков нема.

Аның гаилә поезды, безнең станциягә туктамыйча, узып китте микәнни? Әллә ятып калганчы, атып калыйммы? Миен тырнап узган бу уе аны йокысыннан уятып җибәргәндәй булды.

Мөнирәнең аяз күк йөзе мисле зәңгәрсу күзләре, сыгылмалы гәүдәсе, аның белән очрашкандагы мөлаем йөзе беркайчан күңел түреннән китмәде. Тик Гавазның хәзерге хәлендә һәр яктан килгән, сәламәт Мөнирәгә сукырның ни хаҗәте бар. Аңа күзләремне Ватан азатлыгы өчен бирдем, дисәң, Ватаныңны кочаклап ят, дияр, и вәссәлам.

Җавап та таба алмассың. «Патриотизм», «туган илгә мәхәббәт» кебек кызыл сүзләр тантаналы бәйрәмнәрдә, шундый җыелыш уздырылды, дип тамга кую өчен генә кирәк. Фанфаралар тынуга, кеше михнәт-хәсрәтләре, төзәлмәс яралары, чирләре белән берүзе кала. Чәчәкләр генә түгел, орден-медальләре дә шәхси фаҗигане үзгәртә, җиңеләйтә алмый. Шул авыр, хәсрәтле уйларыннан аерылып, янында җавап көтеп утырган карт ягына борылып:

– Әмзә авылыннан Мөнирә атлы кызый белән сугыш елларында даими хатлар алышып тордык. Күзләремне югалткач, соңгы хатына бик озак җавап яза алмыйча тордым һәм: «Мөнирә, мине көтмә, мин өйләндем, бәхетле бул», дип, соңгы хат белән муеныма элмәкне үзем салдым. Яраландым, дип җәлләтәсем, мескенләнәсем килмәде. Аны бик ярата идем, хәзер дә аның белән әкияти Мәҗнүн кебек саташып, газапланып яшим.

Сәләхетдин карт, телен йоткандай, озак тынсыз утырды. Бер яктан, Гавазның, яраткан кешесенә авырлык тудырмас өчен, намуслы алдашуга баруын чын егетлек, дип бәяләсә, икенче тарафтан, дөресен әйтеп язса, бәлки, кызы аны аңлап, ярдәм кулын сузган булыр иде, дип тә фаразлады.

Ул, Гавазның гамәленә бәя бирү юлына басмыйча, өлкәннәргә хас булганча, нисби фәлсәфәгә кереп китте:

– Хәләл җефете, заманча әйтсәк, тормыш иптәше табу – ир-егетләр бурычы. Әле ике як та риза булып, бер-берсенә җавап хисләре ташып торса да, дөнья син теләгәнчә генә бармый.

Эскәмиядә җиләс, рәхәт иде. Шуңа күрә тыңлаучы булганда сөйләп калыйм

әле, дигәндәй, Сәләхетдин карт, гаилә бәхетенең гонсырлары турында туйганчы гәп корганнан соң, кинәт мәсьәләгә якынаеп китте.

– Таныш кызың булу шәм яктысы чаклы гына булса да өмет уята. Мин үз ягымнан Әмзәдәге таныш картымнан үтенепме, башка кешеләр ашамы, һич югында үзем берәрсе белән барып кайтыпмы, кызың ни атлы, дисең әле, әйе, Мөнирәң турында белешермен. Сугышта ирләре, йөргән егетләре һәлак булып, тол, ятим калган дөнья бизәкләре һәр авылда җитәрлек. Син бит, энем, күзләреңне үз ихтыярың белән урамда трай тибеп югалтмадың. Акыллы хатын чыраен чытса да, сине аңлар, өлешемә тигән көмешем, дип кабул итәр. Тик сиңа сугыштан алып кайткан начар гадәтләреңнән арынырга туры килер.

Сәләхетдин картның ни-нәрсәне күз алдында тотканын сизсә дә, акыллы башын юләргә салып, сораган булды.

– Начар гадәт дигәннән, сукырлыгымны күздә тотасыңмы?

– Юри башымны катырма. Нәрсә турында сүз барганны бик яхшы беләсең. Ярый, хуш, энем. Өйлә намазы җитә, мин киттем, – дип, карт, кәвешләре белән чирәмле юлны кыштырдатып, үз юлында булды.

Карт белән сөйләшү Гавазны, кинәт суга тарган чәчәктәй, яшәүгә кайтаргандай булды. Җаваптан бигрәк сораулар тулып ятса да, киләчәк аңа өметле күренде. Шул көннән ул хәмер белән шаяруын ташлады диярлек. Элеккеге шешәдәшләрен-әңгәмәдәшләрен, бигрәк тә аның өчен җан атып йөргән Гәзимне үпкәләтмәс өчен, «гафу ит, дустым, чирләбрәк киттем әле, кан басымым кискен күтәрелде бугай, йөрәк сикереп чыгам-чыгам, дип котырына», кебек алдашу юлына басты.

**5**

Әй ул билгесезлек дулкынында бәргәләнеп, кемнедер көтү михнәтләре! Вакыт Гавазга бер урында торгандай тоела. Гәзимнәр белән эскәмиядә бер-берсен макташып, сугышта күрсәткән батырлыкларын искә төшереп утырганда, таралышыр сәгать сукканны сизми дә калалар иде ләбаса.

Ифрат төгәл Сәләхетдин карт тик ятмаган, озын-озак тоелган берничә көннән соң, «шымчылары» аша юнәткән сөенечле хәбәре белән уртаклаша: «Мөнирәң гаиләле түгел, әнисе белән генә яши, әтиләре сугыштан кайтмаган, үлгәнме, югалганмы, кыз сине көтәме-көтмиме, кабул итәрме-юкмы – ул хәтлесен Аллаһ кына белә. Үземнән торганын, хәлемнән килгәнен барысын да эшләдем. Бигайбә! Киңәшем шул: тимергә кызу чакта сугалар, дигәндәй, сине стансыдан каршы алган туганыңның арбасына утыр да, бәхетеңне эзләп, Әмзә тарафларына чаптыр. Өйләндем дигән шапырынуыңны дөрес аңлап, гафу итә алса, бәлки, кушылып та куярсыз. Хатын-кыз күңеле төпсез кое, диләрме әле кызыл авызлар?»

Сәләхетдин картның җылы хәбәре Гавазның инде йомыла, үз кабыгына бикләнә килгән күңелендә өмет чаткысы уятты. Бәлки...

Илаһилык юлын күрсәткән Сәләхетдин бабасына яхшы хәбәре өчен ихластан рәхмәтен әйтеп, инде аның вазифасына һич кенә карамаган соравын да бирмичә кала алмадым. Адәм баласы яхшылык эшли белгән кешегә генә үтенеч белән мөрәҗәгать итә. Янәшәсендә сукыр Гавазга гел игелек теләп торган ак сакаллы карт адашканнарга дөрес юлны тәгаенләүче әкияти Хозыр Ильяс иде. Аңа әйтмичә, кемгә юлласын ди гозерен сукыр Гаваз.

– Әгәренки Мөнирә минем белән чәчен бәйләп, гаилә корып җибәрергә, бергә яшәргә разый булса, – теленә шундый матур сүзләрнең килүенә үзе дә

гаҗәпләнеп куйды, күрәсең, мәхәббәтләр белән идарә итүче Бөек көч аңа хәерхаһ булгандыр, – бер кыенлык туа.

– Нәрсә ул тагын? Калым сорасалар, бирерлек әйберең юкмы? Булган акчаңны туздырып бетердеңме? – Эчүгә тоттыңмы, дип әйтмәкче иде дә, Гавазның хәсрәткә чумган йөзенә карап, үзен тыеп кала алды.

– Юк ла, анысы өркетми, килештерербез әле, эш аңа җитсә. Әни әйтүенчә, ызбабызның бер почмагы череп, җиргә сеңеп беткән икән.

Сәләхетдин бабасы, хәйләкәр елмаюын сакал-мыекларына яшереп, янәдән «су астыннан энҗе эзләүче»не таң калдырып, болай җаваплады:

– Мине, кабәм, юкка гына «Аллаһ колы», көнчерәкләре «суган суфые», дип атамыйлардыр. Өегезне сипләү кирәклеге турында персидәтелебез Гәрәй Гыйлемшин белән сөйләшенгән. Иртәгә үк бүрәнәләрен китертеп, сөрсегәннәрен алыштырып куярга осталарын җибәрәчәк. Ул, минем белүемчә, иншалла, сүзен үти торган егет. Син үзеңне тәртипкә китер. Кияү егете карап туйгысыз кәттә булырга тиеш.

Шул мизгелдә егетне алыштырып куйдылар, диярсең. Җилкәләрен турайтып, башын югары тотып, өенә керергә җыенды.

– Сәләхетдин бабай, барысы өчен рәхмәт сезгә. Бүген үк мунча кереп, яхшылап кырынып, үземне тәртипкә китереп, иртәгә үк сәфәр чыгачакмын.

– Замир абыеңның вакыты, теләге булса?

– Ул инде «кайчан кәләш алырга барабыз», – дип, гелән кымтырыклап тора.

Гавазның юлга әзерләнгән көннәрендә ничек борчылуын, үрсәләнүен мондый халәтне үз башыннан кичермәгән кеше күз алдына китерә алмас!

«Мөнирә аны ялганы өчен гафу итмәсә, тәкъдимен кире какса? Бөтен тәненә шыплап тулган мина ярчыклары ирлек кодрәтенә зыян китергән булса? Һәр төнне диярлек төшендә саташып, Мөнирәсен кочаклап ятулары акланмыйча, буш хыял булып калса? Сугыш тынып торган араларда солдатлар еш кабатлаган «ирлек хурлыгын татымаган адәм юктыр», дигән сүзләре аңа да караса. Мөнирәне алып кайтып, хурлыкка калсаң, оятыңны кая куярсың?

Җанын телгәләгән шик-шөбһәләре белән Гаваз Замир абыйсының яшел печән исе борынны кытыклаган арбасына утырып юлга тәгаенләде.

Ат җигүченең уттай янып торган акыллы күзләрен, мыек астыннан хәйләкәр елмаюын, илаһи җылылыгын, күз төпләреннән битенә сызылып төшкән җыерчыкларын, мал-туарга кычкырып ачылган, авыл кешесенә хас калын тавышын, ахыр чиктә «барысы да яхшы булыр», дигән сабырлыгын Гаваз күңел күзе белән тоеп барды.

**6**

Вакыйгаларның алга таба ничек, ни рәвешле агышын батыр Гавазга тугрылыклы Замир абыйсы үз «кулына алып», матур тәфсилләде. Арттырса да, ялганласа да, барысы да аның намусында. Дөрес, Замирның өстәп-ялгап сөйләргә, борчак шыттырырга маһирлыгы, үз алдавына үзе үк ихластан ышанып бәян итүе дә дәүләт сере түгел иде.

– Значытсы, ат-арба белән Әмзә тарафларына төшке аштан соң чыгып киттек. Дөньяны эңгер-меңгер үз канаты астына алган вакытларда авылга килеп кердек. Алашабыз, чакырылган кунакка ашыккан шикелле, элдертә генә, малай.

Мин аны хәерлегә юрадым. Хайван сизенә бит ул. Мөнирәләр йортын урамда очраган ерык авызлы бер малайдан белешеп алгач, атны чаптырып, имән баганалы биек капка янына килеп туктадык. Ул эчтән бикләнгән булып

чыкты. Шакылдатам, тавыш-тын юк. Бер тәрәзәдән төшкән тонык кына утны шәйләп, өйләрендә кеше барлыгын чамалап, капканы ныграк төя башладым. Шактый вакыт узгач, баскыч башыннан гына, өлкәнрәк яшьтәге бер апаның тонык, әмма усаллыгы бөреләнеп чыккан тавышы ишетелде.

– Син йөрисеңме анда гауга күтәреп, мөртәт. Мөнирә сиңа кат-кат, мине бульше борчып йөрмә, бер киселгән икмәк кире ябышмый, дип өздереп әйтте, тапканны югалтмаска өйрән, – дип, ишеген шыгырдатып аргы яктан ябарга җыенган иде, абзагыз тиз генә чигенә торганнардан түгел, монда што-то ни ту, дип, хәйлә уйлап табып, тавыш бирдем.

– Без – юлчылар, Әсәй авылыннан, эчәргә су гына бирмәссезме? – дидем.

Апабыз, киңәш-табыш итәргәме, су алыргамы, ишеген шапылдатып япмыйча гына, өенә кереп китте. Көтәбез.

Ачылырга ашыкмаган капка янында басып торганда, Гавазның дулкынлануын, өзгәләнүен күз алдына китерүе кыен түгелдер. Хисчән гашыйкның йөрәге тышаудан котылган узышчы ат кебек, тамагыннан чыгып китәрдәй булып үрсәләнә. Җитмәсә, яшәгән өе янына килеп туктагач, Мөнирәсенең сурәте, яктырып, кичә генә күргәндәй булып, Гавазның «янында йөри».

Үзе юлда сөйләгәнчә, соңгы мәртәбә, военкомат кырында Гавазны суырып үпкәндә, җанашы йомры тез башларын гына каплап, тәненә сыланып торган чәчәкле күлмәктән, тәбәнәк үкчәле арзанлы чүпрәк туфлидән иде. Көлгән чакта аның күзләре хәйлә катыш гаҗәпләнү белән кысылып, як-якка киңәеп, бит очлары чокыраеп киткәне хәтерендә. Ә инде колагына: «Гавазым», дип пышылдаганда, тавышы халык моңнарына тиң тоелган иде.

Мәңгегә шундый матур булып калды Мөнирә аның күңелендә, йөрәгендә. Шул мәлдә «татар кызының үрнәге, хәтта Ходай Тәгаләнең дә югары казанышы, мөгаен, Мөнирәдер», дип уйлап куйганы да хәтерендә. Хәзер менә, билгесезлеккә буйсынып, таҗик чегәннәре мисле, ябык капканы бизәп тор инде. Колга буең белән! Гаваз ачылмаган капканың теге ягыннан иңгән усал сүзләрне ишеткәч, татлы уйларыннан аерылып, катгый карарга килеп:

– Замир абый, атыңны кирегә бор да, кайтып китик. Безнең киләсен белгәннәр, кемдер хәбәрне җиткергән. Үзебезне мыскыл иттереп хәерчеләнмик, – диде.

Замир:

– Ашыкма, энем, безне башкалар белән бутыйлар булса кирәк. Атка бер чиләк, безгә бер стакан суыгыз жәлме әллә, – дигәч, шул ук апа капкага якынлашып, курка-курка гына аны ачып җибәрде.

Гаваз тагын кәҗәләнеп, каршы сүз әйткәнче, хуҗабикә капканы ябып куйганчы дип, Замир егетне култыклап эчкә узды.

Шул арада өйдән, күңеле нәрсәдер сизенгәндәй, алъяпкычынамы, тастымалынамы юеш кулларын сөртә-сөртә, әле генә агачтан өзелеп төшкән, өлгергән кызыл алмадай чибәр кыз йөгереп-атлап чыкты да ярты юлда туктап-төртелеп калды. Кара күзлекле, ыспай итеп киенгән Гавазга текәлеп бик озак карап торды һәм, күз нурларын теленә күчереп:

– Гаваз, бу синме? Гаваз түгелме? – дигәнрәк сорау төшерде уймак авызыннан.

Аны тавышыннанмы, еш-еш сулавыннанмы таныган егет:

– Әйе, бу мин, Мөнирә, – диде.

– Бу тирәдә нишләп йөрисең? Әни, мосафирларга су чыгар да, юлларында булсыннар.

– Мин, Мөнирә, сине эзләп килдем.

– Хатыныңны кайда калдырдың, ник монда алып килмәдең?

Аралашуга кара томан булып сарыла башлаган киеренкелекне Гавазның шаярту хисен югалтмавы коткарды.

– Капка төбендә калды. Бәйләп куелган.

Чибәркәй, башын тыгып, урамга күз салды.

– И, алдакчы, анда аттан башка җан иясе күренми. Әллә хатыныңны калдырып кайттыңмы, янәдән өйләнергә йөрисеңме? Шәп!

– Минем ялганыма ышандыңмы, Мөнирә? Сиңа мәшәкать тудырмас өчен, киләчәгең турында уйлап алдаштым. Синнән башка берәүгә дә якын килгәнем юк, берәүнең дә кирәге юк.

Шунда әкият-дастаннарда гына очраган гаҗәеп хәл булды. Гаваз, сүзләренә күктән таяныч эзләгәндәй, кулларын әүвәл өскә күтәрде, аннары бер тезен җиргә иңдерде. Мөнирә, кинәт йөгереп килеп, култыклап алып, Гавазны аягына бастырды да, аккош муены кебек ап-ак куллары белән кочаклап алып, ике як битеннән үбәргә тотынды.

Туктап, читкәрәк китеп, зәңгәрсу күзләренә «буяу өстәп», тутырып карады да, янәдән суга төшкән балтасын тапкандай, «хуш киләсең, Гавазым», дип, тораташ басып торган егетне янәдән кочагына алды. Ниһаять, булачак кияү, җылы суга тарган шикәр кебек эреп китеп, Мөнирәне куенына тартып, сөйгәненең иреннәрен эзли башлады. Бер-береннән кыска гына вакытка аерылып торган мизгелдә икесе дә, өйрәтелгән йорт тутыйкошлары шикелле, мәгънәләре белән бер үк җөмләне кабатларга тотындылар.

– Зинһар, бәгърем, гафу ит! Мин синең каршыңда гаепле.

– Миңа үпкәләп, ачу саклый күрмә! Сине өзелеп сагындым!

Ошбу җөмләләрнең кайсын кем әйткәнен Замир абайламый калды, чөнки алар бер-берсен кочаклаган килеш әле еладылар, әле көлделәр. Мөнирәнең эре, үтә күренмәле күз яшьләре бите буйлап акканын күрде. Гавазның сукыр күзләреннән дә бу хәтле дулкынлануга яшь бәреп чыкмадымы икән? Кара күзлеге аша чамалый алмады.

Ни өчен шулай бер-берсеннән гафу сорауларының сере соңрак ачыкланды. Гаваз күзләрен сөеклесе өчен саклый алмаганга һәм Мөнирәсен җәлләп, ирсез калдырмас өчен өйләнүе турында ялган хәбәр бирүенә ярлыкау сораса, кызның аңлатуы җитдирәк булды, озынгарак китте.

– Син хатларыма җавап бирмәгәч, йә сугыш кырында үлеп, йә хәбәрсез югалганга юрап, шул ук вакытта могҗизага өмет итеп, ярты ел көттем. Өйләнүең турында хәбәр иткән хатың килеп төшкәч, синең сатлыкҗан булуыңа ышанасым килмичә, күңелем башканы тойса да, гарьләнүем, үпкәм бугаздан ташып чыкты һәм минем тирәдә күптәннән ышкынып, артымнан йөргән, шулай ук фронтовик мужикка кулымны бирдем. Тик боткабыз пешмәде.

Замир, арага кысылып, сүзен бүлдереп:

– Тоз салырга оныткансыз, – дип әйткән иде, кыз аңа ник туганына үкендерерлек итеп карап куйды да:

– Абый, киресенчә, тозы күбрәк әләкте бугай, – диде.

– Иремнең, хөрәсәнлеге өстенә, шешә төбен яларга маһир ертлач икәнлеге ачыкланды. – Шул хакта сүз калыккач, Гавазның маңгаена салкын тир тибеп чыкты. – Аның өчен тәти уенчык булуымны аңлап, аерылышуны мәгъкуль күрдем. Мужикның да миңа дәгъвасы җитди, уйландырырлык иде. Төшемдә мин ул чордагы ирем Сахипка: «Гавазым, Гавазым, кил янымарак», – дип

эндәшә торган булганмын икән. Әүвәл аерылышуыбызга риза булса, соңрак, кемне югалтканын аңлап, акылына килеп, янәдән кире кайтаруны сорап, төзәлергә вәгъдәләр биреп, артымнан ялынып йөрсә дә, аны якын китермәдем. Нәкъ шул чорда синең яраланып кайтуың турында хәбәр колагыма килеп иреште.

Икесенең дә бер-берсеннән ярлыкау сорауларының сере киләчәктә кавышуларының ачкычы булып чыкты.

Шул арада чәен җылытып өлгергән хуҗабикә – Мөнирәнең әнисе Зәмзәмия апа: «Эчәсебез килә, дип ялынган идегез, барысы да әзер, өйгә узыгыз», – дип чакырды...

...Авылга кайткач, Замир болайрак сөйләде:

– Гавазның булачак хатыны Мөнирәне димләүдә абзагызның теле-телгә йокмады, кызган табага борчакны сипте генә. Нәсел-нәсәбен мактап, уч төбендә биеткәннән соң, түбәндәгеләрне өстәдем. Гавазның, стансадан алып кайтканда, юл буе: «Минем асыл зат Мөнирәкәем кайларда тилмереп йөри дә мине күңеленнән чыгарып ташламадымы икән, аны сагынуларымнан сары сагыш бәгъремне телгәли», – дип, колак итемне ашап бетерде. «Киләчәк тормышымны аңардан башка күз алдыма да китерә алмыйм, дип, Гавазым елап ук җибәрде», – кебегрәк сүзләрен өстәгән идем, соңгысы артыграк булды бугай, егетем ике кабырга арасына, янтыгыма шулай китереп төртте ки, беркавым сулыш ала алмыйча утырдым. Фронтовиклар белән артык шаярырга ярамаганына төшендем шунда.

Ахыр чиктә, икесен дә килештереп, Мөнирәнең әнисенә алып килгән ифрат затлы бүләгемне тапшырып, эшне кызуында хәл итәргә өйрәнгән абзагыз, дилбегәне үз кулына алып, әүвәл димче, аннары башкода вазифаларын башкарып, өч көн үтәр-үтмәс килеп, инде дуслашып киткән Зәмзәмия абыстайның үзен, кызы Мөнирәне төенчекләре, бирнәләре белән авылыбызга алып кайтып, сәвит семьясы корып җибәрдек...

Соңрак Мөнирәнең әнисе, кызыннан аермалы буларак, кара тут йөзле, өлгергән шомырттай күзле, сөйкемле Зәмзәмия ханым, капканы иртә бикләп, озак ачмый торуының сереннән «йозакны» алып ташлады.

– Ул кичне сарыкларны ашатып, тавыкларны йоклатып, кызымнан: «Бүген урамга, клубка-мазарга чыгып йөрмисеңме», дип сорагач, капканы тимер келәгә утыртып, терәп үк куйдым. Бераздан кемдер кече капканы какты, без чыкмагач, шаку көчәйде.

Теге чукынчык, аерылган ире дулап йөри торгандыр әле, өебезгә «кызыл әтәч» үрләтмәсен, дип котым алынды. Ул шулай еш кына, кибеттән кызмача кайтканда, ачыгыз, ату таныш милиционерга әйтеп, иманыгызны укытам, өтермәгә Себергә үк озаттырам, дип теңкәбезгә тия иде. Капканы барыбер ачмый идек.

Кызык яраткан Замир сорау бирмичә кала аламы соң инде?

– Сезне нәрсәдә гаепли соң ул бака кашыгы?

– Мөнирәнең аңардан баш тартып, куып чыгаруы белән килешә алмый.

– Милиция белән килеп, кызыңның кулларын бәйләп алып китмәк буламы?

– Юк, алай түгел. Бездә яшәгән мәлдә минем калхуз кырыннан бер кесә уылган бодай алып кайтканымны күргән иде ул. Шуны күпертә. Янап, куркытып, янәдән кайтмакчы була. Барып чыкмады. Хәзер Мөнирәкәемнең яклаучысы, батыр хәләле бар.

## 7

Яңа гаиләгә килен алып кайтыр көнне Хәмдениса апа күршеләрен, туган-тумачаларын дәшеп, өлешчә сипләнгән өен пычак белән кырдырып, сабын илә юдырып, тәрәзәләрен ялтыраттырып, сугыштан соңгы авыр еллар өчен мөмкин булган тәкъдирдә аш табынын әзерләде, улын каршылаганда гына сандыктан чыгарылган күлмәген киеп, кәшемир яулыгын җилкәсенә төшереп, сөенеченнән балкып, Мөнирәне иң затлы мендәренә бастырып, түргә уздырды.

Бу аның яңа хуҗабикәне тануы иде. Үзен, туа килгән гаилә өчен җаваплы санап, сакал-мыекларын рәвешенә китереп, матурлап кырынган Сәләхетдин карт, бу очракта мулла абзый, яңгыратып никах укыды, Гаваз белән Мөнирәнең Аллаһ каршында ир белән хатын булуларын игълан итте, барысы да бергәләшеп дога кылып, яшьләргә бәхетле тормыш теләделәр. Шуннан соң Гаваз белән Мөнирә, авыл сәвитенә, туганнары Фатыйма апалары янына төшеп, язылышып, таныклык алып кайттылар. Ниһаять, сугыш батыры, сукыр Гаваз – хатынлы, ике ятып бер кат төшенә дә кермәгән Хәмдениса карчык киленле булды. Кичке чәйдән соң, күрше Хәдичә, әни чирләбрәк тора, кунарга керә алмассыңмы, дигән иде, мине югалтмагыз, дип чыгып китте.

Яшьләр аулак өйдә үзләре генә калдылар. Шул төнне үк, кочаклашып, үбешеп утырганда, көтелмәгән бер вакыйга мәхәббәтләренә нокталы өтер куя язды. Хикмәт шунда: адәм баласы, Хода рәхмәте илә, күктән иңгән бәхетенең кадерен белеп, сөенеп яши белми. Инде иң олы морадына ирешкән Гаваз, әллә каян күңеленә иңгән, көнче шайтан вәсвәсәсенә бирелеп, чак-чак кына иң яраткан кешесен – Мөнирәсен югалтмый калды.

Көтеп алынган тетрәндергеч ләззәтне уйламыйча әйткән сүзе, ялган дәгъва белән чак кына нәфрәт ялкынына әйләндермәде Гаваз. Мөнирәсенең ифрат нәзберек, зәвыклы, саф күңелле, кулдан-кулга йөреп таушалмаганлыгына бер кәррә дә шикләнмәсә дә, соңыннан үзе үк бәяләгәнчә, сөяксез теле үтә дә ахмак сорау төшерде:

– Мөнирәкәем, безнең арада, киләчәктә сүз куертмас өчен, бернинди сер калмаска тиеш.

– Соң, – диде Мөнирә, озын кашларын уйнатып, – мин каршы дип уйласаң, бик нык ялгышасың.

– Бу кичтә без бер-беребезгә, киләчәк тормышыбызның алсу таңлы тынычлыгы хакына, иң дөресен әйтеп, ачып бирик!

Хатыны, аның көчәнебрәк әйтелгән сүзләрен, битендәге җыерчыкларның күбәеп китүеннән сизенеп, уен-көлкегә күчерергә ниятләде:

– Мине зөфаф кичебездә иң тирән сереңнең уртасына алып кереп, өйләнүеңнең тарихы турында бәйнә-бәйнә хикәяләп бирергә булдыңмы? Хуш, кем әйтмешли, игътибар белән тыңлыйм.

– Юк ла, – диде Гаваз, чытырманлы кара урманга кереп адаша барганын тоеп. Шулай да «а»ны әйткәч, «б»сын эчендә калдыра алмады.

– Син «тегең»нән («исерек башыңнан», дип әйтмәкче иде дә, үз үткәнен капылт исенә төшереп, тукталып кала алды) башка ир-ат белән чуалмадыңмы?

Гаваз, Мөнирәнең әле генә өзелеп төшкән алмадай алсу йөзе кинәт нәфрәт катыш төшенкелек белән капланганын күргән булса, оятыннан җир ярыгына кереп югалыр иде.

Кыз, ушын югалткандай, куллары белән битен каплап, бик озак дәшми торды. Аягына басты.

– Ярый, мин сине аңладым. Хәзер җыенам да кайтып китәм. Киемнәремне соңрак килеп алырлар.

Мөнирәнең талканы коры, җитди, үз бәясен тәгаен белә торган кеше икәненә янә бер тапкыр инанган, үзенең нинди зур хата эшләгәнен аңлаган Гавазга, хатынлыкка сорап килгәндә, җиргә уң тезен текәсә, хәзер сулына тезләнеп, хатынның аякларын кочаклап, мең тапкыр гафу үтенеп, иңрәүдән башка чарасы калмаган иде.

– Гафу ит, зинһар, Мөнирәкәем, мин тинтәкне. Телем башыма буйсынмый башлады шатлыктан. Синең намуслы икәнеңне, кияүдә булып кайтканыңны яшермичә әйтүеңне, мине кызганып, элеккеге мәхәббәтебезне аяк астына салмас өчен генә кушылырга риза булуыңны аңлаган тәкъдирдә дә шул хатаны эшләдем. Нишлим соң инде мин җүләр?.. Мондый тилелекне башка эшләмәскә ант итәм. Ташлап китсәң, үземә кул салам! Куркытуым түгел!

Хатын күңеле, җаны белән рәнҗесә дә, элеккеге акыллы, ирләрчә чибәр Гавазны ярату, якын итү катыш гариплегеннән чарасызлыгын аңлап, жәлләп, горурлыгын акылына буйсындыра алды.

– Ярый, тор. Утыр. Син – сугыш батыры, алай түбәнсенмә! Сез шулай фашистларның умырткасын сындырмасагыз, без хәзер немец баена бил бөгәсе кешеләр идек.

Ике яшь йөрәкнең яңа тормыш бусагасын атлап чыккандагы беренче һәм, ышанырга кирәк, соңгы, җитди аңлашуы иде бу.

Тиктормас телле Гаваз да ялгышлыкны, хатаны эшләве ансат, ә аны төзәтү ифрат авыр, мина шартлауны сизми калып, күзне югалту белән бер икәнне аңлады, калган гомеренә җитәрлек сабак, гыйбрәт алды. Үксеп-үксеп елап җибәрер иде дә, ичмасам сукыр күздән яше дә чыкмый, йөрәк әрнүе күренми. Ә соңгысы бик тирәннән, җан сыкравыннан килә. Мондый сүзләр Мөнирәнең бәгырен телгәләп узып, тәкәбберлеге, үз бәясен белә торган шәхес булуы өстенә, ханым тайгак юлдан бик җәһәт кенә чыга да ала икән.

– Булды. Җитте. Балавыз сыгып утырмыйк. Бүген ике җанның, тәннең кавышу, бәхет төне, безгә болганчык суда балык тоту, ягъни сүз куерту килешми.

Мәхәббәтләре җитди сынаулар үткән, кавышулар көткән ике тән, бер-берсенә сыенып, таң атканны, җиһанга яктылык иңгәнне дә сизми калдылар. «Без өйләнгәч, төн кыскара», дигәннәре шундый кайнар йөрәкләр мисалында тугандыр инде.

Кайнар мәхәббәтләре ташып торган ике яшь йөрәк, күңел-рухлары киләчәккә юнәлеп, өмет белән, тормышның яхшыга үзгәрүенә ышанып яшәп киттеләр. Бер ел узар-узмас, пар күгәрченнәр сөешү җимешен – улларын алып кайттылар. Аңа Сәлим дип исем куштылар.

Гаиләләре ишәеп китүгә иң сөенгән кеше Хәмдениса апа икәнне искә төшереп тору артык булыр. Оныгын бәллүр савыт тоткандай кулына алганда, улының киләчәге (аңардан берүзе калса) өчен кара сөремгә батып яшәгән карчык күзләренә, кан тамырларына иңгән сөенечен яшереп тә тормады; үтә күренмәле күз яшьләре тирә-юньгә нур сирпеп торгандай балкып агылды. Кыскасы, тәүге оныгы туу карчыкны ничек канатландырып җибәрүе янә бер шигъри дастанга лаек иде.

Туй мәшәкатьләре узуга, йорт тирәсен алабута, кычыткан кебек әрсезләрдән тазартып, барлык көндәлек эшләрне үз кулына алган Мөнирә, беренчеләре тугач, яшәреп, тагын да матураеп китте. Һәм бу гүзәллекне, үзгәрешләрне күрмәсә дә, Гаваз күңел күзе белән тоя иде.

Балалары туганчы Мөнирә бар игътибарын никахлы иренә бирде. Сабыйны тәпигә басарга өйрәткән шикелле, Гавазын өйдә, йортта, урамда култыклап йөртте.

– Син, матурым, күрмәвеңне онытырга тырышып, кулың тигән һәр әйберне, аягың баскан җирне күңелеңә беркетеп, хәтереңә тезеп барырга өйрән, шуңа омтыл. Эчемдә тибенеп, усалланып яткан балаң да шул хакта кисәтә, бир әле кулыңны, атасы, аның ничек кымшанып, минем әйткән сүзләрне хуплавын сизәсеңме? – дип, газизенең кулын шактый бүлтәеп чыккан корсагына куйды.

Бер-берсенә тәмам ияләшкәннән соң, Мөнирә Гавазның ике ятып бер төшенә дә кермәгән, мәгәр күңеленә бәлзәм булып сеңгән бер җитди серен чиште.

– Сугышка алыну хәбәреңне ишетүгә, район үзәгенә килеп, үбешеп аерылганчы ук, кавышасы булган икән, дип, бик нык үкендем. Без бит, үзебез теләгәнчә тормыш итүдән бигрәк, кешеләр, әти-әни нәрсә әйтер, дип куркып яшибез. Ходай Тәгалә, минем теләгемә колак салып, синнән балалы булу ниятемне дә хуплаган булып чыкты. – Берәү дә бәхетебезне күпсенмәс дигәнрәк назлы, иркә тавышы белән Гавазын сөендереп, гариплеген тәмам оныттырып, тирәктәге сандугач мисле сайравын белде.

Гавазны аеруча сөендергәне – аш-су табыны әзерләүгә маһир Мөнирәсенең әнисе белән күптәнге танышлар, хәтта кан кардәшләр шикелле уртак тел табуы, әнкәем, чәеңне куертып җибәримме, менә монысын кабып куясыңмы, дип, каенанасы белән җылы аралашып, кабул ителгән гадәт буенча, бераз чик тә калдырып, тормышларын җайлый белүе, татарның кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләргә иң югары бәясе – өрмәгән җиргә утыртмавы – күңелен җылытып торды.

Әтрәк-әләм белән салмыш йөргәндә, иң якын кешесенең кайгыга батып, саргаюын күрмәс өчен, сукырлыгына да разый булса, хәзер баласын-бәгырен күрә алмавы Гавазның җанын телгәләде.

Сәлимнәре ун айдан йөри башлауга, Мөнирә, Гавазга бернинди ташлама ясамыйча:

– Мәле, улыңның кулын тот та өй буйлап сәяхәткә чыгыгыз, бераздан йортны, тирә-юньне үзләштерегез, елмаюын яшерүне кирәк тапмыйча, яраткан эскәмияңдә дә кунаклап алырсыз, – дип тә өстәүне мәгъкуль күрде. Балалар, кайсы милләттән булуына карамастан, качыш-качыш уйнарга яраталар. Әтисенең сукырлыгын аңлаганчы, Сәлим, өстәл астына, чаршау артына, мич буена качып, Гавазны куллары, янтаулары бәрелеп, кара янып чыкканчы интектереп бетерде.

Улын йоклаткач, Мөнирә Гавазның бер кулына пычак, икенчесенә игәү тоттырды:

– Бармагыңны кисмичә генә үткенләп бир әле, матурым, пычак бәрәңге әрчергә дә ярамый.

Икенче көнне юкә чыгаручылардан мунчала алып кайтты.

– Шулардан киндерә ишәргә өйрән, хуҗалыкка һәрдаим кирәк булачак, көзгә кураларны, карлыганнарны бәйләргә ярап торыр, эш барышында бармакларың да язылыр, – диде. Авылдашлары яшь киленгә, сер итеп кенә, армиядән алып кайткан начар гадәте турында әйтеп өлгергән булганнар. Мөнирә бик акрын гына, мәгәр әнисе ишетерлек итеп, сөйгәненең колагына: «Бу сиңа эскәмиядә шешә бушатып утыру түгел», – дип, тәрбияви мизгелне дә файдаланып калырга

ашыкты. Ханым Гавазына вак-төяк шөгыльләр табып, вакытлыча булса да гариплеген оныттыру әмәлләрен күрде.

Өч-дүрт еллар узар-узмас, Әсәдуллиннар гаиләсен кыз бала бәхетле итте. Аңа, өй белән урамны бер күреп йөргән абыйсыныкына якынрак исемне хуплап, Сәлимә дип кушалар. Гаваз исә, хатынының йомышларын үтәп, аеруча кызының җиһанга аваз салуына шатланып, күктән иңгән бәхетенә сөенеп бетә алмыйча, үзенә генә буйсынган хыялый дөньясында яши.

Анда ул гына хуҗа. Хатыны, балалары Гавазның элеккеге «юанычларын» оныттыра. Үзе дә ул чорда бушка вакыт уздыруларына үкенеп куя һәм, Мөнирәсе «бер алкаштан котылып, икенчесенә килеп каптым», дип уйламасын өчен, ул хәмердән бөтенләй баш тарта.

Тормышы ямьләнеп китеп, һәрьяктан килгән, камил күренсә дә, аның бик сирәк кешегә генә чишә торган бер куркуы, борчып торган сере бар иде. Ул, ифрат батыр, тәвәккәл йөрәкле, дәһшәтле миналарны «йөгәнли» алырлык батыр булса да, ошбу куркуыннан, көзге ач чебен кебек бәйләнчек хисеннән котылу әмәлен белмәде.

Өйдәгеләр, кайгы-хәсрәте белән уртаклашкан якыннары аның шиген елмаеп, берише чигәләрендә бармакларын уйнатып, бүтән кайгысы беткән икән, дип елмаеп-көлеп кенә кабул итсәләр, Гаваз исә ошбу сиземләвенә бик җитди карады. Ничек кенә сәер тоелмасын, елга буенда үскән егет зур судан өрки иде. Ни өчен икәнен үзе дә адәм рәтле аңлата алмый. Ә бит малай чакта Чирмешәндә туйганчы коенып, бернәрсәдән дә шикләнмичә үсте. Өлкән сыйныфта укыганда (кайсында икәнен хәтерләми), сирәк исеменең мәгънәсен беләсе килеп, татарда күпчелек кеше исемнәренең гарәп теленнән алынганлыгын чамалап, авылда бердәнбер дини гыйлемле затка – Сәләхетдин муллага мөрәҗәгать итте. Тегесе зиһен шәрифләрендә «актарынып» таптымы, сүзлекләрдән карап ачыкладымы, мәгәр Гавазны тәшвишкә салып, колагына мондый аңлатма-тәрҗемәне ирештерде:

– Гарәп сүзе «гавас» – «энҗе эзләп тирән суга чумучы һөнәрмән»не, безнеңчә, «водолаз»ны аңлата икән.

Ошбу шәрехләүне яшьлек кызулыгы белән, бигрәк тә сугыш юлларын узганда, мактанып диярлек кабул итеп, оныткан ук иде. Фронтка алып китүче вагоннарга төялеп ятканда, биш-алты яшьлек нарасыен җитәкләгән чегән хатыны (мәгълүм булганча, чегәннәр яшь хатыннарын яннарыннан баласыз җибәрми), рөхсәт-мазар сорап тормыйча, зур төркем арасыннан бары тик Гавазның учын кулына алып, «чибәр егет, син сугышта яраланып, исән-сау кайтып, бәхетле буласың, тик үлемеңне зур судан табасың», дигән сүзен күзенә карап әйтте дә, акча да сорамыйча, ай күрде, кояш алды, дигәндәй, шунда ук юкка чыкты. Гаваз исә бөрмәле кара итәкле, кызыл кофталы, ялт-йолт итеп уйнап торган зур кара күзләр ышыгында аеруча ак күренгән тешле чегән хатынын, аның әйткән куркыныч сүзләрен озак онытмады. Күзләрен югалту хәсрәте генә бу вакыйганы томан эчендә эретте. Сугыш матавыклары онытыла төшеп, гаиләле булып, балалары туып тынычлангач, чегән хатынының сүзләре, келт итеп исенә төшеп, тырнак астына кадалган шырпыдай, гелән күңелен кыбырсытып торды. Дивана чегән кәмпере теленә ни килсә, шуны лыкылдый инде, дип, үзен тынычландырырга, шомлы уйларыннан котылырга тырышса да, барып чыкмады, судан куркуы, бала чакта бүредән өркү шикелле, аны үзеннән җибәрмәде.

Чегән хатынының авыр яралану, бәхетле гаилә кору турындагы фаразлары

рас килүе аны тәмам пошаманга салды. Ышанмаска тырышса да, суга керергә, коеныргга яратмады. Мөнирәсе, кулыннан тотып, елгага алып керсә дә, кендегеннән тирәнгә үтәргә базмады. Урыс мәкалендә әйткәнчә, «Аллаһ йоклаган арада, шайтан ни кылмас».

Елга буенда үскән балаларны тормыш чыганагы – су үзенә тартып, ымсындырып тора. Әсәдуллиннар гаиләсе коеныргга гел бергә, дүртәүләп төшәләр. Сеңлесе суга керүдән курыкса да, Сәлим алты яшендә йөзәргә өйрәнде, хәтта су астыннан «энҗе эзләргә» дә күп алмый. Табигый мохиттәге балык шикелле хис итә үзен.

Язмыш уеныдыр инде. Чегән хатынының өченче фаразы – фаҗига буласы көнне, гөнаһ шомлыгына каршы, «өйдә эшләрем күп», дип, Мөнирә су буена төшмәде. Күрсәтмәләрен генә бирде.

– Карагыз аны, сак булыгыз. Сәлим, син йөзә беләм, дип әтәчләнеп, тирәнгә кермә. Әтиеңне чирәмгә урнаштыр да, Сәлимәсен кочаклап, су тавышын тыңлап утыра бирсен!

Һәм шулай эшләделәр дә. Көн матур иде. Күңелләрне иләсләндереп, йомшак кына җил исә. Гаваз Сәлимгә: «Улым, тирәнгә кермә, миңа тавышыңны ишеттереп тор, кызым, абыеңны күзеңнән ычкындырма», дип кисәтеп торды.

Балалар, рәхәтләнеп йөзеп-чумып, озак итеп су чәчрәтеп уйнадылар. Барысы да канәгать иде шикелле. Бермәлне Гавазның колагына Сәлимнең каты итеп кычкырган тавышы ишетелде:

– Әти, әти, Җәүдәт бата, аны су йота, аякларын тартып чыгара алмый.

Гаваз, ни-нәрсә эшләгәнен белештереп тә бетермичә, итәгендәге кызын чирәмгә бастыра да, каударланудан галошларын да салырга онытып: «Батам, аякларымны күтәрә алмыйм», – дигән тавыш килгән якка чумды һәм, күрше малае Җәүдәтне су астында табып алып, бар көченә баткактанмы, шайтаннанмы, әллә балыкчылар куйган җәтмәдәнме тартып алып, мөмкинлеге, хәле булганча күтәреп, бар көченә саерак җиргә, ярга таба ташлый. Шуннан соң гына үзе чыгарга омтылыш ясый башлый. Аякларын берәм-берәм үзенә суырып торган сазлыктан тартып чыгарырга тырышуы берни бирмәвен сизә. Әйтерсең лә аларны тышаулап куйганнар. Ул лайлалы чоңгылга эләгә. Үзен аска сөйрәгән тиле көчкә бирешәсе килмичә, аякларын коткарырга, бар булган көчен куеп, өскәрәк күтәрелергә омтыла. Шул талпынуында бер генә мизгелгә башын судан өскәрәк чыгаруга ирешә. Күзләре кинәт ачылып киткәндәй булып, еракта зәңгәр күк читенең җиргә тоташканын күреп алгандай була. Колагына гына улы белән кызының, ачынып, елый-елый кычкырып: «Әти, әти, судан чык!» – дигән тавышлары фани дөньялыкта ишеткән соңгы сүзләре була. Бу юлы инде ул яртылаш янган күз кабакларын мәңгелеккә йома.

Үзәктән чакырылган белгечләр «су астыннан энҗе эзләүчене» көч-хәл белән тартып чыгара, бөтен авылдашлары җыелып, батыр егетне, изге җанны, зурлап, соңгы юлга озата.



Әлфия
Ситдыйкова

# ЧОР БУРАНЫ АВЫЛ ЭЧЕНДӘ...

## Аһларың кайда соң?

Яктылык сулышын тоймабыз,
Күзләргә ак төшәр шул көннән.
Татарым, вөжданың, намусың
Кайларга тапталып күмелгән?!

Әткәңнең, әнкәңнең васыятен,
Кадерле бүләген – телеңне,
Бер бармак янауга, читләргә
Куркудан сүз дәшми бирдеңме?!

Чигенә-чигенә соң чиктә
Аттыңмы җаныңны тәмугка.
Ничекләр җир тәнең күтәрә,
Үз телең ятканда табутта?!

Телеңне тереләй күмгәндә,
Аһларың кайда соң, милләтем?
Киләчәк буынны мирассыз
Калдырган язмышны нишләтим?

Заманның коточкыч җәзасы –
Югалту үз телең, илеңне.
Бәддога ишетер көннәрең
Җитәчәк, югалтсаң телеңне.

---

Әлфия СИТДЫЙКОВА (1957) – *шагыйрә; «Утлы җимеш», «Тансык бәхет», «Хәтер җебе» һ.б. китаплар авторы. С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты. Чаллыда яши.*

## Бер гомер

Туулар бар җирдә, китүләр бар,
Китми яшәү мөмкин түгелдер.
Туу да бер җирдә, китү дә бер,
Гомерләр дә безнең бердәнбер.

Яши белеп яши алсак әгәр,
Булмас иде кайгы-газаплар.
Ялгышлыклар кылсаң, кайтавазы
Кайтып кире күпме яңаклар!

Бер абынган өчен мең кат түләп
Тормыш итә кеше чынлыкта.
Бер кабынган учак, дөрләп янып,
Ныклык өсти икән холыкка.

Бер мизгеллек бәхет өчен еллар,
Чорлар белән түләп әҗерен,
Бер гомерне яшәп китә кеше,
Аңламыйча аның кадерен.

Яши белеп яши алсак иде...

## Суга күрмә...

Чынбарлыкны онытасы килә.
Оныттырмый тормыш минут та.
Канат куя кайчак иңбашыңа
Йә биетә сине ул утта.

Кайгылардан сынам, дигән чакта,
Дөнья көлеп карый күзеңә.
Каеннарның тузларына кадәр
Мохтаҗ икән язар сүземә.

Суга күрмә, тормыш, теземә...

## Төшкә керсә

Төштә күргән өндә алга килә...
Күрәзәче түгел түгелен.
Тик шулай да ни буласын алдан
Сизеп тора минем күңелем.

Өметләрнең киселеп төшүләре
Уелып калган яшьлек мәлендә.
Читләр ничек сине үз итсен дә
Уе белән керсен хәлеңә?!

«Кешенеке – кештәктә», – дип халык
Хак сүзләрен әйткән күптәннән.

Төшкә кергән алга килә икән, –
Бу алхәбәр, димәк, үткәннән.

## Көтәмен

Син – кояш, мин – тулган ай сыман.
Сагындым, сагынам, юксынам.
Уч төбе кадәрле йөрәккә
Җанымны көйдергән ут сыйган.

Яндыра бәгырьне сагышым,
Каргышым, ялгышым, табышым.
Кадерләп саклыймын хәтердә
Яраткан йөрәкнең тавышын.

Ал кояш керфеген какканда,
Тулган ай яшерә ак йөзен.
Һаман да көтәмен зарыгып,
Утлардан аралар хак сүзең.

«Яратам, яраттым, яратып
Китәрмен дөньядан…» – дисәң син,
Кайтырмын яшьлеккә. «Җан атып
Яшәүчем бар, – диеп, – исән син!..»

## Давыл тынар

Кем китсә дә, йөрәк сыкрап кала,
Булмый җанны, булмый юатып.
И кадерле, газиз авылдашлар,
Китәсез лә безне елатып.

Ничек ярдәм итик сиңа, авыл,
Яшәртергә сине ничекләр?!
Күгәненнән каерыла язып,
Әрнеп елый, әнә, ишекләр.

Капкалар да үксеп ябылалар,
Киң урамнар кала бушанып.
Гөрләп торган чагың узганына
Булмый һич тә, булмый ышанып.

Чор бураны өермәләр булып,
Дулап йөри авыл эчендә.
...Авыл уртасында иркен йортта
Бала елый бөтен көченә.

Давыл тынар, якты өмет кебек
Ишәерләр беркөн балалар.
Авылыбызны саклап калыр өчен,
Җаны барлар кире кайталар.

## Сөя белү

Ярату ул – җанны бүлеп бирү,
Хисләреңне, якын кешегә.
Яратылмый яшәгәннәр һәрчак
Ялгызлыкта туңып күшегә.

Яратканнар, күзен ачу белән,
Сөйгән ярын искә төшерә.
Табынына тәмле сыйлар тезә,
Бисмиллалап ашын пешерә.

Тик ярата белгән кеше генә
Ут-су кичә сөю хакына.
Хыянәтсез гомер юлын үтә,
Тугры калып йөрәк антына.

Ә мәхәббәт күтә белә микән?!
Күтә назны, җылы карашны.
Бәхет мизгелләре тоташтыра
Йөрәк белән йөрәк арасын.

Тик яраткан җаннар гына парын
Ышыклыйдыр җилдән, яңгырдан.
Үзгәртәлә хәтта тиң ярының
Бар тормышын, ямьләп, тамырдан.

Сөйгән кеше хаталардан саклый,
Ялгышларың булса, кичерә.
Әҗәл чире тигән чагында да,
Шифа итеп сөю эчерә.

Мең мәртәбә күккә кадәр чөя,
Түбәнсетми сине ялгыш та.
Икең бергә булган чакта гына
Татлы була икән сагыш та.

Ярату зур талант билгесе ул,
Чиксез бәхет шаулы дөньяда.
Сөеп яшәгәннәр рәхмәт укый
Язмышына әнә шуңа да.

Хисләр сүнә, диеп әйткәннәрнең
Сүзләрендә һич юк дөреслек.
Мавыгулар гына вакытлыча,
Чын мәхәббәт бар һәм мәңгелек!

## Яулап ал


Аңламыйсың хисләремне, димә,
Йөрәгемә боз да катмаган.
Каты кабык белән нечкә җанны
Төреп куйдым, шуңа шатланам.

Өркәклегем – алданудан курку,
Газапларым татлы булса да.
Җилләр ялгыш ишек каккан чакта,
Тетрәп куя хәтта тупса да.

Кайчагында сине җилгә тиңлим,
Кайвакытта тыныч дулкынга.
Карашларың белән дәшмә мине
Сөю дигән серле упкынга.

Яратырга курка торган чагым, –
Югалтудан – җаннар кавышкач.
Кырау ала бакча гөлкәйләрен,
Җәйге көннәр көзгә авышкач.

Көзге хисләр ышанычлы, диеп,
Кабатлыйсың инде ничә кат!
Көчең җитсә, яулап ал син мине,
Йөрәгемә куйган бикне ват!



Альберт
Гадел

# ИТЕКЧЕ

БӘЯН

Казан шәһәренең Яңа Бистәсе. Революциягә кадәр бу бистәдә бер генә дә бүтән милләт кешеләре яшәмәгән дисәк тә ялгыш булмас. Аны татарның мөстәкыйль районы дип әйтергә була. Кичен яшьләр, Идел буена җыелышып, уеннар оештыралар.

Яңа Бистәне хәзерге Татарстан урамыннан тимер юл күпере бүлеп тора. Бистәгә бару өчен балчыктан дамба салынып, аннан трамвай, ат юллары уза. Дамба яз сулары ясый торган сай күлне урталайга бүлә.

Җәй көннәрендә күлдә кыр үрдәкләре, акчарлаклар йөзә. Яр буйлары камышка күмелә.

Яңа Бистә кешеләре, бигрәк тә кызлары-егетләре, бер-берен яхшы белеп гашыйк булалар, үзара ярәшеп тормыш коралар.

Бистәнең атаклы гармунчысы, шаян Мөхәррәм дә гел кызлар телендә. Ул буш вакытларында әтисе белән милли чүәкләр тегә. Аларның кулыннан төшкән чүәкләр базардан кире кайтмый, сатылып бетә. Аның шаянлыгыннан, сәләтеннән көнләшүчеләр булмый каламы соң?! Күз атып йөргән бистә кызы, чибәрләрнең чибәре Зөбәйдәгә гашыйк булган көндәшләре дә аз түгел. Бигрәк тә мехкомбинатта эшләүче комсомол Хәйрулла кичке уенда гел Зөбәйдә тирәсендә бөтерелә. Аны күргәч, Мөхәррәм, тырышып-тырышып бию көе уйнаган җиреннән, җиңел генә җыр көенә күчә.

Яңа бистәдә җыр-моңнар сызылып таңнар атканчы яңгырый.

Мөхәррәм белән Хәйрулла Зөбәйдә өчен бәхәскә дә кергәлиләр. Хәйрулла әче телле, Мөхәррәмне «кулак малае», дип кимсетә, итекче малаена Зөбәйдә тәтемәячәк, дип, иптәшләре аркылы гел җиткереп тора. Аңа җавап итеп, Мөхәррәм кичке уеннарда егетләр арасында гына сөйли торган мәзәкләре белән көлдерә.

Мөхәррәм мех комбинатында, ремонтчы-слесарь булып эшли. Бөтен эш җиһазларын вакытында тикшереп, төзәтеп, майлап, чистартып тора.

Хәйрулла һәрвакыт ыспай киенеп йөрер. Комбинатта тегелгән туннарны

---

Альберт ГАДЕЛ (1939) – *драматург, артист, режиссёр; «Бер чүлмәк алтын», «Кырлай кызы Айсылу» пьеса җыентыклары һәм «Фокуслар энциклопедиясе» авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

тикшерү, аларны сатарга җибәрү бүлегендә эшли. Эше белән бик горурлана, «аксөякләр» рәтенә кертә.

Егетләр бер-бере белән еш әйткәләшә торгач, Зөбәйдә кичке уеннарга чыкмый башлый, юкса аның өчен көнләшеп, дәртле егетләр якалашып алырга да күп сорамаслар.

Кичке уенда төрле такмаклар әйтеп җырлау ярышы бар. Кем «әчерәк» итеп, «төрттеребрәк» җырлый, шул җиңүче. Мөхәррәм үзе уйнап, такмаклар әйттергәндә, Хәйрулла эреләнеп, көчкә түзеп тора да читкә китеп күзәтеп утыра.

Мөхәррәм уйный да, җырлый да:

Нәгълләт төшсен Николайга,
Ике сыер саудырды.
Рәхмәт төшсен Ысталинга,
Кәҗәмнән дә яздырды.

Безнең җырлар төче түгел.
Бераз ачы булса да;
Ысталинга ышаныгыз,
Ышанмаслык булса да.

Мөхәррәм булмаган кәҗәсен саткан, дип, яшьләр кызык табып көлешәләр.

Көзгә таба көннәр сүлпәнләнеп, кичке уеннарда киләсе язга кадәр «каникуллар башлана».

Кемдер, Мөхәррәм өйләнә икән, Зөбәйдәнең әти-әнисенә яучы җибәргән, ураза бәйрәменнән соң туйлары була, дигән сүзне Хәйруллага ишеттерә.

Мөхәррәм үзенең өйләнәсен үзе дә белми әле. Бу гайбәтне Хәйруллага үч итеп бистә егетләре таратып, кәмит буласын көтәләр. Тик көткән кәмитләре Мөхәррәм өчен кайгы-хәсрәткә әверелә.

Капка баганасына эленгән почта тартмасыннан Мөхәррәмнең әнисе улын милициягә чакырган кәгазь ала. Сабира апа белән Зиннәтулла абзый куркуга калып, улларын эштән кайтышлый ук каршы алалар. Җитмәсә повесткада фәлән көнне, фәлән сәгатькә паспорт белән килергә кушылган.

Гаилә борчылып төн йокламый, сөйләшеп чыгалар.

– Атасы, әллә синең чүәкләр тегеп сатуыңны берәрсе әләкләп язды микән? Хәзер бит бүтән замана. Юк-бар гаеп табып та төрмәгә ябалар, – дип Сабира апа шик өстенә шик өсти.

Зиннәтулла абзый, борчылып, төне буе ишегалдында йөри һәм бакчада кошлар сайрамавыннан гаҗәпләнеп кала. Җәйнең соңгы көннәре җиткән ич. Сайрар кошлар бала очырта. Аларның гомеркәйләре бик кыска шул. Үзләренә алмашка бала үстереп, очыртып өлгерергә тырышалар. Зиннәтулла абзый да үзен шул кошлар язмышына тиң кебек хис иткәндер.

Мөхәррәм иртүк, милициядән килгән чакыру кәгазен күрсәтеп, эшеннән сорап китә.

Дежур торучы милиционер аны «особый отдел»га чакыруларын әйтеп, башы белән генә ишарәләп, белдерүсез ишеккә күрсәтә. Өстәл артында өлкән лейтенант кабул итә:

– Уз, утыр! Кем буласың? – ди, паспорт белән повесткасын алып укыгач. – Ну, нәрсә, Зиннәтуллин, кайда, кем булып эшлисең?

– Мехкомбинатта, слесарь-ремонтник.

– Комсомолмы, партия членымы?

– Юк, берсе дә түгел.

– Гармунда уйныйсыңмы?

– Әйе, бераз шыгырдатам.

– Такмакларны күп беләсең, диләр, анекдотлар сөйләргә осталыгың да бар икән.

– Оста дип, аны барысы да җырлый, сөйлиләр дә инде.

– Ю-ю-юк, монда синең такмакларың илле сигезенче статьяга тарта! Бөек юлбашчыны хурлап, такмаклар җырлыйсың икән. Совет хөкүмәтеннән көлеп, анекдотлар сөйли, коткы тарата, дигән гариза килде.

Шундый гаепләнүдән Мөхәррәм кинәт каушап, бераз сүзсез торгач:

– Нинди гариза, кем язган?

Өлкән лейтенант гаризаны күрсәтә дә үзе укып чыга. Чынлап та, анда матур почерк белән аның Совет хөкүмәтеннән көлеп мәзәк сөйләгәне, Сталин турында такмак җырлавы язылган.

– Ул бит шаярып, үзара гына сөйләнүләр, – дип акланып караса да, тикшерүче аны «антисоветизмда» гаепләп язылган протоколга кул куярга куша.

– Юк, куймыйм. Мин бит аны шаяртып кына җырладым.

– Ярар алайса, кулыңны куйма. Уйларга бер тәүлек вакыт бирәм, ә хәзергә камерага кереп утырырсың.

– Ничек камерага? Ни өчен?

– Бөек юлбашчыдан көлгәнең, Совет хөкүмәтен хурлаганың өчен. Әгәр кул куйсаң, яшьлегеңә карап, судья бәлкем гафу итәр, – дип, өстәлгә бармаклары белән чирткәләп, астыртын гына, гаепләнүчене күзәтә. Следовательнең тыныч, йомшак сөйләве, җитмәсә татар кешесе булуы Мөхәррәмгә тәэсир итте бугай, имзасын куя.

– Ә хәзер бар, кайт! – дип, аңа китәргә рөхсәт итә.

Җиләс көн булса да, Мөхәррәм борчылудан тирләп-пешеп кайтып керә.

– Улы-ым, нәрсә булды, төсең беткән? – дип, әнисе – Сабира апаның каршы алуына:

– Берни дә булмады. Такмаклар җырлап йөрмәскә куштылар, – дип кенә тынычландыра.

Зиннәтулла абзый иртүк, чүәк тегә торган коралларын, матур бизәкләр салынган «заготовкаларын» җыеп, кечкенә капчыкларга салып, бакчадагы куе үлән арасына күмеп, яшел яфраклы чыбыклар белән каплый.

«Үзеңнеке, үзең дә таба алмаслык» итеп яшерү, ул инде, андый-мондый тентү булса, дип эшләнгән эш. Чөнки совет законнары бик кырыс, штраф салып, әйберләреңне генә алып китмичә, ябып та куюлары ихтимал. Бу хәлләр көн кебек ачык. Иске бистәдәге «коллегасын» итеге-читеге белән бергә алып китеп, алты ай судсыз-нисез дигәндәй, Пләтән төрмәсе шулпасын чөмерттеләр.

Зиннәтулла абзый, улыннан ничек сорау алганнарын җентекләп сорагач, бәлкем, Алланың рәхмәте белән, узып китәр, дип, намазга басып, Ходайдан ярдәм сорап дога кыла. Сабира апа да күңелен бушатып, ялварып, Алладан мәрхәмәтлек сорый.

Тикшерүче өлкән лейтенант Юнысовның шулай «йомшак» сөйләшүе каты урынга утырту өчен булган икән. Мөхәррәмне, бер атна үтүгә, судка чакырып кәгазь килә.

Зиннәтулла абзый белән Сабира апаның борчылуы чиктән ашып, улларын югалту кайгысы басып, хәлдән калдыра. Бердәнбер улларын такмак җырлаган өчен хөкем итәчәкләр...

Мөхәррәм кичләрен Зөбәйдәләр тирәсеннән берничә мәртәбә узып-китеп йөрсә дә, күрешүдән мәхрүм була. Читтән генә торып булса да, бик-бик күрәсе килә. Эчендәге борчылу, нindидер билгесезлек тынгы бирми, йокысы «кача», тамагыннан ризык үтми... Эшендә аның күңелсез, борчулы йөзен күреп сораштырсалар да, ул серен ачмый.

Билгеләнгән сәгатькә, Идел буе районы судына өчәүләп килүләрен көтеп, тикшерүче Юнысов коридорда әрле-бирле йөренә. Суд билгеләнгән сәгатьтә башлана. Прокурор, гаепләп, дәүләткә куркыныч таратучы, дип, ун елга хөкем итүләрен сорый.

Якларга бернинди дә адвокат юк. Ул чорларда адвокат булып эшләү куркыныч һөнәргә әверелә. Судьяның, гаепләнүеңне танйсыңмы, дип соравына, эчкерсез, гади эшче егет:

– Бөтен яшьләр дә такмак җырлый инде. Урыслар әллә нинди анекдотлар да сөйли бит әле, – дип, күз яшьләрен сөртә.

Зиннәтулла абзый белән Сабира апа, һушларын югалту дәрәҗәсендә сүзсез калып, суд карарын көтәләр. Судья «киңәшләшү» бүлмәсенә кереп, ике-өч минуттан «бүреге белән киңәшләшеп» чыккач, суд карарын укып, Мөхәррәмнең яшьлеген, әлегә кадәр судка тартылмавын искә алып, «нибары» биш елга төзәтү, тәрбияләү лагерена, дип, хөкемен игълан итә.

Әлегә чаклы күзгә чалынмаган ике конвой Мөхәррәмне култыклап, алып чыгып та китәләр. Менә сиңа советларның иң гадел хөкеме.

Урамда, суд бинасы янында, тартып торучы тикшерүче Юнысовны күреп, Сабира апа нindидер эчке батырлыгы белән йөрәк әрнүен әйтә:

– Мин сине үлгәнче каргаячакмын! Бердәнбер улыбызга нахак бәла ягып, төрмәгә утырттың. Үзең дә шунда ун елга китсәң иде! – ди.

Кайгыдан бөкрәйгән Зиннәтулла абый белән Сабира апа өйләренә кайткач кына исләренә килә: уллары Мөхәррәмнең өстендә күлмәк белән көн дә кия торган пиджагы гына иде.

– Көз якынлашкан саен, көннәр салкыная, ул мескенем анда нишләр, – дип, икенче көнне улларына эчке кием, ашарына ризык алып, Пләтән төрмәсенә иртә таңнан барсалар, анда чират, алар кебек кайгы-хәсрәткә баткан кешеләр таң атканчы ук килеп басканнар. Һәркем үз зарын чиратта басып торучы күршесенә сөйләп, күңелен юатырга тырыша.

Сөйләүләре буенча, яшьләрне, юк кына гаеп табып, бишәр-унар елга хөкем итеп, Коми якларына урман кисәргә җибәрәләр, ди. Мөхәррәмне гаепләүнең төп сәбәбе – көчле яшьләрне лагерьларда бушлай эшләтеп, дәүләтнең экономикасын күтәрү икән. Аларның язмышы – дәүләт өчен арзанлы эшче кул. Болары «китсә», яңадан яшьләре үсеп килә бит...

Берничә сәгать аягөсте чиратта торып, улларына бирәсе әйберләрне җентекләп тикшергәч кенә, «передача»ны кабул итеп, кәгазь кисәгенә кул куеп җибәрәләр.

«Фәләненче числода этап китәчәк. Саубуллашасы килгәннәр шул көнне килеп, тимер рәшәткә аша саубуллаша ала», дигән игъланны да укыйлар.

***

Унөченче санны «чёртово дюжина», дисәләр дә, Мөхәррәмгә аз гына булса да язмышы мәрхәмәтле булды. Унөченче камерада унбишләп тоткын, барысы да яшьләр. Күбесе – районнардан, авыллардан. Күкрәк кагып утыручы блатнойлар юк. Яшьләр тиз аралашып, бер-беренә нинди «гөнаһлар»

тагылганны, ничәнче статья нигезендә утыруларын белешәләр. Аларның статьялары «халык дошманы»на тарта. Ул замандагы канатлы сүз – «кешесе генә булсын, статьясы табылыр» – бик актуаль сәясәткә әйләнә.

«Передача» әйберләре биргәндә, Зиннәтулла абзый: «Улым, өрә белмәгән эт авылга бүре чакыра, авызыңа йозак эл, үзеңне сакла!» – дип язу тыккан була. Әтисенең сүзләре Мөхәррәмнең күңеленә ташка чокып язган кебек сеңеп кала.

Татарстанда хөкем ителгәннәрне, шәһәр төрмәләреннән товар вагоннарына төяп, Коми якларындагы лагерьларга алып китәләр, чөнки яшь кеше – урман кисү өчен бик кирәкле, арзанлы эшче.

Өч көн буена, сохарины салкын суга манып, рәхәтләнеп ял итеп, коры такта сәндерәдә йоклап, ниһаять, төнлә «курортка» килеп җитәләр. Таң атканчы вагон ишекләре ачылмый, чөнки лагерьдан сакчылар көндез генә килеп, егерме чакрымлап юлны этләр белән саклап, җәяү барырга тиешләр. Бер йөк машинасына утырып егермеләп конвой килеп җитә дә, һәр вагонны чорнап ала. Берәмләп тоткыннарны тезеп бастыргач, буш калган вагоннарны кабат тикшереп чыккач, конвой начальнигы кыска гына кисәтү ясый: «Кем дә кем уңга яки сулга тайпылса, ул качарга җыенучы булып санала. Конвой кисәтүсез атачак, эттән талатачак».

Тоткыннар колоннасының башына һәм азагына, икешәр ягына да, овчаркалар белән конвой куела. Колонна уртасында да ике яклап дүртәр солдат, винтовкаларын әзер тотып, юлга чыгалар.

Берничә көн яуган яңгыр, урман юлын җебетеп, урыны белән кечкенә күлдәвекләр хасил иткән. Колонна, бернигә дә игътибар итмичә, чыпырдап торган юлдан, тайга эченнән, егерме чакрымлап юл узып, биш елга сузылачак «тәмуг»ка килеп җитә. Тимер чыбыклар белән чолгап алынган бараклар, лагерьның һәр почмагында сакчы утыра торган вышкалар күңелләргә шом сала, шушы якты дөньяда соңгы юлыңны узасың, дип ишарәли кебек.

Колонна лагерьга кергәч, бер офицер каршы алып, исемлек белән тоткыннарны барларга боерык бирә. Старшина Сидорчук һәр фамилияне тамак ярып барлагач, хөкем ителгән, хокуксыз җан иясе генә булып калган кеше, колонна каршына чыгып басып, үзенең барлыгынраслый. Тоткыннарның барысының да аяклары сазга баткан. Мөхәррәмнең җәйге туфлие җебеп, ертылып ук чыга. Аягы салкын пычрак балчык эчендә. Ачлыктан ашказаны «борып» авырта.

Исемлекне барлагач, отрядларга бүленеп, баракларга тараталар. Яңа килгән тоткыннарга ярым буш торган бараклардан ятак бирелеп, тамгалар яздырып эләләр. Такта сәндерәләрдә – салам-печән тутырган матраслар. Өскә ябынып ятарга юка гына юрган.

Мөхәррәмгә Чистай егете Василий белән ике катлы сәндерә бирелеп, шобага салгач, Мөхәррәмгә икенче каттан урын эләгә.

Аларның бәхетенә, ял көне туры килеп, чәчләрен алып, мунча кертеп юындыргач, лагерь киемнәре кидерәләр һәм ашханәгә алып баралар. Кәбестә шулпасын ипи кисәге белән чөмергәч, сыек кына борчак боткасы салынган тәлинкәләр дә тиз арада бушап кала.

Бараклар эчендә керосин лампалары гына, чөнки генераторның көче җитми. Сак вышкаларына элегән прожекторлар ике кат чәнечкеле чыбык арасындагы «мёртовая зона»ны һәм бараклар алдындагы мәйданны гына яктырта. Ул «зона», җәен атна саен йомшартылып, тырма белән тырмалап күпертелә. Качарга ниятләгән кешенең эзе шунда басылып калачак.

Василий – Чистай егете. Ул да такмак әйтергә, анекдотлар сөйләргә яратканы өчен биш елга хөкем ителгән.

Дүшәмбе көн, иртән сәгать алтыда, барлык лагерь халкы аякта. Урамдагы юынгычларда юынып, һәр отряд тезелешеп иртәнге ашка бара. Мөхәррәмнәрнең отряды икенче чиратка кала, чөнки ашханәдә урын җитми. Иртәнге ашны капкаларга унбиш минут вакыт бирелә. Шуның өчен тоткыннар өстәлгә ябырыла. Ул арада: «Выходи строиться!» – боерыгы яңгырый. Иртәнге сәгать сигездә бөтен тоткыннар «плац» дип аталган мәйданга чыгып тезелә. Һәр отрядның старшинасы, исемлекне кычкырып барлагач, лагерь начальнигы каршына барып хәбәр итә. Лагерь начальнигы, майор дәрәҗәсендәге офицер, тоткыннарның исенә төшерә: «Качарга теләүчеләр булса, тотылгач утыру вакыты тагы да артачак. Урман кисүдә норма үтәмәүчеләрнең ашавы кысылачак, каршылык күрсәтүчеләр карцерда ун тәүлек «ял» итеп чыгачак. Һәр отряд, тезелешеп, тайгада бүлеп бирелгән җирләргә юнәлә. Киселәсе, гасырлар яшендәге чыршы-наратлар алдан ук тамгаланган. Күз күреме саен овчаркалы сакчы – куаклар арасында әрле-бирле йөреп күзәтә – аеруча хәтәр тоткыннарны саклый бит...

Киселәсе агачка дүртәр кеше куелып, ике куллы пычкылар, балталар алынгач, эш башлана. Күп тә үтми, «берегись» командасы яңгырый башлый. Ике кеше колачы җитмәслек зифа буйлы чыршы-нарат гөрселдәп җиргә ава. Ботаклары юнылгач, унар метр озынлыгында агач киселә. Соңынтын ул бүрәнәләрне, «ЧТЗ» тракторы белән тарттырып, бер урынга өячәкләр. Кыш җиткәч, трактор чаналарына төяп, тимер юл станциясенә озатачаклар.

Мөхәррәм белән Василийның тайгадагы эш көне шулай башланып, биш ел буена дәвам итәчәк, исән-сау калсалар...

«Блатнойлар» – уголовниклар аерым баракта. Алар үзләрен лагерь элитасы дип атыйлар. Тайгада эшләгәндә: «Эй, вы, частушники», – дип көлеп, кимсетергә төрле сәбәп табып, тавыш-гауга чыгарырга тырышалар. Мөхәррәм белән Василий, бернинди дә провокацияләргә игътибар итмәскә сүз куешалар. Бүтән тоткыннар белән сер алышмаска, әтисе язганча: «Авызыңа йозак эл!» – дигән киңәшне истә тоталар.

Яңгырлы салкын көз дә килеп җитә. Җәйге тайганың канэчкеч озын борыннары кышкы йокыга тала. Чебен-черки югалып, аларны бетләр, кандалалар алмаштыра, тәүлек буена тоткыннарның канын инде алар эчә. Мунчада юынган арада тоткыннарның киемнәре термообработка узса да, бер-ике көннән яңадан шул хәшәрәтләр басып ала.

Ноябрь аенда җир туңып, кар төшә. Тайгада урман кисү тукталырга тиеш түгел. Күбесенең аяк киемнәре тузып ертыла. Чолгаулар тиз чылана. Делянка уртасына учак ягылып, шунда аяк киемнәрен, чолгауларын киптереп алганда, бераз ял итеп, җылынырга да була. Кем ничек булдыра ала, шулай ботинкасын төзәткәли, купкан табанын бау кисәге белән бәйли.

Мөхәррәм үзенең дә, Василийның да ботинкаларын хоздворга алып кереп, мөмкин кадәр төзәтеп, күпмедер вакыт киярлек яраклы итә. Аның оста куллы булуын старшина Сидорчук күреп: «Давай, татарин, возмись, все рваные ботинки моего отряда почини. За это я тебя на лесоповал не возьму», – дип, итекче малаен тәки «сапожник» итә. Мөхәррәм, булган кадәр иске күн, резина итекләрен җыеп, отрядтагы агайларның ботинкаларын төзәтә башлый. Сидорчукның күңеле булып, ул лагерь начальнигына: «Минем отрядта барысының да аяк киемнәре төзек!» – дип рапорт бирә. Ни әйтсәң дә, лагерь

өчен экономия, яңа аяк киемнәрен дәүләттән алу бик катлаулы. Тоткыннар кайгысы түгел, армияне киендерү мөһимрәк.

Европа илләрендә сугыш бара. Немецлар Советлар Союзына һөҗүм итәргә мөмкин, дигән куркыныч хәбәрләр йөри.

Лагерь начальнигы майор Хоменко, старшина Сидорчукка Мөхәррәмне хоздворга җибәреп, аяк киемнәре төзәтү урынын билгеләргә, кирәкле кораллар, күн, резина кисәкләре бирергә куша. Хоменконың боерыгы тиз үтәлә, Мөхәррәмгә хоздвор барагының бер почмагында урын, кирәкле эш кораллары да бирелә. Әтисе өйрәткән итекче һөнәренең бик тә кирәге чыга. Мөхәррәмгә өйдән, айга бер мәртәбә булса да, хат килгәли. Әти-әнисе, гадәттәгечә, борчылуларын, юксынуларын язып, исән-сау әйләнеп кайтуын телиләр.

***

Мөхәррәмне «этап» белән лагерьга озатуга, Сабира апа тынычлыгын югалтып йокысыз кала. Улын югалту, сәламәтлеген бик нык какшата – кан басымы күтәрелә, көчле баш авыртуы азаплый. Хәле бетеп, өянәге тәмам урын өстенә яткыза. Зиннәтулла абзый да үзен кинәт картаеп киткән кебек хис итә, сүлпәнләнә төшә. Чүәк тегәргә әзерләгән әйберләрен чормага ук менгезеп, иске сандыгына салып куя. Эшләргә кулы күтәрелми, күңел боеклыгы җиңә. Җитмәсә, гомер иткән җәмәгате, Сабирасының авыруы аны үзенекеннән дә ныграк борчый.

Урын өстендәге хатыны еш кына:

– Атасы, миннән алда гына китә күрмә. Берүзем калып нишләрмен, – дип өзгәләнә.

– И-и-и анасы, кемнең кайчан китүен бер Ходай үзе генә белә. Юкка борчылма. Әле савыгып, улыбыз кайтуын күрергә насыйп булсын! – дип, догалар укып, хатынын юата.

***

Мөхәррәмгә хуҗалык бүлегендә аяк киемнәре төзәтү, аш бүлмәсендә утын кисеп яру, атнага бер мунча ягылганда су, утын ташып тәэмин итү бурычы йөкләнә. «Отбой» булганчы ул үзенең мастерскоенда төрле эш табып вакытын уздыра. Василий да аның янына еш кереп, өйдән килгән хатындагы яңалыклар белән уртаклаша. Почмакта яткан брезент кисәкләренә Мөхәррәмнең күзе төшеп, яхшылап караса, әле кулланырга ярыйсы гына җирләре табыла. Бераз чамалап үлчәгәч, өстен брезент кисәгеннән, табан астына иске, ертык киез итек кунычын кисеп, ыспай гына, өйдә киеп йөрерлек чүәк тегә. Чүәкнең өстенә күн калдыкларыннан лалә чәчәге дә ясап ябыштыра. Карап торырга гади генә әйбердән өйдә кияргә хатын-кыз чүәге әзер була.

Старшина Сидорчук хуҗалык барагына кергәләп йөри. Икесе генә калгач, Мөхәррәм, чүәкләрен сузып: «Гражданин начальник, менә хатыныгызга бүләк булыр», – дип, кулына тоттыра.

Сидорчук, гаҗәпләнеп, бүләкне кабат-кабат әйләндереп карый.

– Молодец, татарин. Спасибо за подарок! – дип, бүләкне култыгына кыстырып чыгып китә.

Берничә көн узгач, старшина тагын керә:

– Ну, как дела, сапожник? – ди.

– Мөхәррәм, «үрә катып», кем булуын һәм кайсы статья буенча хөкем ителгәнен әйтеп бетерми, Сидорчук, аны шундук туктатып:

– Слышь, Зиннатуллин, ты хромовые, офицерские сапоги шить умеешь?

– Мужские, женские ичиги шил, а офицерскиларны юк.

– Ичиги?

– Әйе, җиңел итек. Урамга чыкканда, аңа калуш кигезәләр. Өй эчендә киеп йөрергә җайлы.

– Ярар. Нинди материаллар кирәклеген язып бирерсең, – ди дә чыгып китә.

Мөхәррәм кечкенә кәгазь кисәгенә кирәкле товарларны: эш коралларын, энәсен, җебен, сумала белән балавызын да язып, старшинага тапшыра. Күн итек тегү өчен калып кирәклеген, аны имән йә каен агачыннан гына ясалуын әйтеп, үзенә ярдәмче бирүләрен дә сорый. Калып ясар өчен итекнең кем аягына тегеләсе алдан ук билгеле, старшина үз аягының үлчәвен күрсәтә. Күчермә өчен иске итеген биреп торырга була. Ә ярдәмчене үзегезнең барактан сайлап ал, ди.

Мөхәррәмнең тәкъдиме Василийга ошый-ошавын, тик аның итек тегү түгел, үз гомерендә калуштан башканы кигәне булмаган икән. Теләгең булса өйрәнерсең, дип, Мөхәррәм аңа тайгадан ботаксыз каен түмрәннәре алып кайтырга куша.

Тоткыннар һәркөн эштән соң тайгадан ягарга әзер утын пүләннәре күтәреп кайта. Бараклардагы мичләрне ягып җылыту – анысы истопниклар бурычы. Алар инде үз эшләрен тырышып башкаралар. Бараклар тиз җылына үзе, тик иртәнгә кадәр суынып та өлгерә.

Василийны Мөхәррәмгә хуҗалык эшләренә ярдәмче итеп билгелиләр. Василий тайгага баргач, үзе сайлап алган төз каенны, Мөхәррәм әйткәнчә кисеп, дүрт калыпка җитәрлек итеп әзерләп алып кайта. Агачларны мичтә бераз киптергәч, старшина аягы зурлыгында бер пар калып ясала.

Күн итек тегү читек тегү кебек кенә түгел, ул бик катлаулы, мәшәкатьле эш. Мәгәр, Василий сәләтле өйрәнчек булып чыга, кулы-кулга йокмый, итек тегү һөнәренең серләренә тиз төшенә, Мөхәррәмгә эшне җиңеләйтә. Бер атна эчендә «офицер итеге» тегелә. Старшина, ялтырап торган итекләрне кулында әйләндерә-әйләндерә карагач:

– Ну-у-у татарин, ты настоящий мастер, – дип, аркасыннан кага.

Мөхәррәм күн итек тегү осталыгының киләчәктә нинди хәсрәт китерәчәген уена, күз алдына да китерә алмый...

Сидорчук лагерь начальнигы Хоменкога Мөхәррәм теккән күн итек белән мактана, әгәр теләсәгез, сезгә дә тектерәбез, дип ялагайлана. Лагерь начальнигы аның тәкъдимен хуплагач, Сидорчук тагын берничә парлык кирәк-ярак, фабрикада ясалган калыплар китертә. Атна-ун көн эчендә, лагерь начальнигына да ялтырап торган хром итек тегелә. Начальникка да бу оста кул теккән күн итек бик ошый. Мөхәррәмгә ашханәдән өстәмә ипи, балык-селёдка бирдертә.

Сидорчукның «аппетиты» арта, ул башка офицерларга да күн итек тектереп, үзенә «авторитет» яулый. Ни әйтсәң дә, аның кул астындагы тоткын тегә бит. Яңа ел бүләге итеп лагерь начальнигының хатынына да «ах» итәрлек чүәк тегелә.

Тайгада урман кисүче тоткыннарга киез итеккә охшаган «чабутка» дип аталган аяк киеме бирелә. Ул бераз аяк җылысын саклаfamilyса да, бик тиз туза. Мөхәррәм белән Василий кыш буена шул чабуткаларны төзәткәләп, сипләп утыралар. Язга таба, карлар җепшекләнә башлагач, ул чабуткалар тагын да тизрәк туза, җәелеп үк төшә. Уголовниклар бер-ике мәртәбә Мөхәррәмгә «этлек» эшләмәкче булалар. Ләкин «Авторитет-зэк»: «Сапожников не

обижать!» – дип «боерык» биргәч, туктыйлар. Ертык ботинка белән берәүнең дә йөрисе килми. Итекчеләргә ел әйләнәсендә эш күп. Тайгада аяк, өс киемнәре тиз туза.

Уголовник-авторитетның әшнәсе, хөкем ителгән вакытын тутырып, ireккә чыгарга әзерләнә, аның өчен Мөхәррәмгә яңарак, төзегрәк ботинка табарга кушалар. Иреккә чыгучы, яңа булмаса да, әле нык кына ботинканы киеп, рәхмәт тә әйтмичә (алар арасында рәхмәт әйтү юк), «пацаны, на свободе сочтёмся», дип, мастерскойдан чыгып китә.

Мөхәррәм белән Василийның «дәрәҗәсе» уголовниклар тарафыннан «неприкосновенныйга» әверелә. Старшина Сидорчукның нәфесе үсә. Ул, шәһәрдәге таныш-белешләреннән дә (билгеле инде, бушлай түгел) заказлар алып, итек тегүчеләрне иртә таңнан отбойга кадәр эшләтә башлый. Василий чүәкләр тегәргә өйрәнгәч, аңа ирләрне дә, хатын-кызларны да чүәкле итү бурычы йөкләнә.

Сидорчукның «эшкуарлыгы» ярыйсы гына керем китерә башлый. Шул исәптән лагерь начальнигына да өлеш чыга.

Хатына Яңа Бистәдән, озак кына җавап килми торса да, Мөхәррәмгә, ниһаять, берьюлы ике хат килеп төшә. Беренче хатта әтисенең каты авырып хастаханәдә ятуын язсалар, икенчесендә кыска вакыт эчендә, тамагыннан ризык үтмичә, бик ябыгып үлүен хәбәр итәләр. Беренче хат айлар буена лагерь канцеляриясендә яткан, һәм ул икенче хат килгәч кенә Мөхәррәмгә тапшырыла. Егерме яшен генә узган егетне лагерь тормышы, кинәт әтисен югалту хәбәре, эчке тойгылары тагы да аз сүзлегә әверелдерә. Күңелендә дөрләгән нәфрәт хисе, дөньяда яшәүнең мәгънәсен, аның киләчәген томалый. Өч елдан артык тайгада черкидән талатып, кандала, беттән кан эчереп, «нара»да аунап яту, кешеләрне җәнлеккә әверелдерә. Ирекtә яшәүчеләргә карата нәфрәт, көнләшү хисләре тудыра башлый.

***

Иртәнге аштан соң, развод вакытында, бөтен состав плацка тезелеп баскач, лагерь начальнигы Хоменко, Германиянең Советлар Союзына каршы сугыш башлавын хәбәр итә. Һәм лагерьда «хәрби хәл» игълан ителә. Эчке кагыйдәләрне бозучыларны каты җәза көтә. Һәр тоткын урман кисүнең нормасын үтәргә тиеш. Кем дә кем хәйләләп эшләми, күз буйый – кыскартылган рацион буенча тәүлеккә ике мәртәбә генә ашатылачак һәм хәрби судка биреләчәк. Бу катгый кисәтүдән соң блатнойлар тынычлана төшеп, барысы да урман кисәргә йөри башлый. Ә Мөхәррәм белән Василий җәй буе итек, чүәк тегүләрен дәвам итә.

Җәй тиз узып, салкын көз башлана. Немецлар армиясе Мәскәүгә үк килеп җитә, бөтен лагерьларга НКВД җитәкчеләреннән тәкъдим килә: «Кем дә кем үзе теләп сугышка китәргә теләсә, гариза язарга тиеш. Сугышта катнашкан кешеләр, статьяларына карап, иреккә чыгарыла, аларның хөкемгә тартылуы Ил каршында гафу ителәчәк». Бөтен лагерь тоткыннарында иреккә чыгу теләге уяна. Мөхәррәмнәр барагы да риза булып гариза яза. Бүтән барактагы тоткыннардан да гаризалар күп була. Прокурор һәм НКВД хезмәткәрләре һәрбер кешенең «дело»сын җентекләп өйрәнә. Мөхәррәм белән Василий да гаризаларын, беренчеләрдән булып, старшина Сидорчукка тапшыралар. Кыска вакыт эчендә, фронтка барырга теләүчеләр НКВД хезмәткәрләре белән озаклап сөйләшкәннән соң, «доброволец»ларның ант бирү кәгазенә кул куя.

Мөхәррәмне сөйләшүгә чакырмыйлар. Сидорчукның әйтүе буенча, имеш,

аның анкетасы каралып, кире кагылган. Ә Василий, фронтка китүче беренче партия исемлегендә кала, китәргә җыена. Икенче көнне «штрафник»ларны плацка тезеп, фамилияләрен кычкырып барлагач, лагерь капкасы янында торучы кораллы солдатлар сагында, тимер юлга кадәр озаталар. Алар аннан товар вагоннарына төялеп, учебный пунктта бер-ике атна эчендә сугыш курслары узып, туры фронтка китә.

Тоткыннардан торган хәрби часть, «штраф батальон» дип аталып, фронтның иң алгы сызыгында катнаша. Алларында – дошман-фашистлар булса, артларында НКВД карательләренең заградотрядлары тора. Бер штрафникның да артка чигенергә хакы юк, тик алга барырга, дошманнарны тар-мар итәргә! Алар өчен иреккә чыгу – алга барып, дошманны җиңүдә йә инде каты яраланып, гөнаһыңны гафу иттерүдә. Өченче вариант: күпләр өчен сугыш кырында дошман пулясыннан «батырларча» һәлак булу.

Күп елларга хөкем ителгән, җитди җинаять ясаган тоткыннар, лагерьда калып, норма тутырып, урман кисүләрен дәвам итәләр. Мөхәррәм, үпкәләп, Сидорчуктан нигә аны фронтка җибәрмәүләрен сорагач:

– Слышь, сапожник, что, тебе здесь плохо? А на фронте стреляют, убить могут или инвалидом станешь. Так что не высовывайся. Отсидишь свой срок, поедешь домой. Глядишь, там уже война кончется, – дип тынычландырмакчы була.

Димәк, итекчене фронтка җибәрмәүләренең сере бик гади. Доброволецлар фронтка киткәч, лагерь бушабрак калуга, тагын бер «партия» китерәләр. Лагерьда калган тоткыннар, ял көне булу сәбәпле, үзләренең бараклары тирәсендә җыелышып, яңа килүчеләрне күзәтә.

Мөхәррәм дә, мастерскоеннан чыгып, «яңалар» белән кызыксына. Татар фамилияләре дә ишетә. Тоткыннарны тагын, гадәттәгечә, статьяларына карап, кайсы баракка билгеләнүен әйтеп, чәчләрен алдырып, мунча кертеп, дезинфекция уздырып, лагерь киеме кидерәләр.

Мөхәррәм, үзләренең барагында, яңа килгәннәр арасында татарлар очрамасмы, дип, ярым караңгы наралар арасында күз салып йөргәндә, маңгайга-маңгай Яңа Бистә егете, комсомол, көндәше Хәйрулла белән очраша. Икесе дә сүзсез калып, озак кына бер-беренә карашып торгач, беренче булып Мөхәррәм сүз башлый.

– Менә сиңа яңалык. Яңалык дисәң дә яңалык. Нихәл, якташ Хәйрулла? Яңа Бистәдә нихәлләр? Һуштан язарсың бу яңалыкка. Сине дә «санаторийгә» җибәргәннәр икән. Күпмегә путёвкаң?

Мондый очрашуга Хәйрулла үзе дә аңын югалтыр дәрәҗәдә гаҗәпләнә. Мөхәррәмгә туры карарга уңайсызланып, идән ярыгына карап:

– Алты елга, – ди.

– Ни өчен?

– Хәрбиләргә дип тегелгән бер машина тун югалган өчен.

– Шулкадәр тунны кая куеп бетердең?

– Минем гаебем юк. Отдел сбыт начальнигының гаебен миңа яктылар.

– Нәрсә, үзеңә бер тун да эләкмәдеме?

– Мин карак түгел. Сволочь, следователь Юнысов алдалап кул куйдырды. Кул куймасаң, ун елга китәсең, ди. Әгәр кул куйсаң, бәлкем, судья яшьлегеңне, комсомол булуыңны исәпкә алып, бөтенләй үк гаепләмәс, дип алдады. Прокурор ун елга дип торса да, судья алты гына ел бирде.

– Рәхмәт сиңа, Хәйрүш... Мин инде бишенче елымны тутырам. Урыслар

әйтмешли, «раньше сядешь, раньше выйдешь». Үзе теләп китүчеләрне фронтка алалар. Әле күптән түгел безнең баракtан илледән артык кеше, үзләре гариза язып, сугышка китте. Син дә гариза язып кара!

Хәйрулла, озакка сузмый, лагерь канцеляриясенә кереп, фронтка җибәрүләрен сорап гариза яза. Ләкин лагерь начальнигы майор Хоменко, ирония белән елмаеп, синең лагерьда, тайгада урман кисүдә туган илгә күбрәк файдаң булыр, дип борып чыгара. Чөнки Хоменко фронтка «доброволецлар» җибәрү планын тутырган. Хәзер урман кисү буенча норма үтисе бар. Подполковник дәрәҗәсен алу өчен.

Хәйрулла, Мөхәррәм янына кереп, гаделсезлектән зарлана.

– Сиңа, Хәйрүш, күнегергә кирәк. Закон как дышло, куда повернёшь, туда и вышла, диләр. Мин синнән үч алмыйм. Сиңа инде Ходай Тәгалә үзе җәза биргән – алты елга урман кисәргә җибәргән, – дип, сүзен бетерә дә эшен дәвам итә.

Хәйрүш тә урман кисүнең бөтен «ләззәтен» татый. Мөхәррәмнән үтенеп, үзенең табаны каерылып чыккан ботинкасын алыштырып, яңарагын ала. Ул Яңа бистә яңалыкларыннан: Зөбәйдәнең следователь Юнисовка кияүгә чыгуын, күп кенә яшьләрнең сугышка алынуын, үзенең вакытлыча «бронь» белән калгач, нахак бәла ягып, алты елга хөкем ителүен сөйли.

Дөньяда барыбер гаделлек бар. Җирдәге бөҗәкләр кебек мыжылдап йөргән, явызлык эшләгән кешеләр үз җәзаларын иртәме-соңмы алыр. Гөнаһсыз, гаепсез кешегә ялган бәла ягып көн күрүчеләргә каргыш барыбер төшә...

Мөхәррәмнең иреккә чыгар вакыты якынлаша. Берничә мәртәбә Сидорчукның исенә төшерсә дә: «Әле управлениедән рөхсәт кәгазе килмәде», – дигән җавап ишетә. Тоткыннарны азат итү кәгазе вакытында килсә дә, лагерь начальнигының үзенә кирәкле кешеләрне яртышар ел иреккә җибәрмәве, күптән гамәлгә кергән хәл була.

Сабира апа улының кайтмавына борчылып хатлар язса да, Мөхәррәмгә иреккә чыгу рөхсәте кебек, җавапсыз калып, лагерь канцеляриясендә ята...

***

Казанның Яңа Бистә милициясендә хезмәт итүче яшьләрне НКВД частьларына алып, алар «штрафбат» батальоннары артыннан «җәза бирү» батальоннарында хезмәт итәләр. Юнысов та «җәза бирү» батальонында взвод командиры була.

Белоруссия азат ителеп, Украинада, Балтыйк буе республикаларында көчле сугышлар бара. Немецларга сатылган бандеровчы милләтчеләр урманнарга качып, Совет Армиясе хәрби частьларына һөҗүм итеп, тынгы бирмиләр. Пленга алынган совет солдатларын ерткычларча җәзалыйлар.

Юнысов та үзенең взводы белән чолганышта кала. Пленга бирелмәс өчен, актык патроннарынача, соңгы сулышларына кадәр сугышалар. Бандеровчылар пленга алмыйлар. Солдатларны атып кына үтерәләр, ә офицерларны урманда асып кую алар өчен аеруча батырлык булып санала.

Капитан Юнысов, каты яраланып, аңын югалтып ятканда, бандеровчылар кулына эләгә. Аның әле тере икәнлеген күргәч, гәүдәсен сөйрәп, юан имән агачы янына алып барганда, ярасының әчетеп авыртуы аңына китерә.

– Ну-у щоо, москаль, очухался? – дип, бандеровчылар көлешәләр. – А сейчас трошки-трошки вешать будем, – дип, юан имән ботагына ат дилбегәсен элеп, Юнысовның муенына элмәк салып, акрын гына күтәрә башлыйлар...

Язмыштан узмыш юк дигәндәй, чолганышта калмаган комендант ротасы солдатлары, урман эчендә бүреләр кебек качып йөрүче бандеровчылар эзенә төшеп, чолгап ала. Көчле атышлар башлангач, бандеровчылар җәзалауны ташлап кача башлый.

Ярдәмгә килеп җиткән солдатлар офицерның муенындагы, кулларындагы бауны чишкәч, рота санитары ясалма сулыш ясап, нашатырь спирты иснәтеп, аңына китерә. Бугазы бауга буылу сәбәпле, сулышы кысылган, тавышы зәгыйфьләнгән була. Аягындагы яралар бәйләнеп, вакытында беренче медицина ярдәме күрсәткәч, Юнысов исән кала. Кыр госпиталена барып җиткәнче шактый вакыт уза, күп кан югалтуы, ярасына пычрак эләгү сәбәпле, аягында гангрена башлана, хирурглар аягын тездән югары кисәләр. Бугазы яньчелү аркасында сулыш алуны җиңеләйтү өчен, трахеясына ясалма клапан куялар. Дөньяда гасыр буена яшәргә дип йөргән ир-егет гарипләнеп, кызганыч хәлгә дучар була.

***

Октябрь бәйрәме якынлаша. Тышта көзге салкыннар башлана. Туң җир өстенә төшкән беренче кар язга кадәр ятып калачак.

Коми якларында беренче кар төшү – кыш башлану дигән сүз. Баракларда истопниклар мичләргә яга башлый. Тайга эченә «яшеренеп» яткан лагерьда алтынчы ноябрьнең төшке аш вакытында бер-бер артлы көчле шартлау өч баракны йомычка урынына күккә чөя. Лагерьдагы тревога һәммә сакчыны аякка бастыра. Янгынны сүндерергә батырчылык итүчеләр табылмый, чөнки кул насослары ачык һавада күгәреп ята. Суга да кытлык, хуҗалык өчен генә җитәрлек су артезиан коесыннан гына алынып, кечкенә башняга җыела. Барлык хуҗалыкта башбаштаклык, өстәвенә бәйрәмгә каршы көн... Бөтен сак вышкаларына, КППга өстәмә сакчы-солдатлар куелып, резервтагы прожекторлар яктыртыла. Хоменко өенә кайтарып җибәргән шофёрын чакыртып, лагерьга килеп җиткәндә, өч барак та нигезенә кадәр янып бетә яза. Шәһәрдән килгән янгын сүндерүчеләргә кисәү башларын гына «коендырырга» кала. Утта янып бетмәгән такталар, кирпеч ватыклары арасыннан янып үлгән өч гәүдә табыла. Алар – баракларда «дневальный» торучылар, төшке ашны алдан ашап килгән булганнар.

Янган бараклардагы тоткыннарны исән калган баракларга күчереп «тыгызлыйлар». Блатной тоткыннар бердәм булып, «колхозникларны, частушникларны» кысрыклап, аларның ятак урыннарын алалар. Ризасызлык күрсәткәннәргә янау, куркыту башлана. Октябрь бәйрәме көнне шәһәрдән комиссия килеп төшә, бөтен тоткыннарны мәйданга тезеп бастырып, исемнәрен барлап чыгалар. Лагерь җитәкчеләре бәхетенә, бер тоткын да качмаган, дөресрәге кача алмаган.

Комиссия, җентекләп тикшереп тә ут чыгуның сәбәбен тапмый. Янгыннан саклау идарәсеннән инспектор Галиев килә. Ул янгын чыгу сәбәбе буенча кирәкле кәгазьләргә кул куярга тиеш була. Галиев, янган баракларны карап чыккач, аптырап кала – агач йортлар, бараклар янып бетсә дә, морҗалары, мичләре исән калырга тиеш бит. Ә бу очракта мичләр нигезенә кадәр җимерелгән, исән калган бер кирпече дә юк. Үзенә ярдәмгә сакчылардан ике солдатны алып, өеп куйган утын пүләннәрен җентекләп тикшерә башлыйлар. Комендант взводы барагы янындагы утыннарны тикшергәндә, озак та үтми, ярдәмче солдат бер утын агачыннан шикләнеп, Галиевка тикшерергә бирә.

Шик тудырган утын пүләне эре итеп ярылган, бер башына биш-алты сантиметр зурлыгында түгәрәк бөке тыгызлап кагылган. Дикъкатьләбрәк карасаң да, шик тудырырлык түгел, оста куллар бик яхшы итеп яшергән. «Нәрсәдер...»

Лагерьда, кышка дип әзерләнгән бөтен утын өемнәре тикшерелә, шул исәптән, лагерь канцеляриясенә дигән әрдәнәдән дә сигезләп шикле утын пүләне табыла. Комиссия вәкилләре шикле пүләннәрне лагерьдан ерак түгел бер чокырга өеп ут төртәләр. Үзләре куркынычсызрак урынга яшеренеп күзәтәләр.

Көчле шартлау, учакны күккә чөеп, янып торган кисәүләрне төрле якка ыргыта. Калган шикле пүләннәрне НКВД вәкиле, саклык белән төреп, тикшерү өчен шәһәргә алып китә.

Прокурор вәкиле, тоткыннарның шәхси эшләрен тикшергәч, берничә кешенең хөкем ителгән вакытлары үтеп тә ireккә җибәрелмәүләрен ачыклый. Икенче көнне иртүк, Мөхәррәмгә һәм тагын өч кешегә, ireккә чыгу кәгазьләре бирелеп, тимер юл вокзалына кадәр озаталар. Ireккә чыккан тоткыннарны «зурлап» озатуының сәбәбе шул: лагерь начальнигы үзенең гөнаһысын йомшартырга теләгәндер. Шаһитләрдән тизрәк котылу кирәк бит.

***

Мөхәррәм плацкарт вагоныннан урын ала, үзе теккән брезент «юл сумкасын» өстәге сәндерәгә куйгач, тәрәзәдән күзен алмыйча, күңеленнән генә карурман белән саубуллашып бара. Бер зур гына станциядә милиция хезмәткәрләре пассажирларның документларын тикшерергә керә. Чират Мөхәррәмгә дә җитә, аның азат ителү кәгазен кат-кат укып, «юл сумкасын» да җентекләп тикшергәч, күп кенә сорауларга җавап тотарга туры килә. Кайда утырганын, ничәнче номерлы лагерьда урман кискәнен юри кабат-кабат сорагач, бернинди дә шик тапмыйча, аны тынычлыкта калдырып чыгып китәләр.

Янәшәдә утырып баручы пассажирларның күбесе хатын-кызлар һәм тагын берничә өлкән яштәге ирләр. Юлдашлары «төрмәдән» чыккан егеткә кызганып та, шикләнеп тә карыйлар. «Төшке аш» вакыты җиткәч, Мөхәррәм, кондуктордан кружка сорап алып, тукталыштан әле генә алып кергән «кипяток»ка сохариен җебетеп, теләр-теләмәс кенә «кимерә».

Хатын-кыз тормышта дикъкатьлерәк тә, шәфкатьлерәк тә була. Мөхәррәмнең сохари кимереп, «кипяток» эчеп утыруын күреп, бер өлкәнрәк хатын ипи телеме тәкъдим итә. Аннан күреп, икенче хатын йомырка белән тозлаган кыярыннан өлеш чыгара.

Читенсенмичә ашарга кушалар. Ашауның ояты юк, дип кыстыйлар. Егет, рәхмәт әйтеп, оялып булса да тамак ялгый.

***

Ниһаять, иртәнге сәгать бишләрдә поезд Казанга кайтып җитә.

Шәһәр үзгәрмәгән, шул ук иске, шыксыз йортлар. Урамда кешеләр сирәк очрый. Машиналар күп күренми. Күбрәк йөк ташучы, җигүле атлар гына урамнарны җанландыра.

Тимер юл вокзалы белән Яңа Бистә арасы ерак түгел. Ул, трамвайлар йөри башлавын да көтеп тормыйча, җәяүләп, шәһәрне карап, туган-үскән йортына кайтып җитә.

Менә ул – әтисе белән бергә ясаган, капка төбендәге ике-өч кеше утырырлык эскәмия. Ул да «картаеп» такталары чери башлаган. Малай чагында, шушы

эскәмиягә утырып, гармун уйный иде. Узып китүчеләр төрле мактау сүзләре әйтеп, аның күңелен күтәрә, уйнарга дәрт өсти иде.

Әнә, иртәнең беренче трамвае, үз маршрутына эшкә чыгып, мехкомбинатка дөбер-шатыр менеп килә. Әле вагоннары буш, тәрәзәсе аша бер-ике кеше генә күренә.

Капка бикләнмәгән, ишегалдына керүгә, тирә-якка каранып, бераз моңсуланып ала. Күптән ирләр кулы тимәгән алма бакчасының чүп үләннәре кар астында калган. Ишегалдын юка гына чиста кар каплаган.

Тәрәзә шакыгач, озак көттерми, таң эңгере изрәткән өйдә ут алына. Сабира апа, каушап, яулыгын бәйли-бәйли, ашыгып ишек ача, ышанырга да, ышанмаска да белмичә, улын кочып ала.

Тормышта бөтен авырлык хатын-кыз «җилкәсенә» төшә. Бердәнбер улының, юктан гына гаеп тагып, биш елга хөкем ителүе, гомер иткән иренең авырып дөньядан китүе, менә инде дүртенче ел барган Бөек Ватан сугышы кайгы өстенә кайгы китерә.

Нинди кодрәтле көчләр саклыйдыр бу бәхетсез аналарны?

Мөхәррәм үксеп елаган әнисен көч-хәл белән тынычландыра.

Өй эче, гадәттәгечә, пөхтә итеп җыештырылган. Мөхәррәмнең гармуны комод өстендә – чигүле ак яулык капланган. Ул инде биш елдан артык хуҗасын көтеп утыра.

Мәрхүм Зиннәтулла абзый, улы хөкем ителгәч: «Хуҗасы исән-сау кайтып, кулына алганчы, анасы, шунда торсын инде!» дип, шунда куйган була. Менә ничә еллар моңсуланып, гармун хуҗасын көтеп утыра.

Әтисенең юклыгы, аны күреп сөйләшүнең мәңгегә насыйп булмаячагы Мөхәррәмнең сулышын кыса, үзеннән-үзе күздән яшь ага. Ходай Тәгалә, кешесенә кыска гына гомер биреп, нигә шулкадәр сынауларын, җәзасын күпләп өя икән? Яшәү өчен көне-төне көрәшергә кирәк. Бәлкем, бу гаделсезлектер. Кемдер теләгенә җайлы гына ирешә, белем алуы да җиңел генә бирелә, мул тормышта яши. Кемнәрдер, сәләтле, тырыш, гадел холыклы булса да, тормыш юлында җәфа чигә, көтелмәгән гаделсезлектә рәнҗетелә, кимсетелә.

Сабира апа, шатлыгыннан каушап, күз алдында торган самавырын көч-хәл белән эзләп табып, чоландагы ризыкларын җылытып өстәл әзерләгәндә, Мөхәррәм гармунын ала. «Исәнме, гомерлек дустым», дип, аны нәзберекләп сыйпый. Биш елдан артык гармун күрмәгән бармаклары теләр-теләмәс, ялгыша-ялгыша көй эзли.

Исенә төшкән көйгә такмаклый башлый, кычкырып түгел, күңеленнән генә:

Нәгъләт төшсен Николайга –
Ике сыер саудырды.
Рәхмәт төшсен Ысталинга –
Сыер саудырып мәшәкатьләндермәде,
Туры лагерьга озатты...



*Зөләйха минем балачак дустым. Ул бер яшьлек вакытыннан бишенче класска кадәрге аралыкта Зөбәер авылындагы Сафыя әбисендә үсте. Озын, калын толымлы, туп кебек йомры гәүдәле, елмайганда күзләреннән нур бөркелә торган, мәктәп тормышының башлангычларга ярый торган һәр эшенә чытырдап ябышучы, тырыш, яхшы билгеләренә генә укучы, бик хисчән кыз бала иде. Алга таба аны язмыш башка төбәкләргә,башка авылларга алып китте. Югары белем алды. Әнисе – Татарстанның атказанган укытучысы Мәшүдә Фазлыева кебек, һәрвакыт «көчле укытучы»лар исемлегендә йөрүче мөгаллимә булды. Кырык елдан артык хезмәт стажының утыз биш елында татар теле һәм әдәбиятын укытты. Үзе белем биргән мәктәпне, үзе яшәгән авылның һәркайсын Актаныштагы Зөбәерне яраткан кебек яратып, шигырьләр язды. Шигърият сөючеләр аның исемен, анда-санда булса да район газеталары битләрендә, «Аргамак» («Мәйдан»), «Мәдәни җомга» газета-журнал сәхифәләрендә укып, күңелләренә теркәп куйганнардыр, мөгаен.*

**Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА**

Зөләйха
Закирова

# БЕР-БЕРСЕННӘН МАТУР УЙЛАРЫМ БАР...

## Шуңа, ахры, сөям тормышны

 Craft

Янып-көеп йөргән көннәрем бар,
Йокламыйча чыккан төннәрем бар;
Һәрнәрсәне күрер күзләрем бар,
Кешеләргә әйтер сүзләрем бар, –
Шуңа, ахры, сөям тормышны.

Алга ашкындырган юлларым бар,
Бер-берсеннән матур уйларым бар;
Күпме шатлык, күпме моңнарым бар,
Җырланачак күпме җырларым бар, –
Шуңа, ахры, сөям тормышны.

Бу дөньяда күпме дусларым бар,
Бәхет теләп әйтер тостларым бар;
Җир җылысын җыйган йөрәгем бар,
Кешеләргә минем кирәгем бар, –
Шуңа, ахры, сөям тормышны.

## Әнием сүзе

Балачакта куыш уйнаганда,
Егылып борынымны канаттым.
Тузаннарны кагып өсләремнән,
Әнием әкрен генә юатты:
«Балачак бик шаян вакыт,
Тезләр генә янар инде.
Түземлерәк булу кирәк,
Борын гына канар инде».

Тәүге хисләр, тәүге сөю килде,
Һәм хыянәт белән таныштым.
Мендәремә кайнар яшем тамды,
Ишеттем мин әнкәм тавышын:
«Яшьлек бит ул хисләргә бай,
Яшьләр генә тамар инде.
Өметеңне өзмә, балам,
Мәхәббәт бер табар инде».

Дөреслекне ялган басып китте,
Бергә бутап агын-карасын.
Әнкәм дә юк, ялгыз торып калдым,
Күңелем белән сизәм карашын:
«Явызлыкны юлдаш итмә,
Нурлы күңелең тапланмасын.
Кояш барыбер якты сибәр,
Болыт күпме капламасын».

Яшь тал кебек күреп, тормыш җиле
Төрле яктан исеп сынады.
Ныклык биреп авыр вакытларда,
Әнием сүзе җанда чыңлады:
«Тормыш итү җиңел түгел,
Бирешмәскә тырыш, бала.
Кеше гомере бик кыска ул,
Тик игелек җирдә кала».

## Мокамай

Бер китапны Коръән белән бергә
Әбием киштәсендә саклады.
Җиденчедә укыган кече абый
Беркөн шуннан шигырь ятлады.

Ул укыды, ә мин отып бардым,
Дога кебек сеңде күңелгә.
Гаҗәпләнеп абый әйтеп куйды:
– Шигырь җиле тигән сеңелгә!

Бу шигырьнең тирән мәгънәсен дә
Аңлап бетмим әле, мин – сабый.

Сугышларда үзе белән йөртеп
Алып кайткан аны Дәү абый.

...Кәкре аяклы, сары чәчле чагым,
«Чебиләгән» ялантәпиләр...
Күтәрепләр куеп сәхнәбезгә,
Шигырь сөйләттеләр әтиләр.

Ә мин сөйлим, кулларымны болгап,
Үзем – Һади, үзем – Мокамай.
– Эх! – дип, шунда ыңгырашып куйды
Чит җирләрдән кайткан бер агай.

Концерт саен халык «Мокамай»ны
Сорап-сорап миннән сөйләтте...
Ике дусның тәкъдир-язмышлары
Телгәләде һаман йөрәкне.

Хәзер инде совет шагыйрьләрен
Төрле төскә манып карыйлар:
«Монысы – үтә кызыл булган» диләр,
«Ярамый»лар артты, «ярый»лар.

Һәм «Мокамай» калкып чыкты шунда:
Кызылмы ул, акмы, карамы?
Ни булса да, шул малайлар өчен
Ярты гасыр йөрәк яралы.

Изге дуслык хисен мәңгелеккә
Бүлешкәннәр алар урталай.
Шигъри һәйкәл бара киләчәккә:
Берсе – Такташ, берсе – Мокамай!

## Яфрак

Каенымда сыңар яфрак калган,
Йолкып-йолкып көзге җил исә...
Нинди куәт тотып тора икән?!
Зәгыйфь кенә яфрак югыйсә.

Каенымда сыңар яфрак калган,
Көн дә карлы яңгыр камчылый.
Яфрак буйлап әллә сулар ага,
Әллә күз яшьләре тамчылый.

Авырлыклар баса иңнәремне,
Башкайларым һәрчак ваемда.
Чыдамлыкка гүя һәйкәл булып,
Сыңар яфрак тора каенда.

## Ирсез хатын

Ирсез хатын – йөгәнсез ат, диләр,
Кидер, бәгърем, тизрәк йөгәнне!
Авыл халкы, берүк, белми калсын,
Сине ничек өзелеп сөйгәнне.

Ятлар ишек какса, этем өрер,
Авыл тулып гайбәт сүз йөрер...

Гайбәтләрдән өстен булганга шул
Күңелкәем сине хуш күрер.

Йөрәк җәрәхәтем дәваларлык
Сөюең булса гына кил миңа.
Юк икән – юк!
Шәмдәлендә эрегән шәм төсле,
Мин сүнәрмен ялгыз, тын гына...

## Үзең ничек чыдыйсыңдыр?

– Тукта, Сөю, кабынма, – дип, –
Тигез җирдә абынма, – дип, –
Акыл күпме тукый торды...
Ә Мәхәббәт күтәрде дә
Әйтерсең лә ташка орды –
Сабыр канатларым сынды.

Каеннарым яфрак койгач,
Көзнең салкын сулышын тойгач,
Карашларың мине тапты.
Син каршымда елмайганда,
Күкләр зәңгәр, көннәр якты,
Гомеркәйләр шундый татлы.

Бу сөюем – соңгысыдыр,
Көемнең иң моңлысыдыр.
Судан алып, утка салып,
Юри мине сыныйсыңдыр.
Дөрләп януымны күреп,
Үзең ничек чыдыйсыңдыр?
Белмим, ничек чыдыйсыңдыр?!

* * *

Хак Тәгалә сыну өчен түгел,
Бары сынау өчен яраткан.
Төрлебезгә төрле язмыш биреп,
Төрле җиргә безне тараткан.

Бәхеткәйләр тигез бирелмәгән
Берәүгә дә фани дөньяда.
Шатлык кына түгел, кайгылар да
Эзләп таба безне кайда да.

Кайгыларны никтер кара, диләр,
Кемнәр билгеләгән төсләрен?
Караларны агартырга тырышып,
Йокыларым кача төннәрен.

Төн утырып язган җырларымнан
Ап-ак моңнар торсын сибелеп.
...Балаларым, газизләрем минем!
Мин бит сезне уйлыйм иң элек.



*Альбина Гайнуллина 1982 елда Әгерҗе районы Татар Шаршадысы авылында туган. Биредә 9 нчы сыйныфны тәмамлагач, 10-11 нче сыйныфларда Кырынды урта мәктәбендә белем ала. Югары белеме буенча – икътисадчы. Хәзерге вакытта «Акчарлак» газетасы редакциясе журналисты. Казанда яши.*

Альбина
Гайнуллина

# ДУСТЫМ, СЕРДӘШЕМ...

ХИКӘЯ

– Кәримә! Мин куркам...

Дустым, карашын бушлыкка төбәп, бер сулышта тезә: «Мин куркам. Син шуны аңлыйсыңмы? Куркам. Башка түзәр көчем калмады. Эчемдә генә саклый алмыйм. Миңа уртаклашырга кирәк. Югыйсә шашам. Әйе, шашам! Җүләрләнәм! Ярдәм ит миңа».

– Ни булды? Бәхеттән куркалармы?! – дигән булам аптырап.

Якынрак килеп, Зиләнең күзләренә төбәләм. Кан туганымдай, сеңлем төсле кадерле, якын кешем бит ул минем. Уйламаганда, кинәт кенә, нәрсәдән шулай куркып кала алыр икән?!

– Бәхеттән?! Ю-у-у-к. Бәхеттән түгел. Бәхеттән куркалармыни...

Зилә ваемсыз гына, елмайган төсле, иреннәрен килештереп кыймылдатып ала. Борчылуының сәбәбен белмәгәч, дустымның үз-үзен тотышы сәер тоела миңа. Хәтта күңелемнән генә Зиләне иркәлектә дә битәрләп куям, шундыйрак инде ул. Гел үзенә каратып торырга, үзен көйләтергә ярата торган. Кечкенәдән өйрәнгән шулай.

– Әмир белән танышкан беренче көннән бирле мин саташа башладым.

Әнигә дә, Әмирнең үзенә дә сөйләргә читенсенәм. Аңламаслар. Кара әле, синнән якын сердәшем юк. Кәримә, сиңа гына ачылам. Берәр киңәш бир. Югыйсә бу халәттән тәмам җүләрләнәм бугай. Инде күзләремне йомарга, йокларга куркам. Шул сәер төшне күрәм дә шыбыр тиргә батып уянам.

Сөйләгәндә, үзе дә сизмәстән, туй күлмәгенең ап-ак бөрмәләрен, ваемсыз бөгәрләп, учына тиз-тиз җыйды Зилә. Шул арада, гаебен таныган баладай, җыерылган итәген җибәреп, сак кына сыпырып тигезли башлады. Калтыранган куллары акылына буйсынмый шикелле. Нечкә бармаклары ап-ак ефәк тукыманы янә бер җыера, бер тигезләргә тотынды. Буш карашның кулларда гаме юк. Анда бары җан өшеткеч салкынлык. Зиләгә хас булмаган, ят шыксызлык. Үзе соңгы өметенә ябышып көзге җилләр белән көч сынашкан үксез яфрак төсле калтырый. Җепселләре берәм-берәм өзелеп, гомер җебе юкарганын күз уңыннан үткәргән, алдагы язмышын белгән, аңлаган сары яфрак диярсең. Мөмкин булган кадәр яшәп

калырга тырышып, сабырлыгы кыл төсле тартылганнан туган калтырау түгелме бу? Яфрак калдырып китәсе дөнья кышка керә әнә. Юлга кар түшәргә өлгергән ноябрь иртәсе хөкем иртәсе кебек?! Зилә ашыгып әллә ул кар-бураннарны туздыра, күлмәгенең ап-ак бөрмәләренә кунган котсыз уйларны себереп төшермәкче буламы? Өнендә саташамы?

– Күлмәгеңне ертасың инде, ни кыланасың! Әллә син дә кияүгә чыгарга куркасыңмы, җүләрем?!

Тиз генә кочып алдым үзен. Куллары боз кебек, йөзе күлмәгеннән аграк. Ни бу? Нинди коточкыч сере булырга мөмкин?! Мин белмәгән серләре юк дип торам... Ялгышаммы? Туй алдыннан каушавы гынамы дустымның?

Кызларның кияүгә чыкканда күңелләре ашкынуы да, курку, борчылу хисләре биләп алуы да табигый хәл инде анысы. Гаилә кору уен эш түгел. Зилә кебек акыллы, зирәк кызлар мондый халәткә бирешмидер, дип уйлый идем мин.

– Әйдә әле, пион төнәтмәсе тамызыйм үзеңә. Әллә ромашка белән чәй ясыйммы?!

– Кирәкми. Миңа әни иртүк әллә нинди дарулар эчерде инде.

– Әллә нинди?.. Үзең дә әллә ни эшлисең. Нәрсә булды соң?

– Мин нигәдер җитешмәм төсле! Аңлыйсыңмы, Кәримә? Яратырга, яратылырга! Нәрсәгәдер өлгермәм, вакыт кинәт туктар да, бар да өзелер, юкка чыгар кебек! Төшемдә дә гел шулай саташып уянам! Ничек итеп аңлатырга белмим! Куркыныч! Әмир белән танышкан көнне беренче тапкыр шулай куркып уяндым мин. Һәм гел шулай, гадәткә кергән кебек....

Зилә сулкылдап күкрәгемә капланды. Сарыкаем, ябык чебешем. Гел кечкенә бала куеныма сыенып бетте. Үзе миннән җиде айга өлкәнрәк булса да, чандыр гәүдәле, тәбәнәк буйлы дустымны янәшәмдә сабый кебек хис иттем.

– О-о-о-о, берүк тынычлан! Хәзер визажистның бөтен хезмәтен суга саласың. Елавыңнан да тукта. Үзеңне кулга ал, Зилә! Берни дә уйлама хәзер. Йә, миңа кара әле!

Каушавымны басарга тырышып, ашыгып тынычландырам дустымны. Икебез дә күңел төшенкелегенә бирелсәк, бетте баш! Акылыма ни килсә, шуны сөйлим. Уйларга вакыт юк. Кирәк чакта аның дөрес сүзләре дә әллә кая, кесә төбенә төшеп югала икән. Экспромт.

– Билгесезлек куркыта инде ул. Син моны үзең дә яхшы беләсең. Без синең белән ничә кызны кияүгә бирдек әле?! Исеңә төшер. Юляны! Без тынычландырып маташкан арада аңын җуеп егылып киткәне хәтереңдәме?! Әнә ничек яшәп ята хәзер! Отличнигым минем! Ә синең барысы да бишлегә булырга тиеш. Шулаймы?! Өстәвенә арыгансыңдыр. Бик нык яратканда, аны йә бәхетле итә алмам, йә югалтырмын дип курка кеше. Син боларны барысын да үзең беләсең. Зилә, безгә тынычланырга кирәк! Тирән итеп сулыш ал! Сула-сула, әйдә, тагы-ы-ын. Үпкәләреңә саф һава тулсын. Булдымы? Һәм әкрен генә чыгарабыз... Ашыкма. Әйдә, тагын кабатлыйбыз. Мин дә синең белән сулыйм.

Үзем сөйлим, үзем куркагымны юатам. Кәләш халәтен аңламаслыкмы инде ул?! Яман халәттән җиңдергәнче, тизрәк басарга кирәк бу дулкынны. Югыйсә макияжын яңабаштан ясыйсы булачак. Ә безнең вакыт калмады. Визажистны да кайтарып җибәрдек. Ресторан тулы кеше, әти-әниләр, туганнар, һәм иң мөһиме – күпме еллар эзләп, ниһаять, табышкан сөекле яры, Әмире көтә дустымны. Туйга былтырдан ук әзерләнделәр бит! Саташмас җирдән саташырсың болай кылансаң! Ул ресторан сайлау, бронь түләп, ике ай узгач, ресторанны ябылу дисеңме. Мәҗлесне алып баручы табып, аның белән узачак бәйрәмнең сценариен төзеп, башыннан азагына кадәр өйрәнеп чыгумы... Зиләнең берәүгә дә ышанмый торган гадәте бар. Һәрнәрсәне үзе тикшерә, кирәк җирен төзәтә, үзгәртә. Шул арада Әмире белән

сүзгә килештеләр. Барысы да әзер дигәндә, киясе күлмәк сайланган, чыгымнарның күбесе түләнгән арада буласы туй кыл өстендә калды. Инде дуслар, туганнар мәҗлескә киясе күлмәкләрен, яшьләргә биреләсе бүләкләрен сайлап, барлап куйган. Ә егет белән кәләш сөйләшмиләр дә хәтта. Зилә шул арада фотографны да кире борырга өлгергән.

– Җүләрем! Артык җаваплы, артык дөрес кеше инде син үзең. Яраткан кешеңне бәхетле итү теләге чамадан тыш көчле ахрысы, җаным. Эшкә урнашканда ничек борчылганың исеңдәме? Ә яңа проект яклаганда?! Ничә көн йокы күрмәдең? Елый-елый диплом язганнарың! Алай ярамый. Гадирәк бул. Тормыш мәктәп тә, институт та түгел бит. Монда сабак ятлап кына булмый. Син, беренче чиратта, үзең бәхетле булырга тиеш! Калганы үз чираты белән килер.

– Ә өлгермәсәм? Чираты җитмәсә, өзелсә...

– Нәрсә өзелсә? – Аптырыйм. Аңламыйм. Үзем дә тынгысызлана башладым. Сиздермәскә, тыныч булырга кирәк югыйсә.

– Белмим. Аңласам, ул кадәр куркыныч та булмас иде кебек. Ул төшләр үзләре шундый матур башлана бит. Соңыннан эчемә салкын йөгерә. Әмир, әти-әниләр, туганнар, бүлмәдә ниндидер балалар... Дуслар, син... Табында ризык урынына дарулар, шприцлар, марля кисәкләре. Шыбыр тиргә батып уянам. Төштә тойган салкынлыктан эчем авыртып алгандай тоела. Әгәр дә безнең балаларыбыз булмаса?!

Чыннан да сәер төшләр. Берара ни дияргә белми аптырап торам. Юк, төш юрар чак түгел инде хәзер. Туй көне! Безне күпме халык көтә. Әмир дә борчыла торгандыр.

– Миңа кара әле, Зилә. Син сау-сәламәтсең. Әйдә, тыныч кына туйларны үткәреп җибәрик тә аннан табибка күренеп кайтырбыз. Ә иң яхшысы, авылга кайтып өшкертербез сине. Әбиләрнең шифалы догасыннан бөтен куркуларың, борчуларың җил алган төсле таралыр да китәр, менә күрерсең. Акыллым, гомер шундый озын ул, син барысына да өлгерәчәксең. Иң мөһиме безгә хәзер – синең туеңа соңга калмау кирәк! Ишетәсеңме мине?! Дусты-ы-ым, тиле чебешем мине-е-ем! Күзләремә кара әле! Менә шушы кечкенә генә сары башка шултиклем куркыныч, тузга язмаган уйлар ничек итеп сыя ала соң, ә?

Ниһаять, елмая Зиләм... Аллага шөкер, тынычландыра алдым фәрештәмне. Карашының зәңгәр дулкыннарыннан җылы очкын, якты нур йөгерде. Барыбер дә керфекләрен лепердәтеп, иреннәрен тешләп утыра. Шулай үз хәленә кайта инде. Мин аны яхшы беләм.

Без Зилә белән мәктәп елларыннан ук бергә. Бу «сары чеби» өченче сыйныфка ерак Удмуртиядән килеп төште. Гаиләләре Казанга күчеп төпләнгән ди. Шыксыз ябык, зур зәңгәр күзле кызыйны башта марҗа дип уйладык. Мәзәк булды, кабат үзен русчага өйрәтергә туры килде. Ижау шәһәренең татар гимназиясендә чеп-чи татарча укып яткан булып чыкты, аннан бигрәк балалар бакчасының татар төркеменә йөргән икән. Иң кызгандырганы – Зиләнең дәү әнисен сагынуы иде. Зәңгәр күзләрен мөлдерәтеп мәктәп тәрәзәсенә сарыла да еракка, билгесезлеккә багып моңая, бичарам. Биләүдән карап үстергән дәү әнисе белән аерылышуны авыр кичерде ул.

Иреннәрен бераз очлайтып, безгә дәү әнисеннән ишеткән әкиятләрне, маҗараларны сөйли башлады, бераз иярәшә төшкәч. Ахыр, сары чебешемнең әбисен юксынулары безгә дә йокты. Сыйныф белән бергәләп яраттык ул ак яулыклы, әкият дөньясыннан төшкән «дәү әнине». Еллар узгач, мәктәпне тәмамлагач, Зиләнең әбисе белән танышу бәхетенә дә ирештем мин. Искитмәле зирәк, олы җанлы юмарт әбекәй иде.

Ни хикмәттер, Зилә белән серләребез килде. Мин аны беренче көнне үк үз

канатым астына алдым. Яңа кешене сыйныф белән дә, кала мәктәбе тәртипләре белән дә таныштырдым. Юашымны яклаган чаклар да аз булмады. Өлкәнрәк сыйныфларда аның да ярдәме күп тиде үземә.

– Рәхмәт, Кәримә. – Зилә калтыраудан туктаган һәм йөзенә алсулык кайткан. Елмая! – Рәхмәт, дустым. Син хаклы булырга тиеш. Дәү әни дә гел сине тыңларга, сүзеңнән чыкмаска куша иде.

– Беркайчан да, бер әйбердән дә курыкма! Менә шушы мизгелдә син хәзер бәхетле бул! Калганын Ходай хәерле кылсын. Син хәзер генә бар! Менә шушында, бүген! Онытма, Зилә. Үткәннәр – үткән, киләчәк – ерак һәм билгесез. Шуңа күрә үзең булган, тойган мизгелгә куана бел. Елмай, көл, ярат! Бие, җырла.

...Зилә тынычланды. Туйлар гөрләп үтте.

Сөйләшенгәнчә, яшьләр туй сәяхәтеннән кайтуга табиб янына юл тоттык. Зилә барлык тиешле анализларын бирде, бөтен шартын китереп, тиешенчә тикшерү узды. Шунысы сәер: шифаханәдә дустымның бу адымын кимсетеп, юктан чир эзләп йөргән тилегә санаган кебек кабул иттеләр. Югыйсә күп кенә авыруларны дәвалауга караганда кисәтү күпкә ансатрак бит. Әмир хатынының кыланмышларын башта сәерлеккә санаса да, кабат фикерен үзгәртте. Хуплады. Һич ялындырмый, табибларга күренеп, үзе дә анализлар биреп кайтты.

Ул арада үземнең дә тормыш мәшәкатьләре баштан ашу сәбәпле, аралашулар сирәгәйде. Насыйбымны очратып, артык чыгымнарсыз, тыйнак кына никах укытып, мин дә гаилә корып җибәрдем. Туй итеп тормадык. Без Дамир белән йорт җиткерү, фатир алу мәсьәләләрен хәл итеп йөргән арада, дустымның кызы туды. Инде ул икенчесенә җыенганда, мин дә калышмадым, үкчәсенә басып дигәндәй, бәби тудыру йортына килеп җиттем.

Әй, шунда Зиләм сабый баладай үпкәләде бит:

– Чиратыма кердең, Кәримә! Миңа дигән малайны алдың. Әмиремә вәгъдә иткән улыбыз иде бит, син чиратсыз кердең, – диде еламсырап. Көч-хәл белән юаттым үзен. Икенче баласын тапса да, һаман сабый акылы икән дустымда. Зирәк акыллы Зиләне Әмир иркәләбрәк тә җибәргән ахры. Кыланмышлары килешеп тора тагын үзенә. Бәхете генә булсын.

Көннәрдән бер көнне тагын үпкә белдереп шалтыратты Зилә.

– Кәримә, вәгъдәңдә тормадың, дустым, – ди.

– Кадерлем, тагын нинди гаепләрем бар инде синең каршыңда?

– Авылга алып кайтып өшкертәм дигән идең? Туйда! Дәү әнием исән булса, сине аптыратмас та идем инде...

Йорттагы барлык эшемне ташлап, баланы алдым да Зиләләргә чаптым.

– Һаман саташасыңмы әллә?

– Әйе. Кәримә, соңгы арада бик еш кабатлана башлады бу төшләр. Күрәзәчегә барыйк мәллә?

– Булмаганны! Күрәзәче эзләп, гөнаһ җыеп йөрмибез, акыллым. Бу атнада авылга кайтабыз! Әткәйнең әнисе, әбекәй төшеңне дә юрар, өшкерер дә шунда.

Шулай итеп, дустымны тынычландырып чыгып киттем. Ләкин ул атнада кайта алмадык. Улым ютәлли башлады. Температурасы күтәрелеп, шифаханәгә яттык. Дәваланып чыккач кайтырбыз, дип торганда, әбекәй авырайган, дигән хәбәр алдык. Ике ай чамасы гына урын өстендә ятып, дөнья куйды газизем. Соңгы юлга озатырга үзебез генә кайттык. Зиләгә дәшмәдек. Аннан дустым тынычланган, Әмиренә малай алып кайтам, дип планнар корып йөри башлаган. Мисырга юллама алганнар икән. Кызларын әниләрендә калдырып, ике атнага ял итәргә китеп бардылар.

– Менә Әмиремә, нәсел дәвамчысы алып кайтып бирсәм, чын отличница булам инде, Алла бирсә, – дип, смс язып салган иде ул.

Ике атнага диңгезгә китеп барган пар алты көннән Рәсәйгә әйләнеп

кайтмасынмы?! Мәскәүдә аэропорттан ук Зиләне шифаханәгә озатканнар. Әмирнең абыйсы каршылаган. Ул зур калада яши, бизнесы шунда.

Анализлар... Тикшеренүләр... Дустым күзгә күренеп гөлдәй сула. Әмир әле бер табибка, әле икенчесенә чаба. Зиләгә дә, беркемгә дә берни әйтми. Түзмәдем, шалтыраттым:

– Әмир, тыңла әле, айлар буе диагноз куеп булмый торган нинди авыру булырга мөмкин? Зилә гел табибларга күренеп, анализлар биреп торды. Нәрсә яшерәсең?

– Телефоннан сөйләшә торган сүз түгел. Кич белән кил безгә. Син Зиләнең бертуган апасы кебек үк гаиләбезгә якын кеше. Күзгә-күз сөйләшербез. – диде дә Әмир, телефонын сүндереп тә куйды.

Ноябрьнең кыскарган көне һич уза торган түгел, кич җитмәс кебек тоелган иде. Кулдан эш төште. Күзгә-күз ни сөйләшмәкче була икән бу Әмир? Башка әллә нинди куркыныч уйлар керә. Зиләнең гел тикшеренеп, табиблар күз алдында йөргәне генә юата, тынычландыра бераз. Ничек булса да, вакытында ачыкланган. Димәк, тиз генә дәваланыр. Шулай булырга тиеш!

Дамир белән без аларга барырга чыгуга, яныбызга Әмирнең машинасы килеп туктады. Зилә яныннан, шифаханәдән кайтышлый үзе кергән. Дустым Казан клиникасында ята икән. Чираттагы тикшеренүне уза.

– Хәле ничек?...

– Хәленә күрә яхшы. Син Зиләгә сезне чакырганны әйтмәдеңме?

Җавап кайтару түгел, көчкә ым кагып өлгерәм. Әмир үзе сорый, үзе сөйли.

Карашы әллә кайда, читтә. Безгә карамаска тырыша төсле.

Көне дә әллә нинди салкын. Калтырата. Агач ябалдашларын чишендергән җил, өзәсен өзгән инде, бераз тынса да булыр иде... Яшим дип чатябышып яткан соңгы корбанын эзләвеме?! Шул яфрак төсле калтырыйм ахры үзем дә. Әллә суыктан, әллә борчылудан, бөтен тән кыл кебек тартылган.

– Кәримә, мин әби белән бабайга ничек әйтергә белмим. Зилә төшенә инде. Белә дисәң дә була... Җүләр түгел бит ул, кая йөрткәннәрен күрә, ишетә. Аңа шикләнәләр, дип кенә әйтәбез... Ышана.

Әмир туктап калды. Елый. Күз яшьләрен тыярга бик тырышты да соң... Сабырлыгы ахыр чиккә җиткәндер, күрәсең. Ничек юатырга, нинди сүз табарга белмим.

– Зиләнең аналыгында яман шеш. – Бу булырга мөмкин түгел, әмма Әмир сүзен әйтеп бетерә алмады, кулын селтәп китеп барды.

Машинасына кереп утырды. Руль өстенә капланып елый. Үкси. Корычтай, алпамша хәтле ир солтаны шулай еласын әле! Моңа нинди йөрәк түзсен? Аяк астымда җир убылган төсле булды. Ләкин җебеп төшәргә хакым юк. Бар да яхшы булачак. Ышанырга кирәк. Машина ишеген сак кына ачтым да:

– Елама. Бар да әйбәт булачак. Вакытында беленгән чир дәвалана ул, Әмир.

– Иң мөһиме – хәзер яхшы клиникага урнаштырып, тиз дәваларга кирәк, – дидем.

– Кәримә! Вакытын ычкындыргансыз, диделәр.

Ирем дәшми. Дамир, сабырлыгын җыеп, безне күзәтә.

– Булмас. Ялгышалардыр. Яхшы табибларга күрсәтергә кирәк Зиләне.

– Әйе. Абый Израильдәге клиникага урнаштырырга ярдәм итә.

Сөйләшенгән инде. Билетлар алдык. Иртәгә Зиләне больницадан чыгаралар. Җомга очабыз.

– Мәскәүгәме?

– Израильгә. Үзенә генә бу хакта ничек әйтергә дә белмим. Әти-әниләренә ничек әйтергә?! Мин ни эшләргә дә белмим. Кәримә, Дамир! Ни эшлим хәзер?

– Киттек. Зиләнең әти-әниләренә барысын да үзем җайлап аңлатырмын, – дип, сүзгә Дамир кушылды.

– Казанда да онкология буенча яхшы табиблар, профессорлар бар. Сөйләшимме?

– Юк, Дамир. Вакыт аз. Вакытны югалтырга ярамый.

Ә вакыт – хыянәтче! Ашыкты! Артыгыннан нык ашыкты! Ничек кышка кергәнебезне дә, кай арада бураннар бөтереп алганын да аңламый калдык. Әмир белән Зилә Израильдә озак булдылар. Әниләрен сагынып елаган кызлары да басылды, әбиләре тәрбиясенә күнегә төште.

Өстәвенә, улыма да гел салкын тия, еш авырый. Тереләдек дигәндә, тагын борыннары томаулап, тамаклары шешеп чыга. Әле шифаханәдә ятып чыгабыз, әле өйдә төрле ысуллар белән дәваланабыз. Аллергия түгел микән, дигән шикләр белән дә тикшеренеп карадык. Прививкалар, витаминнар, антибиотиклар – дәвалауның нинди генә ысулын кулланмадык.

Дамир икешәр айга командировкаларга китеп бара. Кайткач та, ниндидер салкын, ят булып тоела. Кулында гел телефон. Кемдер шалтырата. Кемгәдер үзе яза. Сәер. Ләкин бу хакта уйларга көч тә, теләк тә юк. Теләсә ни эшләсен. Исән генә булсын.

Зилә белән скайп аша аралашабыз. Операцияләрдән соң, Әмир интернет аша язып, хатынының хәлен хәбәр итеп торды. Гаиләнең бердәмлеге, туганнарның кешелеклелеге шундый чакта сыналадыр ул. Әмирнең абыйлары бөтен чыгымнарны үз җилкәсенә алды.

Өч айдан артык Израильдә дәваланып кайтты Зилә. Катлаулы операцияләр, химиятерапия, кыйммәтле, көчле дарулар дустымның газапларына нокта куярга тиеш иде.

Әмирнең тырышлыгы, хатынына тугрылыгы, мәхәббәте, гаиләсе өчен көрәшүе ахыр чиктә дәвалану белән бүләкләнергә тиеш бит инде!

– Берәр карчыкка барып өшкертеп кайтырга хәзер соңдыр инде, әйеме, дустым? Могҗиза булмастыр.

Зилә бушлыкка төбәлгән күе генә битараф елмая.

– Мин теге төшләрнең мәгънәсенә төшендем. Хәзер саташмыйм. Булды. Курыкмыйм да. Син, гомер озын ул, дигән идең. Түгел икән бит... Бирелгән кадәр генә. Күпме көрәшсәң дә, артыгын алу мөмкин түгел икән... Иремне уллы итә алмадым. Үкенечкә кала. Улы булса, бер терәге, сердәше булыр иде дә.

– Гөл кебек кызларыгыз бар бит, Зилә!

– Кызлар, дип инде... Алар кияүгә чыгачак. Ярый, Әмир дә өйләнер, әйеме?! Булыр әле, улы да булыр! Мин тегендә фәрештәләр белән сөйләшеп куярмын.

Күлә... Бу күлүдән дә авыр, куркыныч тагын ни бар икән дөньяда?!

Зилә башта савыгып киткән төсле иде. Әмир чит илдән табып кайтарткан көчле дару да килеште ахры. Бер ампуласы сиксән мең дип ялгыш әйттеме, чынмы, кабат сорамадым. Хатыны өчен үзе тәмугка керердәй булып йөргән кешедә бәя кайгысы юктыр, күрәсең. Абыйлары да бигрәк туган җанлы, эчкерсез кешеләр булып чыкты. Бу гаиләнең бердәмлегенә шаклар катарлык. Мин аларга дустым өчен чиксез рәхмәтле идем. Ләкин озак юаныч табарга туры килмәде.

Мартның соңгы атнасында Зиләне төн уртасында ашыгыч ярдәм машинасы белән алып киттеләр. Өч көннән соң Әмиргә хатынын больницадан алырга куштылар. Шулчак Дамир үз танышларына шалтыратты. Ниндидер үтемле кешеләр аша Зиләгә ярдәм күрсәтүләренә, аны шифаханәдә дәвалауга ирештек. Дамир китерткән профессор тикшерде Зиләне. Баксаң, теге кыйммәтле зәһәр шәп дару дустымның бавырын ялкынсындырган, таркаткан икән. Даруны кадаудан туктагач, атна-ун көн эчендә Зиләнең хәле тәмам авырайды. Инде сугылыр кеше, ярдәм сорап керер ишек калмады. Профессор Әмиргә хатынын тилмертмәскә, өенә алып кайтырга киңәш итте.

Кечкенә «сары чебешем» бүлмәнең ачык ишегеннән залны күзәтә. Анда Әмир,

әти-әниләре, туганнар җыелган. Якын дуслар килгән. Шулар арасында кызлары, башка балалар мәш килә. Сабый акылына сыя торган түгел бу мәхшәр. Алар берни аңламый.

– Кәримә, профессор нәрсә диде?

Сүз таба алмыйм. Дустыма күтәрелеп карарга кыюлыгым җитми. «Соң инде. Озак газапланмасын гына дип тели аласыз», – диде Дамир тапкан профессор. Бу сүзләрне дустыма ничек әйтим...

– Кәримә, мине шифаханәгә кабат салачакламы?

– Юк...

Көч-хәл белән ым кагып алдым. Тамак төбендәге төер сүз дәшәргә ирек бирми. Сеңлем кебек кадерле якын кешем минем! Ни диеп юатыйм икән үзеңне?! Ничек ярдәм итим икән? Үкенечкә калган ялгышларым белән алга таба ничекләр яшисе соң хәзер... Биргән вәгъдәләремдә тора алмадым бит. Бәлки, көрәзәчесенә дә барасы булгандыр. Вакытында өшкертәсе, дога, ырымнар көчен дә сынап карыйсы булгандыр.

– Кәримә, Әмир белән кызларны ташлама инде син... Минекеләрне ташламагыз, ярыймы.

Ачык ишектән Дамир безне күзәтә. Чыннан да минем чыкканны көтә, күрәсең. Кулында улыбыз йоклап киткән. Кайтарып җибәрергә кирәк үзләрен.

– Зилә, мин хәзер әйләнеп керәм.

– Кирәкми. Иртәгә килерсез. Бар.

Киткәндә, хушлашып, ишекне япмакчы идем, Зилә яптырмады. Елмаеп кул изәде. Ходаем, никадәр көчле, сабыр минем сары чебием.

Кайтып җитеп, машинаны куярга да өлгермәдек, Әмир шалтыратты.

– Кәримә... Зилә...

Сүзен әйтә алмый. Аңлашылды. Дамир да артык сорау биреп тормады.

– Нык бул, Әмир. Без хәзер...

Улыбызны әниләргә керттек тә кире киттек.

Зилә кызларына истәлеккә видеоязмалар әзерләп калдырган. Хатлар язган. Ул барысын да аңлаган, белгән. Шулай да өметен өзмәде, көрәште. Соңгы минутына кадәр көрәште.

Миңа да Әмир конверт тоттырды. Ул аны шушы айлар дәвамында, акрынлап, өлешләп язган. Диагнозы билгеле булгач ук яза башлаган. Ноябрьдә. Бу хат – көндәлекне мин озак вакыт укырга базмадым. Йөрәгем җитмәде. Авыр иде.

Дустымның кырыгын уздыргач та, Дамир безне ташлады, гаиләдән китте. Теге телефонда язышулары, шалтыратулары юкка булмаган. Битәрләмәдем, тотмадым. Карар кабул иткән икән, аның өчен шулай яхшырак икән – нишләтәсең. Исән генә булсын. Бәхетле булсын!

«... Дустым, миңа алмашка калган ике сандугач баласы белән горур лачынымны ташлама инде син». Шулай тәмамлаган Зилә үзенең хатын. Әти-әниләренә дә нидер әйтеп калдырган күрәсең. Картлар сентябрь башында кияүләренә димләп килгәннәр мине.

– Әмир сине бик нык хөрмәт итә, кызым. Үзебезгә дә чит кеше түгелсең. Оныкларны ятлар кулына калдырасы килми бер дә. Зиләнең фатихасы белән кавышып карагыз әле. Алла бирсә, җае белән генә торып та китәрсез. Ялгыз башың көзләргә керүе авыр булыр бит. Ир бала үстерәсең. Без дә бик бетерештек бу кайгыдан, – диләр.

Әмир үзе дә ике кызын ияртеп килгән. Өч баланы кочкан да дәшми генә күзләремә төбәлгән дустымның горур лачыны...

# АЛЬБИНА ГАЙНУЛЛИНА. «ДУСТЫМ, СЕРДӘШЕМ...»

Мәдәнияттә «эклектика» дигән төшенчә бар. Ул бер әсәр эчендә (рәсем сәнгате, әдәбият, музыка, бигрәк тә архитектура үрнәге, диик) яки тормыш күренеше (мәсәлән, кием, йорт яки бүлмә бизәлеше) чикләрендә төрле, янәшә килә алмый торган стильләрне, идеяләрне, карашларны, төсләрне һ.б. кушуны аңлата.

Әлеге төшенчә бик ерак тамырлы: аны беренче тапкыр безнең эраның икенче гасырында Искәндәрия (Александрия) шәһәрендә туган юнан философы Потамон кулланганы мәгълүм. Шул вакыттан бирле төшенчәгә караш гел алмашынып торган. Башта ул тискәре мәгънәдә әйтелгән булса, тормыш һәм сәнгать үзгәргән саен, аңа мөнәсәбәт тә тискәредән – уңайга, аннары кабат тискәрегә сикерешләр ясаган. Бүген без бу төшенчәнең уңай мәгънәдә яшәү чорында: заман сәнгатендә эклектика – стильләштерүнең бер төре, янәшә була алмый торган элементларны кушып өр-яңа фикер әйтү мөмкинлеге дип карала. (Әлбәттә, бу хикәягә бернинди катнашы булмаган заман сәнгате – постмодернизм шушыңа, берничә автор язган кебек тоелган берничә текстны бер әсәр итеп оештыруга корылган булуны, хәзер дөнья сәнгатендә аңа алмашка килгән пост-постмодернизм дигән күренешнең исә, тагын да камилләшеп, әлеге төрле текстларның чикләрен дә аерып булмау кебек күрсәтелүен әйтергә мөмкин. Әмма, тагын бер кат искәртик: бу төшенчәләрнең без укыган хикәягә бернинди катнашы да юк.)

Альбина Гайнуллинаның «Дустым, сердәшем...» хикәясе эклектик әсәр булып чыккан. Гади генә итеп, әсәр нәрсә турында дигән сорауга җавап биреп карыйк: ул – яшь хатынның, ирен һәм ике баласын ятим калдырып, яман шеш авыруыннан бакыйлыкка күчүен сөйли. Һәр әдәби әсәрдә шуннан соң тагын бер сорау куела: монда нинди фикер-идея белдерелә? Бу очракта стиль ягыннан бер-берсенә охшамаган һәр «текст»ның һәм аларның кушылмасының, ягъни эклектика куллануның үз мәгънәсе табылу шарт. Шуларны эзләп карыйк.

Хикәя яшь хатын-кыз исеменнән сөйләнә, хикәяләүче – героиняның якын дусты. Әсәр вакыт ягыннан гына түгел, стиль ягыннан ике өлешкә аерылган.

Беренче өлеш, беренче вакыйга – туй көнне ике дус кызның сөйләшүе, биредә әдәби, аның да психологизм кулланылган стиле (әдәби-психологик стиль) күзәтелә. Туй алдыннан Зилә исемле кәләш үзенең дусты Кәримәгә шикләре, куркуы турында сөйли. Хикәяләүче Кәримә аны юата. Ун-унбиш минутлык сөйләшүне сурәтләгән бу өлеш хикәя структурасында шактый зур – аның яртысына якын урынны били. Әлеге сөйләшүдә хис-кичерешләрнең чиктән тыш ярсуы да, төш элементы да, кинәт кенә килеп кергән көзге яфрак детале дә бер максатка – психологизмны тирәнәйтүгә хезмәт итә. Монда автор нәрсә әйтергә тели – күрәсең, чын дуслыкның мөһимлеген ассызыклыйдыр. Моның өчен генә чиктән тыш арттыру, хисләрне киеренкеләндерү кирәк идеме? Сорау җавапсыз кала. Бу мәсьәләгә әле әйләнеп кайтырбыз.

Текстның икенче өлеше – публицистик стиль белән язылган. Анда, сурәтләүдән бигрәк, хәбәр итү төсендә, Зиләнең гаиләсендә ике кыз бала туып, аның өченчегә малай алып кайтырга хыялланувы, Кәримәнең дә, кияүгә чыгып, малай тудыруы, беренче өлештә әйтелгән «төш»тәге кебек, Зиләнең авырып китүе, гаиләсе никадәр генә аны терелтергә тырышса да, үлеме, Кәримәнең иреннән аерылуы сөйләп узыла. Текст Зиләнең ире һәм эти-әниләренең Кәримәгә бер гаилә булып яшәү тәкъдиме әйтелгән вакытта төгәлләнә. Күзгә яшь китерерлек үкенечле бу өлеш белән автор нәрсә әйтергә

тели? Яшь кешеләрнең, балаларын-яратканнарын ятим-ялгыз калдырып, авырудан вафат булуы – зур фаҗига, диме?

Икенче публицистик текстка нисбәтле беренче – әдәби текст кереш ролен үти, мотивлар ягыннан, биредә яшь кешенең күңел сиземләве дә, Кәримәнең әбигә өшкертергә барырга вәгъдә биреп, анда тора алмау үкенече дә, яфрак детале дә үстерелеш таба. Бу, һичшиксез, уңай момент. Әйтик, әлеге көзге яфрак турындагы кабатлана торган күренешне фәлсәфи, романтик яки автор теләгән башка юнәлешле фикерне-идеяне ассызыклау өчен файдаланырга мөмкин булыр иде. Әмма бу очракта ул мөмкинлек булып кына калган. Беренче тапкыр көзге яфрак – Зиләгә карата, икенче тапкыр Кәримәгә карата кулланыла. Беренче күренештә ул Зилә язмышына ишарә ясый, ә Кәримә очрагында – аның психологик халәтен белдерә. Мондый детальләрне кабатлау, шиксез, бер фикерне үстерә барырга, бәйләнештә булырга тиеш. Әлеге деталь ярдәмендә тулы текстны әдәби әсәргә әйләндереп булыр иде.

Беренче һәм икенче текстларда ялганган тагын бер мотив – гомернең кыскалыгы. Зилә, туй алдыннан сөйләшүне искә төшереп, болай ди: «Син гомер озын ул, дигән идең. Түгел икән бит... Бирелгән кадәр генә. Күпме көрәшсәң дә, артыгын алу мөмкин түгел икән...» Әмма фәлсәфә бу мотивта дәвам итми, шушы урында өзелеп кала.

Шул рәвешле, ике төрле (әдәби һәм публицистик) стильдә иҗат ителгән ике текст ялганмый. Татар хикәясендә, гадәттә, публицистик өлешне әдәби текст эчендә, искә төшерү яки аңлатып китү өчен куллану тәҗрибәсе ешрак очрый. Әмма биредә соңгысы зуррак булып, киресенчә, әдәби өлеш публицистик тарихны шәрехләү өчен кертелгән дигән тәэсир кала. Шуңа да әдәби әсәр килеп чыкмаган. Беренче вакыйганы кыскартканда, текст публицистик язма яки мәкаләгә әйләнә.

Әдәбилек (художестволылык) нигезе табылмаганга, текстның аерым урыннарында чиктән тыш арттыру тискәре эффект бирә: ышандыру көчен киметә. Мәсәлән, гел аралашып торган Кәримәгә Зиләнең, инде туй күлмәге киеп, кунаклар янына чыгар алдыннан: «Мин куркам. Син шуны аңлыйсыңмы? Куркам. Башка түзәр көчем калмады. Эчемдә генә саклый алмыйм. Миңа уртаклашырга кирәк. Югыйсә шашам. Әйе, шашам! Җүләрләнәм! Ярдәм ит миңа», – дип эндәшүе ышандырмый. Бу сүзләр ахыргы карар кабул ителгәнче, туй күлмәге киелгәнче әйтелергә тиештер...

Шулай да, А.Гайнуллина текстындагы уңай моментларны билгеләү кирәк. Публицистик стильгә төшеп китү – татар хикәясендә еш очрый торган сыйфат. Ул, гадәттә, үгет-нәсихәт кебек формалаша торган идеянең әйтелүе белән төгәлләнә. Бу текстта ул юк.

Авторның хикәяләү теле матур, ул детальләр ярдәмендә күренешләрне күз алдына китерә белә. Мин исеменнән сөйләү, сурәтләнә торган мизгелдә кичергәннәрне тергезү тәэсирлелекне арттыра. Аерым детальләрне кабатлау (мәсәлән, «сары чыпчыгым») кичерешләрнең көчен күрсәтерлек итеп уйланылган.

Әмма хикәя әлегә хикәя таләпләренә тулысынча җавап бирми. Чөнки анда тормыштагы вакыйганы кабатлап сөйләүдән зуррак булырга тиешле әдәбилек юк. Ике стильне кушу – эклектиканың вазифасы билгеләнмәгән. Бу очракта авторга, каләм алып яза башлаганчы, укучыга җиткерергә теләгән вакыйга-күренешне генә түгел, бәлки фикер-күзаллауны да уйлап бетерергә тәкъдим итәр идем.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы*

*Күренекле үзбәк язучысы, әдәбият белгече, тәрҗемәче Улугбек Хамдам (Улугбек Абдулвахоб улы Хамдамов) 1968 елның 24 апрелендә Үзбәкстанның Әндиҗан өлкәсе Мәрхәмәт районы Юкори Равват мәхәлләсендә дөньяга килгән. 1988 елда Ташкент дәүләт университетының филология факультетына укырга керә. 1992 елда укуын Төркиянең Конъе шәһәрендә дәвам итә. 1993 елда университетны уңышлы тәмамлап, Шәрыкны өйрәнү институтында эшли башлый. 1994-1996 елларда Үзбәкстан Милли университетының үзбәк филологиясе факультеты каршында аспирантурада белем ала. 1997 елда «XX гасырның 30 нчы елларындагы үзбәк поэзиясендә «чиста лирика» проблемалары (Айбек шигырьләре мисалында)» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. Хәзерге көндә «XX гасыр үзбәк поэзиясенең эволюцион фикер үсешендә социаль-психологик нигезләр» темасына докторлык хезмәте яза. 1997 елдан бүгенге көнгә кадәр Үзбәкстан Фәннәр академиясенең А.Нәваи исемендәге Тел һәм әдәбият институтында өлкән фәнни хезмәткәр булып эшли, Ташкент дәүләт университетында укыта, 2003 елдан Үзбәкстан Язучылар берлеге әгъзасы. 2009 елдан «Шәрык Йолдызы» һәм «Звезда Востока» журналларының баш мөхәррире вазифасын башкара.*

*Улугбек Хамдам проза һәм шигърият өлкәсендә уңышлы эшли. «Тигезләнеш», «Фетнә һәм буйсыну», «Сабо һәм Самандар», «Аллаһыга илтүче фетнә», «Гөлчәчәк» романнары, «Ялгызлык» повесть һәм хикәяләр җыентыгы, «Сине көтте…» шигъри җыентыклары авторы. Шулай ук үзбәк, дөнья әдәбиятлары үсешенә караган күпсанлы фәнни хезмәтләр авторы, тәрҗемә өлкәсендә уңышлы эшли.*

*Иҗаттагы һәм иҗтимагый тормыштагы актив, нәтиҗәле эшчәнлеге өчен Үзбәкстанның «Шөһрәт» ордены белән бүләкләнгән.*

**Факил САФИН,**
*филология фәннәре кандидаты*



Улугбек
Хамдам

# ГӨЛҖИМЕШ

**I**

МИНИ РОМАН

*Кеше дөнья йөзендә ни күрергә теләсә,*
*Дөньяның да ул кешедә шуны ук күрәсе килер.*
(Акыл ияләре шулай сөйлиләр...)

Ике күршенең дачаларын аерып торган коры межада кайчандыр гөлҗимеш куагы үсә иде. Әлеге куакны беркем дә утыртмаган, ул үзеннән-үзе үсеп чыкты, хәер, чынлыкта, язмышның серле балдагы сыман, көтмәгәндә ике күршенең тормыш юлында барлыкка килде бит ул... Бәлки, кем белә, аның юлына бу кешеләр үзләре килеп чыккандыр...

Гөлҗимеш елдан-ел биеккәрәк үсә, күккә үрелү генә җитмәгән, киңлеккә дә җәелә, дүрт якка тармаклана, еракtан инде бу куак зур бер агачны хәтерләтә башлады. Ике күрше гөлҗимешкә игътибар да итмәделәр, әллә бар ул, әллә юк, кызның әти-әнисе дә, үсмер егетнең гаиләсе дә аны үзләренеке итеп санамыйлар иде. Көз җиткәч, һәр ике дача бакчасындагы барлык уңышны җыеп алалар, фәкать гөләп чыбыкларындагы җимешләр генә дөньяга ятим күзләр белән багып кала торган булдылар. Үсмер гаиләсендәгеләр күршеләренә шелтәләгән кыяфәттә: «Гөләп җимешләрен нигә җыеп алмыйсыз? Тиздән кар явачак. Ходай биргәнне җыеп алмасаң, гөнаһ булыр бит!» – дисәләр, кыз ягы, мутланып җавап бирде: «Ни сөйлисез, хөрмәтле күршекәйләр? Гөлҗимешнең күпчелек ботаклары сезнең якта асылынып тора ласа, шуңа күрә куакның җимешләре дә, шиксез, сезнеке саналырга тиеш. Күп сүз итми генә, бөтенләй юкка чыкканчы, җыеп алыгыз җимешләрне...»

Шул рәвешле, буш бәхәс корбанына әйләнеп, җимешләр җыелмыйча кала бирде...

Ә ул арада, бер-берсен алыштырып, еллар үтә торды...

Бер язда үсмер егет дачага килде. Кулына кәтмән тотып бакчага чыккан иде, чәчәкләргә күмелгән гөлҗимеш куагы белән рәттән торган күрше кызын күреп имәнеп китте. Егет, авызлыгыннан кисәк тартып туктаткан тай шикелле, баскан җирендә катып калды. Үз уйларына чумган кызны куркытырга теләмәгәндәй, йөткереп алган булды, аңышып та җитмәстән, ирексездән, кызга табан ике-өч адым атлады. Кыз, җәһәт кенә зиһенен җыеп, бераз арткарак чикте, күрше егетенә сәлам бирде һәм, киеренкелекне йомшартырга теләп, күтәренке төстә әйтеп куйды: «Чүт-чүт кенә карап алыгыз әле, нинди матур чәчәкләр!» Кыз көтмәгәндә телдән калды: тирә-юньне тылсымлы болыт сыман каплап алган кызгылт-алсу чәчәкләрдән күзен ала алмыйча, егет аның үзенә табан атлый иде. Чыннан да, чәчәккә төренгән әлеге могҗиза бөтен тирә-якны хушбуй исенә батырган, шушы искә туктаусыз бал кортлары җыела, алар чәчәктән чәчәккә кунып, гөж киләләр. Егет, куак янына җиткәч, иелә төшеп, күз явын алырдай якты чәчәкләрне сак кына иснәп алды. Гөлчәчәк исенә чак кына нindидер йомшак тәм дә кушылган сыман иде. Бәлки, гөлләрдәге нектар шулай балланып аңкый торгандыр.

Бу ис назлы, исерткеч, һушны ала иде!..

Иелгән җиреннән гәүдәсен турайтып, кабат тирән сулыш алды, үпкәгә гөләп чәчәкләренең хуш исе кереп тулды һәм, шушы мәлдә, үз янында торган, дөньядагы иң гүзәл чәчәктән таралган назлы тәмне тойды – бу күрше кызының чәчләреннән аңкыган гамбәр чәчәге исе иде. Мизгел эчендә егетнең башы татлы әйләнеп куйды... Шушы мәлдә аның язмышы хәл ителеп тә куйган иде инде...

– Күрәсезме, теге елдан калган җимешләр һаман да коелып бетмәгәннәр икән бит, алар быелгы чәчәкләр артына яшеренгәннәр, яфраклар астына кереп качканнар! – дип, үзен камап алган исерткеч хис-бөҗрадан арынырга теләп, сөйләнгән булды кыз. – Моның ни аңлатканын беләсезме?

– Ничек инде белмәскә? Күршеләрнең ялкаулыклары турында сөйли ул. Башкача ничек булсын? Җимешләрне вакытында җыярга өлгермәдегезме? – Егет шукланып өстәп куйды: – Шушындый кызга иренү килешми инде.

– Сез үзегез ялкау! – дип чытлыкланды кызый. – Ярый, тулысынча килешәм, көз көне ике еллык уңышны җыеп алып, үзегезгә кертеп үк бирермен.

– Ха-ха-ха! – Егет үтә канәгать кыяфәттә көлеп җибәрде. Аңа кызның чыркылдап көлүе кушылды...

Вакыт тәгәрмәче янә бер әйләнеш ясап өлгерде, теге чакта кызый әйткән күз мәле тагын килеп җитте. Күз!.. Табигать нигъмәтләрен җыяр чаклар!..

...Атна арасында, дачада беркем юк чакта, егет бакчада пәйда булды. Кояш баеп барган вакыт иде бу. Кулына чиләк алып, үз якларына чыккан ботаклардан мәмрәп өлгергән гөләп җимешләрен җыеп алды һәм, тулы чиләкне куак астына куеп, кире шәһәргә кайтып китте...

Гадәттәгечә, ял көннәрендә ике гаилә – ике күрше шәһәр читендәге шушы бакчаларына җыелдылар. Егет, ирен читләренә тантаналы елмаю кунган хәлдә, куак астына яшереп калдырган җимешле чиләкне алып, сукмак буйлап күрше ягына юл тотты, исәбе – телләшергә оста кызны бераз акылга утырту иде. Нәкъ шул чагында ашкынып каршысына атлаучы кыз белән йөзгә-йөз очрашты. Кыз кулына пластмасса чиләк тоткан иде.

– Әссәламегаләйкүм, – дип, иелә төшеп сәлам бирде егет.

– Вәгаләйкемәссәлам! Йортыгызга бәрәкәт иңсен! Бакчабызга рәхим итегез, күрше. Менә, теге ялкаубикәнең вәгъдә иткән җимешләрен алыгыз. – Кыз гөләп җимеше белән мөлдерәмә тулган чиләген югалып калган егеткә сузды! Шул мизгелдә, ирексездән, егет кулындагы чиләккә караш ташлады, кыз да гаҗәпләнүдән авызын ачып калды. Чиләкләрне сукмакта калдырып, алар куак янына йөгерделәр... ә анда... куакта бер генә җимеш тә калмаган иде: кыз егеткә дип үз якларына чыгып үскән ботаклардан, егет исә кызга атап үз ягындагы ботаклардагы җимешләрне җыеп алганнар икән бит. Тик кыз җимешләрне алдагы көнне иртән иртүк килеп җыйган, ә егет шул ук көнне кичен җыеп куйган, ул каршы яктагы җимешләрнең җыелып беткәнен абайламаган да иде...

...Тәмле ис бөркелгән гөлҗимеш тирәсендәге хәлләр белән моңарчы да таныш булган һәм туганлашып китүгә яшертен генә өмет иткән ике әни бу вакыйганы гаилә башлыкларына төрле төсмер, ямьнәр белән баетып сөйләп бирделәр... Инде, шушы хәлләрдән соң, уйда йөргәнне тормышка ашыруны сузудан ни мәгънә бар, әтиләрнең теләге – Ходай теләге бит!..

Туйны яз көне, гөлҗимешләр чәчәк аткан чакта ясадылар...

## II

*Кеше дөнья йөзендә ни күрергә теләсә,*
*Дөньяның да ул кешедә шуны ук күрәсе килер.*
(...шулай сөйлиләр...)

Бу вакыйгадан соң гөлҗимеш тагын, тагын чәчәк атты, күп тапкырлар яфрагын койды, тагын язын яшәрде. Егет белән кыз гаилә кордылар, гөлҗимеш шикелле тормыш кырында тамырландылар, ябалдашлары елдан-ел киңәйде, мул җимешләре күпләрне сөендерде. Шундый вакыт җитте, гөлҗимеш куагы яшәү җегәре белән якын-тирәдәгеләрне сокландыра бирде, ә ир белән хатын картайдылар, бирештеләр, аларның куанычы – тупырдап торган ике малай һәм ике кыз үстерделәр, алардан исә унбер оныклары туды.

Ир белән хатынның, алар инде үзләре әби белән бабай, ата-анасы, балаларына фатихаларын калдырып, күптән бакыйлыкка күчкәннәр иде, ә бу бәхетле пар, картлык баскан көннәрендә, бөтенләй дачага күченеп яши башлады, шәһәргә кайтып та килмиләр иде диярлек. Гади генә әйткәндә, алар бу җирне яраттылар, тормыш мәгънәсен шушында гына таптылар. Гомерләренең соңгы көннәрендә карт белән карчык балаларына васыять әйттеләр: вафатларыннан соң икесен дә әлеге, шундый да якын булып киткән бакчада, рәттән казылган каберләргә күмәргә куштылар.

Ә гөлҗимеш чытырманлыкка әйләнде. Карт белән карчык гомерләренең соңгы көннәренә кадәр куаклыкны карап тордылар, картайган ботакларын кистеләр, яшь үсентеләр белән сабый баланы караган дәрәҗәдә мәш килделәр, аларга ата-ана назын, бар шәфкатен бирделәр; бу игътибарның нәтиҗәсе шул – гөлҗимеш, күпме вакытлар үтеп тә, күпме вакыйгалар кичереп тә, ике дача арасында һаман үсә, һаман исән-имин, һаман чәчәк ата, җимешләрен бүләк итә; аңа карагач, вакытның туктаганын тойган кебек буласың, яңа буыннарга элгәрге чакларның матур мизгелләрен искә төшерә сыман, менә-менә шушы мәлдә теге егет белән кыз йөгереп килеп керерләр шикелле; килеп керерләр дә гөлҗимеш чәчәкләрен күреп, гүзәллеккә һушлары китеп, бер-берсенә сыенып торырлар, аннары исләренә килеп, үткән ел җыелмый калган җимешләрне чиләкләренә өзеп сала башларлар кебек; ә шуннан соң, шуннан соң... күңелле туй мәшәкатьләре башланыр...

Әмма болай булмый шул. Вакыт аяусыз, барыбыз да аның ихтыярында гомер сөрәбез – егет белән кыз үзләренең тормыш юлларын тиешенчә үттеләр, картлык гомерен кичтеләр һәм бакыйлыкка күчтеләр. Аларның кояш астындагы урынына алмашка яшь буын килде. Һәм кабат, моннан күп еллар шикелле, гөлҗимешле межаның бер ягындагы йортта дөньяга карт белән карчыкның төпчек малайларының улы туды, ә күрше дачада, нәкъ шул көннәрдә, карчыкның якын туганы дөньяга яңа варис алып кайтты! Шунысына игътибар итик: яңа буыннарның тормышлары да шушы ук гөлҗимеш куагы тирәсендә бөтерелде. Кызык бит, әйе, кызык шул, бу куак белән мөнәсәбәттә яңа буын күршеләрнең үзара аңлашулары ничегрәк булыр микән: алар бер-берсенә «син» диярләрме, әллә, бер-берсен чит итеп, «сез» дип эндәшерләрме?..

– Гөлҗимешнең хуҗасы мин. Балаларыңа әйт, алар куакка якын да килмәсеннәр. Җимешләрне без үзебез җыеп алачакбыз! – дип, янаган сыман тавыш күтәрә бер як.

– Кесәңне киң тот! Гөлҗимешнең иң зур ботаклары безнең якка салынып төшкән, күреп торасың, ярты бакчаны каплап алган, димәк, куак минем мөлкәтем! Алдан ук әйтеп куям, әгәр бер генә җимешкә кагылсаң да, бакчаңның астын өскә китерәчәкмен! – дип, куркытуга күчә икенчесе...

Шулай итеп, ике күрше арасында ызгыш килеп чыкты. Бер генә як та үз сүзеннән кире кайтырга уйламый иде. Каршылык көчәйгәннән-көчәя барып, ахырда, күршеләр бер-берсен күрә алмас дәрәҗәгә җиттеләр, күрә алмаучылык исә салкын сугышка әверелде. Нәтиҗәсе шул: якын туганнар кан дошманга әйләнде.

Эшләр шуңа барып җитте: көннәрдән бер көнне көрәшкә күтәрелгән ике як ике йорт арасына койма коярга карар кылдылар. Әмма чикне ничек гадел итеп билгеләргә? Тагын каршылык килеп чыкты. Һәр як гөлҗимеш куагының нәкъ менә алар ягында калуын тели иде. Чебешләрне көз көне саныйлар бит, бер күрше хыялында арага дивар коеп куйса, икенчесе аны шундук җимереп атарга тели, чөнки гөләпнең теге якта калачагын чамалый иде ул. Моңа һич тә юл куярга ярамый!..

Күңелсезләнеп йөргән бер көнне бер як күрше үзләренең бакча ягына салынып төшкән ботак-яфракларының саргая башлавын күреп алды. Бакча хуҗасы пошаманга төште, ашламасын мулдан бирә, су сибүдән өзгәне юк, моңарчы сау-сәламәт булган куакка ни булды соң әле? Күрше ягына караш ташлады, ул яктагы яфраклар ямь-яшел, әкрен җилдә лепердәп тик утыралар, җимешләре дә хәйран гына күренә. Үз ягындагы сабак төпләрен җентекләп карарга кереште,

шикләнүе дөрес булган – төп саен акбур сибеп чыкканнар иде. Ачуы бугазына килеп тыгылды, Кыямәт көне җиткәнен аңлатырга кирәк теге иблискә!

Күршесенең бу явызлыгына чыдый алмыйча, ул ике малаен чакырып китерде, өчесе дә кулларына балталар алып һәм, ничектер, кайчандыр ике дача арасындагы межага үсеп чыккан гөлҗимеш куагының сабакларын тураклап өя башладылар. Куакны тураклаган мәлдә, бу күрше теләсә нинди ерткычлыкны эшләп атарга сәләтле иде инде, хәтта, шушы куакны тураклап өйгәч, аның өчен чикләр бетте, инде кемнеңдер канын коюдан да чирканмый иде. Яшерен түгел, күңелендә шундыйрак уйлар чабышты.

Икенче күрше бакча ягында балта тавышын ишетеп, гөлҗимеш куагы янына йөгереп килде, анда өч ир-ат, җан-фәрман балта селтәп, куакларны кисеп бетереп яталар иде. Үз якларында берничә сабак кына калган, үз-үзен белештермичә, бу явызлыкка чик куярга теләп, теге кабахәтнең балта тоткан кулына килеп ябышты. Тегесе балтасын бирмәс өчен җан көче белән тартышырга тотынды. Бер мизгелгә карашлары очрашты, тамырлардан гөжләп, котырып кайнар кан ага, ничә еллар буе кодрәт җыеп яткан вулканның телгә килүен күз алдына китерегез! Тәннәре бер-берсенә килеп орынды, чигенү юк, һәркайсы соңгы алышка чыкканын аңлый иделәр.

Нәтиҗә шул: әле генә агачның каты кәүсәсен кыеп алган балта йөзе, тукталып калмастан, күршесенең муенына килеп эләкте...

Берничә елдан соң, күршесен үтергәнгә хөкем ителеп, рәшәткә арасына эләккән тоткын үзе дә бу дөньяны ташлап китте, үпкә туберкулёзыннан, диделәр...

### III

*Кеше дөнья йөзендә ни күрергә теләсә,*
*Дөньяның да ул кешедә шуны ук күрәсе килер.*
(...сөйлиләр...)

Кан коелган вакыйгага бәйле рәвештә ике күрше дә юкка чыккач, алдагы язда тураклanып беткән гөлҗимешнең исән тамырларыннан яңа үсентеләр баш төртте. Еллар үткән саен, гөләп тармакланды, куәтләнде... Тагын яңа яз килде, табигать кабат уяну сөенечен кичерде! Кошлар күңелле чыркылдаша, бал кортлары гөж килә, җилләр үз телләрендә, пышылдап кына, килеп-киткән адәм балаларына кагылышлы гыйбрәтле хәлләр хакында бәян итәләр. Гаҗәеп җанга ятышлы бөтенлек һәркемне сафландыра, һәркем бу дөньяның бар матурлыгын күңеленә сеңдерүдән ләззәт кичерә иде. Әмма җилләр телен аңлаучы берәү бармы монда? Яфрак лепердәвеннән бөтен дөньяның яшерен серләрен ача алырлык кеше җиргә кабат туачакмы? Җирдәге барлык байлыкларны Ходай нигъмәте итеп кабул итәрлек кеше калдымы?

### Беренче көн

Менә Адәм баласы дөньяның бар гүзәллегенә дан җырлау өчен үз алачыгын ташлап китте: яшүсмер кызый өйләреннән атылып килеп чыкты да бакча ягына йөгерде, гөлҗимеш куагы яныннан үткән чакта сизмәстән таеп китте. Яшь ботакларның шау чәчәккә күмелгәнен күреп, биһуш китеп, баскан җирендә катып калды. Каршы яктагы бакча башында нәкъ шушы яшьтәге, бәлки бер-ике яшькә олырактыр инде, яшүсмер егет күренде. Кыз янына килеп җиткәч:

– Болай исең китеп ни карап торасың? – дип сорады.

– Бу куакны кем утырткан микән? Чәчәкләре шундый матур! Кем утырткан аны, беләсеңме?

Үсмер «белмим» дигәндәй, башын чайкады. «Ә чәчәкләре, чыннан да, бик матур», – дип уйлады ул. Иелә төшеп, чәчәкләрне иснәп алды.

– Матурын-матур да бит, әмма шушы куак аркасында... аның аркасында! – кыз ярты юлда сүзен өзде. Аның тамак төбенә төер утырды. Ул бераз басып торды да үкереп елап җибәрде һәм кире өйләренә табан йөгерде...

## Икенче көн

Үсмер иртүк уянып, күзләрен ачты. Хәер, болай да йокы эләкмәде аңа. Яткан килеш уйланды да уйланды, әмма күңелсез уйларының очына чыга алмады. Ниһаять, үсмер авырлык белән генә аякларына торып басты, ишегалдына чыгып, боздай салкын су белән юынды, әмма тәнендә дә, уйларында да җиңеллек тоймады, шыксыз уйлар аның җанын һаман талкый бирделәр. Аяклары, ирексезләп, кабат терелгән теге гөлҗимеш куагы янына атлап китте. Аны билгесез көч тартып бара иде, ул исә бу көчкә каршы килә алмый. Гөлҗимеш янына җитүгә, аның каршында тезләнеп, тын калды...

Вакыт тәгәрмәче әйләнде дә әйләнде...

Әнисе ашарга чакырды, тик малай урыныннан кузгалып та карамады: тезләрен кочаклап, ул кичәге кызны көтә иде. Кемдер колагына пышылдап алды: «Көт кенә, ул һичшиксез киләчәк». Ул шушы эчке тавышка буйсынып, көтүен дәвам итте. Кинәт шәфәкъ нурлары як-якка сибелде, агачлар арасыннан кызның таныш күлмәге күзгә чалынды. «Ниһаять!» Үсмер тирән итеп сулыш алды. Бу сулыш татлыдан-татлы иде.

– Син еладың бит?

Кыз эндәшмәде.

– Еладың шул, бик озак еладың, – дип дәвам итте малай, өлкәннәрчә һәр сүзен ярып салып... – Нигә елаганыңны белдем... кичә әнием барысын да сөйләп бирде. Элек мин бу хәлләрне ишетмәгән идем. Әмма безнең әтиләргә кадәр әби-бабаларыбыз да яшәгәннәр, алар бер-берсен сөйгәннәр, өйләнешкәннәр, мәхәббәтле тормыш корганнар. Син болар хакында беләидеңме?

Кыз һаман бер сүз дә әйтмичә торуын белде.

– Әйе, барысы да шушы гөләп куагы аркасында булган, – диде үсмер.

Кыз тын да чыгармыйча тыңлап тора бирде. Ул үзе дә әбисе белән бабасының күңел тарихларын белә иде бугай. Кыз тагын бераз шулай бер сүз дәшми торды да агачлар арасына кереп югалды.

## Өченче көн

Алар янә шушы гөлҗимеш янында очраштылар.

– Бу куакны кем утырткан инде? Әниеңнән сорадыңмы?

– Юк. Ә син?

– Оныттым...

Алар уйларына бирелеп, бер мәлгә тын гына тордылар.

– Гомумән, моның кирәге бармы соң? – диде малай, тынлыкны бозып.

– Кем белә инде. Мөһим кебек тә... – уйларыннан аерылмый гына җавап бирде кыз.

Алар кайчандыр, кемдер утырткан (үсмер белән кыз шулай уйлыйлар иде) куак янында әле шактый озак басып тордылар. Читтән күренгән кадәресе шул: бу ике өлгереп җитеп килүче яшүсмер малай белән кыз, әлеге гөлҗимешкә нинди мөнәсәбәттә булырга белмичә, әмма билгесезлекне бик тә чишәселәре

килеп, куак тирәсендә бөтереләләр, кызып-кызып, кулларын болгаштырып, бер-берсенә нидер аңлатырга тырышалар иде.

Кем белә, бәлки алар үзләренең борынгы бабайларын искә алганнардыр, ә бәлки, үзләренең әтиләрен хәтерләренә төшергәннәрдер, бәлки инде аларның уйларында бөтенләй башка нәрсә булгандыр? Кем белә бит...

*Кеше дөньяның йөзенә нинди күзләр белән карый,*
*Дөнья да аңа шулай җавап бирәчәк.*

# КҮҢЕЛЕМ ДӘРЬЯСЫ

ХИКӘЯ

Кышлакта туып-үскәнгә күрә, мин табигатьне бик яратам. Шәһәрдә йорт сатып алырга уйлагач, булачак өемнең табигатьнең бер матур почмагында урнашуын шарт итеп куйдым: агачлар да шаулап үссен, яшеллек тә күп булсын, шул ук вакытта машиналарның шау-шуы колакны ярып кермәсен, кешеләр дә сирәгрәк йөри торган төбәк булсын, дип теләдем. Эзли торгач, теләгемә ирештем, күңелемә ятышлы урыннан йорт сатып алдым. Шуннан соң... шуннан соң ни булсын инде? Барлык кешеләр сыман ук яши башладым...

Безнеңчә яшәү ничек соң ул? Иң әүвәл – эш... аннан – өйгә... йорт эчендәге вак-төяк нәмәрсәләр белән булышу, тегесен-монысын табу, балаларның бетмәс-төкәнмәс мәшәкатьләре... Гомер бакый шулай булган. Язмыш диләр бит инде, тик бу төшенчәне һәркем үзенчә аңлый. Бу маңгайга сугылган мөһер шикелле, бер тапкыр чәпәп куйсалар, бетте-китте, кабергәчә шуның белән йөрергә туры киләчәк. Шундый вакыт җитте, бертөрлелек тәмам туйдырып, Аллаһның бирмеш һәр көнендә: «Язмышны үзгәртеп булмый микәнни?» – дигән уйлар бимазалый башлады мине. Бу һич тә ялган түгел. Әмма... күргәнегезчә, һәрвакыттагыча – һәммәсен өр-яңадан башларга кирәк икән бит, һәрвакыттагыча – һәркемнең үз юлы, үзенә язганы... Мөһер...

Язмышны җиңәр көч юк, бусы һәркемгә аңлашыла, ул гына да түгел, язмыш – ул могҗиза, тылсым төенчеге! АНЫҢ тарафыннан язмышың – кавем, буй-сын, тән төсе сыман ук, алдан тамгалап куелган. Әгәр син Ишмәт икәнсең, ничек кенә тырышсаң да, Төшмәт була алмыйсың инде. Пластик операцияләр ясап, дисезме? Бусы инде бик нечкә мәсьәлә. Тышкы кыяфәтне үзгәртеп тә булсын ди, әмма эчке халәт шул килеш кала бит. Күңелең белән син Ишмәт икәнсең, син Ишмәт инде, Төшмәт икәнсең, ни генә кылансаң да, Төшмәт булып калачаксың. Ышанмыйсызмы? Алайса, тыңлап карагыз, үз тормышымнан кечкенә бер кыйсса сөйләп китәм.

Бервакыт үземнең язмышымны ук булмаса, язмышка илтүче юлларны бераз үзгәртү нияте белән яна башладым. Моңарчы яшәгән тормыш мине туйдырды, әйтсәм әйтим, аннан гарык булдым. Мин каты кызгануны белмәүче кырыс хуҗа кулындагы бер ялчы сыман гомер кичерә идем, әйтерсең, ул минем арттан армый-талмый күзәтеп йөри, анысы гына җитмәгән, алга мин чишәргә тиешле берсеннән-берсе катлаулы мәсьәләләрне туктаусыз куеп кына тора. Берзаман күземә кырыс Язмышның каннар тамып торган камчысы да күренә башлады. Җаным имәнеп китте. «Ярый, – дип уйлап алдым, – ярый, миңа мәсьәләләрне әйбәтләп язып бирсен дә яңадан минем өстән тикшерү оештырып

йөрмәсен, мин исә аларны чишү рәтен ничек тә табармын. Җаныма тиеп кенә торучы булмасын. Иң сөймәгәнем – кемнеңдер артымнан күзәтеп, тикшереп маташуы. Артымнан нидер кычкырып, җикереп калырга, кашларын җыерган булып, күзләрен чепиләндереп карарга, шелтә белдерергә, баш өстемдә камчы болгарга, мыгырданырга Язмышның ни хакы бар? Алдан әйтеп куям, минем аның каршында бер гаебем дә юк... Туйдырды тәки...»

Ун ел буе Язмышка илтүче юл-сызыкны бераз гына төзәтеп булмасмы, дип, әллә нинди уй-ниятләр корып бетердем. Әмма бу сызыкның бер генә карышына да кул тидерә алмадым. Теләмәүдән түгел, үзгәртергә теләгем көчле, тик теләк – теләк булудан артмады. Шулай яшәлде дә инде, өйдән эшкә, эштән өйгә, туку станы сыман, бер-берсенә гаҗәеп охшаш көннәрем тукыма канвасына өстәлеп кенә тордылар. Менә шулай үзагымымда тыныч кына йөргәндә, йөзгә йөз очраштым. Кем белән, дисезме? Дәрья белән!

«Бу дәрья шәһәргә ничек килеп чыкты соң әле?» – дип сорарсыз инде. Сорауны соңлабрак бирдегез шикелле, башыма әлеге сөаль шундук килгән иде. (Әйтим инде, шушы ук сорауны бераздан хатынымнан да ишеттем.) Килгән инде, менә бит агып ята, аны арык дип кенә атасалар да, мин аңа дәрья дигән исем тактым. Чөнки ул тиз агышлы, тулып ага, гайрәтле күренә. Үзе матур да әле! Шулай булгач, нигә саранланырга, дәрәҗәсе күтәрелсен – дәрья булсын. Арыкны күргән уңайга, башыма китереп сукты: Дәрья! Менә шулай безнең шәһәр аша дәрья агып ята икән!

– Безнең йорт тирәсендә берәр дәрья бармы? – дип сорадым хатынымнан шул ук көнне. Ул, гаҗәпләнеп, озак кына күзләремә карап торды. – Бармы, юкмы? – дип кабатладым, бераз кыенсына төшеп. – Нигә бу кадәр гаҗәпләндең?..

Хәләлем, иплəп кенә килеп, кулын маңгаема куйды. Соравыма җавап кайтармастан, башка нәрсә хакында сөйли башлады:

– Бүген улыбыз укыган мәктәптә әти-әниләр җыелышы. Шунда барырга тиеш идең бит... Алдан әйткән идем инде, бармагансың. Сыйныф җитәкчесе телефоннан шылтыраткач, җир тишегенә кереп китәрдәй булдым. Бик тә килүебезне теләгән иде, бахыр...

– И-и-и, – дип өтәләнеп алдым мин. – Җен бутаган инде, башымнан чыгып очкан бит. Ничә тапкыр әйтеп, истә калмаган, диген...

– Үткән айда кызыбызны кыен хәлдә калдырдың. «Җәяү йөрмәгез, тиз генә бер эш майтарып кайтам да үзегезне машина белән генә кул эшләре бәйгесенә илтеп куям», – дип вәгъдә бирдең дә чыгып югалдың. Иптәш кызы белән көне буе көтеп утырдылар. Бәйгегә соңга калдылар, югыйсә, күпме әзерләнеп йөргәннәр иде. Бүген дәрья дип башны катырасың. Нинди дәрья булсын ул? Урам башындагы чүп-чар белән тулган арыкны әйтәсеңме? Суы бармы соң аның, булса, шул чыпчык тезеннәндер инде, ага дисәң, хәтерең калыр. Шуны дәрья дип очына бит. Юк, чыннан да, сине җен бутаган!

Эндәшмәдем. Уйласаң, хатын йөз процентка дөресен әйтеп бирде. Хикмәт дәрьяда түгел, аны елга яки дәрья дип атап йөрткәннәре юк иде моңарчы. Арык! Ишмәт – Төшмәт була алмый! Урам башындагы арыкны күрмичә йөргәндәй... Онытуга килгәндә, эшләремнең тыгыз чагы, барысына да өлгерергә кирәк, шул ыгы-зыгыда кайбер нәрсәләр онытылып та куя. Бу хәтерсезлек түгел, башка әллә ничаклы вак-төяк мәшәкатьләр тулган бит. Соңгы вакытларда аларны кәгазь кисәгенә язып, кесәдә йөртә башладым. Сукыр кеше таяксыз йөри алмагандай инде. Башкача ничек истә калдырмак кирәк? Әле алай да барысын да үтәп бетереп булмый. Менә кичә кичкә табан язылганнарына күз

салыгыз: 1. Ишек йозагының каптырмасын алыштырырга! 2. Сәрвәрнең туена шәбрәк бүләк алып кайтырга. 3. Юл уңаенда электр чәйнеге алырга (күптән түгел алганы янып та чыкты). 4. Малайның компьютерын остага илтеп бирергә. Төзәтәсе бар. 5. Электрга түләргә. 6. Поликлиникага барып белешмә алырга (кыз физкультура дәресләренә йөри алмый). 7. Базарга барып: бәрәңге, суган, кишер, ит, ипи, май... 8. Машина шинын тикшерергә. Һавасы чыга бугай. 9. Юнысбадтагы туган-тумачаның хәл-әхвәлләрен белешергә. Күптән сөйләшкән юк. Бабайлары үлгән иде, кабере ни хәлдә микән? 10. Күрше бабайны Карасуга, табибка алып барып кайтырга. Күптәннән үтенеп йөри. 11. Бер ният бар иде. Шуның буенча сөйләшергә барырга кирәк.

Игътибар итегез, бу исемлек бүген өченгә генә. Иртәгәге көнгә башка исемлек төзеләчәк. Алдагы көннәрдә эшләнгәннәрен сызып куям да эшләнми калганнарын яңа исемлеккә терким. Язган саен, алар күбәяләр генә. Эшләнгәннәре дә хәтсез бит инде! Шулай да гел акланып утырудан файда юк, хатын дөрес әйтә, бердәнбер улың белән бер бөртек кызың турында онытып йөргәч соң... Әти-әниләр җыелышы онытылсын да ди, әмма кызымның иптәше белән мине Алай базары янында көне буе тилмереп көтеп торулары... Бер кысага да сыймый. Искә төшкән саен, башыма шаулап кан йөгерә. Бәйгегә соңга калдылар ич! Ни әйтим инде? Алар исемлеккә керми калганнар иде. Шуның өчен оныткан мын да инде. Әгәр алдагы көндә хатын искә төшереп куйса, аларны исемлеккә егерменче итеп булса да теркәр идем. Ул чагында тәртип булыр иде. Бүген кеше исәп-хисап машинасы хәлендә, компьютер белән дә чагыштырырга ярыйдыр хәтта. Уйлаган эшләр кайда да булса язылып, теркәлеп калган икән, үтәлә, шулар хакында гына уйлап йөрисең, язылмаса, гафу... Мин моңа күнегеп киләм инде.

Исемлектәге эшләрне хезмәтем буенча төп вазифамны үтәгән арада эшләп өлгерергә тиешмен, алар барысы да өстәмә эшләр, икенче дәрәҗәдәге нәрсәләр. Төп вазифа башка инде ул. Иртән тугызда эшкә килеп керү белән, теге исемлекне кесәгә салып куям. Төп эшне башкарганда икенчел эшләргә бүленергә ярамый, хезмәткәр өченгә төп вазифаны үтәү – изге! Үзеңнең шәхси мәшәкатьләреңне, йортка кагылышлы шөгыльләрне, таныш-белешләргә, дус-туганнар үтенече белән эшләнәсе эшләреңне, башка вак-төяк йомышларны төп хезмәт белән бутарга ярамый. Кичке алты тулгач, рәхим ит, төп хезмәтеңне йомгакла да иртән кесәгә салып куйган кәгазьне тартып чыгар! Менә шунда чын мәхшәр башлана инде. Әле телефон «хәтеренә» язып куелганнары да бар икән бит! Кәгазьдән күземне алырга өлгермим, «пик-пик» итеп, хәбәр килеп ирешә, телефонның тонык тәрәзендә бүгенниләр эшләргә тиеш икәнлекне искә төшерүче язулар пәйда була. Әйтик, мондый язу чыга: «мет. 21.00», димәк, кичке тугызда метро станциясендә булырга кирәк. Бер сыйныфта укыган иптәшем ерак сәфәргә китә. Озатмасаң, үпкәләр. «Нот. 18.20», димәк, кичке җиденче егерме минутта нотариуста булу сорала, машинама бәйле документларны тәртипкә китерәсем бар. Таныш нотариус «эшләп бирербез», дигән иде. Саный китсәң, байтакка җыела...

Ул көнне хезмәт урынымда да эш вакытым әйбәт кенә үтте, исемлеккә язылганнары да үтәлде, арып-талып, әмма яхшы кәеф белән өйгә кайту ягына борылдым. Кинәт кенә машина рулен бору авырлашты, аннан ул бер якка ишелеп төште. Шофёрлар яхшы белә: тәгәрмәч тишелде! Туктап, төшеп карадым: шулай, тәгәрмәчне алыштырырга туры киләчәк. Запас тәгәрмәчне өстерәп чыгардым, алыштырып мәшәләндем, тегесен багажникка салып

куйдым. Иртәгә яматырга туры киләчәк. Аны исемлеккә беренче итеп теркәп кую лазем. Кузгалып киткәнче үк язып куярга кирәк! Шулай уйлап, каләм белән кәгазь алмакчы булган идем, күрәм, ике кулым да кап-кара, пычракка батып беткәнмен. Пластмасса шешәдә һәрчак су йөри иде, бүген анысын да таба алмадым. Як-якка каранып тора идем, ышанасызмы, юкмы – яннан гына челтерәп су агып ята. Һушым китеп, карап тордым! Гаҗәпләнүемнең чиге булмады. Каян килеп чыккан монда мул сулы дәрья? Моннан ерак түгел генә яшим, бер тапкыр да игътибар итмәдем микәнни соң? Елга исә, миңа игътибар итмәстән, челтерәп, якындагы баганадан төшкән утта елык-елык килеп ага бирә, аның матурлыгын аңлатырлык сүзләр тапмалы түгел. Мин бит табигатьне бик яратам. Тик бу яратуның поты бер тиен – үзебезнең йорттан йөз адым чамасында шундый дәрья агып ятсын да ди, аны ничә еллар буе күрмәгәнмен, имеш! Кемгәдер әйтсәң, ышанмас та иде. Әйе, дөрестән дә, йортыбыз яныннан гына арык агып ята икән, һәм мин аны ун ел дәвамында күрмичә яшәгәнмен. Хәзер генә беренче мәртәбә күреп, аптырап торам менә...

Яшәешкә көч бирүче суның сихри куәтен кибегүдән хәле беткән адәм генә белә. Күз ачып йомганчы бөтен тормышымны җаным аша кичердем, ул йөрәк сагышыннан гына торгандай тоелды, һәм мин арык буена ашыктым. Яр читенә килеп җитүгә, йөземә, кулларыма, барлык гәүдәмә салкынча суның талгын тынычлыгы күчте, ирексездән, авызымнан «шәп!» сүзе ычкынды. Иелеп, учларыма су җыеп алдым, талгын гына агып ятучы арык өстенә тамчылар чәчрәттем. Баеп килүче кояшның салмак нурлары, су тамчылары белән аралашып, мизгел эчендә салават күперенә әйләнделәр, бәхетле мәлләр кичердем, җиңелчә генә башым әйләнә башлады. Әйтерсең, шул арада бәләкәй малай чагыма кайттым. Миңа салават күпере аша аллы-гөлле балачагым карап торгандай тоелды. Вәкарь салмаклыкта агып ятучы дәрьяның эчке көчен сиздем, йөрәгемдәге борчу-авыртулар каядыр юкка чыкты, акылдан язган кешедәй, дөньяны яңгыратып кычкырып җибәрәсе килде. Шундый халәт! Бетмәс-төкәнмәс көндәлек вак-төяк мәшәкатьләр, һәрьяктан камап алып, сулышымны буалар, инде күптәннән күңел тынычлыгын югалтып, үземне картаеп беткән кешегә охшатып йөри башлаган идем. Арык буенда мин шушы тойгыдан котылдым! Су агышында бала чагымның чагылышын тотып алгандай булдым. Балачактан кадерлерәк ни бар?! Бәхет-куанычның иге-чиге юк иде. Вакыт исәбен югалтып, су буенда утырдым. Суга караган саен, йөрәк түрендә фани дөньяда моңарчы башыма килеп карамаган уйлар ташкыны куба. Никадәр вак, кирәкмәгән, җитди булмаган эшләр белән вакыт үткәргәнемне аңлап, үз-үземә урын таба алмыйча, тәмам бетәшеп калдым, үземә, эшләремә, язмышыма рәнҗүем тышка бәреп чыкты. Бүтәнчә яшисе килә башлады, бөтен тормышымны үзгәртеп, гел иң кирәкле эшләр белән шөгыльләнү теләге туды. Су агышы моңлы бер көй иде, ул галәм һәм гавам турында иң гүзәл җыр булгандыр! Бу җыр кеше турында һәм анда тормышымның барлык төсмерләре чагыла иде. Су буеннан китәсе килми, алай гына да түгел, кочак җәеп су иркенә ташланасы килү теләге отыры көчәеп, калган бөтен теләкләрне зәр-зибәр китереп ташлады. Әгәр суга ташлансам, чиста, саф су эчем-тышымдагы барлык керләрне юып кына төшерәчәк, һәм мин бөтенләй икенче кешегә әйләнеп калачак идем. Башкача яңарышка ирешеп булмаячак, һәм үзгәрергә омтылышларым да барып чыкмаячак!

Ашыгып күлмәгемне салып ташладым, майкага тотынган идем, машина сигнализациясенең ачы тавышы колакны ярды. Шул арада сыбызгы сызгырттылар,

һәм колак төбемдә каты тавыш ишетелде: «Сезнең машинамы? – җавап бирергә өлгермәдем, таләпчән тавыш иясе дәвам итте: – Сез монда коенмакчы буласызмы? Акылыгыздан яздыгызмы әллә? Яра-мый!!!»

Мин яртылаш салынган майкамны кире киеп куйдым, ирексездән, ярдан читкәрәк китеп бастым. Эшнең асылын аңлаудан мәхрүм идем.

– Документларыгызны күрсәтегез!

Машина кабинасыннан кирәкле кәгазьләрне алып, ГАИ инспекторына суздым.

– Нindirәк кагыйдәне боздым соң әле? – дип сорадым, ниһаять, исемә килеп.

– Гаебегез бик тә җитди, – диде инспектор, документларны әйләндереп карый-карый. – Бу урында тукталу тыела, әйтерсең, моңарчы белмәгән сыман кыланасыз. Җитмәсә, тыелган җирдә су коенасыз, – диде инспектор һәм, күзләремә карап, авыз чите белән елмайгандай итте.

– Икенчесе сезнең компетенциягә керми. Минем су коену-коенмавым сезгә бөтенләй кагылмый. Әле тагын шунысы бар: мин су коенмадым, хәтта суга якын да килмәдем, коену турында уемда да юк иде. Әллә нәрсәләр уйлап тапмагыз инде! – дидем кайнарланып.

– Әле шулаймыни?! – Инспектор, папкасыннан чиста бланк чыгарып, нидер язарга тотынды. – Сезнең ярамаган урында туктап торуыгыз да бик җиткән!

Шулай итеп, йөртүче таныклыгымнан колак кактым. Моңарчы да таныклыкны алып калганнары бар иде. Инде янә шул ук хәлгә тарыдым. Начар бу, начар... Өр-яңадан имтихан биреп йөрисе булачак. Инспекторның дорфа тавышы бераз һуш кертте: «Машинаңа утыр да ычкын моннан!»

Сабыр савытым тулып, ташып чыкты. Шундый матур кәефне бозып ташлады, каһәр. Дорфа сүзен ишеткәч, инспектор белән пәрмә-пәр сугышасы килә башлады. Талонны алудан түгел, кимсетүле сүзләре йөрәгемә уктай кадалды. Теләк бер нәрсә, мөмкинлек икенче нәрсә, дигәндәй, суына төштем. Кагыйдә дә боз, инспекторга кул да күтәр. Артыккарак китәр, ахры.

Кулдан җиргә төшеп ярылган карбыз хәлендә, башны иеп, күңелсез рәвештә машинага кереп утырдым һәм кабызу ачкычына үрелдем...

***

Өч көнләп вакыт үтте, машинасыз калуның бөтен «матурлыгын» күрергә өлгердем. Кулымда – җыен вак-төяк эш язылган кәгазь кисәге. Туп-тулы! Бу хакта сез яхшы беләсез, баш миендә чүп-чар проблемалар кайнаша, әмма аларны чишү өчен иң кирәкле әйбер – машина юк. Һәр эштә иң зур ярдәмчем машина булган икән. Нәтиҗәсе дә күренә башлады. Атна үтмәде, исемлек ике мәртәбә артты. Хатын мыгырдана, нервым котыра... Нишлисең, өлгермим! Көнкүреш – ләхет, дип юкка әйтмиләр икән. Югыйсә без өйдә дүрт кенә кеше, бөтенебез дә йолкыш чебеш хәлендә йөрибез, шул дүрткә кирәк әйберләрнең исәбе-хисабы юк икән. Укытучылар бәйрәменә балаларга белем биргән һәммә мөгаллимгә бүләкләр алып куясы бар, бәйрәм кичәсенә балаларга өр-яңа кием-салым сайлап аласы бар, аның өчен базардан әйләнеп кайтырга кирәк. Әниемнең туган көне якынлаша, үткән ел да эш-мәшәкать дигән булып, җүнле-башлы котлый алмадык, быел алай кылану ярамас. Хатын өйдә утыра – сәламәтлеге какшады, документларын эш урынына кертеп чыгасым бар, аннан үземнең эшкә йөгерәсе... Кайтышлый аптекага кереп дарулар аласы була... Барысын да хисапласаң, башлар әйләнеп бетә, күз аллары караңгылана. Кайчакларда теге каһәр төшкән дәрья турында

уйлап та карыйсым килми. Шуның аркасында башыма күпме проблема ишелеп төште. Әгәр аңа исем китеп карап утырмаган булсам, боларның берсе дә булмый иде бит. Булмый иде! Мавыгып китеп, харап булдым. Әле, кыен булса да, үземә тиешле эшләрне вакытында башкарып бара идем. Һәммәсенә өлгердем бит! Әти-әниләр дә, хатыным да, дус-туганнар, мине чолгап алган ерак һәм якын таныш-белешләр дә рәхмәт әйтеп туймыйлар иде. Дәрьяга тап булдым да, барысы да асты-өскә килде. Нәкъ шулай!..

***

Тиздән әлеге тышкы интегүләр эчке халәтемә күчтеләр: мин саташулы төшләр күрә башладым. Аеруча теге инспекторның ачы сыбызгы тавышы баш миен бораулый иде. Шуңа күрә йоклаганда да, уяу чакта да сак йөри башладым. Уяу чакта ярый әле ул, төштә чактагысы... бусы сәер иде. Баймы син, шыр хәерчеме, йоклаганда һәммәсе тигез бит. Йокы белән идарә итеп булмый, анысын да яхшы беләм. Ә мин... Уяу чак кына җитеп бетмәгән, төшемдә дә теге дәрьяны күреп, куркып уянып китәм, күземне йомам – янә елга ярына табан китеп барганымны күреп, дертләп куям... Инде яр буена килеп җиттем дигәндә генә, сәер тынгысызлык башлана: каяндыр килгән ачы сыбызгы тавышын ишетәм дә, шыбыр тиргә батып, күзләремне шар ачам. Аннан таң атканчы күзләремә йокы керми. Көн туса, тырышып, абына-сөртенә ныклап эшкә тотынам, ничек тә күбрәк эшләп өлгерәсем килә. Кичкә кадәр шулай чапкач, чынлап арыйм, ул чакта төш кайгысы калмый. Ярый, бу дөньяда һәрнәрсәнең чиге бар. Күп вакытларда артка борылып карарга да җай чыкмый. Ни гаҗәп, нәкъ шундый тыгыз чакларда башымны уй көйдереп ала: кеше дөньяга нигә дип килә, ни өчен яши, нәрсәгә дип җәфалана? Җавап таба алмыйм. Кешене хезмәт бизи! Акылы булган кеше бу сүзләргә беркайчан да шик белдермәс. Тик эш белән эш арасында аерма зур шул. Бу арада шушы хакта уйлана башладым әле. Хәзерге кеше шул кадәрле болгавыр тормыш кичерә, артка борылып карарга да вакыты юк. Уйландыра торган хәл. Кешелек – үз тирәсендә гаять катлаулы мохит тудырган һәм үзе шушы вазгыятьнең колына әйләнеп куйган. Аллегорик тел белән әйткәндә, бу заман кешесе алдагы көннәрендә рәхәт кичерермен дигән уй белән шәптин-шәп йорт сала башлаган да, аны төзеп бетерә алмыйча җәфа чигә. Гомере буе шушы йорт тирәсендә кайнаша: әле измә болгата, әле кирпеч, таш сала, әле диварын сылап маташа... Эшнең генә ахыры күренми. Озакка сузылган төзелешнең шундый хикмәте бар – бер яктан төзи барасың, икенче яктан җимерелә тора ул. Әйтерсең, нигезен салганда ук бер күрәзәче, бөтен якны да уйлаганнан соң, катгый итеп: «Бу йорт беркайчан да төзелеп бетмәячәк!» – дип, тамга салып куйган. Әмма адәм балалары бу хакта белмиләр, һаман да төзелеш тирәсендә кайнашып интегәләр, тырышыпмы тырышалар. Сизиф турындагы мифны искә төшерик. Онытмагансыздыр бит? Теге, авыр ташны тау түбәсенә тәгәрәтеп менгерергә дип җан тартышкан Сизиф инде, аны кем генә белми! Бөтен дөньяны шаулатып кычкырасым килә: «Безнең һәркайсыбызда Сизиф яши, без – Сизифлар!» Тик кычкырып әйтергә ярамый, үзалдыма гына шулай уйлап йөрим. Әгәр шулай сөйләнә башласам, җүләргә санап, миннән кычкырып көләчәкләр. Адәм көлкесенә калу фаҗига ук булмаса да, турысын әйтүдән бер мәгънә дә күрмим. Дөньяның асылын миннән башка да танып белүчеләр күп булгандыр анысы. Барысы да таныйлар, аңа игътибар итүче генә юк. Их, дәрья янында тукталмасам, ак сакаллы карт була идем дә... Туктыйсым калмаган! Ни өчен дигәндә, һәркемнең күкрәк тирәсендә

бер сыбызгысы бар. Сыбызгы игътибарны башка якка юнәлтергә ирек бирми, барысы да бертөсле яшәсен дип тырыша, сызгырткан саен, безне башкалар тарафыннан таптап бетерелгән эзгә төшерә: чур, чур-р-р!..

***

ГАИ инспекторы белән бәйле вакыйгадан соң күп сулар акты. Көч-хәл белән имтихан биреп, йөртүче таныклыгымны кире алу бәхетенә ирештем. Тормыш үз җаена ага бирде, гадәттәгечә, бетмәс-төкәнмәс мәшәкатьләргә чумдым: машинада чабам, кесәдә исемлек, иңсәмдә гражданлык, малайлык, аталык, ирлек, дус-туганлык һәм башка бурычлар өелгән. Болар танып-белүнең үзәген тәшкил итәләр... Бу тиклем эштән арынып, дәрья турында ничекләр искә алыйм да, ничек кенә вакыт табып, су буена төшеп утырыйм, ди?! Бер мәртәбә тугарылып китеп карадым инде, башыма күпме бәла алдым ул чакта! Күпме вакыт сарыф иттем, күпме чишелмәгән проблемалар өелде, якыннарым, кардәшләремә күпме борчулар салдым. Нигә дип үземне дә, башкаларны да тагын хафага салыйм? Дәрья... күпме мәшәкать тудырдың син, синең ярыңа килеп басуга онытылган хәсрәтләр тагын өскә ишелеп кенә төшәр сыман. Әгәр дә, юлым шушы якка төшеп, дәрья өстенә килеп чыксам да, туктап тормаячакмын. Сабакны шәп алдым!

Туктыйсым килсә дә, туктап булмастыр – һәр адымда инспектор тора бит. Йә Аллам, башка җирләрдә алай ук күзгә чалынмыйлар бит. Ни пычагыма монда җыелышканнар алар? Бер метр җир киткәнче, ике тапкыр сызгыртырга, өч-дүрт мәртәбә кызыллы-аклы таякларын болгап алырга өлгерәләр. Кая монда дәрья белән хозурлану! Бу сыбызгылы һәм кызыл таяклы җирдән тизрәк ычкыну ягын карыйсың.

Хәзер инде, өйдән чыгуга, иң беренче итеп дәрья ягына күз ташлыйм. Ышансагыз – ышаныгыз, ышанмасагыз – юк: кайчан карама, елга тирәсендә инспекторлар бөтереләә. Башка этле җан да күреми. «Аңлашылды, шуңа да бу елганы моңарчы күрмәгәнмен, – дип уйладым мин. – Кызыл таякны шәйләүгә, үзең дә сизмәстән, сихеренә буйсынып, башка якка борылып китәсең икән бит... мөгаен, шулай булгандыр. Йә Ходаем, теге чакта тәгәрмәч тишелгәч, ник монда туктыйсы иткәнмен инде? Су күреп, исәңгерәп тордым бит әле. Яр буенда рәхәт чигеп утырдым, кулымны юып мәшәләндем, учларыма су алып чәчрәтеп уйнадым, баеп барган кояш нурларыннан тукылган салават күперен күреп хозурландым, никадәр күңелле иде миңа ул мәлдә. Кызык, кызыл таяклар кая китеп беткәннәр иде микән әлеге мизгелдә? Һәрчак уяу инспекторлар кая китеп югалганнар? Ни өчен бер генә мәртәбә дә йөрәк өшеткеч сызгырту ишетмәдем?»

Ярый, ул чакта ни булгандыр, хәзер кызыл таякларда эшем юк, дәрья да мине кызыксындырмый. Нигә анда урамнарын ябып куймыйлар! Күпме җәфа чиктем! Бөтен тормышым асты өскә килде. Иң мөһиме, өемә кайтып керә алсам һәм кирәк чагында чыгып китәргә җай булса, башкасы кирәкми... Менә шул...

***

Еллар актылар да актылар...

Игътибарны читкә юнәлтмәдем.

Машина чабып тора, кулымда – исемлек, башымда – боларны вакытында башкарып чыгу уе.

Үземнең өемнән ерак түгел, шәһәр уртасында агып яткан елга турында күптән оныттым.

Тик... тик, бервакыт төнлә, барлык кылган догаларым көлгә очтылар...

Колач буе исемлектәге эшләремне эшләп бетергәч, йокларга яткан идем, төш күрдем. Төшемдә... дәрья белән кабат очраштым...

Ә ул боргалана-боргалана мул суларын чак-чак дулкынландырып, иректән истирәхәт чигеп ага да ага...

Ә ул мине көтә икән бит...

Мин дә аны сагынганмын икән!..

Гүзәллеккә соклanудан телсез калып, күңел тибрәнүләренә чара тапмыйча, яр буена йөгердем.

Елгага иелеп йотлыгып татлы суын эчтем. Яр буенда үскән агачларның яфракларына көмеш тамчылар чәчрәтеп уйнадым. Янәдән салават күпере барлыкка килде. Ул шундый төсле-төсле иде!

Һәм бу төсләрдән дөнья нурга төренде!

Һәм дөнья салават күперенә әверелде...

Һәм мин, ирексездән, урынымнан тордым. Торуга, ни өчендер кулларымны күкрәгемә куеп, каяндыр кәгазь бите тартып чыгардым. Кәгазьгә иртәгә эшләргә тиешле эшләр тезеп язылган. Исемлек би-ик озы-ын иде!

Һәм мин, искитмәгән кыяфәт белән, исемлекне елгага агыздым.

Һәм мин үземне богаулардан азат ирекле кош сыман тойдым!

Дөньяны тойдым, Күкнең сулышын татыдым...

Исемлек кайнаган дулкыннар арасында бөтерелә. Алар аны йотмадылар! Кәгазь дулкыннар өстендә тирбәлә, дулкыннар исә, туплы уйнагандай, аның белән уйныйлар, шаяралар, ачыктан-ачык мыскыл итәләр... Гомерем буе җанымны басып, изеп, авыр йөк булып торган шушы исемлек, исемлектәге бетмәс-төкәнмәс эшләр хөр дулкыннар өчен бер уенчыкка әйләнер дип башыма да килеп карамады. Уйлау сәләтеннән мәхрүм идем.

Һәм мин кулларымны янә күкрәгемә куйдым. Кулымда сыбызгы пәйда булды. Уйлап та тормыйча, сыбызгыны да бөтен көчемә дәрьяга томырдым. Аһ, бу мәлдә сез мин тойган рәхәт хисләрнең кечкенә чаткысын татып карый алсагыз иде! Күкрәгемә басып торган авыртулар, әрнүләр, курку-шөбһәләр, күңелсезлекләр шушы каһәр суккан сыбызгы белән бергә агып киттеләр.

Барысы да юкка чыкты!

Кабат куеныма тыгылып, ниндидер таякчыклар тартып чыгардым. Бер караш ташлауга, аларны танып алдым. Әйе, алар!.. Болар мине гомер бакый дәрья буена китермичә, юлыма киртә булып торган кызыл таяклар иде. Тагын бер нәрсәне күрегез! Машина! Әйе, әйе, машина! Җанымны томалаган нәрсә шушы машина икән бит!

Аны да хөр дулкыннар кочагына ыргыттым... Барысын да томырдым! Бер генә нәрсә дә калдырмадым.

Күкрәгемне, җанымны бимазалап торган һәммәсен елгага ташладым.

Алар барысы да дулкын кочагындагы уенчыкка әйләнделәр.

Кабат куеныма тыгылдым, әмма анда бернәрсә дә юк иде инде.

Җиңеллек тойдым.

Каршымда кабатланмас моңы белән җанымны иркәләгән бөек дәрья агып ята иде.

Һәм шушы мизгелдә... уянып киттем...

Уяндым да, үземне белештермәстән, ашыгып кулымны куеныма тыктым...

*Үзбәкчәдән* **Факил САФИН** *тәрҗемәсе.*




*Классик язучы Галимҗан Ибраһимов һәм ТАССР халык мәгарифе комиссары Шәһит Әхмәдиев. 1928 ел.*



*Язучыларыбыз Кукмара районының Зур Сәрдек мәктәбендә. Сулдан уңга: Фоат Галимуллин, Гариф Ахунов, Ләбибә Ихсанова, Шаһидә Максудова. 1998 ел.*



*«Уй да мин...». Драматург, режиссёр, актёр Гафур Каюмов (1959-2018). 2017 ел.*



*Вагонда очрашу. Фатих Хөсни һәм Шәүкәт Галиев. 1976 ел.*



*«Без танышкан ай» (Шамил Шәрифуллин көе) җыры иҗат ителгәч. Уңнан сулга: Равил Фәйзуллин, Бикә Рәхимова (җыр сүзләре авторы) һәм уллары Алмаз. 1982 ел.*

## *Котлыйбыз!* *Шагыйрь Марат Закирга – 50 яшь!*



*«Казан утлары» хезмәткәрләре (сулдан уңга): Алмаз Хәмзин, Мансур Вәлиев, Марат Закир һәм Камил Кәримовның төзелеш-төзәтү эшләре белән мавыккан чагы. Июнь, 2010 ел.*
*Фото Камил Кәримов архивыннан.*

*Сәхифәне* **Равил ФӘЙЗУЛЛИН** *әзерләде.*



Гөлфия
Галиуллина

# ЛОКМАН КАРТ ХИКМӘТЛӘРЕ

хикәя

Нишләптер соңгы араларда бетереште Локман карт. Ярыйсы гына эшләп йөргән җиреннән хәле китә, иңбашы әрни. Ашказаны да үзенекен итә ахрысы. Барган җиреннән тукталып, сулыш алырга мәҗбүр. Гомер буе бер ялсыз эшләсә дә, мондый хәлсезләнгәне юк иде әле аның. Пенсиягә чыккач та эшләвен дәвам итте. Акча кирәктән дә түгел, хәрәкәт итеп яшисе килүдән. Хәрәкәтләнде ул, бәрәкәт икәнен аңлап хәрәкәтләнде. Тормышны дәвам итәсе килүдәндер, бүген дә кар көрәп кайтыйм әле дип чыгып китте.

Кичтән ахшам җитүгә ятып йоклагач, иртә торыла. Вакытны тән үзе тоя. Яктыра башлауга тора да, тәһарәт алып, иртәнге намазын укый. Карчыгы белән иртәнге чәйне эчә дә кар таптала башлаганчы дип чыгып китә.

Ул көрисе кибет алды ерак түгел. Ике урам аша гына. Сызылып кына кояш чыгып килә. Ап-ак кар күзләрне камаштыра. Салкын битне чеметә. Рәхәт! Шыгыр-шыгыр кар шыгырдавына кушылып, сөякләр үзләренең барлыгын сиздерә. Аяк атлавына кушылып, тел дә зекергә кушыла. Эчтән генә тәсбих тартып атлый карт: «Аллаһу әкбәр!!! Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр». Аяклар зекере – хәрәкәт булса, тел зекере – Аллаһны олылау. Бүген исән-сау торганына, чыгып китә алуына мең шөкер итә ул. Йөрәкнең дә үз зекере бар ахрысы, нишләптер үзен сиздереп чәнчеп куя. Карт зекерен арттыра. Тел генә түгел, йөрәкнең дә зекер итәсе килә ахрысы дигән уй аякларны атларга мәҗбүр итә: «Ал-ла-һу!». Ике мәртәбә сулыш алып чыгаргач җиңеләя тагын. Ул юлын дәвам итә, ә йөрәк үзенекен итә! Аллаһның язганыннан узып булмас. Поликлиника дигәннәре ерак түгелен түгел дә. Әллә кереп, йөрәкне тыңлатып чыгасы инде дигән уй килә. Ничек булса да поликлиникага барып җитәргә. Өйдәгеләргә әйтеп, куркытырга кирәкмәс, бәлки йөрәк тә түгелдер әле. Әллә нишләп уртадан, ашказаны тирәсеннән авырта, бер-бер нәрсә ашаганмындыр. Иртәнге ашаган ризыкларын хәтердә барлый карт: сөтле чәй, күмәч, ике күкәй. Кичтән токмачлы тавык шулпасы ашаган иде, йоклар алдыннан сөткә бал кушып эчкән иде инде.

Табибларны өнәп бетермәсә дә, барып тикшеренеп кайтмый булмас. Егылып китүең дә бар. «Паспорт та үзем белән түгел бит әле», – дип сукранып куйды карт.

Бәхетенә каршы, табиб ишеге төбендә кеше күп түгел иде. Алдында торган ике кешегә ничек тә түзәрлек. Икенче каттагы күршесе дә монда

икән. Исәнләшергә дә өлгермәде, кинәт хәле китте Локман картның, күз алды караңгыланды.

Ниндидер ап-ак бүлмәдә, пепеләгән чыбыклар арасында аңына килде ул. Өстендәге ап-ак япманы күргәч, үлгәнмен, кәфенлек ахрысы дигән уй узды. Янында шундый ук япмадан селкенмичә ятучы кешеләрне күргәч тә аңышмады. Өстәл артында ап-ак халаттан утыручы яшь кенә кызның: «Күзләрен ачты», – дигәненнән, «үлмәгәнмен, больница булырга охшаган», дип уйлады.

Барлык көчен җыеп, кайда мин, кызым, дип сорыйсы итте, ләкин теле әйләнмәде, тавышы чыкмады. Картның уйларын укыгандай, ак халатлы кыз: «Борчылма, бабакай, үлеп терелдең инде, реанимациядә син», – дип, янына килде, пульсын тотып карады. «Хәзер врачны чакырам», – дип чыгып китте.

Пепелдәгән чыбыклар арасында яткан дистә минут Локман картның гомер юлын тергезде.

Уникенче бала булып туган ул. Әнисе, «унике туып бер калган», дия торган иде. Туганнары үлеп барган. Бишәү генә калганнар алар: ике апасы, ике абыйсы һәм төпчеге – ул Локман. Апасы Җәүһәриянең дә гомере озын булмады, биш баласын калдырып, яман чирдән үлеп китте. Җитмешнең теге ягына чыккан этисе белән әнисе, апасының биш баласы Локман җилкәсенә калды.

Үзе дә студент. Яхшы билгеләренә генә укый, стипендия акчасына киенә, калганын әти-әнисенә алып кайтып бирә. Кем әйтмешли, ашау байдан… Балалар бакчасына каравылга керде. Садик апалары яратты үзен, ризык калдыралар, тамагы туйганчы ашый: кәбестә ашы, боткалы кәтлит, күмәч белән чәй. Тамак тук. Укыйсы да укыйсы. Анысына мең шөкер.

Апасы үлеп, өч елдан соң җизнәсе дә мәрхүм булды. Биш бала тома ятим калды. Ярый әле, апасы урынына күрше авылның Әкълимә бер баласы белән килеп, шул биш малайны үзенеке янына сыендырды. Олы энесе Камилне абыйсы Вакыйф үзе янына алдырды. Төзелешкә эшкә урнаштырды. Аннан Равил килде. Равил артыннан Әгъзам, төпчеге – Газинур, соңыннан Фәнис тә күченеп килде. Шулай итеп, апасының ятим биш малае – төзүче булды, Казанда урнашты.

Әюп пәйгамбәр гомеренә дә моның хәтле үлем бирелмәгәндер. Алар нәселендә үлем артыгы белән булды. Әлхәмдүлилләһирраббилгаләмин!

Ике абыйсы, бер апасы үлеп, туксан яшенә чыккан апасы Исламия язмышына үлем бигрәк тә күп тиде. Авылда ул яшәгән йортны «үлем йорты» дип атыйлар. Унөч яшендәге малаен каен урманыннан алып кайттылар. Уйнаганда чигәсенә ботак керде. Аннан ире Кыям, пенсиясен дә тотып карамыйча китеп барды. Исламия апа кечкенә кызы – Гүзәлиясен утызын да тутырмаган килеш озатты. Грипптан йөрәге чыдамады. Аның артыннан Казандагы малае Фәрит мунчада үлеп китте, йөрәк өянәге, диделәр. Фәритнең өчесенә Алабугада яшәүче Сәриянең җәсәден алып кайттылар. Машина таптады...

Бер нәселгә бер-бер артлы тигән үлем. Йөрәк кенә түзсен?! Түзә, сабыр итә. Туганлык җепләре әкрен генә өзелгәндә, сабырлыкны җыеп, яшәүне дәвам итәргә кирәк иде. Сабырлык сорады Локман карт.

Вертолёт заводында гомер буе эшләп, кан пешүдән иртә үлеп киткән Вакыйф абыйсы өчен, ирле-хатынлы бер-бер артлы китеп барган абыйсы Исмәгыйль белән җиңгәсе Роза өчен, иллесен дә тутырып бетерә алмаган Равил, Фәнис һәм утызын да тутырмаган Камил өчен дә сабыр итәсе бар әле аның. Үлем турында уйларын кире куды карт. Нәсел язмышын үзгәртергә кирәк, үлемгә башка төрлерәк карарга кирәк дигән уй сызылып үтте. Бердәнбере – авылда яшәп ятучы Исламия туганы Локман үлгән

дигән хәбәрне күтәрә алмас. Телефоннан хәл сорашырга шалтыратсаң да, Локманыммы, дип сорый бит.

«Аллаһның язганы булыр», – дип кабатлады карт. Уйларын янына килеп баскан табибның: «Хәле әйбәтләнгән, палатага күчерерсез», – дигән сүзләре бүлде.

Мизгел эчендә аны палатага күчереп тә куйдылар. Зәңгәр стена, заманча җиһазландырылган ике олы тәрәзәле бүлмә. Алты карават. Һәр караватта йөрәк чирле берәр кеше. Һәр карават башында әллә нинди чыбыклар, розеткалар.

Локман картны караватка салдылар. Күп тә үтмәде, ап-ак халаттан чандыр гына табиб килеп керде. Карт, беләзегенә беркетелгән биркага күрсәтеп: «Бала тугач та буе, авырлыгын язып кигезелә торган бирка мәллә бу?» – дип сорап куйды. Табиб авыз читеннән елмайды да: «Әйе, бабай, яңадан тудың, тәпиләндерәсе генә калды», – дип шаяртты. Табибның көләч йөзеннән, шаян сүзләреннән йөрәгенә җиңел булып китте. Табиб бабайның тагын бер мәртәбә йөрәген тыңлады, нәрсәдер сөйләде, үзе белән алып кергән язуларын күрсәтте. Карт аңладым дигән кыяфәт чыгарып, башын кагып торды. Табибның сүзләреннән, бабай, барысы да яхшыга таба бара, болай булгач яшисең әле, дигәне генә истә калды.

Табиб чыгып китүгә, уйлары белән ялгыз калырмын дигән иде дә, булмады. Тирә-янында үзеннән күпкә яшьрәк ир-атларның ятуын күргәч имәнеп китте. Чир дә яшәрә икән бит! Ярар, минем яшем яшәлгән, ашым ашалган. Болар монда нәрсә эшләп яталар дигән уйдан арынырга өлгермәде, шәфкать туташы кереп, кырыгы да тулмаган егеткә, операциягә әзерләнегез, дип чыгып та китте.

Караватташының күзләре белән очрашты карт. Кырык яше дә тулып җитмәгән егет сакалы агарган, тәсбих тартып ятучы картка ниндидер өмет күзләре белән карый. Егет үлем белән очрашырга әзерләнә, нәрсәдер сорамакчы була иде.

– Бабай, теге ни, кире палатага кайтып булмаса, минем өчен дә бу әйберне санарсың әле, ымы! – диде, картның тәсбихенә күрсәтеп. Карт тәсбихен кулына кигезеп куйды да, әз генә урыныннан кузгалып, егеткә якынрак килде.

– И-и-и-и, пәйгамбәребез Мөхәммәд салаллаһу галәйһи вәссәламнең дә, күкрәген ачып, йөрәгендәге кара тапысын фәрештәләр чистартып, кире тыгып куйганнар. Пәйгамбәр яшенә җиткәнсең, улым, бу дөньядан алтмыш ике яшенә җитеп ахирәткә күчкән пәйгамбәребез, – диде Локман карт.

Локман карт үзе пәйгамбәр яшен узган иде. Йөрәгендәге кара канын чистартырга туры килмәде аңа. Чираттагы операциягә дип сөйләшүгә килгән табибның: «Бабай, йөрәгеңне яңартабызмы?» – диюенә, «олан, шунысы белән җиде дистә ел яшәдем, гомер белән узышып булмас, яшәлгән хәтле яшәлмәс, Аллаһ биргәнен шул йөрәк белән яшәп бетерим инде», – диде. Шул минутта яшь табиб: «Килешәм, бабай, килешәм, үз йөрәгең үзеңнеке инде ул, гомер буе шатлыгын да, хәсрәтен дә кичергән, калган гомереңдәге кичерешләреңне дә сыйдыра әле бу йөрәк», – диде. Карт эченнән генә, гомер юлын кабат искә төшерде дә: «Аллага шөкер!» – дип кабатлады. Бу минутта, ул үзенең гомеренә йомгак ясап, Аллаһның биргәненә, сабыр итеп яшәүнең тагын бер мәртәбә кирәклеген аңлап, кулларын күкрәк турысына күтәрде. «Йә Аллам, биргәнеңә мең шөкер, биргән авыруыңа мең шөкер, боларны аңлар өчен шул авыру кирәк булган бит», – дип шөкрана кылды. Шөкер яшьләре, йөзе буйлап аска тәгәрәде, күкрәгенә тамды...

Шул рәвешле, Локман карт, йөрәк тикшертергә килгән җиреннән, яшәү серен, яшәү мәгънәсен, авыруның бирелү хикмәтен аңлап кайтып китте.

# АРТИСТ ЯЗМАЛАРЫ

## Лилипут

Минем белән еш кына кызык хәлләр булгалавы турында язган идем инде. Шундыйларның тагын берсе исемә төште. Мәскәүдә, Щепкин исемендәге театр училищесының беренче курсында укыган чагымда, бик кызык бер хәл булды. Безнең уку йортыбыз ике катлы бинада урнашкан. Беренче катында ниндидер оешмалар эшләгәне истә калган. Беркөнне мин иртән иртүк, дәрескә хәзерләнергә кирәк дип, чыгып киттем. Училище ишек төбендә безне өлкән яшьтәге маржа апа каршы ала, чит кешеләрне кертми, без беренче катта чишенәбез. Мин чишендем дә, икенче катка менә генә башлаган идем, сарык бәрәне кебек аптырап, катып калдым. Бер бәләкәй генә бала авызына папирос капкан да, рәхәтләнеп тартып, әрле-бирле йөри. Мин моңа баскычтан кычкырам:

– Ты что делаешь? А ну-ка брось! Не кури здесь! А то я тебя проучу!

Бу миңа борылды да, теш арасыннан гына:

– Что смотришь? Пошёл вон отсюда! – диде.

Мин акрын гына баскычтан төшәм: «Ты ещё на меня?» – дип, өстенә килә башлаган идем, бу миңа күтәрелеп карады – күзләре ачудан ут кебек яна: «Иди-иди подальше от греха!» – ди.

Мин нәрсә әйтергә дә белмичә, кызарып, бүртенеп чыктым. Якынрак килеп карасам – өлкән яшьтәге бер абый, минем каршымда басып тора. Шунда, безне чишендерүче маржа апа килде дә мине култыклап алып китте. «Лилипут бит ул, синнән ике-өч тапкыр өлкәнрәк, бар, гафу үтен», ди. Кайда монда гафу үтенү, оятымнан тиз генә икенче катка менеп киттем. Менә шулай итеп мин, үз гомеремдә беренче мәртәбә, лилипутны күрдем. Бу хәлне беркемгә дә сөйләмәм дигән идем. Кая, сөйләмичә ничек түзәсең!

Берсендә Сарман районында спектакль уйныйбыз... Тагын лилипутлар белән очрашырга туры килде. Мәктәп тулай торагында бергә яшәдек. Алар да гастрольгә чыкканнар икән, безнең артистлар болар белән бик кызыксына башладылар. Равил Шәрәфиев хәтта бер хатын-кызны курчак урынына күтәреп тә йөрде, чөнки ул шулхәтле матур, зур күзле, озын сары чәчле, нәкъ менә матур курчак инде. Равил миңа аларның бүлмәләрен дә күрсәтте әле, бер тимер караватта алты кеше йоклыйлар икән. Минем, нишләптер, алар янына барасым килмәде, чөнки теге лилипут абый миңа онытылмас сабак биргән, күрәсең. Менә хәзер генә аңлыйм тормышта аларның нәрсә кичергәнен, Ходай Тәгалә мондый хәлне беркемгә дә күрсәтмәсен. Шундый акыллы, тәртипле, сәләтле кешеләр сәхнәдә чыгыш ясап, үзләренең беркемнән дә ким түгеллекләрен исбат итәләр. Кеше буларак, минем өчен иң кадерлесе менә шул! Табигать тарафыннан шундый авыр хәлдә калганнарның, тормышта бөтен авырлыкларга түзеп, кеше төсле яшәүләре миндә аларга карата бик зур хөрмәт, горурлану хисләре уята.

## Миңсылу

Мин бу турыда язарга күптәннән җыенып йөри идем, менә бүген, иртәгә язам, дип, гомер дә узып китте. Ахыр чиктә түзмәдем, кулыма каләм алдым.

Мәскәүдән Щепкин исемендәге театр училищесының беренче курсын тәмамлап кайткач, әнкәй: «Балакаем, безгә Миңсылу килеп йөри, кайчагында су да алып кайта. Шуңа күрә син, Буранлыга барып, аның өчен оек белән исле сабын алып кайтчы. Үз исемеңнән рәхмәт әйтеп бирерсең, кыз бала бит, күңеле булыр», – дип, йон саткан акчасын миңа сузды. Миңсылу... Мин андый кыз баланы искә төшерә алмыйм, әнкәйгә ярдәм итә торган игелекле бала кем икән, дип аптырадым.

Буранлы авылы безгә өч-дүрт чакрым гына. Магазинга кердем:

– Кызлар, миңа бер матур оек бирегез әле, – дим.

– Ничә яшьтә соң ул? – диләр.

– Яшен белмим, үзен әле күргәнем юк, әнигә су китерергә ярдәм итә.

– Мәскәүдән алып кайтырга кирәк иде, бездә андый матур оеклар юк. Шулай да менә бу матуррак, менә монысын ал, – дип, гәҗиткә төреп, нәрсәдер бирделәр.

– Хәзер инде миңа бер исле сабын да кирәк.

– Әйберләрне алып кайткач, бу бүләкләрне үзең бир инде, синнән алса, күңеле булыр, – диде әнкәй.

Миңсылуның килгәнен көтә башладык. Гадәттә, ул төшке аш вакытында килә икән. Ләкин көндез дә килмәде, кич тә юк Миңсылу! Икенче көнне әнкәй, күрше Нурлыхәзә түти кызын җибәреп, Миңсылуның хәлен белергә кушкан иде. Нәрсә булды икән, әллә авырыймы? Күрше кызына: «Мин анда бармыйм, ерактан бер абый кайткан, мин аннан оялам», – дип әйтергә кушкан Миңсылу.

Ике көн узгач, көндезге аш вакытында, Миңсылу килде. Аны күргәч, аптырап калдым. Минем андый кыз баланы күргәнем юк иде. Йөзе әллә ничегрәк, руслар андый балаларны «солнечный», диләр. Тәбәнәк кенә буйлы, ябык гәүдәле, өстендә кояш нурында төсе уңа башлаган күлмәк, аягында сандали сыманрак әйбер, табак битле, пилмәнгә охшаган борын, нишләптер зур авызлы булып тоелды. Чыннан да, йөзе нәрсәсе беләндер кояшны хәтерләтә, чөнки гел елмаеп торган шикелле. Кыяфәтенә караганда, ундүрт-унбиш яшьләр чамасы кебек, бәлки, олырак та булгандыр, аларның яшен белеп булмый бит.

– Миңсылу, мин сиңа әйткән идем, Әзһәр абыең Мәскәүдән кайта, дип, әнә, бүләкләр алып кайткан.

– Миңсылу, әнигә ярдәм иткән өчен сиңа зур рәхмәт, менә, ал, оек белән исле сабын.

Бер сүз дә әйтмәде, «һе-һе» дигән тавыш кына ишетелде.

– Миңсылу, хәзер инде мин кайттым, әнигә суны үзем ташыйм, син безгә килеп йөрмә инде, яме.

Бу миңа бераз карап торды да әйберләрне алып кайтып китте. Әнкәй мине тиргәргә тотынды:

– Балакаем, нигә инде, хәзер ул бөтенләй килмәс, авыру балага алай дип әйтергә ярамый, гөнаһ була, – диде.

Мин сораштыра башладым:

– Аның эти-әнисе бармы соң?

– Әй балакаем, Миңсылуны белмәгәч, син авылны бөтенләй оныткансың, ахры. Әллә юри кыланасыңмы? Шәмси абыеңнар очындагы бәләкәй генә йортны белмәскә. Эти-әниләре исәннәр, Аллага шөкер, алар җибәрмәсә, ул безгә килеп йөрмәс иде. Мин бит аны су алып кайтсын өченгә түгел, әнә шундый булганына күрә ашатып, эчертеп чыгарам. Хәзер инде ул безгә бикияләште. Зинһар өчен, аның белән ипле сөйләш, җаена гына тор.

Күрәсең, әни үзе дә гарип булгач, кыз балага үзенчә ярдәм итәргә уйлагандыр. Мин инде язган идем: әнинең, колхоз фермасын төзегәндә, таш күтәреп, эче төшә, шуннан бөкрәеп кала, җитмәсә, бер кулы сынык, кәкрәйгән, күзеннән яшь агып тора. Моны ни өчен искә төшердең, дип сорасагыз, шуны гына әйтә алам: Миңсылуның бәхетсезлеген әнкәй шуңа күрә бөтен күңеле, җаны белән кабул иткәндер.

Беркөнне Шәмси абыйларга бара идем, юлда Миңсылу очрады.

– Миңсылу, әни сине бик сагына, нишләп килми икән, ди. Улым кайткач, күп итеп тәмле ризыклар пешердем, бергә чәй эчәр идек, күрсәң әйт, килсен, ди. Миңсылу, мин бит сиңа суны үзем ташыйм дип ялгыш әйткәнмен, иртәгә Буранлыга барам, син инде әнине ташлама, ул сине көтә.

Миңсылу миңа бик озак карап торды, кыяфәтем авыл егетләренекенә охшамагангадыр...

Хәзер инде ул һәркөнне көндез әнигә су китерә. Су китерә дигәннән, чиләк тутырып ташымый инде, төбенә генә салып кайта. Ләкин ике мәртәбә бара, әни шулай кушкан. Мин өйдә булсам, безнең белән бергәләп өстәл янына килеп утырмый, мин ашагач кына өйгә керә. Беркөнне бәләкәй арба тартып, межага печән чабарга бардым. Шулхәтле

авыр чабыла, көчкә арбаны тутырдым, кайтырга гына чыккан идем, җиләклеккә очрадым. Җыяр идем, савыт юк. Тукта әле, мин әйтәм, әни белән этигә чеме белән җыям, күңелләре булыр, дим.

– Әнкәй, кара әле нинди матур җиләкләр, шулкадәр күп очрады, сабагы белән җыйдым.

Шулвакыт Миңсылу судан кайтып керде. Әнкәй мин җыйган җиләкнең бер өлешен аңа да бирде.

Миңсылу җиләкне алды да чыгып китте, кире өйгә кермәде. Күрәм, бу кыз миннән гел ояла, мине күргәч, әллә нишли башлый.

– Әнкәй, әллә ул үзенең гариплегеннән ояламы? – дим.

– Юк, улым, ул үзен авыру дип уйламыйдыр. Бары ирләрдән генә ояла. Әнә бит, этиең белән дә исәнләшми, югыйсә күпме әйттем, исәнләш, дип.

Көн артыннан көн уза, мин дә Миңсылуга ияләштем. Ул килгәнче, чишмәдән ике көянтә су алып кайтам, калган савытны ул тутыра. Беркөнне шулай, моның чишмәдән су алып кайтканын көтеп тордым да читән артыннан әкрен генә «Зөләйха» көен җырлый башладым.

*Ай югары, ай югары,*
*Ай югары салкынга.*
*Агач булсам янар идем,*
*Эчем тулы ялкынга.*

Үзем җырлыйм, үзем күзәтәм, бу җырны ул ничек кабул итәр икән дип уйлыйм. Миңсылу, кем җырлый икән, дип, як-ягына карана башлады. Минем якка борылгач, аска чүгәләдем, беркем дә сизәрлек түгел. Күрәм, Миңсылуның йөзе үзгәрде, читән янына килә башлады. Мин кинәт торып баскан идем: «Кит, җүләр, кит, җүләр», – диде дә әни янына кереп китте. Күрәсең, җыр шулкадәр тәэсир иткән, йөзе бөтенләй үзгәргән иде. Әллә, мин әйтәм, моның күзе миңа төште микән, дим, эчтән генә көләргә тотындым. Авылда малайлар Миңсылуны: «Киявең кайткан, киявең кайткан», – дип үрти башлаганнар. Үзләренә бер кызык тапканнар, күрәсең. Гомумән, авыл кешесе юктан кызык эзләргә ярата бит ул.

Шулай бервакыт күрше Миңлегали абый безгә керде. Миңсылуны үртәргә тотынды:

– Әнә, Әзһәр абыең Мәскәүгә китә, сине дә үзе белән алып китә икән. Син Мәскәүгә барасыңмы соң? Син бармасаң, Әзһәр абыең Мәскәүдә нишләр, ул сине сагынып елар инде, – ди.

Кинәт Миңсылу, битен каплап: «Кит, җүләр, кит, җүләр! Эһе-эһе», – дип, урамга чыгып йөгерде. Миңлегали абый рәхәтләнеп көлә, үзе миңа карап:

– Хәзер ул сиңа ияләшеп беткән, син киткәч, нишләргә белмәс инде, бичара, алар бит шундый халык, – дип куйды.

Чыннан да, Мәскәүгә китәсе көнне Миңсылу иртә таңнан безгә килеп җиткән, нишләптер кыяфәте бик нык үзгәргән, әллә йокламаган, әллә авырып киткән. Һәрхәлдә, мин күнеккән кыз бала түгел, көләч йөзе сулып калган.

«Ярый, Миңсылу, мин китәм, син инде кирәк чакта әнкәйгә ярдәм ит. Бөтенләйгә китмим, киләсе елга тагын күрешербез», – дип әйтүем булды, ул: «Кит, җүләр, мин синең белән бармыйм, бармыйм», – дип, елый-елый урамга чыгып йөгерде.

Әллә ул, чыннан да, Мәскәүгә барырга җыенган булды микән, аңламадым. Менә хәзер язарга утыргач та, андый авырулар безнең кебек ярата беләләр микәнни, дип аптырап торам. Әниләргә хат язганда: «Миңсылу нишләп йөри, безгә киләме? Минем турыда сорыймы? Аңа бик күп сәлам әйтегез. Барысы турында да әйтеп языгыз», – дидем.

«Миңсылу турында шуны әйтергә тиешбез: аны Чистайга алып киттеләр, үзе кебек авыру балалар янына. Бер дә китәсе килмәде. Әтисе белән әнисенә, анда иптәшләре белән бергә булачак, аны караячаклар, ул яхшы якка үзгәрәчәк, сез монда аңа кирәкле тәрбияне бирмисез, шуңа күрә безгә рәхмәт әйтегез, дип алып киттеләр. Әниең Минҗиһан түти бик елады, барыбыз өчен дә күңелсез булды», – дигән хат алдым.

Хатны күрше Сабира апа язган, әнинең хат язарлык белеме юк иде.

Мин, икенче курсны тәмамлап, авылга кайткач, әнкәйдән Миңсылу турында сораштыра башладым:

– Әй улым, сорама инде. Кыш көне Чистайдан авылга кайтам дип юлга чыккан булган да буранда адашып үлгән, дип сөйләделәр. Дөресе ничек булгандыр, без белмибез, бары тик кеше сөйләгәнне генә әйтәм. Зинһар, кешегә әйтмә инде, күңелле хәбәр түгел, – дип еларга тотынды. – Бик кызгана идем мескенкәйне, хараплар гына булды, нишлисең, язмышы шулай булгандыр. Тәкъдирдән узмыш юк...

– Әнкәй, елама, үлгән артыннан үлеп булмый. Мондый хәлдә яшәгәнче, аның үлүе яхшырак та булгандыр әле.

– Әй улым, син әле яшь шул. Аңламыйсың. Вакыты җиткәч аңларсың, ләкин соң булыр.

Вакыты җиткәч аңларсың, дип әнкәй дөрес әйткән. Менә тагын Миңсылу искә килеп төште. Бу, чыннан да, бәхетсезлек, Ходай Тәгалә беркемгә күрсәтмәсен. Нигә миңа бәхетсез кешеләр шулкадәр тәэсир итәләр икән?!

## Мәскәү күмәче

Мин инде Мәскәүгә укырга баруыбыз турында язган идем.

Казан тимер юл вокзалыннан утырып киттек. Икенче көнне, иртән, радиодан: «Поезд приближается к столице нашей родины...» дигән тавышка уянып киттем. Бу хәбәрдән барыбыз да бик нык дулкынландык, Мәскәү бит ул! Җитмәсә, Советлар Союзы гимны яңгырый башлады, барыбыз да торып бастык, бер-беребезгә карамыйбыз, күзгә яшь килде, ахрысы, миңа шулкадәр көчле тәэсир иткәне әле хәзер дә истә.

Поезд килеп туктагач, ниндидер марҗа апалар: «Вы не видели, где здесь татары?» – дип йөренә башладылар. Мин аңламыйм, бездән башка тагын нинди татарлар бар икән монда, дип, як-ягыма карыйм. Шунда арабыздан кемдер: «Это же мы татары, мы здесь», – дип кычкырган иде, барыбыз да аңа кушылдык. Эзләүчеләр безнең укытучыларыбыз икән. Гомерләрендә татар күргәннәре юк, ахры. Безне, китапларда язганча, бик кыргый, куркыныч, урыска охшамаган «дикий» халык дип уйлаганнар, күрәсең. Урыслардан бернинди дә аермабыз юк икәнен күргәч, оятларыннан бурлат кебек кызардылар. Безгә дә бераз уңайсыз булып китте. Безне Рига вокзалы янында немец әсирләреннән калган ике катлы иске баракларга урнаштырдылар. Менә сиңа Мәскәү!

Яшьлек елларымны искә төшергәндә, минем белән төрле хәлләр булды, дип язган идем. Берни эшләр хәл юк, холкыма күрә шулайдыр, күрәсең. Күз алдына китерегез, егерме өйле авылдан, 16 яшьлек малай, Мәскәүгә Щепкин исемендәге театр училищесына укырга китә... Бервакыт шулай, Равил Шәрәфиев белән бергә, беренче мәртәбә дәрескә барабыз. Мин, гомеремдә дә күрмәгән биек, матур йортларга карап: «Күр әле, Равил, нинди матур йортлар, капкасы да капкасы – бу хәтле матур йортлар да булыр икән», – дип, карый-карый бара торгач, маңгаем белән нәрсәгәдер шундый итеп бәрелдем ки – күземнән утлар күренде, борыннан шарлап кан китте. Җирдә ятам. Ул арада тирә-юньгә халык җыелган. «Смотрите, он весь в крови! Скажите, что случилось?» – дип өзгәләнәләр.

Гомеремдә мондый матур йортларны күргәнем юк иде, шуларны карый-карый бара торгач, башым белән агачка бәрелдем, дип әйтә алмыйм бит инде. Ялгыш аягым таеп китте дә сөрлегеп егылдым, дидем. Равил дә русчалатып шулай аңлатты. Көч-хәл белән аякка бастым, күлмәк-чалбарга бераз кан чәчрәгән, йөзем шешеп киткәндәй булды, баш әйләнә. Мәскәү урамнары белән танышуым шулай башланды. Җитмәсә, минем аркада беренче көнне үк дәрескә соңга калдык. Курсыбызның старостасы Хәмбәл абый Закиров: «Тагы бер мәртәбә соңга калсагыз, училищедан кудыртам!» – дип котыбызны алды.

Укулар башланды. Без бит авылдан килдек, беребезнең дә ашарга кашыгы да юк. Нишләргә белмибез, сатып аласы килми. Мин ашханәгә кергәч, почмакта шундый матур калаклар, чәнечкеләр өелеп торганын күрдем. Шунда ике калакны яшереп кенә кесәгә тыктым, ашап бетергәч, тагын өчне алдым да, беркем дә күрмәсен, дип, тиз генә чыгып киттем. Тулай торакка кайткач, егетләрне сөендерим әле дип, кашыкларны өстәлгә тезеп куйдым: «Карагыз, янәсе, мин сезгә нәрсә алып кайттым. Бишебезгә биш калак! Калак юк, дип зарланган идегез. Миннән булсын яхшылык!» Барысы да өстәл янына җыелдылар. Безнең арада иң өлкәне – курсыбызның старостасы Хәмбәл абый

Закиров, ул миннән тугыз яшькә зуррак. Консерваториянең өченче курсын ташлап килгән, тормышның нәрсә икәнен белә. Бик озак кына миңа карап торды да:

Хәзер үк, каян алдың, шунда илтеп куй, юкса мин сине училищедан кудыртам! – ди. – Татар студиясе студентлары кашык урлаган икән дигән сүз чыкса, беләсеңме нәрсә булачак?!

Мин, нәрсә әйтергә дә белмичә, аптырап катып калдым. Хәмбәл абый мине сүгә дә сүгә, ахыр чиктә түзмәдем, елый башладым. Ярар, ярар, минәйтәм, хәзер кире илтәм. Мин бит аны сезгә яхшылык эшлим дип алып кайткан идем, дим. Елый-елый, калакларымны бер гәҗиткә төрдем дә кире ашханәгә чыгып киттем. Юл буе үземне сүгәм, нишләп мин шундый аңгыра, бәхетсез кеше булдым икән, эшләгәнче башта уйларга кирәк иде.

Килеп кердем столовыйга, хәзер калакларны урлаган урынына ничек куярга белмим, бар кеше дә миңа карап торадыр сыман тоелды, шундый куркамын, бөтен тәнем калтырый. Нишләргә белми бик озак азаплангач, түзмәдем, столовыйның чүп чиләгенә салдым да, беркемгә дә карамыйча, тиз генә чыгып киттем.

Шушы вакыйгадан соң, урлаган әйберемне беркемгә дә күрсәтмәм, дип ант иттем. Чыннан да, Хәмбәл абый Закиров миңа гомергә онытылмас сабак бирде. Көн артыннан көн үтә, акрын гына Мәскәү тормышына ияләшеп киләбез. Безнең театр училищесыннан ерак түгел урында матур гына кафе бар иде. Беркөнне түзмәдем, кереп карыйм әле, монда ашарга кыйммәт микән, кешеләр нәрсә ашыйлар икән, дим. Килеп кердем, өстәлдә киселгән ап-ак күмәчләр, икмәкләр, кешеләр әллә ни күп түгел, килеп утыралар да тәмле итеп рәхәтләнеп ашыйлар. Мин, тиз генә училищега кайтып, Равилне эзләп таптым. Мин шундый урын таптым, туйганчы ашап чыгарга була, дим.

Равил белән чиратка бастык, бездән: «Молодые люди, вы что будете кушать?» – дип сорыйлар. «Да, мы только чай будем пить», – дибез. Икешәр стакан чәй алдык та өстәл артына килеп утырдык. Сизми дә калганбыз, өстәлдә өелеп торган тәмле йомшак күмәчләр, икмәкләр бик тиз арада юкка чыкты. Рәхәтләнеп, туйганчы ашадык, чәй эчтек, шулхәтле рәхәт булды, дөнья рәхәт, дөнья киң. Равил, минәйтәм, иртәгә тагы керербез, яме, син инде, зинһар, моны беркемгә дә әйтмә, икәү генә белик, дим. Икенче көнне нәкъ шул хәл кабатланды, тик бу юлы ике стакан чәй урынына берне генә алдык, акча әрәм итмәдек. Шунда мин бер әйбергә игътибар иттем, күмәч, ипи кисеп торучы апа безгә әллә ничек, күзләрен акайтып карый. Күз алдына китерегез, өч тиенгә чәй алып, туйганчы икмәк ашап, хәерче студентлар ничек кыланалар, шаккатарсың, әйтерсең лә өч сум түләп, өстәл тутырып ризык алганнар.

Өченче көнне кафега керүебез булды, теге маржа апа: «Уходите, уходите, больше сюда не ходите», – дип, безне куып чыгарырга тотынды. Кафедагы бөтен халык, нәрсә булды икән, дип безгә карый. Мин: «Вы не имеете право», – дия башлаган идем, Равил мине тизрәк алып чыгып китте. Урамга чыккач кына аңладым, безне бит куып чыгардылар, хур булдык бит, хур булдык. Әгәр хәзер иптәшләребез күреп торса, рәхәтләнеп, хахылдап көләрләр иде... Югыйсә, теге маржа апа безнең ач студент икәнебезне әллә каян күреп тора инде. Берәү булса, кызганып, үзе ашатыр иде, өстәлдәге икмәк бушка бит. Нишлисең, маржа апа шул. Яшьлек елларымны искә төшергәндә, күпме хата киткән, күпме җәфа күрелгән, әгәр мондый хәлләр булмаса, мин бөтенләй икенче кеше булыр идем дип уйлап куям.

## Үлемнән калу

1962 елның 17 декабрендә «Без аерылышмабыз» спектаклендә башкорт егете Котлыбай ролен уйнап кайтып киләм. Күңел күтәренке, тамашачы спектакльне яратып кабул итте, чын башкорт егетен уйныйм бит, гадел, көчле, кешене рәнҗетмәс – бер сүз белән әйткәндә, уңай герой. Трамвайдан төшеп, үзебезнең тулай торакка кайтырга чыккач, «Клуб» (исеме онытылды) яныннан узып барганда: «Помогите! Помогите!» – дип кычкырган хатын-кыз тавышы ишетелде. Мин тиз генә ярдәм итәргә ашыктым. Килсәм, кечкенә буйлы, ябык кына бер егет кыз баланы чишендереп маташа. Аптырап киттем. Кыш көне, нишләргә уйлагандыр, аңламыйм.

– Ты что делаешь, отпусти её! – дип әйтүем булды, бу йөзгә шундый итеп китереп

сукты, күземнән утлар күренде. – Ах ты, сука! Ты на меня! – дип, муеныннан эләктереп алдым да рәшәткәле коймага китереп бәрдем. Ул елап кычкырырга тотынды:

– Ребята, помогите, меня убивают! – ди.

Шулвакыт клубтан бертөркем яшьләр чыкты да мине кыйнарга тотынды.

– За что, это он на меня! Я же помогал девушке! – дип кычкырам.

Баштан бүрекне салдырып алдылар, шарф белән буа башладылар. Көчкә шарфны ычкындырдым. Ничек кенә булса да болардан качарга чамалыйм, аягым таеп китте, егылдым, мине типкәли башладылар, ярый әле кыш көне, билдән кар. Җәй көне булса, беткән идем. Әгәр өч-дүрт кеше булса, бетерәләр иде, монда бер көтү кеше бер-берсенә комачаулыйлар, барсының да кыйныйсы килә. Белмим, ничек араларыннан ычкынганмындыр, шул кар аркасында инде. Чабам да чабам. Арттан киләләр иде, туктадылар.Тимер юлга килеп чыктым. Хәзер юл буйлап Ватутин урамына, үзебезнең тулай торакка кайттым. Өйгә кердем дә, пычак алып, кире клубка киттем. Кыйнаган егетләрнең бер-икесен чәнчим, дим. Шулкадәр үч, ачу, кимсенү көчле иде, үзем белән нәрсә буласын уйламадым да. Клуб баскычына бала-чага, хатын-кыз җыйналган. Әкрен генә баскычтан менә башладым. Яланбаш, пәлтәнең якасы умырылып төшкән, борыннан кан ага, йөземне, кыяфәтемне әйтеп тә тормыйм инде.

– Это вас чуть не убили, вы живой? – дип сорый башладылар.

– Сейчас всех в милицию забрали. Они уже там.

Мин нишләргә белми бераз басып тордым да әкертен генә өйгә шылдым. Керү белән караваткка аудым. Иртән торсам, бер күз бөтенләй күрми, көзгегә карасам – куркып киттем, бит кара янган, сыдырылып беткән, эч авырта, косасы килә, укшыта.

Түзмәдем, поликлиникага киттем. Врачның: «Зачем вас избили?» – дигән соравына ничек булган, барысын да сөйләп бирдем. Ул дару бирде дә хәзер үк милиция участогына барырга кушты. «Баш мие селкенгән, бөере кузгалган», – дип, справка да тоттырды. Милиция участогында мине көтеп торалар иде инде. Артист икәнемне белгәннәр. Ике көннән тагын килергә куштылар.

Мине кыйнаган егетләрне кулга алганнар.

Җәйге кара макентошымны, Миргалим Харисовның иске бүреген киеп, тагын милиция участогына киттем. Капитан Михайлов дигәне теге кыз белән егетне минем янга алып керде. Сергей исемле икән: «Мин бит аны куркытырга гына теләдем, без бит ул кыз белән йөрешәбез. Сиңа бүрек тә, шарф та, пальто да, перчатка да алып бирәбез, без гаепле, гафу ит», – ди. Кызы да: «Без өйләнешергә сүз биреште к, зинһар, безне харап итмәгез», – дип елый башлады.

Татар бит мин, кызгандым, гаризамны кире алырга булдым. Тегеләр чыгып киткәч, капитан Михайлов: «Зря Вы их простили, эти бандиты нас замучили. Надо было всех посадить. Они же её заставили так говорить. Она его первый раз видела!» – диде. Шуннан капитан минем белән булган хәлнең дөресен сөйләп бирде. Халык мине кыйнаганнарын җыйналып карап торган, тегеләрнең кем, нинди кансыз затлар икәнен белгәннәр, шуңа күрә ярдәм итәргә дә курыкканнар. Бөтен клубны үз кулларында тоталар икән. Берәрсе каршы килсә, шундук кыйнап ташлыйлар, ди. Мин – алар өстеннән милициягә гариза язган беренче кеше икән, әле моңарчы беркемнең дә гариза язганы юк иде, ди.

Менә хәзер, сиксән яшькә җитеп килгәндә, уйлап куям, Ходай Тәгалә ничек мине саклап калган. Үлсәм үләм, аларның бер-икесен үтерәм дип уйладым бит шул чакта. Әйе, җаным өзгәләнгән иде.

Яшь организм бит, атна-ун көн эчендә әкрен генә кеше кыяфәтенә кердем. Бу миңа сабак булды дип уйлыйсызмы? Юк! Бернигә карамыйча, барыбер кешеләргә ярдәм итәргә ашкынам. Тумыштан шундый инде мин, ышанмасагыз, мине белгәннәрдән сорагыз.

*P.S.* Ике ел узгач, әнә шул, мине кыйнаган төркем кеше үтерде. Теге вакытта аларны төрмәгә утыртмаганыма үкенәм. Минем тарафтан бик зур хата монысы.

**Әзһәр ШАКИРОВ,**
*РФнең һәм ТРның халык артисты*

# ӨЧ КИТАПТА – ӨЧ ХИКМӘТ

## ТӘЛГАТ ГАЛИУЛЛИН ИҖАТЫНА БЕР КАРАШ

Үтеп киткән 2018 елда китап киштәләрендә затлы тышлыкларына Тәлгат Галиуллин тәхәллүсе куелган, төрле әдәби-мәдәни жанрларга караган өч җыентык пәйда булды: «Китек көзге», «Мы – потомки страны Тартария», (Татарская поэзия XX – начала XXI вв. как единый философско-эстетический процесс) һәм «Бәетләр – язмыш көзгесе». Әдәбиятыбызның, милли мәдәниятебезнең төрле юнәлешләрен колачлаган мәҗмугаларның исемнәре үк «сатып торганча», алар берсен-берсе кабатламыйлар: «Китек көзге» дип аталганына прозаикның төрле елларда язылган, күбесе таныш, дөрес, беришесенең әле «карасы да кипмәгән» алты бәяны, утызга якын хикәясе урнаштырылса, икенчесендә галимнең күп еллык эзләнүләр нәтиҗәсе – XX-XXI гасыр татар шигъриятенең үсеш баскычлары фәлсәфи-сәнгати үзенчәлекләре турында уйланулары урын алса, өченчесе, кем әйтмешли, бөтенләй башка операдан – анысы халык иҗатының үзенчәлекле төре – бәетләргә багышланган. Язучы-галимнең олуг юбилеена нисбәтән Татарстан китап нәшриятында һәм Фәннәр академиясендә (бәетләргә багышланганы) басылып чыккан әлеге мәҗмугаларны шәрехләүгә керешкәнче, Тәлгат абый Галиуллинның тормыш һәм иҗат юлына кыскача гына булса да күз ташлау лаземдер дип саныйм.

Татарстанның Норлат вилаятенең Кычытканлы дигән сәер, әмма яшәешкә якын исемле авылда туып-үскән егет, урта мәктәпне тәмамлагач, бер ел Свердлау өлкәсендә алюминий кайната, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә югары белем алгач, шул уку йортында татар телен укыта. Әдәбиятка, халык иҗатына күңел тартуы аны Тел, әдәбият һәм тарих институтының фольклор секторына алып килә. Халык иҗаты белән поэзия арасындагы үзара керешүне, экиятләр, бәетләр, йола җырларын өйрәнүдән тәм тапкан егетне, гаиләле булып, уллары тугач, кеше почмагында яшәү, фатирсызлык дуамалрак юлга этәрә (янәсе, кем инде үз теләге белән Казанны ташлап китә). Үзе «Замана балалары» китабында язганча, бар мөлкәтен берничә ак сәрпинкә капчыкка (аларның да күбесе китаплар) төяп, «олы көпчәкләре белән суны шап-шап кыйнап баручы» иске пароходка утырып, билгесезлеккә, Алабуга якларына юл ала.

Белемле, яшь, тырыш егет анда да ким-хур булмый, педагогия институтында мөмкин булган бөтен баскычларны үтә: урыс әдәбияты укытучысы, декан урынбасары, кафедра мөдире, проректор, 1971-1986 елларда ректор вазифаларын башкара, Алабугадан берничә факультетны күчереп, хәзерге Чаллы педагогия университетына нигез сала. Шул вакыт аралыгында Т.Галиуллин үткен телле тәнкыйтьче, әдәбият белеме галиме буларак танылa, әүвәл фәннәр кандидаты дәрәҗәсен ала, егерменче-утызынчы еллар татар шигъриятенең иҗат методы дигән темага Казакъстан Фәннәр академиясендә докторлык диссертациясен яклый.

Җитлеккән әдәбият галиме, тәнкыйтьче, педагог Т.Галиуллин 1986 елда Казанга әйләнеп кайта. Мәскәү акчасын бирсә дә, фатир мәсьәләсе тиз генә хәл ителми. Тулай торакта яшәп, педагогия институтында укытып йөргәндә, үткән тормыш юлы, күргән-белгәннәре турында оныклары өчен генә булса да, һәммәсен түкми-чәчми, М.Булгаковның «кулъязмалар янмый» гыйбарәсен истә тотып булса кирәк, кәгазьгә теркәп калдыру нияте, күңелен ихластан бушату теләге туа. Шул рәвешле, чорыбызга шактый кыю бәя биргән, публицистика белән сәнгатьлелек арасында тәңгәллек тапкан «Замана балалары» исемле хакыйкый бәян туа. Шуның артыннан югары мәктәп студентлары, укытучылары, авылдашлары тормышына багышланган, күбесе юмористик

рухтагы хикәяләре дөнья күрә. Язучылык «кәсебенә» керешкәндә, Т.Галиуллинга 48 яшь була. Ул укучы күңеленә XX гасырның соңгы чирегендәге торгынлык елларын, ачы хакыйкатьне, фирка басымын фаш иткән «Замана балалары» белән үтеп керсә, шул ук йөзьеллыкның соңгы унъеллыгындагы башбаштаклыкны, җәмгыятьнең акча, байлык колына әверелүен, кеше канының судан да арзанаюын тасвирлаган «Сәет Сакманов» («Тәүбә», «Элмәк», «Төнге юллар») трилогиясе белән гаҗәпләндерде.

Казанда да оештыруга сәләтле, тәҗрибәле кешегә «тынычлык» бирмиләр. Аны университетка чакырып алалар һәм 1944 елдан бирле эшләп килгән татар теле һәм әдәбияты бүлеген үстереп, татар тарихында беренче милли факультет оештыру эшен тапшыралар. Ниһаять, «татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр» исемле фәнни-гамәли берәмлек хасил була. Т.Галиуллин егерме биш ел дәвамында шул фәнни совет белән җитәкчелек итте.

Нинди генә иҗтимагый вазифалар йөкләнмәсен, Т.Галиуллин өчен иҗади-фәнни юнәлеш иң мөһиме булып кала бирде. Тынгысыз эзләнүләрнең нәтиҗәсе күз алдында. Ул – егермедән артык җыентык, монография, меңләгән мәкалә авторы. Татар сүз сәнгатендә аңа «баш бирмәгән», ул көчен сынап карамаган жанр юк, дисәм, кемдер, «ул шигырь язмый», дисә, мин аңа хәзерге тәнкыйтьчеләребез, әдәбият галимнәре арасында ярты гасырдан артык татар поэзиясен шултиклем бирелеп, яратып тикшергән тагын ничә фидакаребез бар дигән сорауны бирер идем. Аның соңгы, беркадәр сәеррәк исемле «Мы – потомки страны «Тартария» җыентыгы буенча гына да XX гасыр һәм XXI йөз башы татар шигъриятенең төп казанышларын күз алдына бастырып була. Әлеге китаптан тулы бер гасырның, XXI йөзьеллыкның ике унъеллыгында татар сүз сәнгатенең куәсе, җиһанның теләсә кайсы «мөһерле» поэзиясе белән аяк терәп сөйләшә алырлык, милли мәнфәгатьләрне кайгырту җәһәтеннән бәяләгәндә, күбесеннән өстен торган мирасыбыз, бүгенгебез белән таныша алабыз.

Җыентык авторы XX гасырның беренче яртысы шагыйрьләре иҗатын иңләү аша үткән йөзьеллыкның икенче яртысында, Мостай Кәрим язганча, 60 нчы елларда Р.Фәйзуллин, Р.Харис исемнәре белән йөртелгән «икенче шартлау» шагыйрьләре иҗатын, «көмеш чор»ны бәяләү аша 90 нчы елларда башланган милли яңарыш чоры шигъриятенә тукталa, иң яшь буын каләм тибрәтүчеләр арасында өметле эзләнүләрне күреп ала. Исемнәргә, поэма-шигырьләргә бәя биргәндә, авторның мәктәп, көллият, югары уку йорты таләпләрен истә-күздә тотып язган педагог булуы сизелеп тора.

Иҗатларын, үзләрен яхшы белгән С.Хәким, И.Юзеев, Г.Зәйнашева кебек шагыйрьләрнең иҗат портретлары һәркайсының үзләренә генә хас индивидуальлекләре турында уйлaнулары белән хәтердә калалар. Һәркайсы шигырьләрендә үзләре «яшиләр».

Җылы сүздән читтәрәк калган, яңачарак фикерләүче, профессор – математик – шагыйрь Җәүдәт Сөләйманов поэзиясенә багышланган «Сөләйман» мәкаләсе тулылыгы, бәяләрендә төгәллеге, иҗат серләренә үтеп керү юлларын эзләве белән уңай тәэсир калдыра. Баһадирыбыз Ф.Яруллин шикелле үк, язмыш рәнҗетүенә бирешмичә, кул-аяклары хәрәкәтсез килеш, каләмен авызына кабып, шактый саллы мирас калдырган шагыйрь, рәссам Гакыйль Сәгыйровка багышланган әдәби очерк өчен авторга рәхмәт әйтәсе килә. Рәмис Аймәт, Ленар Шәех кебек яшьрәк буын шагыйрьләрне «олылар сафына» әйләнешкә кертеп җибәрү дә уңышлы фал.

Татар халык иҗатына гына хас тарихи, күбрәк шәхси фаҗигане, гомумән, яшәеш хакыйкатен үзәккә алган, борынгы жанр булса да, хәзергәчә телләрдән төшми, һаман да языла (шул исәптән, хәзерге шагыйрьләр тарафыннан да), әйтелә килгән бәетләргә багышланган, киңкатлам укучыны күздә тотып язылган җыентыкны тәфсилле тикшерүне максат итмәсәм дә, үземнең мөнәсәбәтне сиздереп үтмәү дөрес булмас.

Мәҗмугага, нигездә, элегрәк дөнья күргән җыентыклардан, традицион мәдәниятне өйрәнү үзәгенең архивыннан зәвык белән сайлап алынган үрнәкләр урнаштырылган. Хезмәт авторның бәетләрне яңачарак бәяләгән, төртмәле дә, үткен сүзле дә тәфсилле кереш сүзе белән ачыла. Яшьлек белгечлеге буенча фольклорчы Т.Галиуллин бәетләрнең тормыш фаҗигасен үзенчә бәяләвен, халык фәлсәфәсен кояш нурларыдай үзенә сеңдергән «иске» жанрны «яңача» укуга ирешкән. Иң мөһиме: автор берәүне дә кабатламаган, чыганакларны ифрат төгәллек белән күрсәтеп барган.

«Китек көзге» мәҗмугасында тәкъдим иткән әсәрләрендә язучы әдәп-әхлак, кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр, һәркемнең тормыштагы үз урыны, үз-үзенә бәясе турында уйландыра. Күбесенең өслүбендә авторның реализмга, психологик анализга, эчке сөйләмгә, диалогларга иркен таянуы, телебезгә ихтирамы сокландыра.

Элегрәк язылган «Кияү» бәянында катнаш никахларның фаҗигасе ачыла. Тәҗрибәсез, авыл мокыты Сәгыйрь, армиядә хезмәт иткәндә, утны-суны кичкән хатын җәтмәсенә эләгеп, ахыр чиктә «ярык тагарак» янында калуын сурәтләгән әсәре буенча күренекле режиссёр, язучы Әхтәм Зарипов күп серияле телефильм иҗат иткән иде. 90 нчы еллар азагында, яңа гасыр башында «Кияү» зәңгәр экраннардан кат-кат күрсәтелсә дә, ил сәясәтендә вазгыять үзгәргәч, хәзер ул «лента», үз сәгате кайтуына өметләнеп, архивта «ял итә».

И.С.Тургеневның «Ася», «Беренче мәхәббәт» һ.б. шул рухтагы бәяннары турында язган галимнәр аның барча каһарманнары мәхәббәт сынавын узалар («Испытание любовью») дигән фикерне еш кабатлыйлар. Т.Галиуллинның матбугатта уңай бәя алган «Мәкер», яңа җыентыгына исем биргән «Китек көзге» әсәрләрендә, «Колючник», «Өйләнү», «Спид вә мәхәббәт», «Ниткән хат ул» һ.б. хикәяләрендә һәр инсани зат башыннан үтә торган олы хис сынавын һәммәсе кабатланмас рәвештә уза. Беренче ике повестьның каһарманнары, бәхеткә лаеклы булып та, мәхәббәтләрен саклый алмаулары нәтиҗәсендә гомерләрен күңелсез уздыра, күбесе тагын да авыр сынау – ялгызлыкка дучар була. Мәсәлән, «Мәкер»дә кызу канлы Әмир белән тәкәббер, чибәр Сәвия бер-берсен табып, ихластан яратышып, бер алманы икегә бүлешеп, шатланышып гаилә корып, бәхет нурында коенып яшисе урынга, бик оста үрелгән мәкерле җәтмәгә эләгеп, «алтын кошларын» кулдан ычкындыралар. Ялганчы Ленарның үз максатына ирешү, аңардан йөз чөергән Сәвияне кулга төшерү өчен, армия хезмәтен тәмамлап кайтучы Әмирне стансыда атналар буена саклап торып, Сәвияне төрлечә хурлап, җенси азгынлыкта гаепләп, кызның колагына, Әмирең өйләнгән, марҗасы белән кайта, дигән уйдырмасын сеңдереп, араларын үз файдасына бозуга ирешә. Ленарның мәкеренә ышанган Әмир Сәвиясеннән колак кага һәм гомерен яратмаган кеше белән уздырырга мәҗбүр була. Һәркемгә Ходай Тәгалә горурлыкны, үпкәчеллекне бирә. Яшь чакта алар ташып тора. Көнче Әмир тузына, Сәвия аңа ялынып килми, кайнар канның басылганын көтми һәм яратмаган Ленарга кулын биреп, аңа ияреп авылдан чыгып китә. Ахыр чиктә, милициягә эшкә кергән иренең кыланышларына, рәнҗетүенә түзә алмыйча, аны үз коралы белән атып үтерә. Ике бәхетсез бәндә картлык көннәрендә очрашып, аңлашып, күз яшьләрен түгүдән, каһәрләнгән мәхәббәтләре алдында тезләнеп гафу үтенүдән уза алмыйлар. Шуңа күрә тәрҗемәче бәянның русчасын «Прости, любовь» дип атаган. Автор ошбу бәянында мәхәббәтнең кешене яшәтә, үстерә торган һәм бәллүр савыт кебек сакланырга тиешле бөек хис дигән фикер уздыра.

Җыентыкка исем биргән повестьның асылында шуңа якынрак хәл-әхвәл ята. Бу – әсәрендә авторның кеше хисен, холкын, менәзен ачу алымнарын баетуның яңадан-яңа мөмкинлекләрен эзләвендә күренә. Әсәрнең буеннан-буена сузылган табыш – «китек көзге» метафорасы, символ дәрәҗәсенә күтәрелеп, кулдан ычкынган «китек бәхет», «бәхет кошына» килеп тоташа. Әлеге метафора тәкъдирдә язылган, язмышта булачак котылгысызлыкны искәртеп тора төсле. Замана байларының артык иркә үскән, үз-үзенә ышанучан, тәкәббер Ләйлә тәүге тормыш дәресен ала. Дөнья аның кубызына гына биеми икән шул. Чыгарылыш кичәсендә күзе төшеп йөргән Артур аның биергә чакыруына теш арасыннан гына: «Я вальс не танцую», дигән җөмләне төшерә. Егетнең бу сүзләре «төрле мәгънәви эчтәлек, аһәң белән җан канатларын көйдереп, колагын зыңгылдатып торды». Салкын судан чыккан үрдәк хәлендә мескенләнеп калган, беренче җитди язмыш сабагы алган Ләйлә бәйрәмне ташлап, өенә йөгереп кайтып, зур көзге каршындагы урындыкка лып итеп утырып, үз сурәтенә кадала. «Көзгедән почык борынлы, кыска буйлы, көнбагыш чәчәге кебек сары чәчле, чытык чырайлы, күзләре туңдырылган балыкныкы шикелле» бер ят кызый Ләйләне «шул кирәк сиңа», дип үртәп тора сыман. Ул, үзен-үзе белештермичә диярлек, озын үкчәле туфлие белән көзгегә тондыра. Сугуны көтеп кенә торгандай, көзгенең уң як чите кителеп төшә.

«Пыяла тавышын ишеткән әнисе Халидә йөгереп килеп җитә:

– Ләйләм, нәрсә булды?

– Күзгенең бер чите убылып төште. Көзге ватылу бәхетсезлеккә, диләр бит.

Анага кызы да якын, яңа өйгә күченгәч алган беренче җиһазлары да кызганыч. «Тарихи көзгебез әрәм булган!» – дип нәтиҗә ясый Халидә.

Әнисенең ирексездән, уйламыйча әйткән сүзләре Ләйләгә җитә калды. «Ул нәфис куллары белән битен каплап, ачынып: «Сиңа көзге жәл. Ә минем – фаҗига. Беренче мәхәббәтем үз урыныма төртеп күрсәтте».

Икенче җитди мәхәббәте дә атасының «ярдәме» белән фаҗигагә юлыга.

Очраклы рәвештә, самолётта килергә тиешле кешеләрне көткәндә, Морад белән Ләйлә танышып, дуслашып йөреп, бер-берсенә гашыйк булып, матур гына гаилә корып җибәрәләр. Бәләкәчләре туа.

Морадның фәнни яктан да үсеп китүе, аңарга килеп тезләнмичә бизнесын үстерүе, Ләйләнең әтисе Сахипнең саруын кайната. Ахыр чиктә, атасының киявеннән көнләшүе, шымчысының машина номерларын бутавы нәтиҗәсендә яшьләрнең мәхәббәте, матур челтәрле көзге төсле, убылып төшә. Морадыннан колак каккан Ләйлә, кызын алып, өйләреннән чыгып китә. Сахип Миндрахманович баласының бу адымына бик исе китми:

– Син артык борчылма, карчык. Кызыбыз нервларын тынычландыруга, мунча кереп, бассейнда коенасы килүгә, әйләнеп кайтыр. Габбасовлар тәрбиясен алган кеше ич ул...

«Китек көзге» әсәренең төп үзенчәлеге – һәр образның кабатланмас шәхес булып, күңелдә фикерләү рәвешләре, тел үзенчәлекләре, дөнья барышын үзләренчә аңлаулары белән ачылуда, психологик анализ алымнарына иркен таянуда. Т.Галиуллин прозасының бу үзенчәлеге «Гомер тәлгәшләре», «Итле пәрәмәч» (икенче исеме – «Түрәләр сые»), «Ура, таптык» (яңа исеме – «Кысыр хәсрәт») әсәрләрендә тулы көчкә ачыла. Әүвәл «Казан утлары»нда басылып чыккан, вакыт ягыннан иң соңгы бәяннарының берсе «И карак»та (2005) автор бер гаилә язмышында хәерчелек белән югары әхлаклылык арасындагы конфликтта соңгысының җиңеп чыгуын үзәккә ала. Татар әдәбиятында шактый яктыртылган, сугыштан соңгы авыр чорны сурәтләсә дә, язучы берәүне дә кабатламаган дип уйлыйм.

Авыл халкы иртә таңнан караңгы төшкәнче бил бөгеп эшләсә дә, кулына аның тоз, шырпы, керосин, сабын кебек көндәлек кирәкле әйберләрне юнәтерлек тә акча керми. Сугышта алган яраларыннан өендә вафат булган ирен югалтып, дүрт бала белән калган әнисенең чарасызлыктан бәргәләнүен, сиздермәскә тырышып елап утыруын күргән өлкән сыйныф укучысы Рафикъ караклык юлына баса. Укытучысының тәрәзә төбендә калдырып киткән сумкасыннан ике унлык белән бер бишлекне ала һәм «юлда таптым», дип, әнисенә кайтарып бирә. Азгын малай булса, конфет, прәннек ише тәмле-томлы әйберләр алып, шикәрне чишмә суына манып суырып, ләззәтле мизгелләр кичерә алган булыр иде. Юк шул, ул өй, яшәү өчен иң хаҗәт әйберләр алырга әнисен кибеткә «куа». Ана күңелен алдап булмый икән. Ул ачка үлсә-үлә, әмма хәрәм акчага (хәтта урамда табылган булса да) кызыкмый, кибеткә барырга да җыенмый. Ана улын турыдан-туры караклыкта гаепләмәсә дә, кеше әйберенә кагылуның зур гөнаһ икәнлеге, алар нәселендә мондый очракның була алмавы турында озак итеп балаларына тәфсилләп сөйли дә шыпырт кына урамга чыгып китә. Рафикъ та тыныч кына өйдә кала алмый һәм әнисенең тарих укытучы Нәсимнәргә кереп киткәнен күрә. Егерме биш сум акчаның югалуы сер булудан «туктаган» була. Җитмәсә, директор комсомол оешмасы сәркатибе Нәсимгә бу очракны тикшерү бурычын йөкләгән икән. Рафикъның әнисе сөйләве буенча, тарихчы акчаны кем урлаганын тәгаен белсә дә, яшүсмерне гаепләргә ашыкмый.

Югары белемле яшь укытучы дин тарихында, безнең борынгы хикәятләрдә очраган тәҗрибәне кабатларга була. «Мәктәпкә килгән уңайдан ук, җәннәт агачыннан ясалган Муса таякларын алыштыра алмасалар да, үз бурычларын үтәрләр, дип, кырдан арыш камыллары кисеп ала һәм интернатта кунарга калган укучыларга тарата.

– Барыгызга да тигез итеп киселгән камыллар өләшәм. Тик берсе генә бераз озынрак. Шул салам эләккән укучы Рәсимә апагыз төшереп калдырган («сумкасыннан урлаган», дип әйтә алмады) акчаны хуҗасына кире кайтарырга оялган кеше булыр».

Шул гадәти алымга алданган Рафикъ, куркып, үз камылының очын яшереп кенә кисә. Нәсим бар авырлыкны үз өстенә ала. Без Рәсимә белән тиздән гөрләтеп туй уздырып, бергә яши башлаячакбыз, алда торган мәшәкатьләр өчен сумкасыннан акчаны мин алдым, дип аңлата мәктәп хуҗасына һәм карак үсмерне әрлисе, милициягә тапшырасы урынга, кулына бурычка дип зуррак сумма акча тоттырып җибәрә. Шул адымы белән педагог аңа гомерлек сабак бирә. «И карак» бәяны – безнең көндә дә яңгырашын, тәрбияви-әхлакый әһәмиятен югалтмаган, рухи бөеклек үрнәген сурәтләгән әсәр. Җиңел, халыкчан тел белән язылган бәян мәктәп дәреслекләрендә урын алырга лаеклы дип саныйм.

Т.Галиуллин югарыда кыскача гына карап үткән бәяннарында үзен профессорларча җитдирәк тотып, нигездә психологизм, эчке сөйләм, икеләтелгән проекция, тәфсилләү алымнарына киңрәк таянса, кыска күләмле күпчелек хикәяләрендә исә халкыбыз яшәешендә нинди генә читен хәлләргә юлыкмасын, күңел көрлеген, киләчәккә ышанычын, үзенә читтән карап, чеметеп, көлеп бәя бирү сәләтен югалтмый дигән фикер уздыра. Кыска күләмле, тыгыз эчтәлекле хикәяләрендә иҗатчының осталыгы ачык күренә. Мәҗмугага тупланган хикәяләр эчтәлекләре җәһәтеннән өч төркемгә тартылып торалар. Бер өлешенә уку йортлары тормышын, укытучылар, талиб-талибәләр арасындагы мөнәсәбәтләрне сурәтләгәннәре керсә («Абу», «Туган көн», «Ышанычымны акламадыгыз», «Һавада – «татарин» һ.б.), икенчесендә тормышчан, бераз сәеррәк, авыр яшәешне җиңеләйтү юлларын эзләп, шаярта, юктан юаныч таба белгән ачык күңелле дә, хәйләкәр дә туган авылы гидайлары каләм очына алынса («Тимерче бабай», «Әгъләм артеле», «Бараксин», «Ибрай Гаязы», «Әти һәм аның даирәсе» һ.б.), өченче төркемне, шартлы рәвештә, әдәп-әхлак, кешеләр арасындагы катлаулы, четерекле мөнәсәбәтләр, мәхәббәт-нәфрәт кебек бер чорда да искерми, «төсен» җуймый, һәрберебезнең газиз башыннан, йөрәгеннән уза торган мәүзугларны сюжет канвасына салып тасвирлау тәшкил итә («Ниткән хат ул», «Спид вә мәхәббәт», «Төш», «Өйләнү», «Тормышчан бетем»). Бу хикәяләрендә ул гадәти күренгән вакыйганың «тешен» табып, дусларча чеметеп, шаяртып, аны җор тел белән яңа калыпка сала. Китапта «Безнеке – иң чибәре», «Һавада – «татарин», «Ниткән хат ул» кебек, Г.Гобәйдуллин, М.Зощенко, Ф.Шәфигуллин әсәрләрен искә төшереп торган, сәхнәдән укырлык һөҗү хикәяләре шактый авторның. Ул елмайту, көлдерү аша уйландыра.

Халкыбызның җиһанның башка кавемнәре кебек яшәү, һич югы аның белән санашу хыялын чагылдырган, шундый могҗизаның булуына үзен, башкаларны ышандырырга тырышкан бер «сабый» студент Әнвәр Мөхәммәтҗановны тасвир үзәгенә алган «Һавада – «татарин» хикәясе генә ни тора. Радиодан «Һавада – «татарин», дип ишеткән егет күрше бүлмәдә һаман да йокы симертеп яткан сыйныфташларын уята, әрли, үзен авыл мәктәбенә гади укытучы булып барасы урынга, министрлыкта куе чәйне көмеш кашык белән бутап утыручы түрә итеп күрә. Кайсыдыр диварда асылынып торган (ул чорның юкка чыгарылган зур казанышы) радиоалгычны ачып җибәрсә, аннан Левитанның көчле тавышы «В воздухе гражданин Советского Союза Гагарин», дигән сүзләре яңгырый. Барысы да өсләренә салкын су койгандай уянып, мескен Әнвәрдән көләргә җыенсалар, аңардан «җилләр искән була». Бу ялгышуда Әнвәр йөзендә бөтен татар милләтенең хыял-өметләре чәлпәрәмә килүе ачыла кебек. Чөнки 1961 елда космик корабта очарга әзерләнүчеләрнең беренче сафында татар кешесе дә булган дигән хәбәр колакларга чалынган иде.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, каләм иясенең бер елда бастырган, төрле әдәби жанрларга багышланган өч китабы аерым нәтиҗә чыгаруны сорамыйлар да кебек. Мәгәр яңа басмалары Т.Галиуллинны үткен телле, төрле эчтәлекле әсәрләр язуга, гаҗәпләндерүгә сәләтле прозаик, тәнкыйтьче, әдәбият галиме буларак кына күрсәтмиләр, ә халык иҗаты энҗеләренә мөкиббән фольклорчы буларак та таныталар. Аның фикерләү киңлеге сокландыра, әсәрләрен укыган кешене яшәүгә рухландыра. Һәрхәлдә алар миндә шундый тәэсир калдырды.

**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ,**
*филология фәннәре докторы*

# МОГҖИЗАЛАР АЧАР СҮЗ ОСТАСЫ

## ГАЛИМҖАН ГЫЙЛЬМАНОВ ИҖАТЫ ТУРЫНДА

Балалар өчен әдәби әсәрләрне бәяләүдә бүген куела торган төп критерийларның берсе – тормыштан алынган характерларны бирү, геройларның күңел кичерешләренә, бала психологиясенә тирәнтенрәк үтеп керү. Бу зарурияттне аңлаган язучылар яңа ысул, алымнар эзләү юлына аяк басты. Алар арасында талантлы прозаик Галимҗан Гыйльманов та бар.

Г.Гыйльманов балалар һәм яшүсмерләр өчен прозада да үзенә генә хас стилен, мәсләген тапты кебек, чөнки аның һәр әсәрендә кабатланмас ниндидер символик мәгънәгә ия деталь, фәлсәфи фикер, иң әһәмиятлесе, милли характер бар. Мисал итеп, «Язмышның туган көне», «Ике дус һәм ак бабай хакында кыйсса», «Бүреләр һәм Иоһанн Себастьян Бах», «Фәрештә», «Гөлләр дә елый», «Йорт иясе», «Тәкъдиргә юл», «Педагог», «Күңел күзең күрәме», «Ана сүзе», «Җанбалык», «Китек ай», «Илаһи көн», «Күңел күзең күрәме?», «Туган көнсез малай» һ.б. әсәрләрен китерергә мөмкин.

Лирик рухта язылган «Ике дус һәм ак бабай хакында кыйсса»сына тукталыйк. Хикәянең исемендә үк күзгә ташланган образ – «ак бабай» образы. Татар әдәбиятында ак әби, ак бабай образлары еш кулланыла. Аларны милләт гаделлек, аклык билгесе буларак күрергә инде күнеккән. Гомумән, төрки халыкларда ак бабай аксакал, ихтирамга лаек, тормыш тәҗрибәсе зур булган карт кеше буларак күзаллана һәм, фольклор әсәрләреннән башлап, образ нәкъ менә шушы юнәлештә ачыла да.

Хикәя кыска күләмле, сюжет гади. Яз көне килгән кошларны каршы алырга теләп, ике дус, Хәлим һәм Сәлим, оя ясарга булалар. Икесе дә тырышып эшли, әмма эш барышында ак бабайга мөнәсәбәтләр төрле: «Хәлим Ак бабай янында үзен бик сәер тотты. Әллә каян исәнләшеп каршы алса да, күрше карты белән ачылып китеп сөйләшмәде. ...Бераздан: «Өйрәткән булып, ник эш кешесен борчып йөрисең инде?» – дигәндәй, берничә мәртәбә картның күңелен кырыс, шелтәле карашы белән өшетеп алды»; «Сәлим шулай (ак бабай өйрәткәнчә) итте дә. Бакча читендә, аулактарак, көнчыгышка йөзен ачып утырган каен агачын сайлап, үзе ясаган басмалы ояны менгереп бәйләп тә куйды».

Биредә автор геройларның төрле характерда булуларына басым ясарга омтыла. Ак бабайга мөнәсәбәтле ике караш капма-каршы куела. Хәлимдә «мин беләмлек» өстенлек итә. Аның нәтиҗәсе дә аянычлы: «Хәлим ясаган ояда үскән ике сыерчык баласы да канат җәяргә вакыт җиткәч кенә җиргә егылып төште... Хәлим тавыш-тын чыгармыйча гына елады. Аңа кушылып Сәлим дә елады...» Традицион фикер. Өлкәннәрнең сүзен тыңларга кирәк. Әмма, хикәядә акыл сату, өйрәтү юк. Тасвир, аянычлы нәтиҗә аша төп фикер җиткерелә. Әле алай гына да түгел, иң кызыгы, фикер алга таба да үстерелә: «Ак бабай малайлар янына бик сирәк керә. Кошлар гамен үз язмышларына алып яшәүче бу яшь җаннарны ул койма аша гына күзәтеп яши. Чөнки аның үз хәле хәл: ниндидер бер изге гамәлне кылып җиткермәде ул. Ниндидер бик мөһим сүзне таба, әйтә алмады». Бу фикер инде өлкәннәр өчен бирелә: балаларга нисбәтле игътибарлы булу кирәк. Фикерне нәни укучылар сизми дә калырга мөмкин.

«Монда аларга оя кирәк, өй кирәк...» Күренә ки, автор тарафыннан кошлар һәм балалар арасында параллельлек үткәрелә. Ныклы, ышанычлы нигез булса гына, тормыш матур булачак. Һәм ул тышкы яктан түгел, эчтән дә матур булырга тиеш. Хәлим ясаган сыерчык оясы Сәлимнекеннән мең мәртәбә матуррак булса да, акыл белән эшләнмәгән эш фаҗига тудыра. Кош оясы ясау – тормышны дөрес кора белү дә ул.

Хикәянең эчтәлеге ике катламлы килеп чыккан. Беренче катламда бирелгән, беренче карашка бик гади күренгән вакыйгалар – бала аңы өчен. Күз алдында туган картина бала күңеленә тирән үтеп керерлек итеп тасвирланган. Салмак сөйләм, балаларның төрле ситуациядә үзләрен тормышчан тотуы, матур тел – авторны чын мәгънәсендә

психологизм остасы буларак ача. Икенче катламда бирелгән «Офык читендә тәгәрәп йөрүче кояш кына, аңа карап: «Борчылма, Хода бәндәсе, кеше гомере генә озын ул, бер ялгышны төзәтергә язмышлар кирәк. Табигатьнең гомере яз саен кабатланып тора, киләчәк язларда сак бул, уяу, сизгер бул...» кебек сүзләр инде өлкәннәр өчен. Шулай итеп, талантлы әдип буларак, Г.Гыйльманов тормышны берьюлы ике яссылыкта күрә: балаларча һәм өлкән кеше буларак. Нәтиҗәдә, зурлар яшәеше аңлатмаларын балалар теленә күчерәсе урынга, тормышны аларча күрү һәм шуны сәнгатьчә ачу мөмкинлекләре туа. Дөрес, бу урында әйтеп китү урынлы булыр, үз вакытында ике катламнан торган әсәрләр фикерне турыдан-туры әйтү мөмкинлеге булмаган чорларда, дәүләт һәм дин басымы астында язылган әсәрләрдә еш кулланылды. Мисал итеп, төрле тарихи вакыйгалар, шәхес культы еллары, колхозлашу дәверен ачкан әсәрләрне китерергә мөмкин булыр иде. Г.Гыйльманов исә бу алымны өлкәннәр һәм балалар арасындагы мөнәсәбәтләргә бәйләп, өлкәннәр өчен гыйбрәтле сүз әйтер өчен файдалана.

Эчтәлеге ике катламнан торган мондый әсәрләр арасында авторның «Бүреләр һәм Иоһанн Себастьян Бах» хикәясен дә карарга мөмкин.

Хикәянең сюжеты катлаулы түгел. Музыка белән шөгыльләнүче Ленар, февральнең бер көнендә әбисенә кунакка кайтырга була. Күчтәнәчләр алып, юлга кузгала. Әмма станциядән җәяү авылга кайтып барганда, аңа бүреләр очрый. Табигать һәм кеше арасында килеп туган хәлне тасвирлау, әлбәттә, әдәбият өчен зур яңалык түгел. Әмма мондый төр әсәрләрдән Г.Гыйльманов хикәясе шактый аерыла, чөнки бу вакыйга алда әйтеләчәк автор идеясе өчен нигез, таяныр нокта гына.

Хикәядә тасвирланган вакыйгалар шактый тәэсирле – чөнки автор әсәрендә герой кичерешләрен беренче зат исеменнән да сөйләтә һәм ул фикерләрнең укучы өчен үтемле булуын тәэмин итә: вакыйгаларны укучы үз кичерешләре кебек кабул итә, нәтиҗәдә тирән психологик халәт туа. Мисал өчен, барлыкка килгән хәлдә геройның чарасызлыгы беренче зат исеменнән түбәндәгечә җиткерелә: «Тагын нишләп була соң? Ни кылып була?.. Ник китмиләр инде болар, күпме (скрипкада) уйнарга була?» – дип уйлады Ленар... Барыгыз инде, китегез, үз урманыгызга кайтыгыз. Ә мине әбием көтә... Аннары... өшедем дә инде, бармакларым бик өшеде...»

Шунда ук автор ситуациягә бәя дә бирә: «Ленарның үз гомерендә бүре күргәне юк. Мондый хәтәр хәлдә калганы да юк. Шуңа күрә бу хәлдә нишләргә кирәген ул белми. Бүреләр дә белмиләр, ахры. Әнә, алар туктап калдылар, борылып, авылга таба карап тордылар...».

Мәгълүм, бүре төрки халыкларда элек-электән куркусызлык, батырлык, ирек һәм тугрылык билгесе булып кабул ителгән. Аеруча Ак бүре «могҗизалы-мифологик» образ буларак исәпләнгән. Ләкин бу очракта бүреләр – кыргый табигать гәүдәләнеше.

Алда бәяләп үтелгән әсәрләрдә без Г.Гыйльмановның табигатькә җанлы организм итеп каравын кат-кат дәлилләгән идек инде. Бу очракта да автор бүреләр мисалында табигатьне җанлы итеп, кешеләштереп бирергә омтыла. Бүреләрдә дә кешеләргә хас хис, акыл бар дигән фикерне алга куя һәм Ленарның скрипкада уйнаганын тыңлап утырган бүреләр түбәндәгечә тасвир ителә: «Көй, музыка тәэсир итте микән – өнсез булып, туктап калганнар. Бу яңгырашның, чынлап та, җан иярләренә шаукымы бар микән әллә? Бардыр. Ерткыч бүре булып та бу кадәр иләсләнеп, исәнгерәп утырмаслар иде...»

Әмма язучының төп фикер-идеясе әле алда. Иң авыр вакытта Ленарның күңеленә уй килә: «Әллә сөйләшеп карарга мы? Алай дип әйтергә татарча белми бит ул. Ә болар – татар бүреләре. ... Ә-ә?! Димәк, алар музыканың да татарчасын гына үз итәләр?.. Кызганыч, Ленар бер татар көе дә белми... Шулай да Ленар бер көйне белә... Укытучылар аңа Тукайның «Туган тел» шигыренә язылган музыканы бирделәр.

Караңгылык иңә башлаган кышкы яланга моңлы татар көе тарала башлауга, бүреләр тагын кузгалышып куйдылар, хәтта тынгысызлана башладылар. Ленар, гаҗәпләнүеннән, җылынып киткәндәй булды: әллә чынлап та тәэсир итте ме? Фан-тас-тика!»

Димәк, хикәядә күтәрелгән төп фикер туган тел, милли аһәң, милли әдәбият-

мәдәният һәм, ниһаять, милли тарих белән бәйләнгән булып чыга. Әгәр бу хикәянең без беренче, күренеп торган катламын гына бәяләп, гадәт буенча, музыка төп геройны үлемнән саклап кала, дип кенә бәя бирәбез икән, хикәянең бәһасен байтак дәрәҗәдә төшерәбез дигән сүз. Моңа өстәп, анализ бик беркатлы һәм гади булып чыгар, язучының төп фикерен ассызыклый алмас иде. Чөнки төп фикер икенче, яшерен катламда бирелгән.

Ленарның татарча начар белүе дә, әти-әнисенең бу эшкә битарафлыгы да автор тарафыннан тәнкыйть ителә: «Ленар бераз каушап калды. Чөнки ул татарча белми иде. Элегрәк, авылга кайтып йөргәндә, әбисеннән бераз өйрәнгән иде өйрәнүен... Шунда ук бер як читтәрәк, олы, затлы урындыкларында чумып утырган әти-әнисенә карады. Ничектер бәләкәйләнеп калганнар иде алар».

Мәскәү консерваториясенең зур залында Иоһанн Себастьян Бахның скрипка өчен язылган сонаталарын уйнап, скрипкачылар конкурсында лауреат булган Ленарны, соңгы чиктә, кыргый табигать белән күзгә-күз очрашкан вакытта, «Туган тел» коткарып кала. Әлбәттә, бу вакыйга символик мәгънәгә ия. Татар авылы тирәсендә яшәп, шул тормышка күнеккән татар бүреләре, гомумән, табигать лауреат Ленардан акыллырак, югарырак үсеш дәрәҗәсенә ирешкән түгелме? Риторик сорау – җавапсыз.

«Педагог», «Тәртипсез малай» хикәяләре дә Г.Гыйльмановның педагогика һәм психология фәннәрен «яхшы үзләштерүе»нең нәтиҗәсе буларак аерылып тора.

Самига Гариповнаның кызыксыз дәресләрендә Николай Островскийның «Корыч ничек чыныкты?» исемле китабын укып утырган тәртипсез малай Илһамны, педагогика таләпләре буенча, нишләтергә? Авторның җавабы ачык, мөгаллимнәр, нәкъ менә яшь директор Марат кебек, баланың күңеленә юл таба белергә тиеш: «Илһам күңеленә мөлдерәмә тулган сөенечен башка яшереп кала алмый иде инде – бүлмәне балкытып елмаеп җибәрде. Аннары, китабын куенына кысып, ишеккә йөгерде. Малай артыннан ачылып-ябылган ишектән мәктәп завучының ачулы йөзе генә күренеп калды».

Г.Гыйльманов балалар һәм яшүсмерләр өчен әсәрләрендә борынгыдан килгән кыйммәтләрне, әхлакый яшәешне, язылмаган, әмма гаилә ныклыгын сакларга ярдәм иткән кануннар һәм шулар буенча яшәүче геройларны яратып тасвирлый. Мондый әсәрләрендә ул герой кичерешләрен тирәнтен сурәтли алырдай психологик портрет остасы буларак та ачыла. Мисал өчен, «Ана сүзе», «Ясимә ятимә түгел» кебек хикәяләрне китерергә мөмкин.

Мәгълүм ки, татар әдәбияты тарихында фольклордан ук килгән традиция буенча, әниләр кадере, әниләр изгелеге, Ана белән бала арасындагы мөнәсәбәтләр турында әсәрләр күпләп язылды. Г.Гыйльмановның «Ана сүзе» хикәясендә дә Ш.Камал («Буранда»), Ә.Еники («Матурлык», «Әйтелмәгән васыять»), А.Гыйләҗевләрдән («Җомга көн, кич белән...») килгән дәвамчанлык, психологик тирәнлек сизелә.

Хикәя сюжетында хәрәкәт юк дәрәҗәсендә. Ул, нигездә, монологтан тора, һәм эчке монолог аша төп героиня ачыла. Гомумән, 1980 еллардан татар язучылары әсәрләрендә рухи яктан авыр һәм җаваплы шартларга куелган геройларының хис-кичерешләрен эчке монологлар аша гәүдәләндерүгә аеруча игътибар юнәлтә башлады. Болай эшләү, әлбәттә, үзен аклый. Беренчедән, герой күңеленең киеренке, газаплы вакытында кичерешләрен тирәнрәк ачарга сәләтле. Икенчедән, тормышның шатлыклы яки күп очракта авыр вакытларында герой тарафыннан үзенең рухи халәтен билгеләве дә табигый, ягъни эчке монологка мөрәҗәгать итү килеп туган хәлне аңлау, аннан котылу юлларын эзләү, ниндидер бер карарга килүне ачыклауга корылган.

Г.Гыйльмановның төп героинясы, үлем белән көрәшеп ятучы баласыннан аерылырга куркып, палатада утыра. Табиблар, шушы өченче тәүлек эчендә дә бала аңына килмәсә, гомеренең өзеләчәген фаразлыйлар. Авыр психологик халәт: «Син, кызым, сөйләш аның белән. Сөйләш... Бертуктамый сөйләш. Бер минутка да сүзеңнән, тавышыңнан өзмә. Аңындамы, түгелме – анысын син дә, мин дә белмибез».

«...ак халатлы, өлкән яшьтәге, фәрештә кебек, җиңел, җил-җил атлап, атлап та түгел, салмак кына йөзеп йөрүче» бу ханымның сүзен тыңлап, Ана балага кичергәннәрен сөйли башлый. Сөйләме аша героиняга характеристика, бәяләмә бирелә, үткәне, балага мөнәсәбәте ачыла. Эчке сөйләм героиняны индивидуальләштерүдә дә мөһим фактор

булып тора: «Әтиең бар иде... Ул безне ташлап китеп барды... Бала чүпрәкләреннән, бала тавышыннан куркып китте... Әни урынына да, әти урынына да үзем булдым...». «Бер сукканым өчен әле дә үкенеп бетә алмыйм. ... Эшемнән бик арып кайттым ул көнне. Җитмәсә, эштә бер юньсез ир бәйләнеп интектерде. Беркемне дә күрәсе килмичә кайттым. «Әнием!» – дип каршыма йөгереп килгән балама сугып җибәрдем... Син елый башладың, ә мин юатмадым... Хәзер шул чагымдагы юләрлегем өчен кыенсынып йөрим...»

Монолог-таныштыру рухында бирелгән әлеге юлларда героиня образы тулы гына чагылыш таба. Әлбәттә, төп героиняны бу юнәлештә бирү әдәбият өчен яңалык түгел. Мондый төр язмышлар әдәбиятта еш кабатлана. Хикәянең яңалыгы – традицион герой язмышын психологик планда ачу, уй-хисләрен, күңелендә барган кичерешләрне геройның үз авызыннан сөйләтү һәм, ниһаять, шуңа бәйле рәвештә башка күп кенә мәсьәләләр килеп кушылу. Ягъни, характер психологизм белән бәйле рәвештә тирәнрәк ачылган булып чыга. Әмма вакыйгалар барышында автор ана язмышын, аңа бәйле проблемаларны тормыштан аерып куймый: ана кешенең хис-халәтен, заманны, аның проблемаларын бәяләүчегә әверелә, яшәешнең ачы хакыйкате ана образы аша чагылыш таба.

Димәк, авторның төп фикерен җиткерүдә Ана образы зур роль уйный. Әлеге герой – сәнгатьчә бирелеше ягыннан да, әсәрнең идея-эстетик эчтәлеген ачу ягыннан да Г.Гыйльмановның зур уңышы саналырга лаек.

«Язмышның туган көне» повестенда да ана образын ачу өчен Г.Гыйльманов психологик анализның бер алымы булган әдәби детальдән файдалана: «Тәрәзәдән кояш көлеп карады. Зөһрә курчагын ипләп кенә мендәр читенә яткырды да идәнгә шуып төште, тәрәзә янына барды, аннары, күк читеннән балкып килеп чыккан көзге кояшка карап:

– Кояш! Син иң яраткан әйберем минем! – диде, кулларын өскә сузып, кояшны сәламләде...

Шулвакыт күрше бүлмәдән әнисе килеп чыкты. Зөһрәнең бүлмәсендә тагын бер кояш пәйда булды. Өй кояшы. Күңел кояшы. Бүлмәләр, күңелләр балкып китте». Нәни кызның хисләре, әни кешенең кадере шушы гади юлларда – автор һәм персонаж сөйләмендә тулаем чагылыш ала. Бу очракта инде автор баланың кичерешләрен сөйләп бирү юлы белән ача, чагыштыру алымы ярдәмендә исә фикер төгәл, үтемле итеп җиткерелә. Әдәби деталь – кояш образы киң мәгънәсендә кулланылып, фәлсәфи фикернең тирән кичерешле икәне ачыклана. Кояш – яктылык һәм җылылыкның шартлы образы, әдәбият аша бу фикер инде дәлилләнгән. Димәк, фикерләрне табигатькә бәйләп бирү авторның гомумилеккә нигезләнеп иҗат иткән образын ачыграк, үтемлерәк һәм укучы өчен аңлаешлырак итә. Дөрес, сурәтләүдә беркадәр абстрактлылык күренә кебек. Әмма игътибар белән укыганда, хикәядә ана образының җылылык, гаиләгә бирелгәнлек символы булуы белән бергә башкаларга хас түгел үзенчәлеккә дә ия булуы ассызыклана, һәм ул баланың күңел монологы аша тудырыла.

Автор хикәядә Зөһрәнең эчке, шул ук вакытта тышкы билгеләр аша психологик портретын ача.

«Язмышның туган көне» повесте яшәү фәлсәфәсе, гомумкешелек кыйммәтләре турында. Ана һәм бала мөнәсәбәтләре бу әсәрдә дә уңышлы чагылган. Зөһрә образында барган үзгәрешләр ышандыра. Әнисе Гүзәлиянең сабырлыгы нәтиҗәсендә табылган бәхет – бала уйлары белән аваздаш. Укучыларның кабул итү үзенчәлеген белеп язу аша бирелгән чишелеш, Язмыш образы исә уйлану, нәтиҗәләр өчен зур җирлек калдыра. Димәк, язучы үзенең төп максатына ирешкән дигән сүз.

Инде кат-кат ассызыкланды, Г.Гыйльманов прозасының геройлары, аларның рухи дөньясы, холыклары гадәти генә түгел. Бу, барыннан да элек, язучының мифология белән тирәннән таныш булуыннан, миф тудыру алымнарына, күпмедер дәрәҗәдә дини фәлсәфәгә таянып эш итүеннән, галәм, табигатьне тере җан итеп тасвирлавыннан килә. Мисал өчен, «Ходай бүләге» бәяны, «Хак чишмәсе» хикәясе – шундыйлар җөмләсеннән. Бәяндагы төп героиня Хәния – чын табигать баласы: «Хәниядә чынлап та сәерлек бар иде шул. Ул табигать тавышларын ишетә иде. Кечкенәдән шулай булган:

уйнап йөргән җиреннән кинәт тукталып кала икән дә, берәр агач яисә чәчәк, үлән янына килеп, сөйләшә башлый икән... Сәет белән йөри башлагач та, шул гадәтеннән котыла алмады. Һаман үзе генә белгән дөньяда яшәде, үзе генә белгән телдә үзе генә белгән җан авазлары белән сөйләшеп йөрде». Тирә-юньдәгеләр күпме генә авырлыклар тудырса да, Хәния сафлыгын, ихласлыгын саклап кала. Вакыйгалар үстерелеше һәм чишелештә исә үзенең бик күпләрдән өстенлеген раслый, бәхетен таба. Табигый, мондый чишелеш язучының төп идеясе белән бәйләнә.

«Хак чишмәсе» хикәясендә дә Г.Гыйльманов, геройны ачу өчен, мифологик элементлардан, кодлардан файдалана. Әсәр гайбәт сүз таралу белән башланып китә. Моның нәтиҗәсе буларак, Гөлшаһидәне, унбиш ел бергә яшәгән хатынын, ике баласы белән бергә ире урамга куып чыгара. Шуннан соң булган хәлләр, башлыча, Скотник Нурулланың ялганын ачуга кайтып кала. Нурулла сөйләгән сүзләренең хакмы, түгелме икәнлеген белү өчен, халык аны «Хак чишмәсе» буена алып китә. Әсәр үзәгенә куелган «Хак чишмәсе» турындагы ышануны автор түбәндәгечә тасвирлый: «Кеше теленә кергәннәрне, якындагы Күке тавы итәгенә урнашкан Хак чишмәсенә алып барып, «ант эчергәннәр»... Ант дигәнең шул чишмә суы үзе була инде. Бу изге чишмә янында кеше гел дөресен генә сөйли башлый, имеш».

Мәгълүм ки, төрки халыклар өчен чишмә һәм чишмә буе гасырлар дәвамында изге саналган. «Татар мифлары» хезмәтендә Г.Гыйльманов үзе дә чишмәләр турында мәгълүматлар биреп үтә: «Чишмә» сүзенә салынган мәгънә үзе кызыклы. Еш кына бу сүз мифологик (магик) код, ачкыч буларак та йөргән, ахры. Чишмәнең (суның) җаны бар, дип уйлаган борынгылар. Гомумән, кан белән җанны тиңләп караганнар. Каны агып беткән кеше үлгәч, аның җаны да шул кан белән китүенә ышанганнар. Шуңа күрә дә чишмә хакында: «Чишмә – ул су гына түгел, ул – җан азыгы», – дигәннәр».

Г.Гыйльманов «Хак чишмәсе»нә мифологик мәгънә сала, аның аша геройның ялганын фаш итәргә алына: герой «Хак чишмә» суын, изге чишмә суын эчеп ант итә, икенче тапкыр ялганга бара. Аның бу гамәле берьюлы ике якны бәхетсез итәргә сәләтле: бер яктан – Гөлшаһидәне, аның балаларын, икенче яктан – Гөлшаһидәнең ире Исмайны.

Хикәядә хакыйкатьне ачу өчен, вакыйгалар тагын да үстерелә: Нурулла үз көенә салмак кына, тыныч кына агып яткан чишмәгә ачуланып, саф суын болгата башлый. Һәм бу хәл хак чишелешкә – фаҗигагә китерә, чөнки «Татар мифлары» хезмәтендә автор үзе үк чишмәләр янында төкеренергә, нәҗесләнергә һәм чишмәнең суын болгатырга ярамавын искәртә.

Нәтиҗә-финал ачык: «Ямьсез җикеренеп, такмаклап торган Нурулла, үз ачуы белән мавыгып, тау аланындагы сазлыкка бата башлавын сизмәде дә. ...Менә ул үзенең афәтен тоеп, җан ачысы белән кычкырып җибәрде.

...Таныдылар: бу – Скотник Нурулланың җан авазы иде. Ләкин, нишләптер, кешеләр үзләрен бик сәер тоттылар. Хак чишмәсе ягына карангалап, таптанып тордылар да, тавыш-тынсыз гына, үз сукмакларына төшеп, йортларына таралыштылар...»

Һәр явызлык, кылган начар гамәл үз җәзасын алырга тиеш. Г.Гыйльманов прозасында бу табигый ышаныч шактый тәэсирле, гадәти булмаган алымнар һәм мифологик ышанулар ярдәмендә укучыга җиткерелә.

Шулай итеп, Г.Гыйльмановның балалар һәм яшүсмерләр өчен прозасы фәлсәфи төсләр галереясенә, халык күңелендә яшәп килгән төрле ышануларга нигезләнгән сюжетка, каршылыклы характерга ия геройларга гаять дәрәҗәдә бай, дип нәтиҗә ясарга җирлек зур. Язучының иҗатында татар прозасы өчен үзгәрәк, гадәти булмаган геройлар алгы планга чыкты. Табигый талант, төпле белем, дөньяга үзгә караш исә фикер һәм хис агышында авторның фикерләү куәсен, бары тик аңа гына хас стилен, уй тирәнлеген күрсәтергә ярдәм итә. Гомумән, Г.Гыйльманов – үзенчәлекле дөнья сурәтен тудыра алган, татар балалар һәм яшүсмерләр прозасына яңалык алып килгән әдип.

**Ләйлә МИНҺАҖЕВА,**
*филология фәннәре докторы*



*Шагыйрә Бикә Рәхимова (Миңлебикә Рәхмәтулла кызы Фәйзуллина) (1939-2011) Әлки районы Чуваш Кичүге авылында туа. Туган авылында – башлангыч, Әлкидә урта белем ала. Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. Элекке ССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият, тарих институтында эшли, мәктәптә татар теле укыта, Татарстан китап нәшриятында мөхәррир була.*

*Аның «Сәрвиназ», «Ачыл, күңел!», «Мәрхәмәт» һ.б. шигырь китаплары, «Бакый сагыш» исемле җыентыкта публицистик язмалары дөнья күрә. Ул балалар өчен дә шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр, пьесалар иҗат итә.*

*Бикә Рәхимованың халык язмышын үзәккә алып язылган, ватанга мәхәббәт белән сугарылган шигърияте әле дә күңел офыкларына яктылык бөркеп тора. Ә без укучыларыбызга бу юлы Бикә Рәхимованың заманча яңгырашын һич югалтмаган гамьле фикерләрен тәкъдим итәбез.*

# ГАМЬЛЕ ФИКЕРЛӘР

• Вакыт безне танымый. Кайчан йөзебезне җуйдык?..

• Уйсызлык телсезлеккә китерә, диләр. Бер уйласаң, нәкъ шулайдыр бу. Уйламый йөрсәң, синең өчен сүзне дошманың әйтер...

• Татар барыбер киңлеккә омтыла, Сабан туе бәйрәмен җир-җәя үткәреп булса да...

• Китап үткәнне үткәндә калдырмый, күз алдында тота.

• Килен белән каенана арасы кылычтан үткен, кылдан нечкә сират күперендә, кара-каршы торып, бер-береңә якынаю кебек. Шуңа чәчәкләр түшәп килсәң, упкынны тоймыйча да үтәсең...

• Суда көймәнең эзе калмый, ә менә суның көймәдә эзе кала.

• Карт агач та бәхетле, орлык очырган булса...

• Дөнья каршылыклардан тормый, без аңа карышабыз.

• Бу дөньяда кешегә кеше булу читенләшә бара: ерткыч сукмакларын салучылар күбәйде.

• Кылган гамәлең кеше күзенә күренерлек булса, үзең дә күренерсең.

• Кеше кылган яхшылык та, явызлык та бу дөньяда кала. «Теге дөнья»га кеше шуларның әҗерен ала: йә бәддога, йә дога...

• Күгәрченгә – җим, дуслыкка аралашу кирәк.

• Бүгенге шартларда татар теле укытучысы дәреснең яртысын ана телебезгә мәхәббәт уятуга багышларга мәҗбүр.

• Берзаман иң кадерле кешең булган берәүгә карата нәфрәт хисенә күчү үз-үзеңә нәфрәт булыр иде. Хатаңны татлы ярага әйләндер...

• Дөньяда тарихтан гыйбрәт алмаган бер генә халык бар...

• Мәхәббәтне сер итеп саклап булмый: йөзеңнән укып беләләр, үсеп чыккан канатларыңны күрәләр.

• Илһамлыга Илаһы булыша.

• Чүптән чүмәлә өюче үзе дә исләнеп бетә.

• Илдә чыпчык үлми. Чыпчык үлмәслек илең булса, син бәхетле.

• Нәфеснең чиге юк, аны чикли белгән генә бәхетле була.

• Дустың сер сыярлык булса, дөньяга серле тоелырсың.

• Дөнья сыңар куллы гына. Шуңа күрә әле сөя, әле кыйный. Ике куллы булса, берсе кыйнаганда, икенчесе яклар иде. Кеше моны үз тәҗрибәсендә белмимени?..

• Берәр бәндә рәнҗетсә, Ходай белә, диген. Коткару килер.

• Кеше кояш кебек – чыгышыннан баешына бара.

• Үз телең дипломатия теле булса, чит тел дуслык теле була.

• Иң куркак һәм хамелеон зат ул – явызлык. Явыз, гамәлен акларга тырышып, яла өстенә яла уйлап чыгарып, җәзадан кача. Ялт-йолт төс алыштырганда, чалыш йөзе чагылып, явызлыгы шом салып тора.

• Тик кенә басып торган багананың да дошманы була.

• Кешенең кеше булуының төп билгесе – мәрхәмәтле зат булу. Алай түгел икән, димәк, кеше булып җитмәгән әле.

• Тормыш ул – бурыч. Үзеңә тигән басуны сөрәсең, чәчәсең, урасың, сугасың, җилгәрәсең.

• Күгәрченнәр янында чыпчыклар да туена.

• Дөньяны аңлар өчен, тәҗрибә җыю мөһим. Әмма тәҗрибә капчыгың тулганда, гомер капчыгың бушый.

• Бәхет ул болытлар арасыннан чыккан Кояш кебек, һәр мизгелдә кире кереп китәргә мөмкин.

• Үз акылың ышанычлы булса, кешене дә ышандырырсың.

• Әшәкелек җилемсез дә ябыша.

• Туганнары белән оешып-берләшеп яшәүчеләрнең ятка йомышы төшми.

• Мәхәббәт мескен булмый, җавапсыз булырга мөмкин.

# ШАГЫЙРЬНЕҢ СОҢГЫ МӘХӘББӘТЕ*

*(1911-1912 елларда Габдулла Тукай тормышына кагылышлы, укучыларга мәгълүм булмаган вакыйгалар)*

Габдулла Тукайның бердәнбер мәхәббәте дип Зәйтүнә Мәүлетова исәпләнә. Шагыйрь аның белән берничә мәртәбә очрашкан һәм Зәйтүнәгә багышлап шигырьләр иҗат иткән. Чынлыкта исә, хатын-кызлардан читләшүче егет, мәхәббәт утында бер генә тапкыр янмаган...

Бөек даһиебыз хакында барысын да беләбез кебек тоелса да, тормыш итү дәверендә могҗизалар да булгалап куя. Басмаларымда туган җирем Мартукны телгә алу нәтиҗәсендә, үзем дә сизмәстән, мәңгелек Тукаебыз тормышыннан безгә бик аз мәгълүм, ә күпләргә бөтенләй билгесез вакыйганың ачылышына сәбәпче булдым.

90 нчы елларда «Казан утлары» журналында Мартук искә алынган повестем басылып чыкты. Көтмәгәндә-уйламаганда, Казанда яшәүче, укымышлы сиксән яшьлек ханымнан шактый күләмле генә хат килеп төште. Әлеге ханым журнал белән танышканда, Мартук искә алынуын күрә. Баксаң, Бохара һәм Сәмәркандның Ислам үзәкләрендә кайчандыр лекцияләр укыган, хезмәтләр бастырган дин белгече, дин әһеле – бабасы сугышка кадәр бездә сөргендә булган. Шунлыктан, яшь чагында Казанда гомер итүче әлеге ханымның гаиләсен безнең Мартук Мәккә кебек илһамландырган – алар анда айга бер тапкыр хат юллау, елга бер тапкыр посылка җибәрү, ике елга бер туганнарын барып күрү хокукына ия булган. Коточкыч рәхимсез еллар! Бу хатны мин «Казан утлары» журналына тапшырдым. Әнием исән чакта, әлеге дин әһеленең эзенә төшәргә тырыштым. Кызганыч ки, вакыт шундый лаеклы шәхесләрнең дә эзләрен юа. Шулай да әлеге имам Мартукта яшәүче өлкән буын вәкилләренең хәтерендә уелып калган. 30 нчы елларда посёлокта шушы дин әһеленең яшәвен ишетеп беләләр. Мөгаен, аның бездә яшәве Мартукта һәрвакытта тирән белемле, укымышлы имамнар булуына этәргеч биргәндер. Әлеге имамнарны күрше посёлокларга, хәтта Актүбә һәм Акбүләккә дә еш чакыралар.



*Әминә Хәбибуллина (1895-1976). 1972 ел. Фото Рауль Мир-Хәйдәров архивыннан.*

Ни өчен әле мин аның турында язам? Чөнки язмыш җиле Мартукка китереп ташлаган, алда бәян ителәчәк Әминә исемле ханымны ул дин белгече, әлбәттә, тәгаен белгәндер. Казаннан килгән ике укымышлы кеше кечкенә генә посёлокта күрешмичә калмагандыр.

Интернет челтәренә, «Фейсбук»ка Мартук хатирәләрен чагылдырган «Балачагым станциясе» хикәясе урнаштырылгач, кинәт тагын хат килеп төште. Барлык татарларга да кызыклы булыр дип уйлыйм – бу хатның эчтәлеге Тукайның шәхси тормышына кагылышлы истәлекләрне бәян итә. Хатны сезнең игътибарга искәрмәләрсез генә тәкъдим итәм, аннан да төгәлрәк, ачыграк җиткереп булмас. Хат, кат-кат тикшерелеп анализланды, сүз барачак кешеләрнең фотосурәтләре, хәтта каберләре дә табылды. Тик «...башта Казакъстанда, аннары Татарстанда кымыз эчеп дәваланган» дигән җөмләдә кымыз турында төгәлсезлек барлыгын искәртү урынлы булыр.

## Рамил Шерланов хаты

*Әлеге вакыйга турында миңа әниемнең әнисе – әбием бәян итте.*

*Якынча бу хәл 1912 елда була. Ул вакытта алар Казан губернасы Арча өязе Күпербаш авылында яшәгәннәр. Әтисе, ягъни минем карт бабам таза хәлле крестьян саналган, әнисе, ягъни минем карт әбием хуҗабикә булган. Карт бабам үтә тәкъва, югары әхлаклы, укымышлы, таләпчән, әмма гадел кеше була, шуңа авылның старостасы*

* Журнал варианты

*итеп сайлап куелгандыр да. Әбиемнең Әминә исемле бик чибәр, тыйнак, эш сөючән унсигез яшьлек бертуган апасы булган. Туганына хуҗалык эшләрендә Әминә һәрдаим булышлык иткән. Шушы авылга Казаннан танылган татар шагыйре Габдулла Тукай кайтып йөргән. Ул чахотка (үпкә чире) белән авырганлыктан, табиблар киңәше буенча, тормышының соңгы елларында башта Казакъстанда, аннары Татарстанда кымыз эчеп дәваланган. Ә минем карт бабам асраган бия сөте Казан губернасында иң яхшысы саналган. Әминә, чынаякка салып, яңа гына эшләнгән кымызны Тукайга кертә торган булган. Тукай, кымыз эчә-эчә, Әминәдән күзләрен дә алмый, аның белән озак кына гәпләшеп утырган, киткәндә рәхмәт әйтеп саубуллашкан. Ул вакытта шагыйрь агарынган йөзле, үтә ябык булса да, йөз-торышы нәфислеген, матурлыгын җуймаган. Яхшы киенгән. Карасу сюртуктан, жилет, костюмнан, түбәтәйдән йөргән. Шагыйрь үтә пөхтә, тыйнак, укымышлы, акыллы, кызыклы кеше буларак тәэсир калдырган. Алар бер-берсен бер күрүдә яратканнар. Эш шуңа кадәр барып җиткән ки, Тукай карт бабамнан кызы белән никахлашырга рөхсәт сораган. Тик карт бабам, тормышы корылмаган кешегә кызын бирүдән баш тарткан (кызганычка каршы, ул елларда шагыйрьләргә дә артистларга булган кебек караш хөкем сөрә).*

*1913 елда 27 яшендә Габдулла Тукай, гаилә дә кормыйча, хәерчелектә, үпкә чиреннән вафат була, ә Әминә, революциядән соң, кызылармияче Баһаветдиновка кияүгә чыгып, аның белән Казакъстанга, Актүбә өлкәсе Мартук шәһәренә юл тота. Анда ул ике кыз табып үстерә. Хәзерге вакытта Мартук шәһәрендә оныклары, оныкчыклары, оныкларының оныклары яши. Әминә гомеренең соңгы көннәренә кадәр үзенең беренче мәхәббәте булган Габдулла Тукайны оныта алмый, аның шигырьләрен кат-кат укып, акрын гына күз яшьләрен түгә. Әбием миңа Габдулла Тукайның Әминәгә багышланган шигыре барлыгын әйткән иде, тик шигырьнең исеме хәтердә калмаган.*

*Хәзерге вакытта мин Нукуста (Каракалпакстанда, Үзбәкстанда) яшим. Әминә апа (ире фамилиясендә), кызлары Фәүзия һәм Мәрзия Баһаветдинова булып йөриләр. Әминә апаның оныклары – Марат белән Гөлкәй – Мартукта яши, ә Рөстәм исемле онығы һәм аның балалары (үземнең туганнан туган апам әйтүе буенча) Әминә апаның туган ягында – Казан өлкәсенең Арча шәһәрендә гомер итәләр. Миндә Әминә апаның фотосурәтләре юк. Алар туганнан туган апамда бар иде (минем аларны күргәнем булды). Әмма ул (мулла хатыны – абыстай) аларны яндырган (мөселман йолалары буенча, үлгән туганнарның фотоларын (йөзләрен) сакларга ярамый). Абзыемның хатыныннан сорап белешү дә урынлы булыр дип уйлыйм, аларда да фотосурәтләрнең саклану ихтималы бар. Миндә әбиемнең (Әминә апаның сеңлесенең) фотосурәте бар. Уйлавымча, Мартуктагы оныкларында Әминә апаның һәм аның кызларының фоторәсемнәре булырга тиеш.*

*Мин Әминә апаның бертуган сеңлесенең онығы булам. Сүз уңаеннан, мөфти Госман хәзрәт Исхакый – минем әнием Сәмигуллина Рәйсә Хисмәтулла кызының өченче буын ир туганы, ә мөфти Тәлгать Таҗетдин әниемә кияү тиешле (ул әниемнең өченче буын сеңлесенә өйләнгән). Госман абыйның әнисе (шагыйрә Рәшидә апа) белән Тәлгать абыйның каенанасы (Сәлимә апа) – минем бабам Хисмәтулла Сәмигуллинның туганнан туган сеңелләре. Ул ятимәләрне минем бабамның абыйсы – Заһри абый Сәмигуллин тәрбияләп үстергән.*

*Әбием Хәбибуллина Гыйльмениса метрикасындагы мәгълүматлар: Әминә апаның кыз чагындагы фамилиясе – Хәбибуллина (минемчә, ул, кияүгә чыккач, иренең фамилиясенә күчеп, Баһаветдинова булып йөри). Аның әтисенең (минем карт бабамның) исем-фамилиясе – Дәүләтшин Хәбибулла, әнисенең (минем карт әбиемнең) исем-фамилиясе Галиуллина Мәхүбҗамал була. Октябрь инкыйлабыннан соң – 1918 елда әниемнең әтисен, кулак буларак, кызылармиячеләр атып үтерергә булалар (аларның кулларында аны атарга дигән мандат була), урманга алып китеп, карарны укыйлар, әлеге хөкемне тормышка ашыра башлаганда, Күпербаш авылы крестьяннары, безне туендыручыны атасыз икән, безне дә үтерегез, дип, аның янәшәсенә басалар. Әниемнең әтисен атмыйча калдыралар. Барлык мал-мөлкәтләрен тартып алып, аның күп балалы гаиләсен (аның 10 баласы була) ач-ялангач калдыралар. Шуннан соң, ачлыкның ни икәнен дә белмәгән авыл халкы АЧЛЫК ачысын татый.*

Рамил Шерлановның хатын алганнан соң, май башында, Г.Тукайның сөйгәненең эзләрен табарга өметләнеп, мин Мартукка юл тоттым. Һәм, ни гаҗәп, миңа максатыма ирешү мөмкин булды.

Мартук архивын өйрәнгәндә, Рамил Шерлановның нәрсәдәдер ялгышканын һәм Әминә апаның тормышы турында тулы мәгълүматтан хәбәрдар булмавын ачыкладым. Шунлыктан, шактый гына күзәтелгән төгәлсезлекләрне ачарга мәҗбүрмен.

1. Әминә апа гаиләсе белән Мартукка 1918 елда түгел, ә Казакъстан белән Үзбәкстанда алты ел каңгырап йөргәннән соң (бу турыда Әминә апаның оныгы Рөстәм Әхмәтҗанов тулы итеп яза), 1945 елның җәй аенда кайтып төшә.

2. Әминә апаның барлык балалары да Мартукта түгел, ә Мөндештә туа.

3. Әминә апаның беренче ире кызылармияче булмый, киресенчә, кызылармия вәкилләре аны атып үтерәләр. Шулар ук Әминәнең әтисен «кулак», дип, аздан гына атмый калалар. Бәхеткә каршы, Күпербаш халкы аны коткара.

Шул нисбәттән, Рамил Шерланов турында мәгълүмат биреп китү дә урынлы булыр. Ул – Әминә апаның кече кыз туганы Гыйльменисаның оныгы. Рамил Мартукка еш кайтып йөргән, Әминә апа белән аның соңгы көннәренә кадәр аралашып яшәгән. Рамил Шерлановның әбисе Гыйльмениса Хисмәтулла Сәмигуллин белән тормыш кора. Алар нәселе соңгы йөз елда Ташкентта, Алма-Атада, Казанда, Уфада, Петербургта һәм башка шәһәрләрдә югары дини вазифалар башкара.

Россия мөселманнарының хәзерге мөфтие Тәлгать Таҗетдин Рәйсә ханымның якын кыз туганы – Рамил Шерлановның әнисе белән никахта.

Хөрмәтле мөфти Госман хәзрәт Исхакый – Рамил Шерланов әнисенең өченче буын ир туганы. Госман хәзрәтнең әнисе Рәшидә абыстай белән Тәлгать абыйның каенанасы Сәлимә апа – Рамилнең бабасы Хисмәтулла Сәмигуллинның туганнан туган сеңелләре. Рәшидә белән Сәлимә ятим калгач, ул ятимәләрне Рамил бабасының олы абыйсы – Заһри абый Сәмигуллин тәрбияләп үстергән.

Тукайның сөйгәне тирәсендә менә шундый катлаулы һәм югары туганлык мөнәсәбәтләре урнаша.

Әминә Хәбибуллина белән Тукай арасында шәхси бәйләнешләр булуына инандырганы өчен, мин Шерлановка бик тә рәхмәтлемен. Шулай ук ул миңа 1911-1912 елларда Әминә белән Тукайның бергә булган урыннарын да атады. Эзләнүләрем нәтиҗәсендә, Тукайның Күпербаш дип аталган борынгы татар авылын ни өчен сайлавына төшендем. Тукай гел шушы авылга тартылган, анда иҗат иткән, дәваланган. Әминә Күпербашта яшәгән, һәм Тукай, кызны ешрак күрү ниятеннән, кыска вакыт аралыгында яшәп тору өчен, бүлмәләр дә ала торган булган.

Мин Әминә апаны яхшы хәтерлим, аны вакытлар аралыгы аша аермачык, үтәли күрәм, аның табигате белән итагатьле, инсафлы, әдәпле булуын тоям, сөйләшүе, үз-үзен тотышы, көнкүреш гадәтләре дә, мартуклыларныкына охшамаган, үзягы зыялыларын хәтерләтә иде, һәм бу сыйфатлары аның кызларына да күчкән. Кызлары Мәрзия белән Фәүзиянең яшь чаклары да исемдә, үз-үзләрен тотышлары ягыннан гына түгел, фикер йөртүләре буенча да аларга әниләре кебек мөстәкыйльлек хас иде. Кабатлап китү булса да, шул үзенчәлекле: Мартук Татаркасында без – татарлар бер төркем булып яшәдәк, ә Мәрзия апа, минем үги әтием Исмәгыйль абый эшләгән оешмада ниндидер җитәкче иде һәм аның берничә мәртәбә безнең өебездә дә булганы бар. Аның бертуган сеңлесе Фәүзия апа хакында да шул ук сүзләрне әйтә алам. Искитмәле, әмма Фәүзия белән Мәрзия Татарстанга, әниләре туып үскән төбәккә күңелләре белән һәрвакыт тартылды, алар анда еш булып, Әминә апаны да үзләре белән туган ягына алып кайталар иде. Шулай ук үзләре исән вакытта алар Күпербашта җирләнгән туганнарының каберләрен дә карап, чистартып тордылар.

Мартукта Әминә апаның бердәнбер якын кешесе – аның 1951 елда туган оныгы Марат Әхмәтҗанов кына яши. Марат Рамил Шерланов язганнарны раслап кына калмыйча, әбисе кулында үскәнлектән, Әминә апа турында күп кенә өстәмәләр дә, мәгълүматка төгәллек тә кертте: Әминә апа 1895 елда туган, 1976 елда вафат булган. Унҗиде яшендә Тукай белән очрашкан. Ул туып-үскән Күпербаш авылына Тукай кәҗә сөтенә килеп йөргән. 1911-1912 елларда шагыйрь шул авылдан ерак яшәмәгән

һәм шуңа күрә анда шактый еш булгалаган. Шагыйрь биографиясендә әлеге адреслар төгәл күрсәтелгән.

Миндә Әминә апаның икенче оныгы Рөстәм Әхмәтҗановның хаты саклана. Бу хаттагы мәгълүматлар Рамил Шерлановка билгеле булмаган, шулай ук минем язмаларымда өйрәнелми калган ак тапларны ачыкларга, барларга, тулыландырырга мөмкинлек бирә. Аның истәлекләре ярдәмендә шагыйрь язмышына бәйле тормышының тулы, төгәлләнгән тарихы күзаллана. Сезгә дә аның истәлекләрен үзгәрешләр кертмичә генә тәкъдим итәм.

## Рөстәм Әхмәтҗанов хаты

*«Минем әбиемнең тормышы җиңелләрдән булмаган, әтисе «кулак» дип атарга хөкем ителгән кызның гомер юлы җиңелләрдән була да алмаган. 1913 елдан башлап аның бөтен хәяте рәхимсез вакыйгалар, үзгәрешсез, дәвамлы кырыс дәвер сынаулары аша уза. 1937 елда Әминә апа гаиләсе, дүрт баласын алып, ашыгыч рәвештә, туган җирләрен ташлап китәргә мәҗбүр була. Бу – аерым бер моңсу тарих, ул турыда аерым бер китап язып булыр иде. Гомумән, минем әбиемнең 1914 елгы Беренче Бөтендөнья сугышы, революция, гражданнар сугышы, 20 нче еллардагы ачлык, 30 нчы еллардагы репрессияләр, Бөек Ватан сугышы өермәләрендә кайнаган тормышы Тукай белән берничек тә бәйләнмәгән. Куылып, сугылып йөргән вакытларында ул кызларына, ярый әле Тукай халкы кичергән әлеге газаплы елларны күрмәде, дип кабатлый торган булган. Рамил Шерланов хатыннан күренгәнчә, Әминә Хәбибуллина һәм Хәйрулла Баһаветдиновлардан башлап, безнең нәселнең ишәйгәне күзәтелә. Шәхсән үзем дә әбиемнең бертуганнары Гыйльмениса һәм Нурулла ягыннан булган, бигрәк тә Хәйрулланың әтисе ягыннан булган барлык туганнарыбызны белми идем. Шуңа да карамастан, хәтта Нукус кебек Советлар Союзының башка ерак төбәгендә дә, Тукай һәм Әминә апа тарихын хәтерләүләре билгеле. Без – Әминә һәм Хәйрулланың оныклары белгән мәгълүмат белән Р.Шерланов искә алган истәлекләр тәңгәл килә.*

*Моңа кадәр Сәмигуллин-Баһаветдиновлар буыны ягыннан безнең нәселне Татарстан һәм Башкортстанның югары дин әһелләре белән туганлык җепләре бәйләвен мин әле белми дә идем.*

*Тукай үлеменнән соң, 1918 елда әбием Мөндеш авылының таза хәлле, легендар, авыл халкының әле дә хәтерендә сакланучы Баһаветдин Камалиевның олы улы Әсхәдуллага кияүгә чыга. Баһаветдин Камалиевның оныгы – Арча төбәгендә һәркем өчен таныш, якташларының ихтирамын казанучы Мидхәт Нуруллин әле исән чагында Баһаветдин бабайның озын буйлы, физик яктан нык, көчле эчке энергиягә ия булуын, карашы белән генә дә кешене аяктан ега алуын, ат белән янәшә басып, яки атның көче җитмәгәндә, берүзе генә дә утын төялгән арбаны тауга таба тартып менүен һәм бик күп башка нәрсәләр турында сөйләп калдырган иде. Ул елларда фаҗигале хәлләр еш булып торган. 1918 елда ярлылар комитеты, продразвёрстка отрядлары котырына. Алар таза хәлле крестьяннарның икмәкләрен арзан бәядән генә сатып ала яки бөтенләй түләп тә тормыйча тартып ала. Крестьяннар ашлыкларын бушка тапшырудан баш тарткач,1918 елның көз ахырларында Арчага күпсанлы кызылармиячеләр отряды килеп төшә. Соңрак «сәнәк сугышы» дип аталган әлеге крестьяннар күтәрелеше алар тарафыннан рәхимсез рәвештә бастырыла. Анда 31 крестьян үтерелә, шулар арасында Әминәнең ире Әсхәдулла да була. 1918 елда Әминәнең әти-әнисе «кулак» дип игълан ителә, әтисе Хәбибулланы авылдашлары үлемнән йолып кала. Әбиемнең беренче никахы кыска була, алар ире Әсхәдулла белән дүрт ай гына яшәп калалар, балалары да булмый. Шулай да Әминәнең каенатасы әлеге чуалышлар чорында җитез, эш сөючән киленен гаиләдән җибәрергә теләми һәм, һәммәсенең ризалыгы белән икенче улы Хәйрулланы Әминәгә өйләндерә. Мөндештә аларның балалары дөньяга килә. 1922 елда – Мәрзия, 1926 елда – минем әнием Фәүзия, 1931 елда Камил туа. Кече уллары Вахит 1937 елда туып, ике ел гына яшәп кала. 1936 елда Баһаветдин бабай вафатыннан соң, 30 нчы еллар ахырында әбием гаиләсе белән Татарстаннан күченеп китә. Шулай итеп, чит җирләрдә күченеп йөрүләр, төрле авырлыклар башлана,*

*нужа якадан тарта. Төрле елларда алар әле Үзбәкстанда, әле Казакъстанда яшиләр. 1950 елда аның ире вафат була, ә соңрак ул тагын бер зур югалту кичерә, 21 яшьлек бердәнбер улы Ташкент шәһәрендә мәңгегә күзләрен йома. Әминә апа гадәттән тыш шат күңеллелеге, югары интеллекты белән аерылып торды, аңа нечкә юмор хисе хас булды. Ул безне – үзенең оныкларын бик ярата иде, бигрәк тә безнең өлкәнебез Маратка мөнәсәбәте үзгә булды. Нәкъ менә аңа Тукай әкиятләрен укыды. Безнең арабыздан Марат кына гаилә ядкарен – әбигә бүләк ителгән, Тукайның әкиятләр китабын актара иде, аңа гына бүгенге көндә сакланып калмаган Тукай фотосурәтен күрү һәм кулына алу да насыйп була.*

*Тукай яшь кыз – Әминәгә үзенең фотографиясен һәм шигырьләре тупланган ике китабын (берсе – рәсемнәр белән эшләнгән «Шүрәле» китабы) бүләк иткән. Марат әбисенең яшь чактагы фоторәсемен дә хәтерли: ул калкурак кына гәүдәле, зифа буйлы, ак йөзле булган, аның бу кыяфәте олыгайгач та үзгәрмәгән. Арчада да, Мартукта да Әминә апаның әлегә кадәр очрамаган фотолары табылды.*

*Әйтеп үтелгәнчә, Әминә апа бик тыйнак кеше иде, гомер буе үзенең беренче мәхәббәте, Тукайга булган мәхәббәте турындагы хатирәләрен йөрәгендә саклады. Тукайга булган хисләре һәм үзара булган мөнәсәбәтләр тарихы ире үлеменнән соң да гаиләдән читкә чыгарылмады. Әлбәттә, гаиләдә аның турында ишетеп белгәнлектән, без – оныклары әлеге тарих кыйссасын сораштыргач, әбиебез, тыйнак кына елмаеп, Тукайның үзләренә килүе турында сөйли иде. Һичшиксез, алар арасында булган үзара мөнәсәбәтләр, әхлакый чикләрне узмаган, гыйффәтлелекне бозмаган, шунлыктан әлеге мизгелләр кадерледер дә. Гомер буе Әминә апа һәм аның кызлары Татарстанны сагынып искә алдылар һәм кайчан да булса ватаннарына кайту турында хыялланып яшәделәр. Шуны да әйтү мәслихәт: Әминәнең яраткан сеңлесе Гыйльмениса да, Татарстанны ташлап, Ташкентка күченеп китте. Хисмәтулла Сәмигуллин белән алар ике гаҗәеп кыз – Рәйсә белән Илсөяне һәм бер ул – Илгизне табып үстерделәр. Барлык Хәбибуллиннар, Сәмигуллиннар, Баһаветдиновлар нәселе үзара тыгыз аралашып, бер-берләренә Ташкентка, Нукуска, Мартукка, Казанга, Күпербашка барып, кунакка йөрештеләр. Кызганычка каршы, Әминә әбиемнең туган җирләренә кайту хыялы тормышка ашмады. Соңгы елларда әбием бик каты авырды һәм 1976 елның җәендә, йоклаган җиреннән аның йөрәге тибүдән туктады. Ул Мартукта мөселман зиратында күмелгән. Менә шулай итеп, Әминә әбиемнең хәсрәт тулы тормышы, шуның белән бергә аның мәхәббәт тарихы да тәмамланды.*

*Әлеге тарих турында ахырга кадәр укып чыгучыларга бик рәхмәтлемен. Шулай ук бөек шагыйребезгә, шул исәптән аның соңгы мәхәббәтенә кагылышлы барлык нәрсәләргә игътибарлы булсак иде дигән өметемне җиткерәм.*

Әминә апаның бөтен тормышы 1912 елда Г.Тукай белән очрашкан көннән алып, 1976 елга, ягъни Мартукта узган соңгы көннәренә кадәр җентекләп өйрәнелде. Шунлыктан, Хәбибуллиннар, Баһаветдиновлар нәселе ягыннан булган туганнарының шаһәдәтнамәләренә, истәлекләренә, фотосурәтләренә нигезләнү аның тормышын күзаллау мөмкинлеген бирә.

Әминә апа, дәвамлы озын гомер кичереп, 81 яшендә дөнья куя. Мартуктагы мөселман зиратының кабер ташлары белән танышканнан соң, аның кебек озак яшәүчеләр 1895 елда гына түгел, ә хәтта XIX гасыр башында да булмавын кистереп әйтә алам. Туган җирләрендә төпләнеп гомер итүче чордашларыннан фәкать өчесе генә 60 яшькә җитә алган. Шул дәвер өчен Әминә апаның феноменаль яшен ассызыклаганда, Аллаһы Тәгаләнең аның язмышына карата булган рәхмәте турында уйлыйм: Тукай белән очрашу, түзә алмаслык рәхимсез елларда шулкадәрле авыр тормыш кичерү, шуңа да карамастан балаларын, оныкларын аякка бастыру һәм үзеннән соң күпсанлы лаеклы буын калдыру.

**Рауль МИР-ХӘЙДӘРОВ**

**Редакциядән:** *Язманың тулы вариантын журнал сайтыннан укый аласыз.*

# «ҮЗ ИМАНЫ БЕЛӘН ЯШИ КЕШЕ...»

Исән чагында тиешле бәясен алып бетермәгән, шунлыктан халык арасында М.Әгъләмов, Зөлфәт, Р.Гаташ һ.б. кайбер мәртәбәле каләм ияләре дәрәҗәсендә популярлашып китә алмаган, әмма шигъриятне чынлап аңлаучылар чиксез олылаган, бигрәк тә безнең буын остазы да санаган шагыйрьләр арасында Сибгатуллин Минкадыйр Идият улы (1942-1994), һичшиксез, бинибая талант иясе буларак күңелгә килә. Дөрес, аның, иң беренчеләрдән булып, Х.Туфан күреп алган шигърияте Ф.Галимуллин, М.Мәһдиев, М.Галиев, В.Имамов, Р.Гарипов, М.Вәлиев, Н.Акмал, Р.Бәшәр һ.б. каләмдәшләре тарафыннан югары бәяләнде. Бигрәк тә Т.Галиуллин, М.Шабаевлар К.Сибгатуллин иҗатын пропагандалауга зур өлеш кертте, Ф.Сафин исә кандидатлык диссертациясендә, аны киңкырлы һәм үзенчәлекле яктыртып, шагыйрьнең сирәк очрый торган кабатланмас талант булуын, үз әдәби стиленә иялеген күрсәтте.

Кадыйр Сибгатуллин иҗатына кычкырып торган өч зур йогынты бар. Беренче чиратта, болар – әлбәттә, Такташ һәм аеруча Туфан, әмма үтә халыкчан каләменә, бигрәк тә шәхесенә, иҗтимагый барышны күзаллауларына Тукай тәэсире дә сизелеп торырлык. Әнә шуңа күрә, әлеге өч гигантны берләштереп һәм Кадыйр Сибгатуллинның тормыш-яшәешкә мөнәсәбәтен ачып, М.Вәлиев аның поэзиясендәге төп хисне: «Тукайча, Такташча, Туфанча әрнү»[1], дип атады да. Иҗатының башыннан ук, алар кебек, каләмнең гамьлелеген алга куйган К.Сибгатуллин «Атлар көтте авыл малайлары» шәлкеменә эпиграфта болай дип язды: *«Игелеге илгә булыр ирнең, / гаме булса уй һәм хисенең»*.

Тукайны өлкәнәйгән саен, каләмең чарланган саен, ныграк аңлыйсың шикелле. Бу фикерне башкалардан да еш ишетәм. Аның үткен телле поэзиясе үз гамәлләреңне бәяләгәндә дә, тормыш күренешләре турында уйланганда да, милләт язмышы өчен борчылганда да күңелгә килә. К.Сибгатуллинның Г.Тукайның *«Ни сәбәптән җир йөзендә тәңгә – мунча, җанга юк?!»* юлларын эпиграф иткән «Яшь белән дә, тән һәм җан белән дә...» әсәре шушы рәвешчә тәмамлана: *«Кешенеке кебек бар минем дә / чорым, җирем, анам. / Тик барыбер, керсезме, дип, җаным, / мин Тукайга барам»*.

Әсәр татар әдәбиятында популяр булган «Мин Тукайга барам» мотивын үзенчәлекле контекст аша җиткерә. Шагыйрь әлеге әсәрендә һичкемнең катлаулы тормышта керләнмичә кала алмаганын, әмма чын кешенең иман сафлыгына омтылганын аңлатырга тели. Бу очракта, әлбәттә, күз алдыбызга иң гадел хөкемдар рәвешендә Тукай торып баса.

Н.Гафиятуллина «XX гасыр шигъриятендә Тукай» дип аталган хезмәтендә әлеге әсәрдә К.Сибгатуллинның «шагыйрьнең сүзләрен, «уйнатып», үзенә һәм чорга бәя бирүгә» юнәлтүен, шигырьгә «паратекстуальлек алымы» кертүен һәм «Тукайга субъектив бәя өстенлек» алуны язды. «Шартлылык шигырьнең колачлау киңлеген, фәлсәфәсен киңәйтә, тирәнәйтә. Автор дөнья, тормыш кануннарының кеше күңеленә, рухына тискәре йогынтысын күрсәтергә тели», – дип белдерде, әсәрне мөселманнарның «тумыштан саф, керсез яшь җаннар олыгайган саен гөнаһлар туплый бара» фәлсәфәсе белән дә бәйләде.

Кадыйр Сибгатуллин иҗатының моңлылыгын күпләр билгели. Ул аның «Таңнар, кичәләр», «Гомерем дулкыннары» һәм хәтта бер сүз белән генә белдерелгән «Гамь», «Әманәт» китап исемнәреннән дә саркыла сыман. Шагыйрь шул хискә чикләр булмаган «Уел» поэмасында моңның үзе белән үк бергә туганлыгын әйтә һәм аның тарихи-иҗтимагый тамырларын күрсәтә. Тәнкыйтьнең югары бәясен алган әлеге әсәр Кадыйр Сибгатуллинның Тукай белән диалогы рәвешендә дә кабул ителә, чөнки ул анда остазының милли моңга бәйле фикер-кичерешләрен чынбарлык материалына таянып киңәйтә, раслый һәм эпиграфына Тукайның: *«Ишеттем мин кичә берәү җырлый... / ...Әллә нинди зарлы, моңлы көй»*, – дигән юлларын куя.

К.Сибгатуллин, Г.Тукай кебек үк, социаль-иҗтимагый проблемаларны чагылдырганда, реаль чынбарлыктан чыгып, заман тудырган шартларны исәпкә алып,

[1] Вәлиев М. Авылыбыз юлын югалтсак // Казан утлары. – 1982. – №6. – 171 б.

объектив фикер йөртүче шагыйрьләрнең берсе иде. Ул да татар халкын саклап калуда һәм алгарышка илтүдә милләтнең зыялы катламына, әдәбиятка, бигрәк тә көрәшче рухлы сәнгати сүзгә зур өмет баглады.

Шагыйрьнең Тукайчанлыгы рус белән иңгә-иң яшәгән татарның Рәсәйдәге иҗтимагый-сәяси хакларын, ә гаделлек өмет иткән, рухи азатлыкка омтылган шәхескә кешечә мөнәсәбәт таләп итүдә, татар тарихына олы мәхәббәт уятуда, хатын-кызның шигъри хисләр кабындырырлык гүзәллегенә сокландуда, аналарга табынуда һәм, гомумән алганда, борынгыдан килгән шигъриятебезнең уңай традицияләрен әдәбиятта ныгытуда, милли-халыкчан язуда чагылыш тапты.

К.Сибгатуллинның, язмышлары халыкныкы белән тыгыз үрелгән әдәби остазларыныкы кебек үк, милләтебезнең уйсыз-гамьсез катламы өчен җаны әрнеде; ул аны рухи-мәдәни-иҗтимагый томаналык чоңгылыннан чыгару юлларын эзләп баш ватты. Шагыйрьне үз телен онытткан, кыйбласын югалткан, иҗатчының җанын-уен салган кыйммәтле сүзен бәһаләмәгән бүгенге урта буынның, аларның балаларының язмышы гаять борчыды. Ул яшәешнең без көтмәгән, әле кайчан гына булуы мөмкин тоелмаган күренешләреннән имәнеп киткәндәй яза, әле анда, әле монда тормыш парадоксларын күреп ала иде. «Туфан белән сөйләшү» поэмасының өченче бүлегендә һәркемне уйга калдырырлык мондый юллар бар:

*Әй буталды дөнья,*
*буталды…*
*…Татар теле дәресе:*
*укучылар*
*тәрҗемәдә укый Тукайны.*
*Кая китә, дөнья, кыйммәтләрең?*
*Бәяләнә алмый торганнар…*
*Ничә тиен тора безнең шигырь?*
*Ничә тиен тора бу җаннар?*

К.Сибгатуллинның: *«Заманалар затны юк итәләр, / чүп итәләр, / туфрак итәләр»*, – диюе белән килешергә кирәктер. Бу бит күпмедер дәрәҗәдә шул ук Тукайны укымауда, санга сукмауда яисә татар баласының хәтта ана теле дәресендә тәрҗемәдә укуында да чагыла. Талантның, әсәрләренең халык күңеленнән китүе – шагыйрь өчен иленнән тибәрелүеннән, сөргеннәргә сөрелүеннән дә авыррак хәл түгелмени? Кадыйр абый иҗтимагый барышны, бүгенгене чагылдырганда әрнүле-моңлы язса да, тарихның дөреслекне бер кайтарасына ышанычын сүндермәде. Бу «Туфан белән сөйләшү» поэмасында да күренеп тора. Ул анда иманлы адәмнәрнең милләтне яшәтеп калдырасына өметен дә тасвирлый. К.Сибгатуллин шигъриятенең төп герое кем, дип сорасалар, көрәшче, дип әйтергә мөмкин. Ул аның әсәрләрендә балачагы, үсмерлеге сугыш елларына туры килгәннәрнең исән калу өчен җан тырмашуында; ирсез калган хатыннарның гаиләне тартып баруында һәм балаларын зур тормышка алып керүендә; ир-атның илебез төзелешләрендә физик мөмкинлекләрен – көчен, егәрен күрсәтүендә; шагыйрьнең – каләмдә һәм иманда сыналуында чагылыш таба. Бу санауны туктаусыз дәвам итәргә була. Сугышчан каләмне Кадыйр абыйга Тукай тоттырган, көрәшче рухын анда Такташлар, Туфаннар тәрбияләгән. Көрәш мотивы аның иҗатында кызыл җеп булып сузыла. Гаделләрне, иманлыларны, ачларны, горурларны аларның капма-каршысы белән янәшә куйган «Тора дөнья» шигырендә шагыйрь шушындый зур гомумиләштерү ясый: *«Артында да аның көрәш кенә, / көрәш кенә киләчәге аның. / Тик көрәштән тора бүген дөнья, / көрәш кенә йөртә дөнья канын!»*

Гаҗәеп тирән фикерле һәм үтә үзенчәлекле образларга бай әсәрләр язып та, зәвыклы сүз тәмен белгән, кешене урынына һәм холкына мөнәсәбәттә бәяләмәгән каләмдәшләре күңелендә генә чын-чынлап кадерләнгән Кадыйр Сибгатуллин исемен әдәбият тарихыбызга алтын җепләр белән чигәсе килә.

**Рифә РАХМАН**

# «АК КАЛФАКНЫҢ ТАБЫЛГАН ЧАГЫ...»



Бөтендөнья татар конгрессының «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы җитәкчесе **Кадрия Рәис кызы ИДРИСОВА** – җир шарында сибелеп яшәүче татар халкының гүзәл затларын берләштерүче, милләт җанлы шәхесләребезнең берсе.

Татар хатын-кызы дигәндә, һәркайсыбыз үзенең әнисен һәм әбисен уйлап куядыр. Безнең рухыбызга сеңгән тәрбия, милли үзаң, дөньяга караш, беренче нәүбәттә, әниләребездән күчә. Тормышка әни һәм әбиләребезнең бишек җырлары аша ялганабыз, аларның иркәләп эндәшүеннән телебезнең матурлыгын тоябыз. Әтиләр гаиләнең терәге булса, әниләр – йөрәге. Элек-электән үк балага милли үзаңны сеңдерү, телне, гореф-гадәтләрне өйрәтү хатын-кызның төп бурычы булып саналган. Димәк, алар алдында аеруча зур хак билгеләнгән. «Балачакта алган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас», – дип язып калдырган күренекле галимебез Ризаэддин Фәхреддин.

Бүгенге көн шартларында яшь буынны тәрбияләүдә таләпләр тагын да югары. Телебез, рухи кыйммәтләребез югалуга җирлек туган чор. Ни өчендер, чит халыкларның мәдәнияте, яшәеше татар халкына зуррак йогынты ясый кебек. Читләрнең тормыш рәвешләре безгә туры килә аламы соң? Әлбәттә, юк. Һәр халыкның үз матурлыгы, үз җире, үз йөзе, үз моңы бар. Тулы бәхет шулардадыр.

*«Кеше үз гомерен бер елга кайгыртса, иген иксен, ун елга кайгыртса, агач утыртсын, йөз елга кайгыртса, кеше тәрбияләсен. Бала туу – һәр гаиләдә зур бәйрәм. Сабый дөньяга аваз салу белән, әллә никадәр сораулар, яңа борчу-мәшәкатьләр алга килеп баса. Җәмгыятебездә, тормыш-көнкүрешебездә булган яшәешебез бала тәрбияләүдә әкренләп борынгыдан килгән гореф-гадәтләребезне, йолаларыбызны читләтеп, башка халыклар мәдәниятенә, яшәү үзенчәлекләренә якынайды. Бу юнәлештә үз халкыбызның йолаларын, тәҗрибәләрен нигез итеп алып, милләтебезнең йөз аклыгы булган бәхетле буын тәрбияләү – төп максатыбыз»*, – дип яза Кадрия Идрисова үзенең «Тәрбия баскычлары» хезмәтендә. Әлеге сүзләрдә зур мәгънә ята. Нинди соң ул бүгенге татар хатын-кызы? Ул тәрбияләгән яңа буынның киләчәге нинди булыр? Әлбәттә, сораулар күп. Соңгы елларда аеруча актив эш алып барган «Ак калфак» татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Кадрия ханым белән әңгәмә барышында без нәкъ менә шул хакта сөйләштек. Җитәкченең тәҗрибәсе, эшне дөрес итеп оештыра алуы да соңгы елларда «Ак калфак»ның күтәрелүенә зур йогынты ясагандыр. Шулай ук татар хатын-кызларының дөньяга карашы үзгәрүе дә эшчәнлек үсешенә уңай шартлар тудыруга бер сәбәпче булгандыр...

**– Кадрия ханым, «Ак калфак» иҗтимагый оешмасының чишмә башы кайсы елларга барып тоташа? Хәзерге эшчәнлегегез ул вакытлардан нәрсәсе белән аерыла?**

– «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы егерменче йөзнең туксанынчы елларында оешкан. Аның беренче җитәкчесе – язучы, журналист Роза Туфитуллова була. Аннары, Казан шәһәренең Ш.Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясе директоры Камәрия Хәмидуллина һәм филология фәннәре докторы, профессор Резеда Мөхәммәтшина бу эшне алып баралар. Мәдәният министрлыгында эшләп йөргәндә, Ринат Закиров «Ак калфак» оешмасын җитәкләргә чакырды. Мин ризалаштым. Оешкан елларында күбрәк чит илләрдәге һәм чит төбәкләрдәге татар хатын-кызларын берләштерү, аралаштыру,

алар белән элемтәләр урнаштыру эше башкарылса, бүгенге көндә без үз районнарыбыз белән дә максатчан эшлибез. Үз казаныңны кайнатмыйча, читтәгеләргә бернәрсә дә биреп булмый. Хәзерге көндә Россия төбәкләре белән дә тыгыз элемтәдә торабыз. Бөтен дөнья буенча исәпләгәндә, 740 оешмабыз бар. Әле менә март аенда гына Канада һәм Гарәп Әмирлекләрендә дә «Ак калфак» оештырылды.

**– Сезнең эшчәнлегегез нинди максатларга юнәлдерелгән?**

– Эшебезнең төп юнәлеше дип татар халкының югалып барган гореф-гадәтләрен яңадан халыкка кайтару, шәҗәрәләребезне булдыру, милли асылыбызга кайтуны атар идем. Менә хәзер картлар йортларында – татар әби-бабайларын, ятимнәр йортында татар балаларын күрәбез. Ә элек бит бу хәлләр безнең халыкта бөтенләй дә булмаган. Милләтебезнең яшәү рәвеше гореф-гадәтләребезгә, милли йолаларыбызга нигезләнсә, җәмгыятебездә тискәре күренешләр бу кадәр артмас иде. Хәзер без шушы гореф-гадәтләребезне халыкка кайтару өчен зур тырышлык куеп эш алып барабыз. Сүз генә сөйләп калмыйбыз, ә гамәлдә күрсәтеп аңлатабыз.

**– Бүгенге заман кешесен иректә дип әйтергә мөмкин. Күпләр бәйсезлеккә омтыла, алар үзләрен бернәрсәгә дә бәйләргә теләми. Хәтта илләр арасында да чикләр югалган вакыт. Самолётка утырып, дөньяның теләсә кайсы почмагына чыгып китү берни дә тормый. Кешелек өчен рухи кыйммәткә ия булган төшенчәләр җуелу эшегезне тагын да катлауландырадыр төсле...**

– Беләсезме, күбрәк эшләгән, әлеге проблемаларга тирәнрәк кергән саен, бер нәрсәне ачыклый барам – кешеләр үзләренең тарихына, гореф-гадәтләренә сусаган икән. Әгәр дә туксан тугыз төймәдән торган дисбе чәчелеп китсә, без аның соңгысына хәтле җыярга тырышабыз. Милли асылыңны барлау да шулай. Кешеләр үз тарихларын, милли гадәтләрен тулы итеп, барлык нечкәлекләренә кадәр белергә омтыла. Төрле районнар һәм төбәкләргә чыгып, аңлату эшләре алып барганнан соң: «Ник безгә алданрак килмәдегез?» – дип сорыйлар. Хәзерге кеше үзе эзләп табарга түгел, ә әзерне кабул итәргә күнеккән. Гореф-гадәтләрнең ничек үтәлергә тиешлеген күрсәтеп, аңлатып биргәннән соң, милли асылыбыз яңадан яңара.

**– Бу хәл, чыннан да, күңелне куандыра. Димәк, киләчәгебез өметле. Эшегезнең төп нәтиҗәләре хакында да беләсе килә.**

– Аллага шөкер, кайда гына барып чыксак та, анда башлаган эш тукталып калмый, дәвам итә. Мәсәлән, узган ел Чүпрәледә халыкка «Килен төшә – тура пешә» йоласын өйрәттек. Биредә килен төшүнең үз үзенчәлекләре бар. Кияүгә чыккан килен тура пешерергә тиеш. Һәрбер җирлектә шулай үзләренә генә хас булган йолаларның үзенчәлекләрен эзлибез һәм башкаларга да өйрәтәбез. Мәсәлән, Зәйдә «Суккан палас өстендә йомры калач» исемле чара оештырдык. Анда палас сугу бик киң таралган. Без балалар бакчасында да бу һөнәрне күрсәттек. Чүпрәсез, колмак белән икмәк пешерү серләрен ачтык. Һәр килгән кешегә колмак бүләк итеп җибәрделәр. Чиләбедә «Нәни энҗеләр»не барласак, Арчада үткәрелгән өч көнлек «Арча ягыннан чыккан язучылар әсәрләрендә сакланып калган йола, гореф-гадәтләрнең бүгенге көндә кулланылышы» күчмә утырышында булып кайттык. Узган елның көзендә Удмуртиядә шәҗәрәләрне өйрәнү буенча утырыш үтте. Андагы кебек авыл музейларын әле беркайда да күргәнем юк иде. Кая гына барсак та, башта үзенчәлекле берәр йоланы, гореф-гадәтне сайлыйбыз, чарага исем кушабыз. Бу эш бик җентекле башкарыла. Сабада васыятьнамә язу буенча дәресләр үткәрдек. Эшләребез чиксез күп.

Бәйгеләр дә уздырабыз. Бу вакытта эшне баскычлап оештырабыз. Мәсәлән, биш-җиде яшьлек балалар өчен – «Татар кызчыгы», «Татар малае», яшүсмерләр өчен – «Сөмбелә» һәм яшьләребезгә «Татар кызы», «Татар егете» бәйгеләре бар. Яшь киленнәр арасында – «Төп нигез килене», «Килен – каенана», әбиләребез өчен «Ак яулыклы әбием», «Әбием – күз нурым», «Әбекәй-матуркай», «Әбием-алтыным» бәйгеләре үткәрелә.

Шунысын ышаныч белән әйтә алам: татар милләте беркайчан да бетмәячәк ул. Кая гына барсак та, сокланып кайтабыз. Татар хатын-кызларының күзләре янып тора, һәрвакытта да үз эшләренең нәтиҗәләре белән уртаклашалар, бервакытта да туктап, югалып калмыйча, алга баралар.

**– Гореф-гадәтләрне барлау, туплау һәм халыкка кайтару эшенә галимнәрне дә җәлеп итәсезме?**

– Безнең теләк бар, әлегә галимнәребездән дә инициатива көтәбез. Алар халыкка йөз тотса, милли мирасыбызны саклау һәм халыкка тарату эше тагын да нәтиҗәлерәк булыр иде.

**– «Ак калфак» оешмасының эшчәнлегенә башка милләтләрнең үз мөнәсәбәтен белдергәне бармы?**

– Мәсәлән, Самарага баргач, губернаторның беренче ярдәмчесе мине үзенә чакырып алды. Ул оешманың эшчәнлеге белән кызыксынды. Мин бала тәрбияләүдән башлап, милли яшәешнең һәр баскычы хакында сөйләдем. Шуннан ул: «Бездә 157 милләт вәкиле яши, аларның иң актив хатын-кызларын җыеп, семинар үткәрсәгез иде», – дигән тәкъдим белән чыкты. Димәк, алар безнең эшкә сокланып карый дигән сүз.

**– Әлегә кадәр «Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасының эшчәнлегенә еллык йомгак-нәтиҗә ясар өчен, җыеннар уздыра идегез. Быел ни өчен съезд форматын сайладыгыз?**

– Чыннан да, быелгы нәтиҗәләрне күздә тотып, Бөтендөнья татар хатын-кызларының икенче съездын уздырырга ниятләдек. Моны V татар хатын-кызлары форумында татар конгрессы җитәкчелегенә тәкъдим итте. Беренче съезд 1917 елның апрель аенда булган. 102 елдан соң татар хатын-кызлары кабаттан съездга җыела. Без кабул иткән резолюцияләр дәүләт югарылыгында яңгырасын өчен, әлеге форматны сайладык. Беренче съездда татар хатын-кызлары ирек, хатын-кызның гаиләдәге хәле, белем алу мәсьәләләрен күтәрәләр. Хатын-кызларның сәяси тормышта, сайлауларда катнаша алу хокукын таләп итәләр. Ә быел татар халкы үзенең үсеш стратегиясен кабул итәчәк. Шуңа да хатын-кызларыбыз әлеге документ белән таныш булырга һәм анда үз тәкъдимнәрен кертергә тиеш. Шушы хасиятле чорда татар хатын-кызлары съездын үткәрү тагын да үтемлерәктер дип уйлыйм. Съездга күп кенә чит илләрдән – Швеция, Канада, Австралия, Гарәп Әмирлекләре, Германия, Эстония, Казакъстан, Литва, Болгария һәм башка чит илләрдән, шулай ук Россиянең 65 төбәгеннән, республикабыз районнарыннан 500 делегат көтәбез.

**– Киләчәккә нинди уй-ниятләрегез бар?**

– Татар халкының милли киемнәрен дә яшәешебезгә кайтарасы иде. Әгәр үз киемебездә йөри башлыйбыз икән, безнең телебез дә сакланачак, моңнарыбыз, гореф-гадәтләребез дә кире кайтачак. Әлбәттә, моның өчен дәүләт тарафыннан да ярдәм кирәк. Татар милли киемнәре күпләп тегелгән очракта гына алар безнең халыкка барып ирешә алачак. Шуңа да татар балалары, хатын-кызлар һәм ир-атлары өчен дә махсус тегелгән киемнәр җитештерү эшен җайга салу турында хыялланам. Гомумән алганда, һәр халык киемнәрдә үз үзенчәлекләрен сакласа, без болындагы чәчәкләр төсле матур булачакбыз.

Тагын бер зур проект – татар хатын-кызлары арасыннан 100 тарихи шәхесне өйрәнеп, китап чыгарасы килә. Бу эшемнең төп максаты – тарихи шәхесләребезне барлау, күтәрү.

Икенче зур проект булып татар уеннарын барлау тора, аларны тәрбияви юнәлештә куллану, «Татар уенчыклары» бәйгесе үткәрү, шул уенчыклардан күргәзмә оештыру.

Шулай ук башлаган эшләребезне дәвам иттереп, «Ак калфак»лар белән бердәмлектә, яңа буынны тәрбияләү һәм үстерү эшен дөрес якка юнәлдерү дә безнең зур бурычыбыз. Ир-атларыбыз да читтә калырга тиеш түгел, Бөтендөнья татар конгрессының нинди генә зур чаралары үтмәсен, мин анда ир-егетләребез алдында да чыгыш ясыйм. Бала тәрбияләүгә, яшәешебезгә милли гореф-гадәтләрнең тәэсире турында сөйләгәч, алар җанланып китә. Шуннан күбесе сораулар белән яныма килә. Ир-атлар да бу эшкә кушылса, мирасыбызны кайтаруда, балаларыбызны дөрес тәрбияләүдә тагын да зуррак уңышларга ирешәчәкбез. Татар хатын-кызларына ышанычым чиксез, киләчәктә дә алдынгы карашлы булып һәм милли асылыбызны зурлап яшәргә язсын.

*Әңгәмәдәш* – **Айсылу ИМАМИЕВА.**

Ғәп
Фән

# ГАЛӘМ СЕРЛӘРЕ

Галәмдә тормыш формаларын эзләү – астрономиянең төп мәсьәләләренең берсе. XX гасырда Кояш системасына кергән планеталарга космик аппаратлар җибәреп эзләнүләр башласалар да, алар бер дә уңышка китерми.

XXI гасыр башында заманча җиһазландырылган эре оптик телескоплар ярдәмендә Кояшка якын булган башка йолдызлар янында да (100-300 яктылык елы радиусында) планеталар һәм планета системалары барлыгын белә алдылар. Бүгенге көнгә берничә мең йолдыз тирәсендә дүрт меңләп планета ачылган. Аларның күбесе кояш тибындагы йолдыз тирәли әйләнә, Кояш системасындагы Юпитер планетасы массасыннан да 20-30 тапкыр артык авырлыктагы планеталар да бар.

Соңгы ун елда Казан астрономнары, япон һәм төрек коллегалары белән берлектә, башка йолдызлар тирәсендәге планеталарны эзләүче халыкара программада катнаштылар. Казан университеты галимнәре тырышлыгы белән, Төркиядәге кояшлы тау битендә урнаштырылган метр ярымлы «РТТ-150 Россия-Төркия телескобы» ярдәмендә аеруча күп тикшеренү эшләре башкарыла.

Әлеге телескоп югары сыйфатлы спектрометр белән җиһазландырылган. Планеталар эзләү вакытында спектрометрга йодлы күзәнәк – газ хәлендәге йод молекулалары белән тукландырылган тартмачык урнаштыру таләп ителә. Бу күзәнәкне япон астрономнары әзерли. Йод молекуласы нурланышы (спектрлары) белән янәшәдә хасил булган йолдыз нурланышын тикшерү өчен, компьютер программасын төрек галимнәре яза.

Унъеллык спектраль күзәтүләр программасына 50 салкын кызыл гигант йолдызны тикшерү сайлап алына. Йолдызлар эволюциясе теориясе буенча, алар тирәсендә планеталар булырга тиеш түгел. Еллар буе алып барылган күзәтүләр нәтиҗәсендә, «РТТ-150 телескобы» ярдәмендә берничә мең нурланыш өлгесе ачыклана, йолдызларның нур тизлеге үзгәреше тикшерелә. Әгәр йолдыз янында планета була икән, ул йолдызның пространствода хәрәкәтенә тәэсир ясый. (Доплер физик эффекты буенча, йолдыз нуры сызыклары, планетаның әйләнү тизлегенә карап, йөз тәүлектән мең тәүлеккә кадәр вакытта уңга-сулга чайкала.) Әмма нурланыш сызыкларының күчеше бик кечкенә, микронның берничә дистәдән бер өлешен тәшкил итә! Бу гаять кечкенә күчешне үлчәү – бик катлаулы эш, ул белгечләрдән зур әзерлек сорый.

Ун ел буе алып барылган тикшерүләр 2017 елны зур ачышка китерде! Астрономия каталогларында HD 208897 номеры белән билгеләнгән йолдызның нурланыш тизлекләрен анализлау вакытында, аның тирәсендә Юпитер планетасы массасыннан 1,4 тапкыр артык авырлыктагы планетаның 353 тәүлек эчендә бер астрономик берәмлек (150 млн. километр) ераклыгын әйләнеп узуы билгеле булды. Бу – Җирнең Кояш тирәли әйләнү ераклыгына тәңгәл. HD 208897 йолдызы исә бездән 210 яктылык елы ераклыгында урнашкан.

Хәзерге көнгә, дөнья күләмендә санаганда, телескопларда йод күзәнәкләре кулланып күзәтүләр алып бару нәтиҗәсендә 600ләп планета ачылган. Шуларның 100ләбе – салкын гигант-йолдызлар тирәсендәге планеталар. Йолдызлар янындагы күк җисемнәрен өйрәнгәндә, зуррак планеталарны табу күпкә җиңелрәк. Тик дөньяда Юпитер массасына якынлашкан 10 планета гына мәгълүм! Шуңа күрә Төркиядәге Казан телескобында ясалган ачыш уникаль вакыйга булып тора! Бу – Казан астрономнарының уңышлы халыкара хезмәттәшлегенә, әлеге хезмәттәшлекнең дөнья фәне дәрәҗәсендәге казаныш-ачышка китерүенә мисал да.

HD 208897 номерлы йолдыз янындагы планетаны ачу турындагы хәбәр инглиз телендә «Astronomy and Astrophysics» журналында басылып чыкты.

Бүген гигант-йолдызларның нурланышын күзәтү һәм тикшерү эше дәвам итә. Йолдызлар тирәсендә планеталар эзләү программасында Татарстан Фәннәр академиясенең «Астрофизика» үзәге фәнни хезмәткәрләре Илфан Бикмаев, Элдар Иртуганов, Алмаз Галиев, Сергей Мельников катнаша. Үзәкнең фәнни җитәкчесе – академик Наил Сәхибуллин.

**Илфан БИКМАЕВ**

# ШАНЛЫ САКЧЫ

*(Аяз Гыйләҗевнең Төркиядә басылган әсәрләре турында)*

Татар әдәбиятында тирән эз калдырган олуг әдипләрнең берсе ул, минемчә, Аяз Гыйләҗев. Төрек телендә бер-бер артлы укыган «Өч аршын җир», «Җомга көн, кич белән...», «Язгы кәрваннар», «Яра» повестьлары аның татар әдәбиятында гына түгел, дөнья сүз сәнгатендә мәңге сулмаслык, шиңмәслек гөлләр калдырган олпат бер шәхес икәнлеген искәртте миңа. Шушы язмамда укылган әсәрләргә тәфсилләп бәя бирергә җыенмыйм. Бар иҗатын өйрәнмичә, моны башкару бик үк дөрес тә булмас. Аның һәммә язмасын барлаган, хәтта цензурага эләккән урыннарын да ачыклау мөмкинлегенә ия булган хөрмәтле галимә Миләүшә Хәбетдинова ул эшне болай да башкарып килә инде. Ә минем язмам кыскача игътибарны җәлеп итүдән гыйбарәт булачак.

Һәр җәмгыять нәкъ үзе төсле, үзенә охшаган язучыны тудыра. Рус язучыларын нигилизмның караңгы юлларында күрүебез очраклы хәл түгел. Алар, өр-яңа әсәр иҗат иткәнче, искеләрнең, булганнарының тамырын корытканнан соң гына, йөрәк яндыргыч өметсезлек белән яңаны эзлиләр. А.Гыйләҗев – Идел буйларында сулар эчкән, Урал тавы битләрендә атта чапкан татар кабиләсе вәкиле, Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында дөньяга килгән, Баграж урманнары баласы. Идел-Уралдагы татар авыллары – шагыйрь-язучыларны биргән уңдырышлы туфрак. Шулай да ныклы, зирәк акыллы, китап сөючән татар яшьләренә элек-электән һәм бүген дә шанлы-шәүкәтле Казан каласы әдәбият ишеген ачкан, аларны үстергән.

Повесть-романнарында А.Гыйләҗев татар кешесен һәм аның яшәү формаларын мәңгеләштергән. Тормышта ни генә булмасын, ул – бернигә карамастан, үз авылының бакчасында эшләүче бер бакчачы. Ул – киләчәкнең яшь үсентеләренә, төшенкелеккә бирелмәсеннәр өчен, өмет канатлары беркетерлек, йөрәкләрне җилкетерлек милли хәтернең туфрагын булдыручы да, хыяллар бишеге – ана теленең бөтен самимилеге һәм матурлыгы белән аларны тәрбияләүче дә.

А.Гыйләҗевнең соңгы елларда Фатих Кутлу тарафыннан төрек теленә тәрҗемә ителгән дүрт әсәрен уку Истанбулның ыгы-зыгы, шау-шуында минем җаныма ял булды. Укыган һәр китаптан соң А.Гыйләҗевнең эстетикасы күңелемдә аермачык канат җәйде. Язучының барлык әсәрләрен эзлекле рәвештә уку әдип иҗаты турында тулаем фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Бөтенне күрмичә, кисәкләрдән генә иҗатның кыйммәтен аңлау авыр. А.Гыйләҗевнең бер-бер артлы төрек теленә тәрҗемә ителгән повесть-романнарының ишәюе – сөенечле хәл. Һичшиксез, аның бер әсәрен укыган төрек укучысы авторның башка иҗат җимешләрен дә табып укырга тырышачак. Шундый кызыксыну булмаса, өч төрле нәшрият татар әдибенең әсәрләрен басарга теләп алынмас иде! Шул рәвешле, А.Гыйләҗев ун елдан бирле Төркиядә әдәби тормыш әйләнешендә татар әдәбиятының бердәнбер вәкиле исәпләнә. Безнең илдә татар сүз сәнгатенең яңгырашы ни дәрәҗәдә мөһим булуын күрсәтә бу иҗат. Күпме генә фәнни хезмәтләр язылса да, алар тәрҗемә хикәя-повестьларны алмаштыра, төрек укучысының рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерә алмый.

Әсәрләрен яратып укыган әдипләр турында җентекләп язылган биографик яки монографик китаплар тапсам, һичшиксез, алар белән танышырга тырышам. Андый хезмәтләр язучының әдәби уңыш-табышларын ачыкларга булыша, иҗатына карата кызыксыну уята, дөньяга карашларын ачыкларга мөмкинлек бирә. Җир шарында, Дәрдемәнднең «Кораб» шигырендәге төсле, давыл уртасында яшәгән,




вакыт диңгезенең дулаган, чайкалган чоңгылларына сөрелгән, уй газабында янган инсаннарның гыйбрәтле, үрнәк тормышлары, бөтен кешеләрне кызыксындырган шикелле, мине дә кызыксындыра, үзенә җәлеп итә. Әйе, бөек шәхесләр арасында нахакка яла ягучыларның агулы сөңгеләренә дучар булмаган затлар бармы икән?! Ләкин бу – мәшһүрләребезнең дәрәҗәсен, әсәрләренең кыйммәтен һич тә киметми, киресенчә, иҗатларына, биографияләренә карата кызыксындыруны арттыра гына.

Мин Аяз Гыйләҗевнең исемен тәүге тапкыр 1999 елда Уфадагы бер китап кибетендә «Йәгез, бер дога!» исемле китапның тышлыгында күрдем. Яңа китап алганда, һәрвакыттагыча, аны ачып караштырганнан соң: «Әһә, укырлык тагын бер китап чыккан!» – дип, күңелемә беркетеп куям. А.Гыйләҗевнең әлеге әсәре минем аңа кадәр укыган, авыр көннәрнең хатирәләрен чагылдырган үзбәк язучысы Шөкруллаһ Йосыфоглының «Кәфенсез күмелгәннәр»енә охшый иде. Хәтерем ялгышмаса, А.Рыбаковның «Арбат балалары»н да шул ук китап кибетеннән сатып алган идем. А.Рыбаковның «Арбат балалары» һәм Шөкруллаһның «Кәфенсез күмелгәннәр» әсәрләре төрек телендә Төркиядә басылып чыкты. А.Гыйләҗевнең шул ук темага караган автобиографик «Йәгез, бер дога!» романы да минем шикелле аны зур кызыксыну белән укыячак төрек укучысы өчен ачылырга тиешле яңа бер дөнья булачагына шигем юк. Фатих Кутлу әлеге романны төрек укучысына ирештерүне озакка сузмас дип өметләнәм.

2000 елдан соң үзем бик теләп алдырган татар матбугатында А.Гыйләҗев турындагы язмаларны, аеруча да «Идел» журналында өлешләп басылган хатларын һәрвакыт көтеп алып, мөкиббән китеп укыдым. Әдип төрмәдә вакытта аңа хатлар язган булачак хатыны Нәкыя Гыйләҗева – бик күп язучы хатыннарына насыйп булмаган тугрылык һәйкәле. Алар тормыштагы сынаулар сиратын бергә үткәннәр. Бүгенге көндә Нәкыя ханымның тырышлыгы белән, А.Гыйләҗевнең хатлары, көндәлекләре дөньяга чыкты. Татар журналларында азмы-күпме басылган язмаларда А.Гыйләҗевнең бай фикри дөньясына тап булдым. «Кәфенсез күмелгәннәр»нең авторын Ташкентта күреп калдым һәм шунда минем өчен кадерле истәлек булган әлеге китабына култамга алган идем. Ни кызганыч, А.Гыйләҗевне күрергә соңга калдым. Шулай да минем бер юанычым бар – 2013 елда А.Гыйләҗев яшәгән йортта булдым. Йортның хөрмәтле хуҗабикәсе Нәкыя ханым кулыннан тәмле татар ашлары ашадым. Яңа бистә зиратында А.Гыйләҗевнең каберенә барып, рухына догалар укыдым.

А.Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» повестен, үзем өчен әлеге әдипне ачканнан соң унбер ел үткәч, төрек телендә уку бик зур шатлык булды. Яхшы бер иҗатка юлыгу китапларны ярата торган кешегә бәхет капкасы ачылуга тиң иде! Ләкин бер сыерчык яз китерми! Бик күп илләрдәге шикелле үк, Төркиянең тузанлы китапханә киштәләрендә дә бердәнбер әсәре генә төрекчәгә тәрҗемә ителгән, эзлекле рәвештә тәрҗемәләре

чыкмаган уннарча язучыны табарга мөмкин. 1926 елда Фатих Әмирханның Кайа Нуири тәрҗемәсендә төрекчә дөнья күргән «Татар кызы» – боларның берсе.

Барлык чорларда да сәясәтнең «кулы» әдәбиятта уйнамый калмый. Сәясәт бик күп язучыны төрмәләргә «озаткан» кебек, кайберәүләрен, туган якларыннан сөреп, чит илләрдә «шөһрәт казандыра». Салкын сугыш елларында атаклы төрек шагыйре Назыйм Хикмәтнең дөньяга танылуында, рәхмәт төшкере, Совет Рәсәенең өлеше зур булды. Аяз Гыйләҗев әсәрләрен Совет чорында язган булса да, алар үз чорының сәяси калыпларына сыешмый. Шуңа күрә әдәбиятның «чик буе диварлары» да аларга киртә була алмый, Аяз Гыйләҗев иҗаты ерак чит илләрдә яңадан-яңа үз укучыларын табып тора. Үзбәк язучысы Абдуллаһ Каһһар 1960 елларда: «Үзбәк әдәбияты Оренбург чикләрен үтеп чыга алмый», – дип, үпкә катыш зарлана. Әлеге сүзләр – сәясәтнең контроле астындагы әдәбиятның аянычлы язмышын тану үрнәге.

А.Гыйләҗевнең иҗатында, иң беренче чиратта, «җир», «агач», «йорт», «ир-ат», «хатын-кыз» һәм «зират» – мөһим төшенчәләр. Әдип әсәрләрендәге төп вакыйгалар белән бәйле подтекстларны өзлексез һәм максатчан рәвештә татар милләтенең киләчәге өчен «тереклек суы» эзләүгә багышлый. Аның бу рухи халәте туган халкының язмышын кайгыртуга кайтып кала. Мәсәлән, «Яра»дагы күңел фәлсәфәсе Локман Хәким хикмәт-зирәклегенең изгелек, үлемсезлек чылбырын хәтерләтә. Автор повестьтагы «Үзем» бүлеген укучы әсәрне тирәнрәк аңласын өчен язган. Моннан чыгып, аның әсәрләрендәге бөртек хәтле детальнең дә никадәрле әһәмияткә ия икәнлегенә төшенәбез. Аяз Гыйләҗев фикеренчә, эшкәртелгән җир, тәртиптә тотылган йорт булса гына тормыш дәвам итәчәк. Морҗасыннан төтен чыккан йорт ул – бәхетле, тук тормыш билгесе. Димәк, киләчәккә өмет белән карарга мөмкин. Ә җирне эшкәртергә, йортны төзекләндерергә ир-атлар кирәк.

«Җомга көн, кич белән...» әсәрендәге Бибинурның ире Габдуллаҗан фронттан кайтмый. Аксыргакта Бибинур шикелле тол хатыннар күп. Сугышка киткән ир-егетләр яу кырларында меңәрләп ятып кала. Ватан өчен һәлак булучылар, ачлык, мохтаҗлык туган нигезләрен ташлап, дөнья буйлап сибелергә мәҗбүр татарлар язмышы бәгырьне телгәли. Аеруча да яшьләр күпләп китә, авыл карт-коры кулына кала.

«Яра» әсәрендәге Габдулла язмышы да гыйбрәтле. Ул туган йортын үлеп сагына. Госпитальгә икенче тапкыр авыр хәлдә эләккән Габдулла исемен дә, ана телен дә оныта. Егерме яшьләрдә өйдән сау-сәламәт, таза килеш чыгып киткән ир-егет ак биләүгә төрелгән яшь бала шикелле көчсез, танымаслык хәлдә, телен, хәтерен җуйган, исемсез, милләтсез бер затка әверелә. Автор бу урында шуңа игътибар юнәлтә: хәтер татар җырында, моңында яши икән. «Галиябану» җырын ишеткән Габдулланың хәтере яңадан кайта. Тел ул – хәтернең оясы, ди автор. Габдулла белән әңгәмә үткәрергә килгән корреспондент та: «Телең юк икән, тарихта эзең калмас», – дип искәртә.

А.Гыйләҗевнең әсәрләрендә үлем, җеназа мәрәсиме, кабер-каберлекләр кебек мәңгелек төшенчәләр дә мөһим урын били. «Җомга көн, кич белән...» повестендагы Аксыргак авылының колхоз рәисе, кырык дүрт яшьлек Җиһангир Сәфәргалин вафат булгач, әтисе Вәли картның теләге буенча, туган авылы Тегәрҗептә җирләнә. (Өч бертуганы Аурупаның өч аерым илендә җир куенында яталар.) Җиһангирның борынгы бабалары да бу авыл зиратында җирләнгән. Бибинур да, Тегәрҗеп авылы зиратына хәтле барып, картларга булыша, «Әлхәм» һәм «Кулһуаллаһу»сын укып, Җиһангирны мәңгелеккә озата. Әсәрдә тасвирланган «кешенең соңгы туе» аның туган туфрагына бәйлелеген тагын бер кат дәлилли.

Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң татарлар арасында һәйкәлләргә карата ихтирам урнаша. Бу дөньяви гадәт тора-бара татар халкының үз зиратларындагы кабер ташларына карата кызыксынуны көчәйтә. Повестьта әлеге милләтнең бер вәкиле Җиһангир Сәфәргалинның авыл зиратын караштыруы, чистартуы, мөһим, әйбәт фал булып тора (үзе дә шунда барасы!). Автор әсәрләренең берсендә, заманында чиста татар бистәсе булган Оренбург Каргалысының каралмый яткан, шыксыз, ташландык хәлдәге каберләрен уфтанып, күңеле рәнҗеп телгә ала. Кабер ташлары – үткәннең, тарихның ордерлары бит. Ерак тарихны, борынгы бабаларның эзләрен алар аркылы гына барларга мөмкин.

А.Гыйләҗев әсәрләре татарның йөрәк җылысы белән сугарылган. Әлеге җылылык «Өч аршын җир»дәге Шәмсегаянның, «Язгы кәрваннар»дагы Сабира апаның, «Яра»дагы Зәйтүнәнең һәм «Җомга көн, кич белән...»дәге Бибинурның йөрәк җылысы ул – сөю белән типкән татар йөрәге, бигрәк тә хатын-кызларның йөрәге. Бу инде, кырларның үзгәрми торган тып-тын тормышы эчендә үскән арыш басуларының өлгергән башаклары өстендә җилфердәгән җилнең, язның, туган җирнең саф һавасын сулагач, йөрәк авыртуларының басылачагына ышанып, утыз елдан соң Ерак Көнчыгыштан кайтырга юлга чыккан Шәмсегаянның йөрәк җылысы. Яхшы күңелле, чиста йөрәкле Шәмсегаян һәм Сабираның, йөрәк өянәге кузгалып, мәңгелеккә күчүе, Бибинурның тагы да фаҗигале төстә җан тәслим кылуы – безне уйланырга чакырган, сизгер һәм уяу булырга өндәгән күренешләр!

Әдипнең бер-бер артлы укылган «Өч аршын җир», «Җомга көн, кич белән...», «Язгы кәрваннар» һәм «Яра» әсәрләре җаныма шифа булды. Еллар дәвамында А.Гыйләҗевне укучы татар халкы бик тә бәхетле, минемчә. Аның әсәрләренең җанга бәлзәм булып килгән юлларын укыгач, бәгырьне кыса, эчне пошыра торган, йөрәк яралаучы сырхаулары савыга. Күңелдәге депрессия әкренләп юкка чыга, чөнки А.Гыйләҗев иҗаты игелекле, яхшы кешеләргә бай – яше, карты, ир-аты, хатын-кызы... Татар халкының батыр йөрәкле һәм саф күңелле кешеләре... Шул рәвешле, А.Гыйләҗев, хәзерге заман роман технологиясеннән оста файдаланып, үзе яшәгән чордагы замандашларының тормышын, язмышын әсәрләрендә югары кимәлдә тасвирлап мәңгеләштерә.

А.Гыйләҗев югарыда телгә алынган әсәрләрендә, милли барлыгын дәвам иттерер өчен, бар көчен, сәләтен, гомерен биргән татар халкын һәм аның иң кадерле хәзинәсе – киләчәге – авыл яшьләрен, татар авылында бара торган матур, нәфис тормыш манзараларын сәнгать әсәре югарылыгында көн тәртибенә чыгара, бар тулылыгында гәүдәләндерә. Асылда, аларны мәңгеләштерә, кеше күңелендә игелек төшенчәсенә оеткы сала. Әдипнең теле рухны канатландыра. Фатих Кутлу үзенең Локман Хәкимен тапкан. Ничә еллар дәвамында аның А.Гыйләҗев иҗатыннан илаһи нур алып, әсәрләренә мөкиббән китеп эшләве тикмәгә түгел, димәк.

Олы шәхесләр дөньяга гомер үткәрү өчен генә килмиләр. Алар фани дөньяга мәңгелек эз калдырырга, милләтенә хезмәт итәргә киләләр. А.Гыйләҗев тә, бу кагыйдәгә тугры калып, татар әдәбияты тарихына исемен җуелмаслык итеп уйган әдип, милли сүз сәнгатендә балкып янган йолдыз, Урал таулары, Идел буйларына сибелеп яшәгән татар халкы тормышын теркәп, киләсе буыннарга маяк, гыйбрәт итеп калдырган изге бер юлчы. А.Гыйләҗевнең әсәрләрен укыган кеше аның туган халкының улы, милләтенең шанлы бер сакчысы икәнлегенә төшенер.

2028 елда татар халкының бу асыл баласының тууына 100 ел тулачак. А.Гыйләҗевнең йөз еллыгы Татарстанда гына түгел, Фатих Кутлуның тырышлыгы аркасында елдан-ел ишәйгән тәрҗемә әсәрләре ярдәмендә, Төркиядә дә лаеклы рәвештә үткәреләчәгенә шигем юк.

**Һүсәен БАРГАН,**
*фән кандидаты.*
*Төркия, Истанбул*

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ӘДӘБИ МУЗЕЕ

Габдулла Тукай әдәби музее – Татарстан Республикасы Милли музее филиалы – бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның (1886-1913) тууына 100 ел тулу уңаеннан 1986 елда ачыла.

Музей республикакүләм әһәмияткә ия мәдәни мирас истәлеге булган бинада – XIX гасыр ахырында Казан шәһәренең Иске Татар Бистәсендә төзелгән һәм XX гасыр башында Г.Руш һәм Ф.Амлонг проекты буенча яңадан төзекләндерелгән иң матур йортларның берсендә урнашкан. Биредә 1882-1906 елларда, Казанның иң бай сәүдәгәрләренең берсе Ибраһим Апаковның кызы Бибимәрьямбануга өйләнеп, Кавказ халыкларының бәйсезлеге өчен көрәшкән имам Шамилнең уртанчы улы генерал Мөхәммәтшәфи яши. Шул сәбәпле халык аны «Шамил йорты» дип йөртә.

2016-2017 елларда Г.Тукай әдәби музее бинасында төзекләндерү-реставрация эшләре уздырыла, 2018 елның 30 августында заман таләпләренә җавап бирә торган яңа экспозиция ачыла. Яңа экспозициянең концепциясен Татарстан Республикасы Милли музее һәм Г.Тукай әдәби музее фәнни хезмәткәрләре әзерли.

Музей заллары Габдулла Тукайның тормышы һәм иҗаты белән таныштыра. Шагыйрьнең Казан чорына аеруча игътибар ителә. Экспозициядә Татарстан Республикасы Милли музее җыелмаларыннан уникаль коллекцияләр урын алган. Г.Тукайның фотосурәтләре һәм үзе исән вакытта дөнья күргән китаплары тәкъдим ителә. Шагыйрьнең аз санда сакланып калган шәхси әйберләреннән торган мемориаль тупланмасы бәһасез мирас булып санала. Алар арасында кәрәч тартмачыгы; камыштан үрелгән юл кәрзине; кул сөлгесе; кара бәрхет түбәтәе; көмеш җиң каптырмалары; карандаш савыты; кара савыты һ.б. бар. Шулай ук якын туганнарының шәхси әйберләрен – бабасы Зиннәтулланың Коръәнен, әнисенең комганын, апасының камзолын күрергә мөмкин.

Г.Тукай шәхесенә, ул тудырган образларга багышланган декоратив-гамәли һәм сынлы сәнгать әсәрләре – картина, гравюра, скульптура, көнкүреш әйберләре экспозицияне тулыландырып тора.

Г.Тукай әдәби музеенда шагыйрьнең фикердәшләре һәм дуслары К.Мотыйгый, Ф.Әмирхан, Ә.Хәсәни, З.Хәсәния, С.Сүнчәләй, Х.Ямашев, бертуган Шәрәфләр һ.б. шәхси әйберләре, документлары күрсәтелә. Шагыйрьнең серле илһамчысы Зәйтүнә Мәүледованың Г.Тукай шигырьләре язылган блокноты һәм аның белән очрашулары хакындагы истәлекләре бар.

Татар театрының барлыкка килүе, Г.Тукайның театрга мөнәсәбәте турында шагыйрьнең замандашлары, күренекле театр әһелләре, милли сәхнә сәнгатен оештыручы һәм үстерүче И.Кудашев-Ашказарский, Г.Кариев, Г.Камал, С.Гыйззәтуллина-Волжская белән бәйле экспонатлар сөйли.

Экспозициянең бер бүлеге милли мәдәният үсешенә зур өлеш керткән Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары белән таныштыра.

Махсус зал – «Тукай үзәге» – шагыйрьнең иҗади мирасының байлыгын һәм аның төрки телле әдәбиятларга йогынтысын раслый. Биредә әдипнең төрле телләрдә төрле елларда басылган әсәрләрен уку өчен шартлар тудырылган. Китап киштәләрендә – татар һәм рус мәдәниятенең күренекле вәкилләре култамга куйган Тукай басмалары.

Музейда балалар мәйданчыгы эшли. Төрле уеннар ярдәмендә Г.Тукайның иҗаты белән танышырга, татар халыкының мәдәнияте хакында мәгълүмат алырга, мастер-классларда, музей бәйрәмнәрендә катнашырга һәм милли киемнәрдә фотога төшәргә мөмкин.

Тамашачыларга «Г.Тукайның тормышы һәм иҗаты», «Нурлы Казан», «Шагыйрь бишеге», «Иске Татар Бистәсе: тарихы һәм бүгенге көне», «Тукай эзләре буйлап», «Безнең өчен изге йорт» экскурсияләре, «Тукайның әкияти дөньясына сәяхәт», «Үз юлым белән барам», «Г.Тукай – фотографияләрдә», «Шагыйрь мәхәббәте», «Тукай һәм театр», «Габдулла Тукай һәм Камил Мотыйгый» дигән темаларга лекцияләр тәкъдим ителә. Музейда «Әлифба бәйрәме», «Шүрәледә кунакта», «Сабантуй төсләре», «Мияубикә кунакка чакыра» музей бәйрәмнәре, «Исемдә калганнар» музей дәресе үткәрелә.

**Гүзәл ТӨХФӘТОВА,**
*Габдулла Тукай әдәби музее директоры*



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Туфан МИҢНУЛЛИН**

## Минһаҗ маҗаралары

Думыдан чыккач, туп-туры киттем Лилин маузалиена. Зарланасы килә бит, эчне бушатасы килә. Үзен күреп булмаса да, маузали ташына сөйлисе килә.

Торам маузали каршында шулай. Бер салдат яныма килеп басты.

– Исәнмесез, Минһаҗ бабай, – ди.

– Исәнме, – мин әйтәм, – син кем соң? – дим.

– Салтык малае мин, – ди. – Ишеткәнең бардыр әле, Тикятам Гәптри оныгы, – ди. – Керимелдә ыслужить итәм, Лилин бабайны саклыйбыз, – ди. – Нәрсә, Минһаҗ бабай, Лилин бабайны күрергә килдең мәллә? – ди. – Бүген аның янына кертә торган көн түгел шул, – ди.

Аннан бераз уйлап торды да:

– Туктале, камандир белән сүләшеп карыйм әле, – дип йөгереп китеп барды.

Бераздан бер палкауник белән килделәр дә болар маузалиның арткы ишегеннән мине кертеп җибәрделәр. Уйлап куйдым шунда: үткен малайлар бар безнең райунда да, дим. Әгәр дә моңа бер яртыны куйсаң, Лилинны авылыңа алып кайтып күрсәтер.

Кердем маузали эченә инде. Тегеләр ишек төбендә калдылар. Төштем баскыч буйлап аскарак. Яп-якты ут яна. Карыйм – таш карават өстендә, пыяла чыбылдык эчендә ята Былադимир Илич. Үлгән кеше дип уйламассың да. Күзен йомган болай йомуын, әмма дә ләкин бөтенесен күреп яткан кебек. Исән чагында шулай иде инде ул, күзен кысыбрак карый иде. Калмык нәселеннән, диләр бит. Башта инде аны урыслар, үзебезнеке, диделәр, мудадан чыккач, безнеке түгел дип әйтәләр, ди. Җәбрәй дә дип әйтеп карыйлар, ди. Бөтенесе дә «Лилин безгә кирәкми», дия башлагач, татар дия башларлар әле. Булсын, татар булсын.

Басып торам каршында Лилинның. Исән булса, сизәм, торырые да, нихәл, Мингаз дус, дияр иде. Мин аңа барысын да сөйләп бирер идем. «Их, Лилин, Лилин!.. Их, Быладимир Илич! Күпме нужалар күрдең. Сембердән Казанга килдең. Казаннан Себергә җибәрделәр. Ривәлүтсия ясадың. Бергәләп патшаны төшердек. Хәтерлисеңме, бергә эшләгән чакларны? СыСыСыРны төзедек. Әйттең син шул чакта, татарларга да автанум бирик, дидең, риспублика булсыннар, дидең. Исән булсаң, әллә кем булган булырыек. Ысталин худ бирмәде шул. Ысталин. Ысталин көненә калып барабыз бит, Быладимир Илич». Шулай дип уйлап торам Лилин каршында. Шунда, әйтсәм ышанмыйсыз инде, бер галәмәт булып алды – Лилинның тавышы ишетелде. Ап-ачык. Тере чагындагы шикелле.

– Йөрмә монда, кайтып кит авылыңа, – диде ул. – Монда сиңа да, миңа да урын юк. Синең латыйныңа да юри бәйләнәләр алар. Синең латыйның да, урысның язуы да кирәкми аларга. Аларга тавыш чыгарырга гына кирәк, – диде.

– Соң, – мин әйтәм, – берәр киңәш бир. Кайткач, Миңнуллинга ни дип әйтим? Ул миннән җавап көтә, – дидем.

– Әйт Миңнуллиныңа, – диде Лилин тавышы, – иртән-иртүк торып, наскиен кигәндә, «киимме?» дип Мәскәүдән сорасын.

*(Дәвамы бар)*

## Татар әдәбияты нигә үсми?

Берничә язучы үзара сөйләшеп утырабыз. Арабыздан берәү: «Язган әсәрләремне хатыным укымаса, берни дә яшермичә, әллә ниләр язар идем!» – дип әйтеп куйды. Шулчак андый «тусовкалар»да һәрчак хөкемдар ролен үтәгән тере классик Марсель Галиев: «Менә шуңа күрә безнең татар әдәбияты үсми дә инде», – дигән ачы нәтиҗә ясады.

## «Җаваплы»

Кол Шәриф мәчетенең проектын сызган бер төркем архитекторлар Тукай бүләгенә ия булдылар. Алар арасында Зөфәр хәзрәт Галиуллин да бар, мәчетне салдыруда шактый зур көч түккән шәхес. Ләкин Тукай бүләген оештыру эшләре өчен түгел, ә иң элек иҗат иткән өчен бирәләр. Бу очракта Зөфәр хәзрәткә шактый кызыклы пункт уйлап тапканнар: и ш е к л ә р  ө ч е н  ж а в а п л ы.

**Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА**

## Ялгыш шыла

Ркаил Зәйдулла 1989 елда Польшага бара. Көн эссе. Бөтен кеше шортыдан йөри. Ркаил дә кызыга: шорты сатып ала.

Казанга кайткач, Ләис Зөлкарнәй белән каядыр барырга чыгалар. Тиз арада болар янына чыжлап милиция машинасы килеп туктый. Берсе Ркаилгә төбәлеп сорау бирә:

– Син кайсы районнан?

– Чүпрәледән, – ди Ркаил, күп уйлап тормыйча.

– Үзең минем якташ та икәнсең әле. Ә нишләп син көпә-көндез урамда ялангач бот күрсәтеп, трусиктан йөрисең? Утыр әйдә.

Егетләр җайлап кына машинага кереп урнаша.

Милиция бүлегенә килеп керсәләр, боларны милиция капитаны Нурулла абый (язучы Сәйдә апаның ире) каршы ала. Ул, «хулиган элэктерүче»ләргә китәргә кушып, башын кашып тора да:

– Да, бездә халык мондыйга күнекмәгән шул әле... – дип куя. Һәм очрашу хөрмәтенә сейфтан затлы коньяк тартып чыгара.

Ркаилнең авызы ерыла. Тимер рәшәткә арасыннан тәрәзәне шакып, Ләис дустына эчкә керергә ишарә ясый.

– Юк, кермим, – ди Ләис, – анда керсәң, чыгалмавың бар...

Һәм ул әкрен генә өенә шыла.

## Кисәтү

Фәнил Гыйләҗев «ТАТМЕДИА»га барырга җыена. Айсылу Имамиеваның андагы бухгалтериягә больничный җибәрәсе бар икән.

– Фәнил, тапшырырга онытмассыңмы? – дип сорый Айсылу.

– Юк, онытмыйм.

Бераз вакыт үткәч, Айсылу тагын сорый:

– Фәнил, тапшырырга онытмыйсыңмы?

– Онытмыйм, дидем бит инде.

Фәнил курткасын кия башлагач, Айсылу кабат сүз ката:

– Фәнил, тапшырырга онытмассыңмы? Мин бит сиңа үземә ышанмаган кебек ышанмыйм...

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*



*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы
гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу – безнең сәхифә!



*Айзилә Сабирова 2000 елда Арча районы Яңа Кенәр авылында туа. 2018 елда Яңа Кенәр урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, КФУның социаль-фәлсәфи һәм гаммәви коммуникацияләр институтының журналистика бүлегендә I курста укый. «Казан утлары» журналында практикант.*

*2018 елда республикакүләм «Алтын каләм – Золотое перо» фестивалендә катнашып, призлы урынга лаек була.*

# ӨЧЕНЧЕ ХАТЫҢ КАЙДА?

ХИКӘЯ

Туып-үскән йортыңны калдырып, икенче яшәү урынына күчеnү авыр, дип сөйлиләр. Әмма Зифаны мондый зур үзгәрешләр бер дә куркытмады. «Яңа урын – яңа тормыш» дигән уй белән, кыз кирәкле җиһазларын, киемнәрен, савыт-сабаларын катыргы тартмага тутырырга ашыкты. Чормадагы почмакта посып торган иске киштә дә Зифаның игътибарыннан читтә калмады. Тузан томанын җиңеп, ул беренче киштәдән иске альбомын, китапларын актара башлады. Кинәт, саргаеп, бөгәрләнеп беткән иске конверт эченнән өч хат килеп төште. Зифа бу хатлар турында күптән оныткан иде инде, таныш язмага тап булгач, аның күзләре юешләнде.

**1 нче хат**

Сап-сары көзге яфрак, җилдә тирбәлеп, акрын гына синең битеңә төште. Матурлык матурлыкка тартыла шул. Мондый көтелмәгән бүләк бигрәк шатландырды инде үзеңне: рәхәтләнеп көлдең, искән җилләр көенә сикерә-сикерә биедең. Синең көлүең, елмаюың, иреннәрең... Үземне кулда тота алмыйм бит, матурым! Ә мин бөтенләй андый кеше түгел. Гап-гади авыл егете, җәйләрен – утын, кышларын кар ташыйм, сабырлыгым һәм җитдилегем белән горурланам. Үзгәрттең син мине, җаным... Хисләрем белән уртаклашу, кызлар артыннан чабу миңа ят нәрсә иде, әмма тормышымда бер кыз барлыкка килде, Зифа исемле кыз. Бары тик аның өчен генә бу чиксез күктән меңләгән, юк, миллиардлаган йолдыз җыярга, кырыс дөньяның барлык бәлаләрен җиңеп, янына барырга әзермен. И, гашыйк булсаң, сүзләрең дә татлылана икән! Мәхәббәт уклары миңа, озаграк очып, соңрак кадалыр, дип уйлаган идем шул. Бу тормышта барысы да син теләгәнчә булмый икән.

Зифа, әле дә исемдә – синең белән беренче очрашуыбыз, танышуыбыз, дуслашуыбыз. Авылыбызда бер ай элек куелган клуб мөдире яшьләр өчен биюләр оештырырга теләде. Якшәмбе, җәйнең соңгы көнендә барсы да әзер иде: магнитофоннар дөрес тавышка көйләнгән, кызыл һәм зәңгәр утлар түшәмгә эленгән, күлмәкләр киелгән, чәчләр таралган. Минем бу «тусовка»га бер дә элегәсем килми

иде. Ләкин дусларымны тыңлап, клубның ишеген теләр-теләмәс ачып, эчкә үтәргә туры килде. Халык бирелеп бии: кулларын болгый, аякларын тыпырдата, егетләр кызларны вальс әйләндерә. Әлеге күренеш мине бер дә шатландырмады, ә бәлки, киресенчә, кире китәргә этәрде генә. Кинәт миңа шулкадәр ят булган төркем эчендә якты кояш нуры сыман кечкенә генә сылу гәүдә күренде. Акылымны тыңламыйча, йөрәк тибеше артыннан гүзәл кызга таба ашыктым. Күзләребез очрашты. Әйтәсе сүзләр онытылды.

– Сәлам! Ни сорамакчы идең?

– Эээ... м-мин... Марат буламын! – дип кычкырып җибәрдем.

И оят, оят! Синең шикелле чибәр кызларны күргән юк иде шул, Зифа. Җәйге алмалар төсле алсу битләрең, иртәнге чык сыман ялтырап торган зәңгәр күзләрең, кура җиләге шикелле иреннәрең тәмам башны әйләндерде. Танышуыбыз кинолардагы шикелле түгел, ә сәеррәк булса да, онытылмаслык мизгел иде ул минем өчен. Җәйнең соңгы көне шундый шатлык белән истә калды. Зифам, ышан, нинди генә авырлыкларга очрасам да, һәрвакыт синең янда булачакмын.

**2 нче хат**

Төн. Ай яктысы гына алдагы сукмакны яктыртып, безгә юл күрсәтә. Кар бөртекләре синең йомшак чәчеңә ябышып калды, алар, җем-җем килеп, күзләрне чагылдыра. Кышкы буран суыгы иреннәреңне корытты, керфекләреңә бәс кундырды. Йөрәгең мәхәббәт белән тулса, ниләр генә күрмисең икән?! Зифам, син ул төнне аеруча көләч, шат идең. Шундый рәхәт чагыңда сиңа күңелсез хәбәремне бер дә әйтәсем килмәгән иде. Шуңа да инде бу хатымда калган сүзләремне җиткерәм. Башлап җибәрер өчен, ике көн элек булган хәлне сөйләп үтәм. Сәгать теле көндезге икегә килеп терәлгәч, хат ташучы Шамил кулыма конверт тоттырды. Әлеге язма синнән, Зифа, дип уйлап, мин, чаба-чаба, өйгә ашыктым, секунд эчендә конвертны ертып, укый башладым. Юк, синнән түгел икән шул. Интернет челтәрендә информатика буенча укыту мәктәбе оештырган бәйгедә катнашырга һәм үзем ясаган сайтымның адресын җибәрергә кушканнар. Син бит инде беләсең минем компьютер белән кызыксынганымны. Ә мондый мөмкинлек бер генә була! Бу конкурста җиңү турында уйламадым. Әмма тормыш үзенекен эшли шул. Нигә мондый шатлыклы хәбәр безнең өчен күңелсезлек алып килсен соң, дип уйлыйсыңдыр. Бәйгенең бүләге – шул мәктәптә бушлай уку. Хыялымны чынга ашырыр өчен, тракторчыга укуымны ташлап, авылны, юк, Зифам, сине калдырып, шәһәргә китәргә туры киләчәк. Арабыз, ким дигәндә, 564 чакрымга ерагая, бу җаныбызны кимереп торачак. Ләкин без әлеге авырлыкларны җиңеп чыгарбыз, кыенлыкларга бирешмәбез. Матурым, барысы да яхшы булачак. Ышан миңа...

**4 нче хат**

Исәнме, Зифа. Хат алышканыбыз кинәт исемә төште дә, язу өстәленә җитез генә утырып, сиңа әйтәсе сүзләремне кәгазьгә тезә башладым. Кулыма каләм алгач, әллә нинди таныш, җылы хисләр йөрәгемә бәрелде, узганнарны хатирә итеп кайтарды. Әйе, синең белән аерылышуыбызга бик күп, бихисап күп вакыт узды шул. Икебезнең дә үз тормышы, көнкүреше. Ә ун ел элек без һәрвакыт бергә булачакбыз дигән ышаныч белән яши идек бит. Җәй көннәрендә, кичләрен, урам буйлап сөйләшеп баруларыбыз, серләшеп утыруларыбыз, бер-беребезне уздырып, чит ил язучыларының китапларын укуларыбыз... Онытылмаслык мизгелләр, бәхетле чаклар! Кая югалды соң алар? Кая китте безнең мәхәббәт? Ник?! Соңгы хатымны язганыма да ун ел узды. Син аңа тәки җавап бирмәдең. Ә мин көттем, нык көттем. Бәлки, нәкъ синнән киләчәк хат, минем сорауларга җавабың язмышыбызны үзгәрткән булыр иде, безне кавыштырыр иде төсле. Хәзер бу турыда искә алу да мәгънәсез инде – хәйран вакыт узган, дөнья аз гына булса да үзгәргән. Ләкин, шуңа да карамастан, яратуым сүрелеп бетмәде әле, Зифа. Һаман төннәрен теләр-теләмәс синең образың күз

алдыма килә, кешеләр шаулашкан урыннарда кинәт синең тавышыңны ишеткәндәй булам. Бу дөрес хәл түгел... Минем бит гаиләм бар!

Хатыным белән китапханәдә таныштык, шәһәрдә ике бүлмәле йорт сатып алдык, икәүләшеп обойлар ябыштырдык. Бер елдан соң улыбыз да туды. Әмир исемле. Минем шикелле көләч йөзле, яшел күзле, китаплар ярата. Биергә яратмый. Әнисенә охшап, шахмат, шашка белән мавыга. Эштән кайткач, ул һәрвакыт чаба-чаба минем янга ашыга, нәни куллары белән муеныма сарыла. Андый вакытларда үземне иң бәхетле кеше итеп тоям. Ләкин синең турыда уйланулар тынгы бирми. Беренче мәхәббәтеңне онытып булмый, дигәннәргә бер дә ышанмадым, андый кешеләрне аңлый алмый идем. Үзем бу капкынга эләгүемне сизмичә дә калдым бит, Зифа. Бу хатымны юкка гына язмыйм мин. Әйтәсе сүзләремне кәгазьгә күчереп, кирәкмәгән, ят уйлардан арынырга телим. Күптән инде сине йөрәктән өзеп алырга, хисләрне көлгә әйләндерергә кирәк бит. Зифам, сиңа бер генә теләгем бар: бәхетле бул, җаным! Елама, күңелсезләнмә, эчеңне пошырма. Димәк, шулай булырга тиеш, күкләрдән шулай дип фәрман иңдерелгән. Зифам, сау бул, мәңгегә сау бул!

***

Хатның соңгы юлларын укып бетерүгә, Зифа урыныннан сикереп торды, иске кәгазьләрне тагын ашык-пошык актарырга тотынды. Фотолар, рәсемнәр, язмалар бер-берсе белән кушылып бетте, «ботка»га әйләнде. Карамаган җир калмады, әмма иң кирәклесе – язмышны үзгәртергә сәләтле хат табылмады. Кайда соң син, өченче хат?!.

**Айзилә САБИРОВА**

## Онытылмас батырлык

Берлингача, Алман иленәчә
Барып җиткән безнең солдатлар.
Фашистларны җиңү өчен хәтта
Чын ярдәмче булган бит атлар!

Сәламлибез сезне, ветераннар,
Нечкә күңел сездә, дан, зурлык.
Сез китергән җиңү безнең өчен
Тарих кына түгел, горурлык!

**Зөлфия ГАНИЕВА,**
*Әлмәт шәһәренең Риза Фәхреддин исемендәге*
*1 нче гимназия укучысы*

### ЮНЕСКО ҖИТӘКЧЕСЕ КАЗАНДА

ЮНЕСКО генераль директоры Одри Азуле Россиягә өч көнлек сәфәре кысасында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов белән очрашты һәм IV Бөтенроссия ЮНЕСКО кафедралары конгрессында чыгыш ясады.

Одри Азуле Казанга килүенә сөенүен әйтте. «Татарстан ЮНЕСКО эшчәнлегендә актив катнаша. Ул төрле дин, милләт, мәдәният һәм тарих үзәгендә тора. Сезнең мәдәниятара аралашуда тәҗрибәгез зур. Сез бергә-бергә яши беләсез», – диде ЮНЕСКО җитәкчесе.

### ЕЛ КИТАБЫ

ТР Милли китапханәсе Мәдәният министрлыгы, Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән берлектә үткәрелә торган «Ел китабы – 2017» бәйгесенә йомгак ясады һәм җиңүчеләрне игълан итте. Җәмгысы 26 китап бүләккә лаек булды. «Казан утлары» журналының поэзия бүлеге мөхәррире Фирүзә Җамалетдинова «Рус телендә чыккан матур әдәбият» номинациясендә «Рассказы» китабы белән беренче урынны алды. Хезмәттәшебезне котлыйбыз!

### ТЕАТР ПРЕМИЯСЕ

Казанда «Тантана» республика театр премиясен тапшыру чарасы булып узды. Премияләргә 11 номинациядә 12 спектакль, 33 актёр лаек булды.

### КАЛИНИНГРАДТА ФАТИХ КӘРИМ КӨННӘРЕ

Калининград өлкәсендә каһарман-шагыйрь Фатих Кәримнең тууына 110 ел тулуны зурлап билгеләп үттеләр. Бу уңайдан үткәрелгән чараларда Казаннан килгән кунаклар – Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис, КФУ профессоры, әдәбият галиме Фоат Галимуллин, шагыйрә Шәмсия Җиһангирова, Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубы мөдире, җырчы Рафаэль Сафин, шагыйрьнең кызы Ләйлә ханым катнашты. Алар Ф.Кәрим һәлак булган 37,8 нче калкулыкта булдылар, Багратионовск шәһәрендә каһарман-шагыйрьнең каберен зиярәт кылдылар. Монда җирле җитәкчеләр катнашында искә алу мәрәсиме булып узды. Кунаклар өлкәнең тарих музеенда Муса Җәлилнең тууына – 113, Фатих Кәримнең тууына 110 ел тулу уңаеннан үткәрелгән укуларда катнаштылар һәм чыгыш ясадылар.

### УТЫРЫШ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды. Берлек рәисе урынбасары Рәмис Аймәт ике утырыш арасында башкарылган эшләргә хисап тотты. Утырышта Вахит Имамов – «Татарстанның халык язучысы» исеменә, Лев Кожевников («Цветы на обочине» китабы өчен), Айрат Бик-Булатов («История отечественной журналистики», «Музыканты») моңарчы туктатып торылган, хәзер кабат гамәлгә куелган М.Горький исемендәге әдәби премиягә тәкъдим ителде. Рамил Ханнанов, Айсылу Имамиева, Николай Сорокин Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителде. Утырышны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов алып барды.

### ТӘКЪДИМ ИТҮ

ТР Милли китапханәсендә Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Разил Вәлиевнең Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан җиде томлыгын тәкъдим итү кичәсе булып узды. Күптомлыкта язучының төрле елларда иҗат иткән әсәрләре: шигырьләре, роман, повестьлары, пьесалары, публицистик язмалары, шигъри багышлаулары, шәхесләр белән әңгәмәләре, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе буларак чыгышлары һ.б. урын алган. Кичәдә галимнәр Индус Таһиров, Хатыйп Миңнегулов, Фоат Галимуллин, Тәлгат Галиуллин, Әлфәт Закирҗанов, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Фәндәс Сафиуллин, каләмдәшләре Рабит Батулла, Марсель Галиев, Ркаил Зәйдулла, Рәфикъ Юныс, Мансур Мортазин, Татарстан китап нәшрияты директоры Илдар Сәгъдәтшин, җырчылар Георгий Ибушев, Зөһрә Сәхәбиева, Рамил Миндияр, Алсу Фәйзуллина, нәфис сүз остасы Луара Шакирҗанова, К.Тинчурин исемендәге театр артистлары, театр көллияте студентлары һ.б. чыгыш ясады.

### СӨЙЛӘШҮ

Арча районы хакимияте башлыгы Илшат Нуриев районда туып-үскән әдәбият-сәнгать әһелләрен, журналистларны кабул итте. Якташлар район тормышы, туган тел язмышы

турында сөйләштеләр, мәктәпләрдә балалар бакчаларында татар теленә игътибарны көчәйтү максатында үтенечләрен җиткерделәр. Туган тел көнендә, Тукай җирендә ачыктан-ачык ихлас сөйләшү булды. Моның өчен кунаклар район башлыгы Илшат Нуриевка, башка җитәкчеләргә рәхмәт әйттеләр. Аннары мәктәпләргә укучылар белән очрашуларга таралыштылар. Арчага әдәбият-сәнгать әһелләренең шундый зур десанты килеп төшү укучылар, укытучылар, ата-аналарның район күләмендәге уртак бәйрәменә әверелде.

### ЮБИЛЕЙЛАР

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында шагыйрь, журналист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Госман Садәнең тууына 70 ел тулуга багышланган «Үлмәсен җирдә яшәү» дип аталган әдәби-музыкаль кичә булды. Анда шагыйрьнең шигырьләре, җырлары яңгырады. Кичәдә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Татарстанның халык шагыйре Рәдиф Гаташ, язучы-прозаик, әдәбият галиме Тәлгат Галиуллин, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире, шагыйрь Ләбиб Лерон, шагыйрә Нәҗибә Сафина, журналист, җәмәгать эшлеклесе Римзил Вәлиев, Татарстанның халык артистлары Мирсәет Сөнгатуллин, Илсур Сафин, Асаф Вәлиев, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Луара Шакирҗанова, Казан театр училищесы студентлары, шагыйрьнең якташлары, туганнары һ.б. чыгыш ясады.

***

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында шагыйрә Нәҗибә Сафинаның юбилеена багышланган әдәби-музыкаль кичә булды. Бәйрәмдарны ТР мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, ТР Президенты каршында мәдәниятне үстерү фонды башкарма директоры Нурия Һашимова, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, галим Марсель Бакиров, каләмдәшләре Йолдыз Шәрәпова, Эльмира Закирова, Роза Муллануровa, Фәнил Гыйләҗев, Зәй муниципаль районы башлыгы урынбасары Валерий Акатьев, шушы районның үзәкләштерелгән китапханәләр челтәре директоры Фәрия Батыршина, Г.Камал театры артистлары Хәлим Җәләй, Фәннүр Мөхәммәтҗанов, җырчылар Гөлзадә Сафиуллина, Рөстәм Закиров, Искәндәр Биктаһиров, Казан театр училищесы студентлары, 10 нчы гимназия укучылары, Казанда яшәүче якташлары, туганнары һ.б. котлады.

### КАРИЕВ ТЕАТРЫНДА – ПРЕМЬЕРА

Г.Кариев исемендәге Казан яшь тамашачы театрында язучы-сатирик, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Камил Кәримов пьесасы буенча куелган «Шәй-бу, Шай-бу!» спектакленең (режиссёры – Ренат Әюпов) премьерасы булды. Тамаша алдыннан бер төркем журналистлар матбугат конференциясенә җыелды. Анда театр директоры Гүзәл Сәгыйтова, Ренат Әюпов, Камил Кәримов һәм актёр Гөлнара Фазылҗанова әлеге спектакльнең ничек тууы турында сөйләделәр, сорауларга җавап бирделәр.

### СӘФӘРЛӘР, ОЧРАШУЛАР

Бер төркем язучылар Алабуга шәһәрендә әдәби очрашуларда катнашты. «Яшь иҗатчылар» фестивале кысаларында оештырылган әлеге чаралар каланың 1 нче гимназиясендә, КФУның Алабуга институтында булып узды. Фестиваль «Иллюзион» кинотеатрында Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, язучылар Факил Сафин, Гөлзадә Әхтәмова, Сирень Якупова, Марат Закир, Айрат Суфиянов, Гөлзадә Бәйрәмова, Лира Ибраһимова, Фәнил Гыйләҗев һәм галим-мөгаллим Гомәр Даутов катнашында зур әдәби кичә белән тәмамланды.

***

Татарстанның халык шагыйре Марсель Галиев, драматург Рәдиф Сәгъди, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, прозаик Рөстәм Галиуллин Пермь краенда булып кайттылар. Барда муниципаль районы башлыгы Хәлил Алапанов һәм район җитәкчеләре белән «түгәрәк өстәл»дә сөйләшүдә, Барда гимназиясендә, Кунгур районы Тор-Күз авылының Мәдәният йортында әдәби кичәләрдә катнаштылар. Казан кунакларын Барда районының татар-башкорт иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Сәлим Назин озатып йөрде.

***

Чаллы шәһәренең 52 нче мәктәбенә чыгышы белән Балык Бистәсе районыннан булган язучылар десанты килеп төште. Әхәт Гаффар, Фәүзия Солтан, Рәсимә Гарифуллина, Вазыйх Фатыйхов, Рахман Шәфигуллин, Ринат Нуруллин, район кияве Тәлгат Галиуллин катнашында очрашу булды. Очрашуга Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге җитәкчесе Факил Сафин, шагыйрә Әлфия Ситдыйкова да килгән иде. Бу чараны Чаллы шәһәре мәдәният идарәсе, Язучылар берлеге һәм чыгышы белән Балык Бистәсе районыннан булган, шушы мәктәптә татар теле һәм әдәбиятын укытучы Илфәния Нуретдинова оештырды.

2019 елның 15 мартында Мәскәүдә 78нче яшендә СССР Язучылар берлеге әгъзасы, язучы, тәрҗемәче **Илгиз Кәримов** (Мостай Кәримнең улы) вафат булды.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман Р.ТУФИТУЛЛОВОЙ «Ветер судьбы», повесть М.АМИРХАНА «Сажида», повесть Т.ГАЛИУЛЛИНА «Слепой Гаваз», повесть А.АДЕЛЯ «Сапожник»; стихи Г.ТУКАЯ, Л.ЯНСУАР, Т.ШАМСУАРОВА, А.СИТДИКОВОЙ.*
*«Новые имена»: стихи З.ЗАКИРОВОЙ (с предисловием Э.ШАРИФУЛЛИНОЙ); рассказ А.ГАЙНУЛЛИНОЙ «Закадычная подруга...»*
*«Актуальная критика»: рубрику ведёт Д.ЗАГИДУЛЛИНА.*
*«Наши знаменитости»: А.ШАКИРОВ. «Записи артиста».*
*«Из литературы родственных народов»: мини роман У.ХАМДАМ «Шиповник», рассказ У.ХАМДАМ «Состояние моей души» (с предисловием Ф.САФИНА).*
*Конкурс «Исцеляющие руки»: рассказ Г.ГАЛИУЛЛИНОЙ «Мысли старика Лукмана о жизни».*
*«Литературная критика»: статья А.ЗАКИРЗЯНОВА о творчестве Т.Галиуллина, статья Л.МИНГАЗОВОЙ о творчестве Г.Гильманова.*
*«Память»: философские мысли Б.РАХИМОВОЙ.*
*«Тукай и татарская литература»: статьи Р.МИР-ХАЙДАРОВА и Р.РАХМАН. Интервью А.ИМАМИЕВОЙ с руководителем общественной организации «Ак калфак» К.ИДРИСОВОЙ.*
*«Наука»: статья И.БИКМАЕВА «Тайны вселенной».*
*«Книжное обозрение»: Х.БАРГАН. «Доблестный сторожевой».*
*«Наши музеи»: Г.ТУХВАТОВА. «Литературный музей Габдуллы Тукая».*
*«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.*
*«Белый парус»: рассказ А.САБИРОВОЙ «Где твоё третье письмо?»; стих З.ГАНИЕВОЙ.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: Литературный музей Габдуллы Тукая. Фото из архива музея; драматург Булат Салахов.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: novel by R.TUFITULLOVA «Winds of destiny», story by M.AMIRKHAN «Sazhida», story by T.GALIULLIN «Blind Gavaz», novel by A.ADEL «The cobbler»; poems by G.TUKAY, L.YANSUAR, T.SHAMSUAROVA, A.SITDIKOVA.*
*«New Names»: poems by Z.ZAKIROVA (with foreword by E.SHARIFULLINA); story by A.GAYNULLINA «Bosom friend...»*
*«Actual criticism»: section is conducted by D.ZAGIDULLINA.*
*«Our celebrities»: A.SHAKIROV «Artist's records».*
*«From the literature of kindred peoples»: mini novel by U.HAMDAM «Rose Hip», story by U.HAMDAM «State of my mind» (with preface by F.SAFIN).*
*Competition «Healing hands»: story by G.GALIULLINA «Thoughts of old man Lukman about life».*
*«Literary criticism»: article by A.ZAKIRZYANOV about the work of T.Galiullin, article by L.MINGAZOVA about the work by G.Gilmanov.*
*«Memory»: philosophical thoughts of B.RAKHIMOVA.*
*«Tukay and Tatar literature»: articles by R.MIR-HAIDAROV and R.RAHMAN. Interview by A.IMAMIEVA with K.IDRISOVA.*
*«Science»: article by I.BIKMAEVA «Secrets of the universe».*
*«Book review»: H.BARGAN. «Valiant watchman».*
*«Our museums»: G.TUHVATOVA. «Literary Museum of Gabdulla Tukay».*
*«Pages of humor»: section is conducted by M.GALIEV.*
*«White sail»: story by A.SABIROVA «Where is your third letter?»; poem by Z.GANIEVA.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: Literary Museum of Gabdulla Tukay. Photo from archive of the Museum; playwright Bulat Salakhov.*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Габдулла Тукай әдәби музее. *Фото музей архивыннан.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* драматург Булат Сәлахов.